# казан утлары

6

ИЮНЬ · 1975

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**6**
ИЮНЬ
1975

## Бу санда

Ш. ХӨСӘЕНОВ. Әниемнең ак күлмәге. Пьеса . . 3
Г. АФЗАЛ. Уйланулар дәфтәреннән. Шигырьләр . 42
Г. ЗӘЙНАШЕВА. Мәңгелек сакчы. Җыр . . . . 45
Ф. ХӨСНИ. Мичче Гыйният. Хикәя . . . . . . 46
М. ХӘБИБУЛЛИН. Чоңгыллар. Роман . . . . . 56
Г. ЛАТЫЙП. Күкләрем шундый биек. Шигырьләр . 93

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ сельязмасы . . . . . . . . . . . . . . 98
К. ФӘСӘХОВ. Туган авыл, туган җир . . . . . 101

ГАЛИ ХАЛИТКА 60 ЯШЬ

Г. КАШШАФ. Үзенчәлекле талант . . . . . . . 116

БӨЕК ҖИҢҮГӘ 30 ЕЛ

Җ. ГЫЙЛЬМАНОВ. Якташларыбыз дошман тылында. 120
М. ДИБАЕВА. Хатлары килә, үзләре кайта... . . . 128
Х. ХӘЙРИ. Язучы һәм фронт . . . . . . . . . 133

ТӨРЛЕСЕННӘН

В. СЕМЕНОВА. Гадел Кутуй турында . . . . . 144
М. НОГМАН. Казан йолдызлары . . . . . . . 146
М. САДРИ. Соңгы очрашу . . . . . . . . . 148

СӘНГАТЬ

Ф. КАДЫЙРОВА. Татар театрында романтизм . . 149
А. ФАЙНБЕРГ. Яхшы да булсын, төрле дә . . . 158
С. ЧЕРВОННАЯ. Без Казаннан, Иделдән . . . . 160

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. МУСИН. Заман героена йөз тотып . . . . . 164

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**М. ЮНЫС.** «Муса Җәлил» океаннар гизә . . . . 173
**Ә. КАМАЛ.** Тәүбә итү — төзәлү түгел әле . . . 175

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

**Ш. ГАЛИЕВ.** Жираф белән Зариф . . . . . . . . 177

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

**М. ӘМИР.** «Чаян» фронтта . . . . . . . . . . 182
**Х. ГАТИН.** Шәп машина . . . . . . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 190

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 3/II-1975 ел. Басарга кул куелды 25/IV-1975 ел. ПФ 09012. Кәгазь форматы $70 \times 108^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 92000 экз. Заказ Я-88. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1975 ел.

## Шәриф Хөсәенов

# ӘНИЕМНЕҢ АК КҮЛМӘГЕ

(ӘНИ КИЛДЕ)

ӨЧ ПӘРДӘЛЕ ДРАМА

КАТНАШАЛАР:

Ана — 75 яшьтә.
Максуд — Ананың беренче улы, 53 яшьтә.
Саймә — Максудның хатыны, 51 яшьтә.
Альфред — аларның улы, 32 яшьтә.
Ислам — Ананың икенче улы, 51 яшьтә.
Расиха — Исламның хатыны, 35 яшьтә.
Рәйхан — аларның кызы, 7 яшьтә.
Инсаф — Ананың өченче улы, 47 яшьтә.
Сәяр — Ананың төпчек улы, 27 яшьтә.
Римма — Сәярның хатыны, 21 яшьтә.
Гөлчирә — Ананың кызы, 35 яшьтә.
Зөләйха — Сәярның квартира хуҗасы.
Әлмөхәммәт — Зөләйханың каенатасы, 89 яшьтә.
Гөлсем — авылдан килгән кыз.
Баянчы егет — сүзсез.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Ике бүлмәле квартираның аркылы киселеше. Сулда — зал, ул сәхнәнең өчтән ике өлешен биләп тора. Зал төрле елларда төрлечә эшләнгән мебельләр белән җиһазландырылган. Уңдагы бүлмә бик кечкенә. Андагы бар җиһаз — иске тимер карават, тумбочка, ике урындык, ак пәрдә белән капланган кием элгеч һәм иске этажерка. Пәрдә ачылганда сәхнә буш. Бераздан бер-берсенә уралып Сәяр белән Римма керә. Икесенең дә өсләрендә туй киемнәре. Римманың куены чәчәкләр белән тулы. Ишек төбендә үк туктап, озак итеп үбешәләр.

Сәяр. Ниһаять, без үзебез генә! Син минеке! Минем законлы хатыным! *(Римманы үбә.)* Яратасыңмы?

Римма. Яратам! *(Тагын үбәргә килгән Сәярны читкә этәреп.)* Хозяйкаң кая киткән?

Сәяр. Хозяйка бүген өйдә булмаячак! Үзебез генә булабыз бүген өйдә! *(Үбәргә үрелә.)*

Римма *(тайпылып)*. Чәчәкләрне суга куйыйк!

Сәяр. Әйдә үзебезнең бүлмәгә!

Бер-берсенә уралып зал аша узалар, уңдагы бүлмәгә керәләр, бусагадан атлауга кочаклашып үбешәләр.

Р и м м а. Чәчәкләрне суга куйыйк!

Сәяр кухня ягына чыгып сулы ваза күтәреп керә. Икәүләп чәчәкләрне суга утырталар.

Сәяр. Туй күлмәге нинди килешә сиңа! Яле, утыр әле менә шунда! Туйганчы бер карыйм әле үзеңә! *(Римманы урындыкка утыртып, ашардай булып карый.)*

Р и м м а. Ресторанннан ашыгыбрак киттек. Иптәшләр гаеп иткәннәрдер.

С ә я р. Итсәләр инде!

Р и м м а. Тагын бераз утырасы калган. Тагын берәр сәгать.

С ә я р. Җүләркәем! Тагын бер сәгать түгел, бер минут та көтәр хәлем калмады! Берәүне дә күрәсем килми! Гомеремнең иң бәхетле көнендә синең белән икәү генә буласым килә! Бүген дөнья безнеке, Римма! Хозяйка да кайтмаячак! Өйдә үзебез генә булабыз! *(Тумбочка өстендәге тастымалны ача, анда бер шешә шампан шәрабе һәм алмалар. Үбешәләр.)*

Залга З ө л ә й х а керә. Ул аны-моны уйламастан, ундагы бүлмәгә уза, үбешеп торган яшьләрне күреп кире чыга башлый, ләкин Сәяр аны тотып кала.

З ө л ә й х а. Исәнмесез!

Р и м м а. Исәнмесез!

З ө л ә й х а. Берәр хәл булмагандыр бит?

С ә я р *(шампан шешәсен ача-ача)*. Берни дә булмады, Зөләйха апа! Үзебез шулай тиз тоттык. Язылышып чыккач иптәшләр белән азрак ресторанда утырдык та кайттык. *(Бокалларга эчемлек сала.)*

З ө л ә й х а. Мин сезне соң гына кайтырсыз дип тора идем, бигрәк тиз... Ярый, никахыгыз котлы булсын!

С ә я р
Р и м м а } Рәхмәт!

З ө л ә й х а. Ресторанннан ияреп кайтучылар булса дип, пәрәмәчлек камыр куйган идем, хәзер өлгертәм...

С ә я р. Кирәкми, Зөләйха апа! Мин бит әйттем сиңа, туй дигәннең «т» хәрефе дә булмый дидем. Гомернең иң бәхетле көнендә эчеп-исереп утыруны аңламыйм мин. Бүген мин болай да исерек! Берәүне дә күрәсем килми!

З ө л ә й х а. Өйләнештек дип, әллә инде хәзер ашамый да, эчми дә яшәргә уйлыйсызмы? Мин кич кунарга сеңелем янына китәм, өйдә үзегез генә каласыз. Иртә торуга ашханәгә чапмассыз бит! *(Чыга.)*

С ә я р. Ошыймы сиңа минем хозяйкам? Искиткеч апа! Менә күрерсең, бу өйдә безгә яхшы булачак!.. Яратасыңмы? *(Римма яратуын аңлатып баш селки.)* Юк, син телең белән әйт, яратасыңмы?

Р и м м а. Я-ра-там! Приходи к воротам!

С ә я р. Ә нишләп к воротам? Безнең капка төбендә йөргән чаклар узды. Менә өебез! Менә — син! Менә — мин! Я, ничек итеп яратуыңны күрсәт миңа! *(Римма тумбочка өстендәге курчакны алып, күзен йомып торган Сәярнең иреннәренә кагыла.)* И, шулай начар яратасыңмы? Ә мин сине менә ничек яратам! Менә ничек яратам!

Римманы күтәреп алып, иреннәреннән, битләреннән, чәчләреннән үбә башлый. Озак итеп звонок шалтырый. Яшьләр үбешүдән туктап, ал яктагы аяк тавышларына колак салалар. Артта шау-шу, көлешү. Залга М а к с у д, С а й м ә, А л ь ф р е д, И н с а ф һәм б а я н ч ы е г е т керә. Максудның кулында зур кәрзин, аннан берничә шешә муены күренеп тора. Саймә чәчәкләр тоткан. Альфред пирог куелган поднос күтәргән. Инсаф таякка таянган һәм ике аягы да протез булу сәбәпле шактый аксый.

Максуд. Вәт безобразие хәзерге яшьләр! Кая качтылар әле? *(Ике бүлмә арасындагы ишектә Сәяр белән Римма күренә.)* Ха-ха-ха! Әле сез бездән яшереп өйләнешеп йөрисезмени? Барып чыкмады! *(Ишек төбенә килеп кычкыра.)* Әйдәгез, әйдәгез, бирегә кертегез! *(Ике кеше диван-караватны кутәреп керәләр.)* Куегыз шунда! *(Ике кеше диван-караватны идән уртасына куеп, чыгып китәләр.)* Ха-ха-ха! Туйларыгыз котлы-мөбарәк булсын, законлы никах белән! *(Көлешә-көлешә яшьләрне котлыйлар.)*

Саймә. Әтисе урынына калган абыйсына да әйтмәгән, ай-һай! Оялмыйсыңмы, энем, бер дә? Максуд, өйдә тотып кыйныйбыз үзен! *(Шаярып Сәярга суккалап алалар.)*

Сәяр *(аптырап)*. Кайдан белдегез сез?!

Максуд. Әйтмибез!

Саймә. Әйтмә, әйтмә, Максуд! Зурайган, зурайган! Институт бетергән, янәсе, инженер булган! Ай-һай!

Сәяр. Мин бит гел әйтә килдем, Саймә җиңги, туй ясамыйм, дидем! Егерме җиде яшькә җитеп, бик күп туйларда булдым, күрдем. Җыелалар да эчәләр, эчеп исерәләр дә, «Алмагачлары» көенә җырлыйлар. Нәрсәсе кызык шуның?

Максуд. Җүләр! Бер җырлашып та утырмагач, өйләнеп тә тормыйм мин аны! Өйләнү көн саен булып тормый лабаса ул! Шул, күп булса, гомер эчендә бер-ике була инде ул өйләнү!

Сәяр. Синеке ничә булгандыр — белмим, ләкин минеке бер генә булачак!

Саймә *(кабаланып)*. Шаяра ич ул, энем! Абыеңны белмисеңмени инде?

Сәяр. Урынын белеп шаярсын!

Максуд *(тиешсезрәк сүз ычкындыруын аңлап, гаепле елмая)*. Ха-ха-ха!.. *(Диван-караватка тотынып.)* Ягез, кая куябыз?

Зөләйха. Әнә теге якка! Аларның бүлмәсе әнә тегендә!

Күмәкләшеп диван-караватны күтәреп алалар да ундагы бүлмәгә узалар, анда-гы тимер караватны җыеп алып, урынына диван-карават куялар.

Максуд *(диван-караватка утырып)*. Тирбәлеп кенә торачак инде бу!

Саймә *(Максудның аркасына сугып)*. Я, оятсызланма!.. Утырып карагыз инде, энем! Сеңелем, утырып карагыз!

Римма *(диван-караватка утырып)*. Рәхмәт сезгә, зурлагансыз! Гафу итегез безне, уңайсызрак килеп чыкты!

Сәяр. Чыннан да, кем әйтте сезгә?

Максуд. Әйтмибез!

Сәяр *(Инсафка)*. Ә син, абый, ничек Казанда?

Инсаф. Туйга килдем!

Максуд. Туйга килгән, сезнең туйга!

Сәяр. Бөтен планны бозып йөрисез шунда!

Максуд. Әле тагын кунаклар була!

Сәяр. Кемнәр тагын?

Максуд. Ислам белән Расиха!

Сәяр. Тьфу, черт! Соң, мин бит әйтә килдем сезгә, өйләнсәм туй ясамыйм, дидем! Безнең бернинди сыебыз юк! Үзебез дә ресторанда гына ашап чыктык.

Максуд. Оятсызлар! Бүләкнең өстенә менеп утырдылар да бер чынаяк чәй дә кызганалар! Үпкәләдек! *(Килүчеләрне зал ягына куалап чыгарып, ишекне бикләп ала.)* Кияү керәте! Саймә, юкмы шунда берәр таяк? *(Саймә Инсафның таягын тартып алып Максудка бирә. Максуд таяк белән ишекне бикләп куя.)* Кияү керәте! Менә, утырыгыз шунда!

С ә я р *(ишекне тартып).* Абый, ач!

М а к с у д. Абыең ач булмас ул, абыеңның ризыгы үзе белән. Саймә, бушат бәлешләрне!

Көтелмәгәндә килеп чыккан ситуациядән килүчеләр бик канәгать. Көлешә-көлешә, үзләре алып килгән кәрзиннән өстәлгә ашамлыклар чыгаралар. Зөләйха савыт-саба һәм приборлар китерә.

С ә я р *(ишекне тартып).* Абый, дим, кара!

М а к с у д. Карамыйм, энем, карамыйм! Кияү келәтенең ярыгыннан карап йөргән чаклар узган инде. Оятсыз, абыйсын каратып тормакчы!

С ә я р. Абый!

М а к с у д. Абыең булсам, туеңа чакырыр идең. Бәлеш исе чыккач кына куштанланма!

С а й м ә. Ачыйк мәллә, Максуд?

М а к с у д. Ачмыйбыз!

С а й м ә. Киленнән яхшы түгел!

Звонок. И с л а м, Р а с и х а, Р ә й х а н керә.

Р а с и х а. Исәннәрме сез!

М а к с у д. Бик озак җыендыгыз, бүләкнең хәтәрен сайладыгыз, ахры!

И с л а м. Чакырмаган туйга нинди бүләк ди аңар!

Р а с и х а. Өй сакларга кеше табып булмады. Рәмзияне барып алып кайттым, Каравайдан.

З ө л ә й х а. Бикләп кенә килергә ярамадымыни?

Р а с и х а. Кайткан төшеңә бөтен өеңне утап куярлар! Безнең поселок шпана оясы бит ул! Җыен карак-бандит төрмәдән чыга да шуннан йорт ала. Менә шуның кебек малаена хәтле шпана! Чын! Әле кичә ипи кибетенә барып килгән арада өч алманы шартлатып өзеп алдылар!

М а к с у д *(тәрәзәдән үрелеп нидер күзәтүче Исламнан).* Сез нәрсә, машинагыз беләнме?

И с л а м. Шулай иде лә. Янында ике малай маташа... *(Тәрәзәдән йодрык селки.)*

З ө л ә й х а. Тимәсләр лә, тимәсләр! Безнең тирәдә караклар юк!

Р а с и х а *(тәрәзәдән үрелеп карап).* Киттеләрме? Халык бик әшәке хәзер. Әле беркөн капка төбендә өч минут торган арада, кадак белән тырнап, машинаның өстенә оятсыз сүз язып киттеләр. Чын! *(Саймәнең колагына әйтә, Саймә шаркылдап көлеп җибәрә.)* Яшьләр кайтып җитмәдемени әле?

М а к с у д. Кайттылар, кайттылар!

Р а с и х а. Чын, яшьләр кайда соң? Әй, Максуд абый сүзенә ышанып йөрсәң — мыскыл итеп чакыргандыр әле! *(Сәяр ишек дөбердәтә.)* Ай, алла, бу ни хәл бу?

С ә я р. Безне Максуд абый бикләде, Расиха җиңги! Ач әле!

М а к с у д *(ишеккә бара башлаган Расиханың юлын бүлеп).* Сабыр ит! Безнең белән утырасылары килсә, чакырсыннар иде...

И с л а м. Абый, инженер булгач, понимаешь, туганнарыннан хурланадыр ул, бәлкем! Тик без хатынны кеше почмагына алып кайтмаган идек, кесәдә диплом булмаса да. Я булмаса, хатынымны күреп туймам дип куркадыр!

М а к с у д. Яшь шул әле, тәҗрибә юк. Хатынның күзгә пәри булып күренгән чакларын белми... Әйдәгез, утырышыгыз! Альфред! Ачыгыз шампанскийларны!

С ә я р *(ишекне кагып).* Ачмасагыз, ватып чыгабыз!

М а к с у д. Борынына шампанский исе керде тегенең — нинди ярсый! Кычкырма, энем, кычкырма! Менә үз өең булгач ватарсың, кеше ишеген вату егетлек түгел ул!

Р а с и х а. И, болай күңелле түгел лә, Максуд абый!

М а к с у д. Бик күңелле! Илле өч яшькә җитеп, мондый кызык туй күргәнем юк иде әле.

Бокалларга эчемлек салалар.

С а й м ә *(Рәйханны кочаклап)*. Һай-һай-һай, бу тиклем матур күлмәкне кайдан алдыгыз, Рәйхан?

Р ә й х а н. Әни кибеттән алды! Сигез сум җитмеш ике тиенгә!

С а й м ә. Һай, җаным!

М а к с у д. Ярый, сөйләшүне туктатабыз! Тотыгыз бокалларыгызны! *(Зөләйха салат кертә.)* Зөләйха ханым, тотыгыз! *(Барысы да аяк өсте басып бокалларын күтәрәләр.)* Барыгызга да мәгълүм, җәмәгать, бүген безнең төпчек энебез Сәяр үзенең кәләше белән язылышып кайтты...

С ә я р *(ишек кыйнап)*. Абый, ничек оялмыйсыз!

М а к с у д. Оялып торырга, энем, без бит синекен эчмибез, үзебез алып килгәнне эчәбез!... Әйдәгез, җәмәгать, әнә шул юньсезләр саулыгына күтәрик әле!

Эчәләр. Көлешә-көлешә капкалыйлар.

З ө л ә й х а. Салатыннан авыз итегез, кунаклар! Хәзер пәрәмәч өлгертәм! *(Чыга.)*

М а к с у д. Анасы, син нигә эчеп бетермәдең?

С а й м ә. Әй, әллә ничек шунда, әче...

А л ь ф р е д. Баллы түгел, ди!

М а к с у д. Баллы түгел? Хәзер балландырабыз аны! *(Яшьләр бүлмәсенең ишеге төбенә килеп.)* Ишетәсезме, яшьләр, кунаклар эчә алмый утыра, әче, диләр!

А л ь ф р е д. Горько!

К ү м ә к л ә п. Горь-ко! Горь-ко!

М а к с у д. Әйдәгез, яшьләр, баллandырыгыз шампанскийны! *(Уң яктагы бүлмәдә Сәяр белән Римма үбешәләр.)* Әллә йоклап та киттеләр инде? Яшьләр, дим, кунаклар эчә алмый утыра, баллы түгел, диләр!

С ә я р. Баллandырдык инде, баллandырдык! Эчегез, эчегез күпсен!

М а к с у д. Ишеттереп баллandырыгыз! *(Сәяр ишек төбенә килеп берничә мәртәбә авызын чупылдата.)* Менә булды! Менә балланды хәзер!.. Равил, сайрат әйдә сандугачыңны! *(Баянчы «Алмагачлары» көен уйный.)*

Әй икегез, икегез лә,
Икегезнең битегез,
Икегез дә пар килгәнсез,
Чукынышып китегез!

К ү м ә к л ә п.

Ай, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары!

Р а с и х а. Пар килгәннәрдерме, юкмы — киленне күрмәгән бит әле!

С а й м ә. Килен чибәр!

Р а с и х а. Эшлиме, укыймы?

С а й м ә. Укый! Сәяр бетереп чыккан институттан! *(Җырлый.)*

Минем энем бик зур булды,
Һич килмәгән төше юк —
Дипломы бар, хатыны бар,
Туганнарда эше юк!

Кумәкләп. Ай, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары!

Расиха. Сөбханалла, күз тимәсен
Зифа буйларыгызга,
Тагын шулай чакырырсыз
Бәбәй туйларыгызга!

Кумәкләп. Ай, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары!

Максуд. Ай-ли, метро,
Шулай утыру ни тора!

Көлешү, шау-шу. Пәрәмәчләр күтәреп Зөләйха керә.

Зөләйха. Шаярдыгыз, җитәр. Чыгарыгыз инде яшьләрне!

Максуд. Чыгармыйбыз!

Саймә. Чыгар, чыгар, Максуд!

Альфред. Әти, чыгар!

Максуд. Тавышка куям! Кем дә кем... *(Сүзен әйтеп бетерми, төрле яктан «Чыгар!», «Чыгар!» дигән тавышлар ишетелә.)* Равил, музыка! *(Баянчы туш уйный.)*

Максуд ишекне ача. Сәяр белән Римма чыга.

Саймә. Менә, кызык иттеме абыегыз үзегезне?!

Расиха. Ярар инде, җитәрегез! Утырыгыз, сеңелем! Энем, утыр! Яшьләргә эчемлек салыгыз!

Яшьләрне түргә утырталар. Альфред бокалларга эчемлек сала.

Максуд. Әйдәгез, җәмәгать, пәрәмәч алдыннан берәрне тотабыз! *(Бокалын күтәреп.)* Яшьләр исәнлегенә!

Расиха. Озын гомерле булсыннар!

Инсаф. Өй тулы балалары булсын!

Саймә. Әче!

Альфред. Горько!

Расиха. Ярарыгыз инде, оялтмагыз яшьләрне!

Максуд. Оялтырсың син хәзерге яшьләрне! *(Аяк тибеп кычкыра башлый.)* Горько! Горько!

Кумәкләп. Горь-ко! Горь-ко!

Сәяр белән Римма үбешәләр. Барысы да эчәләр.

Максуд. Вәт безобразие! Менә шулай гөрләтеп туй итәсе урында, качып йөриләр!

Альфред. Между прочим, Швецияда шулай. Әгәр кыз кияүгә чыкканда намуслы булса, ул кызны хөрмәт итмиләр.

Максуд. Ничек инде ул алай?

Альфред. Шулай! Намуслы кызларны санга да санамыйлар анда, гадәт шундый.

Максуд. Эх, шунда барып, шул кызларны санап йөрсәң иде!

Саймә. Я, тиешле сүз генә сөйләшеп утырыгыз әле!.. Пәрәмәчләре бик тәмле икән, нишләп ашамыйсыз?

Ислам. Без ашап килдек. Сез әнә яшь киленне сыйлагыз, бик ябык икән!

Расиха. Ябык түгел лә! Хәзер мода шундый — юан кызларны егетләр яратмый. *(Саймәгә.)* Модадан артта калгансың, Саймә апа!

Саймә. Калсам инде тагын, мода дип, ач утырыр хәлем юк әле! Ирләр дә эт түгел, сөяккә ташланмыйлар. Ийе бит, Максуд?

Максуд. Башка ирләрне белмим, әмма мин үзем хатын-кызның шундыен яратам: арт ягына бер китереп суккач, сәгать ярым дерел-

дәп торсын ул миңа! *(Зөләйханың кемнедер каршы алуын күреп.)* Кем бар анда, Зөләйха ханым?

Зөләйха. Әткәй ул. Туганнарны күрергә дип, авылга кайтып киткән иде, шул кайтты.

Максуд. Табын янына чакырырга кирәк!

Зөләйха. Килешерме икән соң?

Саймә. Нишләп килешмәсен! Сәяр, бар, алып кер бабайны!

Сәяр чыга. Әлмөхәммәт картны ияртеп керә.

Сәяр. Әйдә, утыр, бабай! Берәрне җибәрәсеңме?

Әлмөхәммәт *(утырып)*. Килен рөхсәт итәрме икән соң?

Зөләйха. Рөхсәт, әткәй, рөхсәт!

Әлмөхәммәт. Ярый, алайса, яшьләр исәнлегенә булсын, бәхет-тәүфыйк белән гомер итсеннәр! Бисмилла рахманрахим! *(Эчә.)* Әйбәт булган, яхшы. Сәярнең бәхете бар аның. Укып бетергәч, Казанда да калдырдылар үзен. Әнә безнең малай, җир читенә китте дә, ялга да ике елсыз кайтып булмас, дип яза. *(Зөләйхадан.)* Хаты бармы?

Зөләйха. Бар, әткәй, бар! *(Башкаларга.)* Минем улымны әйтә. Узган ел геологическийны бетергәч, Чукоткага киткән иде.

Максуд. Башы исән булсын, булсын, бабай! Исән булса, бер кайтыр.

Әлмөхәммәт *(кинәт уйга калып)*. Анысы хак сүз. Исән кеше бер кайтмаса да бер кайта. Үлгәннәр кайтмый...

Зөләйха. Пәрәмәчләрне суытып бетерделәр инде! Кунаклар, ашап утырыгыз инде!

Альфред. Между прочим, кунакны кыстау культурно түгел! Менә, мәсәлән, Парижда нишлиләр? Кунаклар җыела. Ну, өстәлдә һәммәсе дә бар, конечно. Коньяк, төрле-төрле винолар һәм бер-ике генә төрле закуска. Хуҗа кеше беренче рюмканы эчәргә генә тәкъдим ясый да, шуннан соң кем ни теләсә, шуны эшли. Эчәсе килгән кеше — эчә, ашыйсы килгәне — ашый. Ә кыстау юк. Кунакны кыстау некультурно санала.

Зөләйха. Саналса саналыр тагын! Без Парижда түгел бит әле, Казанда. Ә безнең халыкта әүвәл-әүвәлдән килгән бик матур бер гадәт бар: кунакны аяк өсте басып сыйлыйлар. *(Тәрәзәдән урамга карап торган Исламга.)* Машинагызны күтәреп китмәгәннәрме?

Ислам. Күтәреп китә алмыйлар аны! Аның бит авырлыгы ике мең сигез йөз килограмм!

Әлмөхәммәт *(Альфредка)*. Карале, энем, син ул Париж дигән җирдән күптәнме кайттың?

Кунаклар пырхылдап көлеп җибәрәләр. Сәяр кесәсеннән сигарет чыгарып тарта башлый. Альфред та тарта.

Саймә. Тотындылар инде пыскытырга! Агуламагыз әле һаваны, башыма ярамый!

Сәяр. Бу зарарлы сигарет түгел, Саймә җиңги, курыкмагыз. Бу — фильтрлы сигарет! *(Әлмөхәммәткә.)* Берәрне тартып җибәрәсеңме, бабай?

Әлмөхәммәт. Рәхмәт, улым. Кырык ел тарттым, җитәр.

Сәяр. Ничек ташлый алдың, бабай? Мине дә өйрәтсәң икән!

Әлмөхәммәт. Ничек дип, ташлыйсың килсә, тотасың да ташлыйсың инде, аның өчен курсы бетерү кирәкми. Утыз сигезенче елны ашказанында язве таптылар минем. Апиратсыга салдылар. Прафисыр Думбрачев әйтә,— хәзер үзе дә мәрхүм инде, рәхмәт төшкере,— апиратсы ясыйм, брат, ди. Но түлке тәмәке тартуны ташлыйсың, ди. Ташладым!

С э я р. Шуннан бирле бер дә тартканың юкмы, бабай?

Э л м ө х ә м м ә т. Юк. Сестра кереп, бабай, апиратсыга дигәндә, берне чорнап кабызган гына идем. Шул сүзне ишетүгә, тарта башлаган тәмәкемне ташлап, апиратсыга йөгердем. Тартуны ташлавыма үкенмим. Но түлке апиратсыга чакыргач, тартып бетермичә ыргыткан шул төпчегемне әле дә булса җәлләп торам. Тартып бетерәсем калган икән шуны апиратсыга кергәнче.

А л ь ф р е д. Ха! Ха! Ха! Бу өйдә туалет бармы? Булса — кем аны миңа күрсәтә? *(Сәяр Альфредны туалетка озата.)*

Э л м ө х ә м м ә т *(Альфредның артыннан).* Шәм тотып торучы да кирәкмиме, энем?.. Хуш! Бу кемнәрең була соң инде синең, Сәяр?

С э я р. Туганнарым, бабай. Менә бусы — иң олы абыем, заводта мастер булып эшли. Монысы — аның хатыны Саймә җиңги, трамвай йөртүче.

Э л м ө х ә м м ә т. Ничәнче трамвайда эшлисең?

С а й м ә. Сигезенче маршрутта, бабай, нәкъ мәчеткә илтә торган трамвай!

Э л м ө х ә м м ә т. Мәчеткә барганда билет алып тормыйбыз икән болай булгач.

С а й м ә. Бик алмый торгансың әле, бабай! Мәчеткә йөрүче картлардан бик билет алдырып булмый алардан!

М а к с у д. Ник?

С а й м ә. Алмыйлар! Менә шундый мулла шикелле картлар җомга саен вагонга кереп тулалар — ник берсе билет алсын! Кычкырышып бетәм мин алар белән. Чукынган картлар, мин әйтәм, ичмасам, алла юлында йөргәндә хөкүмәтне алдамагыз!

С э я р. Менә бу — минем икенче абый, бабай. Әле күптән түгел генә пенсиягә чыгып, Магадан өлкәсеннән кайтты. Йорт алып Казанда тора хәзер.

Э л м ө х ә м м ә т *(Исламга).* Бик яшь күренәсең түгелме соң?

И с л а м. Минем стаж горняцкий, бабай, подземный. Шахтерлар пенсиягә илле яшьтән чыгалар.

С э я р. Бусы — аның хатыны Расиха җиңги. Ә менә монысы, бабай, өченче абыем — Инсаф абый. Ватан сугышы инвалиды. *(Инсафка.)* Абый, син чыннан да минем туйга килдеңме?

И н с а ф. Әйе!

С а й м ә. Әй, юк ла! Бу туганыбыз бик авырый безнең, бабай. Сугышта алган яралары төзәлеп бетми. Больницага ятарга килгән.

Э л м ө х ә м м ә т. Туганнарың күп икән, Сәяр...

С э я р. Әле монда барысы да түгел, бабай. Без тугызау! Унау булганбыз да, бер абый сугыштан кайтмады.

Э л м ө х ә м м ә т. Сөбханалла, бай егет икәнсең! Туганнар — байлык ул, туганнарның күп булуы яхшы. Менә бит, нинди зур байлык бүләк иткән үзегезгә әти-әниегез!

Р э й х а н *(алгарак чыгып).* Ә мин — Рәйхан!

А л ь ф р е д керә.

А л ь ф р е д. Ә шулай да дөньяда яшәү күңелле!

С а й м ә. Монысы минем улым, бабай! Исеме Альфред!

Э л м ө х ә м м ә т. Исеме матур икән егетнең. Чын мөселманча исем — Әлфәрит.

С а й м ә *(хихылдап).* Әлфәрит түгел, бабай, Альфред!

Р а с и х а. Я, карт кеше белән сүз көрәштереп утырма, киртәсенә керсә ярар!

Э л м ө х ә м м ә т. Дөрес итеп әйтсәң — Әлфәрит әл. Бу дөньяда тиңдәше булмаган, бердәнбер нәрсә дигән сүз. Минем үз исемем дә шулайрак — Әлмөхәммәт. Ә менә Фәрит сүзе белән Мөхәммәт алдын-

нан килүче «Эл» — гарәпләрдә тәгъриф дип йөртелгән бер нәрсә ул. Безнең татар теле белән урыс телендә андый хикмәтле нәрсә юк. Гарәпләрдә бар! Немецләрдә дә бар! Унбишенче елны плен төшеп, дүрт ел буе бер немеч марҗасының сыерларын карап тордым мин. Унике сыер! Менә немеч халкының да телендә тәгъриф кебек нәрсә бар. Әнә укыган кешеләр беләдер. Ничек була немеччә икмәк? Дас брот?

**Сәяр.** Дөрес, бабай!

**Әлмөхәммәт.** Менә шуның «брот» дигәне икмәк дигән сүз инде аның. «Дас» дигәне — гарәпләрдә тәгъриф дип йөртелүче бер хикмәт. Их эшпрәйхен дойч бит!

**Саймә.** Һай, бабай дигәнебез бездән галимрәк булып чыкты ич!

**Альфред.** Эссе! Барыгыз да күрдеме минем пиджакны? Күрсәгез салып куям! *(Пиджагын салып урындык аркасына элә.)*

**Әлмөхәммәт.** Алай дисәң, ыштаныңны да күрдек инде, энем!

**Расиха.** Иптәшләр, тыңлагыз! Хәзер сезгә Сабирова Рәйхан җыр җырлап күрсәтә! Яле, кызым, теге җырны җырлап бир әле үзләренә!

**Рәйхан** *(урындык өстенә менеп басып җырлый).*

Әрнемә, сызлама, юксынып, йөрәгем,
Сагынып, саргаеп, өзелмә, үзәгем.
Мәхәббәт бер генә, килми ул гел генә
Карлыгач шикелле талпынып һәр язда!

Көлешү, кул чабулар. Кунаклар җырны күтәреп алалар. Звонок. Зөләйха ишек ачарга чыга. Бераздан ишектә Ана белән Гөлсем күренә.

**Саймә** *(абына-сөртенә Анага каршы йөгерә).* Һай, җаным, әни килде ич! Әни килде, Максуд!

Барысы да ишек төбенә җыелалар. Ананы уратып алалар. Гаҗәпләнү аваздары, исәнләшү.

**Зөләйха.** Бәхетленең кунагы да дөрен-дөрен булыр ди — менә бит!

**Саймә.** Сәярың өйләнде ич, әни! Менә бу синең кечә киленең була! Белеп килдеңме соң син, әни, белмичә генәме? Һай, җаным, күр әле бу тамашаны!

**Максуд.** Төпчегең өйләнде бит, әни! Туй бүген!

**Сәяр** *(алгарак чыгып).* Юк-юк, әни, туй мәҗлесе түгел бу!.. Мин туйсыз гына өйләнергә булган идем дә, әни... менә алар әллә кайдан ишеткәннәр дә бәреп керделәр! Син рәнҗемә инде, әни, туй түгел бу!.. Менә, таныш бул, әни, бу минем... бу синең киленең була. Исеме — Римма... Рәнҗемә инде син, әни, мин бит шау-шусыз гына өйләнәсе булган идем... *(Риммага.)* Я, таныш инде — әни бит!

Ана акрынлап үзен кулга ала. Алгарак узып, Сәяр белән Римманы күкрәгенә кыса. Яшьләрне аралап, Ананың итәгенә Рәйхан сарыла.

**Ана** *(Рәйханны күтәреп алып).* Кызым Рәйхан лабаса бу! Нинди зур булып үскән минем кызым!

**Зөләйха.** Үрә каттылар! Табын янына чакырыгыз әниегезне!

**Сәяр.** Әни, менә бу апа — минем квартир хозяйкам!

**Зөләйха.** Исәнмесез! Танышу качмас. Башта әниегезне табын янына утыртыгыз!

**Ана** *(Инсафны күреп).* Син дә Казандамы, улым? Үзең генәме соң?

**Инсаф.** Үзем генә, әни!

**Ана.** Килен белән балалар исән-саулармы?

**Инсаф.** Исән-саулар, әни!

**Саймә.** Әйдә, утыр, әни, утыргач сөйләшербез!

**Ана.** Өстемне алыштырам.

С а й м ә. Соңыннан алыштырырсың, әни, соңыннан!

А н а. Юк, соңыннан түгел, хәзер алыштырам! Улымның туенда бу килеш утырырга, мин соң...

С ә я р. Туй түгел бу, әни! Монда ничек тә ярый!

А н а. Юк, ярамый! Өстемне алыштырам! *(Саймә белән бергә чыгалар.)*

М а к с у д *(Сәярдан).* Әнигә дә хәбәр итмәгән идеңмени?

С ә я р. Юк дип әйттем бит инде!

М а к с у д *(Гөлсемгә).* Бик озак эзләп йөрмәдегезме соң, сеңелем?

Г ө л с е м. И, сорамагыз инде, абый! Көне буе Казан буйлап чаба-чаба әбине үтерә яздым. Башта әбинең олы малаена барган идек...

М а к с у д. Менә мин ул әнинең олы улы.

Г ө л с е м. Адресыгыз белән барып төшсәк — унбишенче йорт юк!

М а к с у д. Безнең йортларны сүттеләр бит, сеңелем!

Г ө л с е м. Шуннан әбинең поселоктагы малаен эзләп киттек...

М а к с у д *(Исламга күрсәтеп).* Анысы менә ул була инде!

Г ө л с е м. Көч-хәл белән эзләп тапсак — аларның да капкалары бикле, ишекләрендә ат башы хәтле йозак.

Р а с и х а. Йозак?!

Г ө л с е м. Әйе!

Р а с и х а. Теге чукынган кыз ишеккә йозак салып чыгып киткән икән! Ислам!

М а к с у д. Я, өегезне күтәреп китмәсләр инде! Соң, шуннан, сеңелем!

Г ө л с е м. Шуннан әби әйтә, Казанда минем тагын бер улым бар бит әле, кызым, янымда адресы гына юк, ди. Киттек справочный эзләп. Шунда әйтеп бирделәр тагын...

Ананы култыклап С а й м ә керә. Ананың өстендә озын итеп тегелгән ап-ак ефәк күлмәк, зәңгәрсу камзул, башында ак ефәк яулык белән ефәк шәл, аякларында чигешле читек. Бу киемнәрдә Ана бөтенләй яшәреп, матурланып киткән.

С а й м ә. Әйдә, әни-җаным! Урынның иң мәдехлесе сиңа бүген, әни! Утыр әле менә шунда! *(Ананы өстәлнең иң түренә, Сәяр белән янәшә утырта.)* Күрегез әле, күрегез әле безнең әнинең матурлыкларын! Кызлар кебек ләбаса безнең әни, һай, җаным, күз тимәсен! Һай!.. Сәяр, син тагын әнине бикәчең белән бутама!

М а к с у д. Вәт безнең әни! Әни нинди дә, без нинди! *(Корсагын бәргәләп куя.)*

С а й м ә *(соклануында дәвам итеп).* Һай! Кыз чагыңда нинди-рәк булдың икән син, әни?! Яман да чибәр булгансың син кыз чагыңда, сөйләп тә бетерерлек булмагандыр. Тирә-як авылларның егетләре сиңа гыйшык тотып үлгәннәрдер!

А н а. Әллә тагын, алай үлгәннәре үк ишетелмәде.

С а й м ә. Үлгәннәрдер, үлгәннәрдер, әни, әйтмисең генә. Ничәдә кияүгә чыккан идең?

А н а. Егерме бердә.

С а й м ә. Ә, менә бит! Ул заманда унбиш-уналтыдан чыга булганнар, син күпме сайлап утыргансың!

А н а. Сайламадым! Әти рөхсәт бирмәде!

С а й м ә. Иртә чыгаргамы?

А н а. Атагызга чыгарга. Ахрысы, чыннан да чибәр булганмын, яучылар күп килде. Әти гел үзенә ошаган якка тартты, хәллерәк кешегә бирәсе килде. Мин үзем теләгән якка тарттым. Менә шулай, әти белән тарткалаша-тарткалаша үземнекен иткәнче, егерме бер тулды да куйды.

З ө л ә й х а. Ярый, кунакны сүз белән сыйламыйлар. *(Гөлсемгә.)* Сеңелем, нигә анда басып торасың? Кил, утыр!

А н а *(үз кырыннан урын биреп).* Кил, кызым, үземнең янга!

С а й м ә. Ә, юк, әни янында үзем утырам! Синең белән янәшә утыру — бик зур дәрәҗә бит ул, әни! Мин синең олы киленең, синең кырыңда мин утырырга тиеш! *(Ана янына утырып, Гөлсемгә урынны Альфред кырыннан күрсәтә.)* Менә шунда утыр, сеңелем! *(Гөлсем утыра.)* Чибәр кызны улым янына утыртыйм әле. Белмәссең!

М а к с у д. Утырма, сеңелем, моның янына, утырма! Бу инде хатын аерган татар!.. Әни, безнең Альфредны хатыны куалап чыгарды бит әле!..

Уңайсыз пауза.

С а й м ә. Чыгарса тагын! Әллә минем улыма кызлар беткәнме!.. *(Максудка.)* Үз улының гайбәтен чәйнәп утырган була тагын, о!..

А н а *(сүзне икенчегә бору кирәклеген аңлап).* Бик сусадым, кызым, бирәр чынаяк чәең булмасмы?

Р а с и х а. Чәй! Әнигә чәй китерегез, чәй!

И с л а м. Әнигә чәй ясап китерегез инде, понимаешь!

Зөләйха чыга.

А н а. Ягез, исән-сау торасызмы, балалар, авырмыйсызмы?

М а к с у д. Юк, әни!

Р а с и х а. Авырмыйбыз, әни! Барыбыз да тап-таза, ат кебек!

И с л а м. Сабан туенда батыр калырлык куәт бар әле, әни, пенсияда булсак та!

Р а с и х а. Әни, ничек болай бер дә хәбәр итмичә киләсе булдың?

А н а. Иптәш булгач, борчып тормадым инде. Киләсе дә түгел идем. Бүгенле-иртәгәле уракка төшәргә торалар — эш өстендә кем йөри Казан буенда! Менә Гөлсем. Әйдә булгач, әйдә, дип, күземне дә ачтырмады.

С а й м ә. Яхшы булган! Шулай итеп кенә алып килмәсәң, китереп буламыни безнең әнине! Рәхмәт сиңа, сеңелем, әнине алып килгән өчен!

Р а с и х а. Бик әйбәт булган, бик әйбәт булган...

Зөләйха Анага чәй кертеп бирә.

С а й м ә *(куштанланып, шул ук вакытта азрак иркәләнеп тә).* Әни! Яшь киленне яраттыңмы соң, әни, нигә бер дә дәшмисең?

А н а *(акланган кебегрәк).* Ул хакта сөйләшергә вакыт юк лабаса әле... *(Торып басып.)* Төкле аягы белән килсен! Улымны яраткан кешене мин яратырмын. Минем улымны яратып килгән лөбаса ул, шундый кешене ничек яратмыйсың! *(Муеныннан гәрәбә муенсасын салып Риммага кидерә.)*

Р и м м а. Рәхмәт!

А н а. Киленнәрдән бәхетем бар минем, берегездән дә авыр сүз ишеткәнем юк!

М а к с у д. Бергә тормаганга күрә генә шулай ул, әни!

А н а. Нишлисең бит, улым, бергә торырга насыйп булмаган. Лачындай җиде малай үстердем — җидесе җиде якка очты да таралды. Канат чыгарганнарын да сизми калдым. Өч кыз бала үстергән идем, алары да туган ояларын ташлап очып китте... Карасана, абыстай шикелле җәелдем дә утырдым! Күчтәнәчләремне чыгарырга онытканмын лабаса! *(Гөлсемгә).* Кызым, әйдә, булыш әле миңа! *(Гөлсем белән коридорга чыгалар.)*

С а й м ә. Һай, җаным, бигрәк күңелле көн булды ич бу!

Гөлсем чемодан кертеп куя. А н а зур кәрзин күтәреп керә.

М а к с у д *(Исламга).* Әни әйтә, киленнәрдән бәхетем бар, ди. Безнең генә хатыннардан бәхет булмады!

Саймә. Өйгә кайтасың барын онытма! Өйгә кайтасың барын онытма! *(Ана күчтәнәчләрен чыгара башлый.)* Һай, бу тиклем җиләкне кем җыеп бетергән моны!

Ана. Үзем җыйдым. Кәрим тугаенда җиләк бик күп быел. Менә, куегыз әле шунда табынга. Берсендә каен җиләге вареньесы, икенчесендә — җир җиләгенеке.

Саймә. Һай, бу тиклем дә хуш исле итеп кайната белерсең икән, әни! *(Варенье савытларын иснәп.)* Исен күрегез әле, исен!.. *(Ананың колагына иелеп.)* Әни, күчтәнәчләреңнең барысын да чыгарып бетермә, безгә дә алып барырсың!

Ана *(төргәк биреп)*. Менә монысы каклаган каз. Берәрегез кайтмасмы дип саклаган идем, кайтмадыгыз да быел... Әллә ни күчтәнәчем юк, кызым. Сыерны сатканнан бирле, килә башласаң аптыраш — ни алып килергә белмисең.

Ислам. Безгә монда берни дә кирәкми, әни! Безнең барысы да бар!

Расиха. Әйе, барысы да бар! Аллага шөкер, ач ятмыйбыз!

Ана. Ач ятмасагыз да, ана булган кешенең алып килеп авыз иттерәсе килә шул. *(Чемоданга күрсәтеп.)* Әнә, өчегезгә өч йөз күкәй, санап алырсыз. *(Инсафка.)* Синең Казанда икәнеңне белмәдем инде, улым...

Саймә. Шаярып әйткәнне чынга алма тагын, әни. Синнән күчтәнәч көтмибез. Син үзең безгә күчтәнәч!

Ана *(Рәйханга күкәй биреп)*. Мә, кызым, пешкән күкәй сиңа!

Ислам. Ашамый ул күкәй, әни! Безнең үзебездә егерме тавык, коеп кына торалар!

Рәйхан Ананың итәгенә менеп утырып муеныша урала, колагына нидер пышылдый.

Саймә. Нәрсә серләшкән булалар соң болар?

Рәйхан. Әбием! Без утырткан алмагачларның алмасы бармы инде?

Ана. Юк әле, кызым! Алмагач өч-дүрт елсыз җимеш бирми әле ул.

Зөләйха. Бигрәк ярата икән инде бу кыз әбисен!

Саймә. Яратмаска — әни үстергән Рәйхан ич ул! Сигез айлык чагында әнигә кайтарып аттылар да, алты ел буе әбисендә үсте ич ул Рәйхан! Әбиеңне яратасыңмы, Рәйхан?

Рәйхан *(Анага уралып)*. Яратам!

Саймә. Әбиең картайган ич инде, аның кай җирен яратасың?

Рәйхан. Картаймаган!

Саймә. Картайган шул! Әнә бит, чәчләре ап-ак!

Рәйхан. Синең үзеңнеке ак, гел буятып йөрисең!

Максуд. Ярый, сүзне туктатыйк! Мәҗлес дәвам итә! Менә яшьләр! Менә нур өстенә нур булып әни килеп төште — тагын да күңелле булып китте. Әни, син гаеп итмә инде, без берәрне тотыйк!

Әлмөхәммәт. Әбигә салмыйбызмыни?

Максуд. Чыннан да, әни, әллә бераз авыз итәсеңме, кызылдан гына? Актык туең бит бу, әни! Кызларың барысы да кияүдә. Инде менә малайларың да өйләнеп бетте. Башка туй булмаячак, әни!

Ана. Кыстама, улым. Менә алдымда чәем.

Зөләйха. Салып куегыз сез аңа, эчмәсә дә тулып торсын!

Максуд. Дөрес! Әнинең бәхете тулып торсын әле! *(Ана алдына тулы бокал куялар.)* Ярый, җәмәгать! Яшьләр саулыгына эчтек. Инде хәзер дөньяда иң якын кешебез булган, барыбыз өчен дә кадерле әни саулыгына эчәбез!

Эчәләр.

Саймә. Әни! Улларың күзеңнең алдында эчеп утырганга рәнҗемисеңдер бит?

Ана. Шушындый көнне дә эчмәгәч, ул ни була ди инде аннары! Аллага шөкер, ул яктан мактанычым зур — эчми минем улларым! Җиде малай үстердем, җидесенең берсе аракы эчеп, ил күзендә рисвай булып йөрмәде. Эчми минем улларым! Эчмиләр дә, тартмыйлар да!

Саймә. Сәярың тарта, әни!

Сәяр *(Ананың йөзе кинәт үзгәреп китүне күреп)*. Юк, әни, юк, тартмыйм! Саймә җиңги юри генә әйтә!

Саймә *(хихылдап)*. Тартасың! Тартасың!

Расиха. Тарта, тарта, әни!

Альфред. Ну, тартса?!

*Уңайсыз пауза.*

Зөләйха. Картаеп беткән кешене үчекләп утырырга бер дә оялмыйсызмы? Тартмый, әби, тартмый. Малаең елга якын миндә тора, тартканын күргәнем юк.

Саймә *(хатасын аңлап)*. Юк-юк, әни, тартмый, шаярып кына әйттем... *(Тәрәзә янына килеп.)* Уф, әллә яңгыр яварга җыена — авыраеп торам!

Максуд. Син авырайган саен яңгыр ява башласа, җир йөзен әллә кайчан су баскан булыр иде инде!

*Көлешү.*

Саймә. Чынлап менә! Аз гына ашадым исә, авыраям да китәм. Ятасым гына килеп тора.

Әлмөхәммәт. Симеребрәк киткәнсең шул, авырайсаң да гаҗәп түгел.

Саймә. Симерәм ич! Юньләп ашавым да юк инде үземнең. Әллә саф һава симертә — без торган җирнең һавасы яхшы бит.

Әлмөхәммәт. Саф һава белән генә симереп булмый...

Саймә. Әй, юк ла, хатын-кыз иллегә җиткәч шулай юаная инде ул... Алай дисәң, менә әни бер дә симерми. Әни, нишләп син симермисең икән? Сигезенче дистә белән барасың — фигураларың кызларныкы кебек!

Расиха. Чын! Бер дә картаймый безнең әни!

Саймә *(Ананың күкрәкләрен капшап)*. Күрегез инде, күрегез! Кем әйтер инде моны ун бала табып үстергән хатын дип! Күзләре дә утлы күмер кебек елтырап кына тора безнең әнинең! Әллә картаймауның берәр серен беләсеңме син, әни? Өйрәт әле безне дә, ничек шулай саклавдың?

Ана. Ашагач түл җыеп ятып торырга вакыт булмады, кызым. Шуңадыр.

Саймә *(Инсафка)*. Син нишләп сөйләшми утырасың — телеңне йоттың мәллә? Әни, бөтен балаларың ядрә күк чәчрәп торалар, нишләп бу Инсаф кына мондый юаш булган?

Ана *(Инсафның башыннан сыйпап)*. Кечкенәдән шулай оялчанрак булды шул ул Инсаф. Оялчан булса да, батыр йөрәкле иде үзе. Бервакыт Инсаф белән Ислам, янә дә Кәрим Иделгә су коенырга төшеп киткәннәр. Кәрим бата башлаган. Ислам җан-фәрманга чабып кайтып керде. Кәрим Иделгә төшеп батты, ди. Шуннан олылар Идел буена йөгереп төшсәләр — Инсаф Кәримне яр кырыена сөйрәп чыгарган. Ничә яшьтә булгандыр инде ул чакта, унөч-ундүрттән артык түгелдер. Кәрим үзеннән зуррак бит әле, ул Ислам белән бер елгы... *(Исламга ымлап.)* Монысының шунда иптәшен коткару өчен суга сикереп төшәргә йөрәге җитмәгән, үкереп авылга кайткан!..

*Көлешү.*

Ислам. Ярый инде, әни, үткән эшкә салават! Син миңа шуны әйт: кайчан үзеңне Казанга алып киләбез? Берүзеңә генә анда күңелсездер бит синең. Яшең дә шактый. Әйдә, Казанга күчеп кил, әни! Үземдә торырсың!

Расиха. Шулай шул, әни, чын! Үзебезгә кил!

Ислам. Сине әллә кайчан аннан алып китү тиеш иде дә, понимаешь, миннән башка моны эшләүче булмады. Инде менә мин кайттым, әни. Күп акча белән кайттым, баеп кайттым!

Саймә. Малаеңның байлыгын сөйләп тә бетерә торган түгел, әни, яман да баеп кайтты малаең. Өйләренә барып керсәң, әйләнеп чыга торган түгел — шул тиклем байлык!

Ислам. Җиткән, әни, сиңа тирестә казынып яту! Алып киләм мин сине, әни!

Ана. Белмим шул, улым. Атагызны ташлап китү авыр.

Ислам. Әллә кайчан череп беткән кешенең каберен берәү дә саклап утырмый, әни. Каберне күтәреп китмиләр аны.

Ана. Нигезне дә нәүмиз калдырасым килми. Ничә бәбкә типкән, күпме гомер иткән нигез бит ул!

Ислам. Синең ул чалышаеп беткән нигезеңне, әни, ут төртеп яндырасы гына калган!

Расиха. Чын! Ут төртәбез дә яндырабыз!

Ислам. Бер ялгызың яшәп, акылдан шашарга мөмкин бит анда, понимаешь! Әгәр теләсәң, әни, үзеңне менә хәзер үк машинама утыртам да выжт иттереп өемә алып кайтып куям! Түр башына менгезеп утыртам! Машина әнә тәрәз төбендә генә тора!

Саймә. Кара боларны! Сездән алда әнинең олы малае белән олы килене бар шул әле монда, алар нәрсә әйтер бит. Ийе бит, Максуд? Юк-юк, әни, киләсе булсаң, беркемгә дә түгел, үзебезгә киләсең!

Расиха. И ходаем, үзләренең кеше сараенда яшәгәннәрен белми!

Саймә. Яшәсә! Яңа йорт салынып беткәнче генә ич ул, көзгә хәтле генә! Тиздән безгә яңа квартира бирәчәкләр, әни. Җәй өчен бакчабыз да күңелле. Алмагачлар арасында җырлап кына йөр!

Расиха. Һа, бөтен бакча эшен анидән эшләтеп ятар иде бугай!

Саймә. Ятса! Җиләк җыешканнан гына әллә ни булмас әле энигә. Ийе бит, әни?

Ана. Эштән курыккан юк ла анысы.

Ислам. Алып киләсе булгач, әллә кайчан алып киләләр аны! Нигә мин кайтканчы суздыгыз?

Инсаф. Әти үлгәч, мин аны Чистайга алып китмәкче идем — бармады.

Саймә. Әйе! Үзе теләми ич ул! Юк-юк, әни, киләсе булсаң, олы малаеңа киләсең, үзебезгә!

Ислам. Абыйга килсәң, рәтле тормыш булмаячак сиңа, әни! Саймә ул ашаган табагын юарга да иренә!

Саймә. Иренсә! Син килеп юмыйсың ич аны! Икенче ашарга кирәк булгач юыла ул шунда... Синең Расихаң аш та пешерә белми әле!

Расиха. Белмәс инде!

Саймә. Белмисең шул! Әллә әнине ни өчен үзегезгә китерәсегез килгәнне белмиләр дип уйлыйсыңмы? Бөтен йорт эшен әнигә ташлап, эшкә кермәкче була ич ул Расиха! Картайган төшкә стажы юк ич аның!

Инсаф. Үзебезгә кил, әни! Бездә сиңа бер эш тә булмаячак.

Римма. Туктагыз әле, абыйлар, апалар! Әнине безгә кил дә, безгә кил, дип тарткалыйсыз, ә безне санга да сукмыйсыз. Без дә

бар ич әле монда! Әллә сез әнине бездән артыр дип уйлыйсызмы? Шулай бит, Сәяр?

С ә я р. Шулай булмыйча! Күңелсезләнә башласа, үзенә кибеттән бер бәби алып кайтып бирербез — тик уйнап утырсын!

И с л а м. Анысын булдырырсыз ла!

Р а с и х а. Әнидән бала каратып ятмакчы — хитрый!

С а й м ә. Әй, юк ла, булмаганны! Сез әле үзегез дә кеше өендә торасыз.

Р и м м а. Кеше өендә дип, алай кимсетеп ташламагыз әле сез, апа. Гел кеше өендә булмабыз, үзебезгә дә бирерләр.

А н а. Тәмле сүзләрегез өчен рәхмәт, балалар! Бәхәсләшмәгез, килмим. Турысын гына әйткәндә, кирәгем бар әле минем анда.

И с л а м. Кемгә кирәк син анда?!

А н а. Кемгә булсын — колхозга! Тизрәк кайт, әби, дип өзгәләнеп калды бригадир әле менә хәзер дә. Районнан берәр кеше килсә, я булмаса Казаннан, барысы да кич кунарга миңа килә.

И с л а м. Әти шул колхоз, колхоз дип үлгәнче йөргән иде, инде син! Ни кырдыгыз соң гомер буе шул колхозга эшләп, баедыгызмы?

А н а. Баедык шул!

И с л а м. Кайда ул сезнең байлыгыгыз? Книжкедәме?

А н а. Менә бит, барыгыз да шул колхоз икмәген ашап үскән балалар! Шуннан да зуррак нинди байлык бар?!

М а к с у д. Ярый, җитте, җәмәгать, туктатыгыз! Аптыратмыйк әнине! Үзе теләгәнчә яшәсен. Инде бер үземә генә авыр дип әйтә икән — килсен. Без тугызау. Тугызыбыз өчен дә әни — кадерле кунак. Әйдәгез, бер биеп алабыз! Равил, музыка!

Баянчы вальс уйный. Сәяр белән Римма, Альфред белән Гөлсем вальс әйләнә башлыйлар. Ана алдагы планда утырып калган Әлмөхәммәт янына килеп утыра.

А н а. Син кем буласың соң, бабай?

Ә л м ө х ә м м ә т. Мин Зөләйханың каенатасы. Зөләйха синең улыңның фатир хуҗасы. Әле менә синең язмышыңа сокланып утырам, әби. Улларың әйбәт, әни дип өзелеп торалар.

А н а. Минем уларым алтын шул, бабай!

Ә л м ө х ә м м ә т. Бәхетле ана булгансың шул син. Картлык көнеңдә газиз балаларыңның таза-сау булуларын күрүдән дә зуррак ни бәхет бар!

А н а. Дөрес, бабай!

Ә л м ө х ә м м ә т. Без дә мәрхүмә карчыгым белән арыслан-арыслан дүрт малай үстергән идек, дүртесе дә сугыштан кайтмады... Чыдаса да чыдый икән ата-анкә бәгыре!

А н а. Ата-анкә чыдый инде ул, бабай. Безнең дә бер улыбыз сугышта югалды. *(Инсафка ымлап.)* Икенчесен әнә гомерлек гарип итеп кайтардылар... Карчыгың үлдемени инде, бабай?

Ә л м ө х ә м м ә т. Күптән! Унсигез ел инде килен белән икәү генә торабыз. Ул тол, мин тол. Ике сабый белән утырып калган иде, бергә-бергә шуларны үстердек. Кызыбыз буйга җитте дә кияүгә чыкты. Улыбызны укуын бетергәч ерак җибәрделәр, кайтып кына җитә торган да түгел. Шулай итеп, тагын без ике ятим үзебез генә калдык...

А н а. Башы исән булсын диген, бабай. Башы исән кеше әйләнә дә бер кайта ул.

Ә л м ө х ә м м ә т. Анысы хак. Исән кеше әйләнә дә бер кайта. Үлгәннәр кайтмый!..

Вальс бетә. Баянчы бию көе уйный. Зөләйха белән Гөлсем савыт-сабаны җыеп чыгалар. Максуд бии. Башкалар урындыкларны читкәрәк тартып зал уртасын

бушаталар. Максуд Саймәне чакыра. Саймә алпан-тилпән бераз бии дә Ананы чакыра. Ана урыныннан күтәрелеп җай гына биеп китә. Аның хәрәкәтләрендә искиткеч матурлык һәм грация, күзләрендә яшьлек шаянлыгы.

Саймә *(бии-бии)*. Һай, җаным, безнең әни гомердә дә картаймас та, үлмәс тә!..

Килен белән Ана икәүләп бииләр. Яшь аралары шактый булган бу ике хатынның биюендә күзгә ташланып торган контраст. Саймә килбәтсезлек, биюнең табигатен аңламау һәм тупаслык мисалы булса, аның янында биегән Ана — матурлык һәм шигърият гәүдәләнеше. Шуңа булса кирәк, Ананың күзләрендә шук елмаю. Ул берсеннән-берсе нәзакәтлерәк хәрәкәтләр ясап бии дә бии — әйтерсең лә безнең алда җитмеш биш яшьлек карчык түгел, яшь бер сылу кыз.

Саймә *(көчкә бии-бии)*. Ух! Уф! Һай, җаным, үтерәсең ич, әни! Уф, үләм!.. Расиха, тор тизрәк, монда киленнәрне биетеп үтереш китте!..

Түгәрәккә Расиха сикереп чыга. Саймә хәлдән таеп урындыкка егыла. Ана белән Расиха бии. Ниһаять, Расиха үзенең Ана белән ярышырга чамасы юклыгын аңлап, кул селти дә утыра.

Саймә. Күр әле, җен икән безнең әни! *(Сикереп торып яңадан Ана белән бии башлый.)* Барыбер сине ардырам, әни! Барыбер ардырмыйча туктамыйм!..

Бию иң кызып җиткән моментта Гөлсем йөгереп керә һәм Ананы кочаклап ала.

Гөлсем. Туктатыгыз! Хәзер үк туктатыгыз! Акылдан язмагансыз лабаса! Төне буе йокламаган карчыкны үтермәкче буласызмы әллә?

Саймә. Үтерерсең безнең әнине! *(Яңадан бии башлап, баянчыга.)* Әйдә, туктама, Равил!

Гөлсем. Апа, дим, туктагыз! Әбигә урын җәеп бирегез, пароходта төне буе йокламый килде бит ул!

Саймә. Шулаймыни. Ярый, алайса, бераз ятып ал, әни! *(Ананы култыклап сулдагы бүлмәгә алып чыгалар, диван-караватка утырталар. Сәяр мендәр китереп сала.)* Менә бу диван-караватны без салдык, әни, туй бүләге итеп. Яртысын Инсаф түләде. Әле беркемнең дә йоклаганы юк бире дә. Матурмы?

Ана. Рәхмәт, кызым... Сез миңа карамагыз, күңел ачыгыз. Мин менә шунда азрак башымны гына терәп торам...

Сәхнә әйләнә. Сул яктагы бүлмә тамашачы күз алдыннан югала. Залда күңел ачу дәвам итә. Баянчы шейк уйный. Альфред белән Римма бөгелә-сыгыла шейк бииләр. Максуд белән Ислам, күрәсең, тагын берәрне төшереп алганнар — шактый кәефләнеп, нәндидер көй сузалар. Ана яныннан Гөлсем, Саймә, Расиха, Рәйхан чыгалар. Гөлсем Максуд янына килә.

Гөлсем. Абый, бер генә минутка бире килегез әле!.. *(Максудны ияртеп алгы планга чыга.)* Әйтсәм дә уңайсыз инде, абый, әйтмәсәм дә... Вакытсызрак чакка туры килдек... Әбинең эш начар бит, абый. Бик начар авыруы бар әбинең. *(Сумкасыннан бер кәгазь чыгарып бирә.)* Менә.

Пауза.

Максуд *(кәгазьне укып)*. Ислам! Инсаф! Сәяр! Килегез әле!

Туганнар Гөлсем янына җыелалар. Кәгазь кулдан-кулга күчә. Төркемгә Саймә, соңрак Расиха килеп кушыла.

Саймә. Нәрсә серләшәләр болар? *(Максуд колагына нидер әйткәч, шып булып кала.)*

Инсаф. Кем куйган диагноз бу?

Гөлсем. Район больницасында куйдылар. Быел җәйгә чыккан-нан бирле инде ул үзен начар хис итте.

Саймә. Ходаем!

Максуд *(шейк биегән Альфред белән Риммага).* Маймылланма-гыз әле, пожалыста! *(Бию туктый.)*

Гөлсем. Ул инде ай буе морфий эчеп кенә тора.

Инсаф. Морфий?!

Гөлсем. Әйе. Авыртуны баса торган шундый бер дару бар.

Пауза.

Саймә *(кулларын угалап, еларга җиткән хәлдә әрле-бирле йөренә).* И ходаем, нишлибез инде менә хәзер? Нишлибез инде менә хәзер? Үлем хәлендәге карчыкны биетеп аптыратабыз бит, җүләр тә-реләр! *(Гөлсемгә.)* Әйтмисең дә, ичмаса, шуны! Әни үзе беләме соң?

Гөлсем. Үзендә шундый авыру барлыгын әбигә әйтергә ярамый, апа.

Саймә. И ходаем, бик көлгән идек шул, күп көлүнең азагы хәерле булмый аның...

Инсаф. Операция ясатсаң?

Гөлсем. Операция ясаудан узган, абый... Авылга җибәрмәгез инде сез аны. Берүзе бит ул анда, су алып бирер кешесе дә юк.

Ислам *(гаять дәрәҗәдә уйга калып).* Йогышлы түгелме бу авыру?

Расиха *(Рәйханны итәгенә кысып, елар дәрәҗәдә).* Рәйхан киче буе әбисенең итәгеннән төшмәде — харап кына булдык лабаса!..

Гөлсем. Бу авыру йогышлы түгел, курыкмагыз.

Пауза.

Максуд. Нишлибез соң инде хәзер?

Саймә. Әни башына көлгәнбез икән! Әни башына көлгәнбез!

Максуд. Ислам! Булмаса, син бүген әнине машинаңа утырт та үзеңә алып кайтып тор, ә иртәгә...

Саймә *(идәннән кәгазь тастымал алып).* Кем ташлаган идәнгә бу салфетканы? Бу салфетканы идәнгә кем ташлады?

Зөләйха. Сабыр итегез! Тыңласагыз, мин дә бер киңәш әйтим әле. Әниегез арып юл килгән, йокласын. Әллә ни зур кеше булмасам да, егерме биш ел больницада медсестра булып эшлим, гозерем төш-кәндә кире какмыйлар иде. Каршы килмәсәгез, заведующий белән сөйләшеп, мин аны иртәгә үк больницага салып куйыйм. Тагын бер тикшергәннән зыян булмас дип уйлыйм.

Расиха *(үксеп).* И ходаем!..

Максуд. Булдыра алырсыз микән?

Зөләйха. Мин ике сөйләшә торган хатын түгел.

Саймә. Рәхмәт инде сезгә, Зөләйха ханым!

Зөләйха. Рәхмәте качмас. Инде яшьләр турында уйларга ки-рәк. Ни генә булмасын, аларның беренче кичләре. Минемчә, кайсыгыз да булса яшьләрне үзенә алып китсә, яхшырак булыр.

Саймә. Максуд! Әйдә, яшьләрне үзебез белән алып китеп, бакча өендә урын әзерлик! Римма! Сәяр!

Сәяр. Без беркая бармыйбыз.

Расиха. Ай, алла, сәгать уныньчы киткән! Ислам, безгә кайтыр-га вакыт! Ислам, дим!.. Кайда, үзебезнең өлеш күкәйләрне ала китим әле!.. *(Ананың чемоданы янына тезләнеп утыра.)* Ислам, сумкамны

китер!.. Сәяр, берәр иске газитең юкмы?.. Рәйханның кофтасын кидерә тор инде, Ислам!.. *(Чемоданнан сумкасына күкәй тутыра башлый.)*

Саймә. Бик кызык ягың белән ачылып киттең бит әле син, Расиха!

Расиха. Ник, Саймә апа?

Ислам. Күкәйләрне үзенә бирмәгәнгә ачуы килә аның. Тутыр, тутыр! Эрерәкләрен сайлап тутыр! Саймәгә ваклары да ярар, ул болай да симез!

Расиха. Сөйләштермәгез әле, саташтырасыз!

Саймә. Саташсаң, санап азапланма, ал да кит бөтенесен!.. Бик кызык ягыгыз белән ачылып киттегез бит әле сез...

Ислам. Ә без кайсы ягыбыз белән ачылсак та курыкмыйбыз. Теләсә кайсы ягыбызны ачып күрсәтергә можем! *(Рәйханны җитәкләп.)* Әйдә, кызым!

Расиха. Ярый, саубулыгыз... Безгә дә килеп утырыгыз, Сәяр!

Ислам, Расиха, Рәйхан чыгалар.

Гөлсем. Миңа да китәргә вакыт. Саубулыгыз!

Саймә. Бик зур рәхмәт инде сиңа, сеңелем! Туганнарың бармы соң Казанда?

Гөлсем. Бар!

Максуд. Рәхмәт, сеңелем! *(Гөлсем чыга.)* Сәяр, әйдәгез безнең белән!

Сәяр. Без беркая да бармыйбыз!

Саймә. Болай уңайсыз була ич инде...

Сәяр. Барыгыз инде, барыгыз, китегез! *(Инсафка.)* Ә син, абый?

Инсаф. Мин бүген больницага кереп ятарга тиеш идем...

Сәяр. Ярый, ят. Без монда синнән башка да эшләрбез, ят!.. Барыгыз, китегез... Я, китәсезме инде сез, юкмы?!.

Максуд, Саймә, Инсаф, Альфред һәм баячы егет чыгалар. Зөләйха белән Әлмөхәммәт аларны озаткан арада Сәяр тәмәке тартып җибәрә, стена буенда моңаеп басып торган Риммага карап ала да коридорга чыга. Бераздан кире әйләнеп керә. Римма янына килә.

Сәяр. Син бик борчылма әле, Римма. Күңелем һич ышанмый. Ышанасым килми. Минемчә, врачлар ялгышканнардыр...

Римма. Синең башка сүзең юкмы?

Сәяр. Бәлки әле операция ясарлар. Терелер. Кайгырма, Римма, тынычлан!

Римма башындагы фатасын салып алып Сәярнең битенә ыргыта, ике кулы белән йөзен каплап, кычкырып елый башлый.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Вакыйга шунда ук бара. Сәяр, өстенә җиңел пальто кигән хәлдә, тәрәзәдән карап тора. Күрәсең, ул кемнедер көтә. Әлмөхәммәт керә.

Әлмөхәммәт. Азрак ашап ал, улым, бәрәңге пешердем!

Сәяр. Ашыйсы килми лә, бабай. Больницадан әнине алып чыгасы бар, Римма кайтып җитми.

Әлмөхәммәт. Син ашаган арада Риммаң да кайтып җитәр. Әйдә! Әтүсәк, син болай да бик ябык. Абыйларың әнә нинди, ә син кечкенәрәк булып калгансың.

Сәяр. Бакыр тәңкә зур булса да, казан төбе ямыйлар, ди, бабай. Көмеш тәңкә кечкенә булса да, энҗеле калфакка кадыйлар.

Әлмөхәммәт. Бакыр тәңкә белән казан төбе ямауларны кайдан беләсең әле син?

Сәяр. Әни сүзе ул, бабай. Иптәшләрем озын-озын булып үсеп киткәч, «Әни, мин нигә үсмим икән? Шулай кечкенә булып калсам, нишләрмен?» — дип, әнине аптырата идем. Шул чакта әни мине шулай юата торган иде. Бакыр тәңкә зур булса да, казан төбе ямыйлар, көмеш тәңкә кечкенә булса да, энҗеле калфакка кадыйлар...

Әлмөхәммәт. Мөгаен, кечкенә чакта манный ботка ашарга яратмагансың.

Сәяр. Тәтеде микән соң безгә манный боткалар, бабай!

Әлмөхәммәт. Сугыш еллары баласы шул син, бик тәтемәгәндер дә. Самай үсә торган вакытта адәм рәтле ризык эләкмәгән.

Сәяр. Син хаклы, бабай, бала чак азрак эләкте безгә. Уйласаң көлке, мин әле менә хәзер дә сабын куыгы очырып уйнаучы балаларга кызыгам. Зур кеше икәнлегемне онытып, шул аллы-гөлле куыкларны очырып уйныйсым килә. Чөнки үз вакытында уйнап булмады — сабын юк иде!..

Римма керә.

Әлмөхәммәт. Менә килен дә кайтты. Әйдәгез, ашап алыгыз, бәрәңге суына, әтүсәк! *(Чыга.)*

Сәяр. Римма! Әнине бүген больницадан чыгаралар. Әйдә, тиз генә барып алып кайтыйк әнине!

Римма. Ә ни өчен моны без эшләргә тиеш?

Сәяр. Без илтеп салдык, без алып та кайтырга тиеш.

Римма. Без карарга тиеш түгел аны. Аңлыйсыңмы шуны — без карарга тиеш түгел! Без әле өйләнештек кенә. Син юньләп эшли башламаган. Кеше өендә торабыз! Безне берәү дә гаепли алмый.

Сәяр. Безне гаепләүче юк. Ләкин әнине больницага без илтеп салдык. Димәк, алып кайтучы да без булырга тиеш. Соңыннан күз күрер. Әйдә!

Римма. Мин бармыйм.

Сәяр. Римма, җүләр булма, зинһар! Әнине алып кайтырга кирәк. Мин моны, әлбәттә, синнән башка да эшли алам, ләкин мин алай теләмим. Икәү барып алабыз, аңлыйсыңмы?

Римма. Мин бармыйм! Каравын да миннән башка эшли аласың икән — бар, алып кайт!

Сәяр. Римма!

Римма. Мин инде егерме ел Римма! Нәрсә, әниеңә нянка кирәк булган өчен өйләндеңмени миңа?

Сәяр. Ничек оялмыйсың син, Римма?! Син мине җәберлисең! Син мине яратмыйсың!

Римма. А, яратуның монда ни катнашы бар! Сүз авыру карчыкның чүпрәкләре турында бара...

Сәяр. Ләкин ул карчык минем анам! Анам, Римма! *(Кискен хәрәкәт белән ишеккә юнәлә. Римма йөгереп килеп аның юлын бүлә. Пауза.)* Беләсеңме, мин зур булып беткәч тә имә идем. Хәзер дә күз алдымда. Урамда уйнап арыгач, әнине эзләп табам да күлмәк изүенә ябышам. Күрше хатыннар әнине сүгәләр. «Шул үгез хәтле малайдан нигә каныңны суыртасың, нигә тибеп очырмыйсың?» — диләр. Ләкин әни тибеп очырмый иде. Мин моның сәбәбен үсеп җиткәч кенә белдем. Мин бәләкәй чакта ачлык булган. Алабута, юкә яфрагы, кычыткан — барысын да ашаганнар. Әни мине кызганган. Яшь балага үлән генә аз, карынына аз булса да сөт керсен, дип, мине дүрт яшькә хәтле имезгән. Үзе ач йөргән хатынның күпме сөте булгандыр — хәтерләмим. Тик шунысы исемдә — имә идем!..

Римма. Без карарга тиеш түгел аны!

Сәяр. Әнинең күп яшисе калмаган, Римма.

Римма. Берәү дә бу дөньяга мәңгегә килми, сөеклем, барыбыз да үләчәк.

Сәяр. Римма!

Римма. Без әле бәлки аның яшенә хәтле яши дә алмабыз.

Сәяр. Римма!

Римма. Ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән. Үкенече калмаган...

Сәяр. Римма!!!

Римма. Нәрсә шул кадәр кычкырасың — синең генә әниең үләме соң?! *(Сәяр чалт иттереп Римманың яңагына сугып җибәрә.)* Менә син нинди! Синең әле мондый һөнәрең дә бармыни? *(Сәяр яңадан Римма өстенә килә башлый.)* Ааа!..

Әлмөхәммәт керә.

Әлмөхәммәт *(Сәярны тотып)*. Ярамый, улым, ярамый, сабыр бул!

Сәяр *(боерган тавыш белән)*. Әйдә!

Римма. Юк!

Әлмөхәммәт. Бар инде, бар, үзең генә алып чык әниеңне! Ә без сез чыккан төшкә килен белән чәй куеп торырбыз.

Сәяр чыга.

Римма *(чемоданга әйберләрен тутыра башлый)*. Барыбер мин моны болай гына калдырмыйм! Алдыма тезләнеп гафу үтенәчәк ул моның өчен!

Әлмөхәммәт. Чын ир булса, тезләнмәс. Чүпрәк булса — тезләнер дә бәлкем. Бар ул шундый идән мунчаласы кебек ирләр. Катырак сүз әйтсә дә тезләнеп гафу үтенә, хыянәт итсә дә. Хатын, җүләр, шуңа юанып яши. Янәсе, ирем хатасын аңлады. Ә ул тагын хыянәт итә, тагын тезләнеп гафу үтенә. Нәрсә дип беләсең соң син аны тезләнүне? Бер өйрәнгәч чүп тә түгел ул! Юк, син иреңнең андый булуын теләмә! Ир булсын ул! Ә син хатын була бел!

Римма. Ир суккан җир тәмугта янмас, мә, җаныем, бу яңагыма да сук! Шулмы, синеңчә, хатын була белү?

Әлмөхәммәт. Гаеп үзеңдә ләбаса синең. Болай да кая барып бәрелергә белми йөри бит ул бала. Газиз әнкәсе ләбаса ул аның! Нигә син аны шулай рәнҗетәсең? Ярату ул бер юрган астында йоклау гына түгел. Бер-береңне хөрмәт итәргә, авыр минутларда бер-береңә терәк булырга кирәк. Ир йөрәге чыдам. Әмма без дә таштан яралмаган. Шуны аңларга тырыш син, кызым, кеше булсаң!

Звонок. Әлмөхәммәт ишек ача. Максуд белән Саймә керә.

Максуд. Исәнме, бабай! Сәяр өйдәме?

Әлмөхәммәт. Әбине алырга китте. Киленегез өйдә. *(Кухняга чыга.)*

Саймә. Нихәл, сеңелем!.. Нәрсә булды сиңа, авырмыйсыңдыр бит?

Римма. Тугыз бала арасында тормышының иң рәте-чираты булмаганы без. Кеше өендә торабыз! Сәяр институтны бетереп юньләп эшли башламаган! Көз җитте — өстенә пальтосы юк!

Саймә. Булмаса тагын! Нигә соң ашыгып чыктың, пальто тектереп кигәнен көтмәдең?

Римма. Ни өчен без карарга тиеш ул карчыкны? Ни өчен без карарга тиеш?!

Саймә. Ни өчен, дип, сезгә карарга кушкан кеше юк ич әле. И, курыкма, сеңелем, безнең әни бик кадерле кеше ул, синнән башка

да караучы табылыр. Аның тугыз баласы бар! Барысына да хәбәр бирелгән. Кайтырлар, җыелышырбыз, киңәшербез!

Римма. Киңәшсәң дә, киңәшмәсәң дә, без карарга тиеш түгел аны!

Саймә. Түгел, дип, нишләп? Син дә әнинең килене ич! Без инде үзебез картаеп барабыз, акыллым, үзебезне карар вакыт җитеп килә.

Римма. Әгәр бүген үк бирәрегез алып китмәсә, мин тормыйм! Китәм! *(Сулдагы бүлмәгә кереп китә.)*

Саймә *(беравык аптырап торганнан соң).* Китсәң тагын! Әллә безнең энебезгә хатын табылмасмы! Синең кебек кызлар Бауман урамы тулы!

Әлмөхәммәт керә.

Максуд. Вәт киленнәр нинди, бабай! Егетләрне яраталар, ә шул егетләрне табып үстергән аналарны — юк!

Әлмөхәммәт. Киленнәрнең дә төрлесе була. Менә безнең Зөләйха. Ул килен булып төшкәндә минем әни исән иде әле. Шуның өстенә карчык белән мин. Ире сугышта үлгәч ике яшь бала, өч без карт имгәк белән утырып калды. Бер уйласаң, без кем аңа? Башта әнине карап җирләде. Аннары карчыкны. Минем карчык урын кастасы булгач та җиде ел ятты!

Артта аяк тавышлары. Ананы култыклап Сәяр белән Зөләйха керә.

Саймә *(каршы килеп Ананы култыклап ала).* Кайттыңмы, әниҗаным?!

Ана *(кулларын бушатып).* Тотмагыз мине, тотмагыз, мин үзем дә йөри алам!

Әлмөхәммәт. Әйдә, әби, әйдә! Хуш киләсең! *(Ананы өстәл янына кадәр озата.)* Утыр! Хәзер чәй эчәрбез!

Ана. Эчәсем килми лә минем. *(Карангалап.)* Яшь килен кайда соң әле?

Саймә. Ә, юк, әйдә, әни... яшь килен теге якта... Яшь килен бит ул, әни, синең янга матурланыбрак чыгасы килә торгандыр...

Әлмөхәммәт. Яшь килен, әби...

Саймә *(бүлеп).* Хе-хе, бу бабай бүреген бер дә башыннан төшерми! Салып куй, бабай, шул бүрегеңне, эссе ич!

Әлмөхәммәт. Эссе, дип, өч айлык җәй инде ул. Өч ай өчен бүрек салып торасым килми!

Саймә. Эээ... я, кәефең ничек, әни? Терелдеңме инде?

Ана *(сулдагы бүлмәгә карангалап).* Зыянлы түгел, кызым. Кайтырга кирәк инде авылга.

Зөләйха. Авылга кайтырга өлгерерсең әле, әби! Ике-өч ай да кунак булмагач, мин аны шул тикле җирдән килеп тә тормыйм!

Ана. Ике-өч ай!

Саймә. Тиздән, алла теләсә, әни, яңа квартир алабыз. Яңа квартирны күрсәтмичә җибәрү юк инде сине!

Сәяр Римманы алып керә.

Ана. Исәнме, кызым!

Римма. Исәнмесез!

Саймә *(Римма янына килеп).* Хе-хе, чәчемне матурлыйм дип, әнине каршыларга соңга калды! Яшь килен әнине каршыларга соңга калды!.. Юк-юк, әни, сине тиз генә җибәрмибез әле!

Максуд. Тәмам терелеп җитмичә сине җибәрмибез, әни!

Ана. Шуннан артык булмас инде, улым. Яшь кеше түгел бит.

Саймә. Юк-юк, әни, тереләсең, алла теләсә! Врачың шулай ди.

Тәмам терелеп җиткәч кенә авылга кайтасың. *(Артта ыгы-зыгы.)* Кемдер бар!

С ә я р. Гөлчирә апа тавышы!

Ана һәм Риммадан башкалар ишеккә юнәләләр. Г ө л ч и р ә, И с л а м, Р а с и х а керә.

Р а с и х а. Менә бит әни кайда!

Гөлчирә берсүзсез туктап кала, үзен Ана килеп кочаклап алгач, елап җибәрә.

А н а *(Гөлчирәнең аркасыннан сөеп).* Я, булды, булды, кызым! Үзең генәме соң? Исән-сау кайттыңмы? Кайчан кайттың?

Р а с и х а. Әле хәзер генә кайтып төште, әни, самолет белән! Безгә килеп керүгә машинага төялеп больницага киттек! Больницага барсак — син анда юк!

А н а. Алып кайтты шул мине Сәяр. *(Гөлчирәгә.)* Булды, кызым, җитте, җитте! Булды! Утыр, сөйлә! Балалар исән-саулармы? Кияү нишләп йөри?

Г ө л ч и р ә *(азрак тынычланып).* Гәрәйне өч айга командировкага җибәрделәр, әни, Афганстанга. Балалар үсә.

М а к с у д. Афганстанга? Ну баеп та кайта икән инде, алайса!

А н а. Былтыр да кайта алмадыгыз, балаларны бик сагынган идем. Кияү өйдә булмагач, кем белән калдылар соң алар?

Г ө л ч и р ә. Олысын лагерьга җибәргән идек, әни,— лагерьда. Илдус атналык садикта. Рөстәм күрше карчыкта калды.

А н а. И, кызым, бигрәк кансыз икәнсең инде! Соң инде, берсеннән-берсе кечкенә сабыйларның өчесен өч җиргә ташлап кем йөри!

Г ө л ч и р ә. Алар өйрәнгәннәр инде, әни! Кечкенәдән шулай бит, есләреннән биклибез дә эшкә китәбез. Син алар өчен борчылма, әни, аларга берни дә булмас!

А н а *(Сәярга).* Улым, нигә бик моңаеп утырасың?

С ә я р *(елмайган булып).* Юк, әни!

А н а *(Гөлчирәгә).* Кечкенәсе сөйләшә торгандыр инде?

Г ө л ч и р ә. Сөйләшә, әни, авызы һич ябылып тормый! Аңарда булган сораулар хәтле бөтен дөньясында да җавап юк... Авылны бер дә онытмыйлар. Аз гына ачуландың исә, әби янына китәбез, дип куркыталар. Әле кичә олысына лагерьга передача илткән идем. Синең яныңа кайтасымны әйткәч, үзенә дип алып барган шоколадны ашамыйча, сиңа җибәрде. *(Сумкасыннан шоколад чыгарып.)* Менә! Менә бу куянны да сиңа җибәрде, әни. Пластилиннан үзе ясаган! *(Сумкасыннан пластилиннан ясалган куян чыгарып Ана алдына куя.)*

А н а *(уенчыкны алып).* Бәбкәм!.. Озакка кайттыңмы, кызым?

Г ө л ч и р ә. Өч кенә көнгә шул, әни! Эш бит! Сотрудникларның күбесе ялда, җибәрмиләр шуннан артыкка...

А н а. Расихалар нигә утырмый?

М а к с у д. Алар, әни, үзләренең машиналарын саклыйлар!

Р а с и х а. Юк ла! *(Йөткергәләп.)* Грипп булган миңа, әни! Яныңа барсам, сиңа да грипп иярер дип куркам!

А н а. Авыруга авыру ияр ми лә ул.

Ә л м ө х ә м м ә т *(хәйләкәр елмаеп).* Җәй җитсә, халыкта шул грипп башлана инде!

С а й м ә. Әйтмә дә, бабай! Быел күренмиләр әле. Узган ел медсестра килеп, борынга вакцин тамызып киткәч, унөч кенә мәртәбә авырган идем!..

А н а. Рәйханны ник алып килмәдегез?

Р а с и х а. Рәйхан... Рәйханны, әни, күрше кызына ияртеп Каравай кибетенә җибәргән идем. Форма табып булмый! Рәйхан зур үсте бит инде, әбисе, быел мәктәпкә керә!..

Ана *(Сәярдан).* Улым, апаңны бикәчең белән таныштырдыңмы соң?

Сәяр. Апа, менә таныш булыгыз, бу — минем хатын!

Гөлчирә *(Римма белән күрешеп).* Гөлчирә!

Римма. Римма.

Гөлчирә. Кайтасым да кичә генә билгеле булды, юньле бүләгем дә юк. *(Бераз уйлап торганнан соң бармагындагы йөзеген салып Риммага кидерә.)* Бәхетле булыгыз!

Римма. Рәхмәт!

Гөлчирә. Сәяр, кәрзинемне генә кертеп бирче! *(Сәяр коридордан зур кәрзин кертеп өстәлгә куя. Расиха ирексездән өстәлгә таба бара башлый, Ислам аны туктатып кала.)* Менә, әни. Җиләк-җимештә витамин күп, барысы да сиңа файдалы ризыклар, ашарсың!

Ана. Рәхмәт, кызым! *(Берничә алма алып Зөләйхага.)* Зөләйха, менә шуларны теге Люсә дигән кызга алып барып бир әле, кызым! *(Башкаларга.)* Мин яткан бүлмәдә бер детдом баласы ята анда, аякларына салкын тигән. Үлдем инде шул баланы жәлләп. Бик сызлый буыннары. Йокысы тынычсыз тагын үзенең, гел өстен ача. Төнә әллә ничә торып өстен ябам шуның. *(Зөләйхага.)* Өйгә кайткач, йон оекбаш бәйләп җибәрәм әле, алла теләсә, шул балага!

Гөлчирә елый башлый.

Саймә. Җитте сиңа!

Зөләйха. Артыккарак китә башлады шул!

Ана. Бу кызым кечкенәдән шулай елаграк булды инде минем, гаеп итмәгез инде сез аны.

Сәяр. Әни, ятып аласың килмиме?

Ана. Юк, улым!

Сәяр. Сине күп сөйләштереп арытырга ярамый, әни, врач шулай кушты. Бераз ятып ал!

Ана. Соң тукта инде, улым! Килгәнемә ай тулды — үзегезне туйганчы күргәнем дә юк!

Максуд *(кәрзиннән груша алып.)* Ташкент кучтәначен ашап карыйк әле! *(Гөлчирәгә.)* Кыйбатмы инде Ташкентта шуның килосы?

Саймә. Син бик хаптырдама әле, сиңа дип алып кайтмаган ул аны!

Ана. Ашагыз, ашагыз, барыгыз да авыз итегез! *(Кәрзиннән алмалар, грушалар алып барысына да өләшеп чыга.)*

Расиха *(үзенә груша сузып якын ук килгән Анадан читкәрәк тайпылып).* Юк-юк, әни, без ашамыйбыз, үзең аша!

Саймә. Әни, малайларыңа күп бирмәсәң дә ярар! Тәмле ризыкны ирләргә бирергә ярамый аны. Алар аның барыбер ләззәтен белеп ашамыйлар — хаптыр-хоптыр иттерәләр дә йотып җибәрәләр.

Ана *(Максуд алдына иң зур грушаны сайлап куя).* Болай булгач, хатыныңнан сиңа тәмле нәрсә күп эләкмидер. Мә, улым, анаң янында сыйланып кал әле!

Максуд. Кирәкми, әни, булды. Груша безнең өйдә дә бар. Кичә генә алып кайттым.

Саймә. Һай, җаным, кичә таш шикелле өч кило груша күтәреп кайткан, авызга кабарлык та түгел! Бер әйбер ала белми инде безнең Максуд!

Расиха. Ашап карап алырга кирәк!

Саймә. Ашау әйберен генә түгел! Әле беркөн миңа халатка дип штапель күтәреп кайткан — капчык тегәргә генә яраулы. Бер әйбер ала белми, вкусы юк! Әни, малаеңның вкусы юк, әйбер ала белми малаең!

А н а. Малаем әйбер ала белми? Бу кадәр уңган, бу кадәр белдекле хатынны ничек ала белде икән соң?!

Көлешү.

С а й м ә. Безнең әни малайларына сүз тидерми ул!

А н а. Улым, Максуд, Хафиздан хат юкмы?

С ә я р. Хафиз абый шушы көннәрдә үзе кайтып җитәргә тиеш, әни!

А н а. Кайта алмас ул. Ул якларда дөньялар тыныч түгел лабаса, җибәрмәсләр. Телеграм сук, исәнлеген белдереп хәбәр бирсен.

С ә я р. Ярый, әни!.. Әни! Сине ялыктырырга ярамый! Әйдә, ятып ал!

А н а. Ятасым килми минем, улым! Бер рәхәтләнеп яныгызда утырыйм инде! Гөлчирә апаң да кайткан, бакчи!

С ә я р *(Гөлчирәгә күз кысып)*. Гөлчирә апа да азрак ял итсен, юл килеп ул да арган!

С а й м ә. О, бик яман арыта ул, әни, самолетта очу!

А н а. Алайса, ул ял итсен, мин сезнең янда утырам!

С ә я р. Юк, әни, юк, син дә ял итәсең! *(Ананы култыклап ала.)*

А н а. Кара, нигә тотасыз мине? Мин үзем дә йөри алам лабаса!

Кулларын тартып ала. Ана, Сәяр, Гөлчирә, Саймә уңдагы бүлмәгә чыгалар.

М а к с у д *(Исламга)*. Син нигә тәресен җуйган кяфер шикелле утырасың? Алтын кадерен генә беләсең шул син. Алтыннарны аны җир астыннан казып табып була. Әниләрне җир астыннан алып булмый бит бер илтеп күмгәч!

З ө л ә й х а. Кухняга чыгып сөйләшегез, әнә тегендә! Әниегез азрак ял итсен!

Максуд, Ислам, Расиха кухняга таба китәләр. Сәхнә әйләнә. Безнең алда Зөләйха квартирасының кухнясы.

М а к с у д. Ишеттегезме, Сәярның хатыны китәм, ди!

Р а с и х а *(гаять кәефе килеп)*. Ник?

М а к с у д. Әнине карыйсы килми!

И с л а м. Хы-хы-хы!

С а й м ә керә.

С а й м ә. Нәрсәдән көләсез?

М а к с у д. Римма китәм дип әйтә, дигән идем, шуннан көләләр.

С а й м ә. Аның ниеннән көләсең! Көлке түгел ул, еларга кирәк!

И с л а м. Хы-хы-хы! Кем инде хатын киткәнгә елый! Менә шуннан син китсәң, абый елармы? Еламыйсың бит, абый? Хы-хы-хы!

С а й м ә. Нәрсә син танавыңны җәеп хихылдыйсың, хайван?!

И с л а м. Кем хайван? Минме хайван?

С а й м ә. Син түгел, син түгел, мин!

И с л а м. Шулай дисәң генә. Хы-хы-хы!

С а й м ә. Бик килешә инде! Әнисе үлем түшәгендә, ә ул...

И с л а м. Әни үлә дип үлеп булмый бит инде!..

Г ө л ч и р ә керә. Өстәл янына килеп утыра да битен кулы белән каплап елый башлый. С ә я р белән Р и м м а керә.

С а й м ә. Я, Гөлчирә, тынычлан! Кирәкми! Елап була торган эш түгел. Тынычлан, кеше елаганга карый алмыйм мин, үземнең дә елыйсым килә башлый.

Г ө л ч и р ә. Диагнозы дөрес булып чыктымы? *(Сәяр баш селки, Гөлчирә кабат елый башлый.)*

Саймә. Тынычлан, сеңелем!

Гөлчирә. Үләсен үзе сизә микән?

Саймә. Аңа әйткән кеше юк ич!

Сәяр. Әйткән кеше юк. Тик әни врачына әйткән. Мине тикшереп азапланмагыз, кызым, мин барыбер үләм, бу минем әҗәл авыруым, дигән.

Саймә. Сәяр! Ул бит хәлем әйбәтләнә дигән була!

Сәяр. Безне борчымас өчен! Сез әнине белмисез, аның табигате шундый. Үзенә авыр икәнлеген ул бервакытта да безгә әйтмәячәк.

Гөлчирә. Күпме яшисен әйтмәделәрме?

Сәяр. Өч ай. Күп булса — ярты ел.

Расиха. И, алай гына тормый әле ул! Ул әле авыртуга чыдый алмыйча кычкырып ята башлагач та әллә ничә ай үтә!

Саймә. Безнең әни кычкырмас, Расиха. Ул бик сабыр хатын.

Расиха. Кычкыра!

Гөлчирә. Туганнарның барысына да яздыгызмы? Кайталармы?

Сәяр. Менә Хафиз абый кайтып җитәргә тиеш иде дә, юк бит! Җибәрмиләр, күрәсең. Ул хезмәт иткән чик буе тыныч түгел бит.

Саймә. Ходаем, үзең сакла!..

Максуд. Ярый, туганнар! Әни юкта сөйләшеп алыйк әле. Нишлибез? Авылга җибәрәбезме әнине?

Гөлчирә. Ю-у-к, авылга җибәрергә ярамый!

Максуд. Ә кая куябыз?

Гөлчирә. Ничек инде кая куябыз?

Максуд. Шулай. Без карый алмыйбыз. Без үзебез кеше сараенда торабыз. Өебезне сүттеләр.

Саймә. Болай ул, Гөлчирә. Май аенда безнең өйне сүттеләр. Безгә квартир биргәннәр иде дә, ерак булгач, безнең күченәсебез килмәде. Шуннан горисполком безгә гарантия бирде, октябрьның беренче яртысында безгә квартир бирәбез дип. Без шуңа риза булып, танышларыбызның сараена күчеп торган идек. Кем белгән бит аның болай килеп чыгасын!..

Максуд. Яшь киленнең карыйсы килми. Китәм, дип куркыта!

Римма. Без карарга тиеш түгел аны!

Гөлчирә. Сабыр итегез, сеңелем!

Максуд. Исламнар алмый!

Гөлчирә. Ни өчен?

Ислам. Чөнки мин үзем пенсионер. Хатын — чирле.

Гөлчирә. Ни булган синең хатыныңа?

Ислам. Ашказаны авырта. Ашаганы кире килә.

Гөлчирә. Минемчә, абый, әнине сез карарга тиеш.

Ислам. Ни өчен без?

Гөлчирә. Башка юл юк чөнки. Сәярләр карарга тиеш түгелдер, дип уйлыйм инде мин. Алар кеше почмагында яшиләр. Яңа гына өйләнештеләр. Тормыш итә башлау ул әле авыру карчыктан башка да читен була. Сез карарга тиеш әнине, абый.

Ислам. Ә ни өчен син карарга тиеш түгел? Син дә бит әнинең кызы!

Гөлчирә. Мин еракта!

Ислам. Кайтып кара!

Расиха. Әйе! Кайт та кара!

Гөлчирә. Туктагыз әле, кычкырышмагыз!.. Минемчә, хәзер без бер генә нәрсәне уйларга тиеш. Без тугыз бала. Ләкин кайсыбызда әни өчен уңайлырак? Кайсыбыз берничә ай гомере калган әни өчен максималь удобстволар тудыра ала?

Максуд. Ислам! Өйләре зур! Бөтен шартлары бар! Хатын яшь, эшләми!

Ислам. Син дә эшләтмә хатыныңны!

Максуд. Акчам синеке хәтле булса, эшләтмәс идем дә бит...

Ислам. Ә син кеше акчасын санама!

Расиха. Әйе! Үз акчасы булмаган кеше кесәсендәгеи санар, ди. Дөп-дөрес!

Гөлчирә. Туктагыз әле! Кычкырышмагыз әле, зинһар, базар хатыннары шикелле!.. *(Исламга.)* Абый! Минемчә, әнине карау ул бик зур честь, дәрәҗә...

Ислам. Алай бик зур дәрәҗә булса, ал да кит үзең белән Ташкентка! Честы да, дәрәҗәсе дә үзеңә булыр!

Расиха. Әйе! Алып кит тә кара!

Гөлчирә *(бераз уйлап)*. Алып китәм. Алып китәм! *(Максудтан.)* Самолетта бара алыр микән?

Расиха. Ник бара алмасын!

Саймә. Әй, юк ла, шунда тиклем җибәрмибез инде аны!

Сәяр. Әни бармаячак.

Гөлчирә. Ни өчен?

Сәяр. Сәламәт чакта йөрмәгәнне, нишләп барсын инде ул шунда кадәр!

Максуд. Юк, Казаннан ары җибәрергә ярамый аны...

Саймә. Аның шунысы да бар бит әле, Гөлчирә. Бәлки ул авылга кайтарып җирләүне сорар, эти янына. Белмәгән бит әле аныкын.

Пауза.

Гөлчирә. Бөтен союзга таралган бит аның туганнары да!.. Инсаф абыйны санап булмый инде...

Максуд. Инсафның башы больницадан чыкмый. Әнә тагын Казан больницасында ята.

Гөлчирә. Нәрсә булган?

Максуд. Яралары ачылган! Тәнендә исән төше юк лабаса аның!

Ислам. Ә хатынына ни булган?

Расиха. Әйе! Ат хәтле хатынына ни булган?

Саймә. Әй, юкны сөйләп утырмасагыз ла, зинһар! Гомере буе авыру туганыгызны карау гына җитмәгән...

Гөлчирә. Дөрес! Инсаф абыйны санап булмый. Апалар еракта. Хафиз абый белән Таһир абыйны да санап булмый...

Расиха. Тегесен дә санап булмый, бусын да санап булмый, бер безне санап була! Ничава не знаю, бөтенесен дә санарга! Кайтып карасыннар, чиратлашып! Кайтмасалар — кеше яллап каратсыннар, акча түләп! Үзебезнең чират җиткәч, кемне дә булса без дә яллarбыз!

Гөлчирә. Акыллы сүз түгел, Расиха...

Расиха. Син генә бик акыллы!

Гөлчирә *(Исламга, ялварып диярлек)*. Абый! Әнине сез карарга тиеш!

Ислам. Ни өчен без? Ни өчен без? Сезнең карарга хәлегездән килмәгән өченме? Ярый ла мин хәзер Казанда! Ә кайтмаган булсам? Магаданский областьта калган булсам, нишләр идегез соң сез?

Гөлчирә. Менә мин дә шуны уйлап торам. Тормышларның иң авыр вакытында син ун ел төрмәдә утырдың. Сугыш вакыты, сугыштан соңгы еллар. Эти үлеп китте! Без биш бала әни кулында калдык! Ул чакта Сәярга ике яшь. Коточкыч еллар иде ул! Әни бер караңгыдан икенче караңгыга хәтле колхозда эшли, ә хезмәт көненә бер грамм бирмиләр! Әни коры сөяккә калды. Ачлыктан гына түгел, семьяга син китергән хурлыктан да! Ләкин ана — ана шул. Кайчакта ул берничә кадак он табып алып кайта да шул оннан икмәк пешерә

иде. Ох, ул икмәк! Ул икмәкнең исен мин әле хәзер дә онытмыйм. Хуш исеннән башлар әйләнә торган икмәк иде ул!.. Әни шул икмәктән сохари ясый иде дә сиңа җибәрә иде... Беләсеңме, әни синең өчен күпме яшь түкте? Хурлыктан урамга чыгарга оялган көннәре дә күп иде аның...

Ислам. Минем өчен хурланасы юк! Минем документларым чиста! Минем судимость снята!

Гөлчирә *(катгый).* Шулай абый! Язмыш синең кешелегеңне сынар өчен тагын бер имтихан куя. Теге вакытта абынгансың, инде дә абынма! Әйдә, машинаңа утыртабыз да алып кайтабыз әнине сиңа!

Саймә. Ислам, җаным, без квартир алганчы гына! Үзем килеп карашырмын!..

Ислам *(мескенләнеп).* Шәфкатьсез кешеләр сез! Йөрәксез кешеләр! Мин ничә ел төрмәдә утырдым, понимаешь. Төрмәдән чыккач, унбиш ел шахтада эшләдем! Якты кояшны күрмәдем! Инде, понимаешь, кайтып, бер кеше төсле яши генә башладым дигән идем — мә сиңа! Башка берәүләр булса, әйтерләр иде, абый, син инде болай да рәхәт тормыш күрмәдең, тынычлап яшә инде, диярләр иде!.. *(Үкереп елый башлый.)*

Расиха *(елап).* Тынычлан! Тынычлан!..

Гөлчирә. Ә кем гаепле? Кем гаепле синең рәхәт күрмәвеңә?

Зөләйха керә.

Расиха. Алып кайтмаска иде аны больницадан! Ник алып кайткан? Кем алып кайткан — әнә шул карасын!

Зөләйха. Оятсызлар! Өч ай гомере калган әниегезне карамас өчен талашасыз! Кеше гомере буе карый! Куалап чыгар үзләрен, Сәяр, тормасыннар монда ачу китереп!

Сәяр *(ишеккә бара башлаган Римманың юлын бүлеп).* Римма!

Римма. Болай булгач мин принципиально китәм!

Зөләйха. Әй, китсәң — китсәнә! Салып җибәрермен, китәрсең атылып! *(Ишекне ачып.)* Бар, кит! Инкубатор чыгарган кияү әзлә! *(Римма чыга.)* Мин карармын әниегезне! Мин эштә чакта карый торырга әнә туксан яшьлек карт бар. Гомерем буе авыру карадым, үлмәдем. Тагын бер карчыкны караганнан гына үлмәм әле!.. Тормагыз монда өелеп! Ярып чыгарганны көтәсезме әллә?

Расиха. Әйдә, Гөлчирә, кайтасыңмы?

Гөлчирә. Рәхмәт. Мин сезгә кайтмыйм.

Ислам белән Расиха чыгалар. Үз алдына җыр көйләп Әлмөхәммәт килеп керә.

Әлмөхәммәт.
Төркем-төркем куйлар бара,
Арасында чем-кара,
Егет, мескен, ни хәл итсен,
Кызлар чакыргач бара...

Саймә. Менә шушы ай ярымы бар аның. Ходай кушып, квартир алсак, берсенә дә бирмим мин аны, үзем карыйм!.. Максуд! Әллә горисполкомга барып карыйсыңмы, эшнең нәрсәдә икәнен сөйләп бирәсеңме?

Максуд. Безгә квартир салына торган йорттан бирелгән бит инде. Шул йорт өлгермичә булмаячак.

Әлмөхәммәт. Синең исеңдә микән, Зөләйха, үләргә өч көн калгач, әни мәрхүм, Зөлхиҗҗә чишмәсенең суын эчәсем килә, диде. Оренбур ягында безнең авыл янында шундый бер чишмә бар. Энем кайтып та киткән иде дә, алып килеп өлгертә алмады шул. Эчәрә

алмадык әнигә Зөлхиҗҗә чишмәсенең суын. Гомерлек үкенеч булып калды!..

Римма керә. Кухнядан нидер эзли башлый.

Сәяр *(катгый)*. Римма, дим! *(Чыга башлаган Римманың кулын тота.)*

Римма *(елап)*. Тотма мине, җибәр! *(Чыгып китә.)*

Гөлчирә. Алай ярамый бит инде, сеңелем!.. Сәяр, бар инде тизрәк артыннан!

Зөләйха. Барма! Утыр урыныңа! Юньле хатын булып чыкмады, китеп куркыта торган хатын булып чыкты. Акылы булса кайтыр. Утыр!

Пәрдә.

### ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Вакыйга шунда ук бара. Ана ике кулы белән тәрәзә төбенә тотынган хәлдә урамга карап тора, өстендә туйда кигән ак ефәк күлмәк. Әлмөхәммәт алгы планда намаз укый.

Ана. Быел кыш үзен иртә күрсәтә, бабай,— кар ява! Урам ап-ак булды!

Әлмөхәммәт. Ап-ак булып озак тормый ла ул. Бездә монда кар җиргә төшеп өлгерми, пычракка әйләнә. Авылдадыр инде ул чын кар.

Ана. Авылда кар күп! Узган кыш бер төн эчендә бөтен өемне күмеп китте, кичкә хәтле чыга да алмадым. Рәхмәт, кешеләр килеп казып чыгардылар... Почта ящигын карап кермәдеңме, бабай?

Әлмөхәммәт. Берәрсе кесәсенә салып киткән, ахры, ачкычын таба алмыйм... Син азрак ятып ал! Көне буе тәрәзә төбеннән китмисең — нәрсә күрәсеңдер аннан!

Ана. И, бабай, балаларымның берәрсе кайтып килмиме, дип карыйм!.. *(Көч-хәл белән, чайкала-чайкала креслога килеп утыра, Әлмөхәммәт аңа утырырга булыша.)*

Әлмөхәммәт. Тәрәзә төбенә хәтле кайтып җитсәләр, кире китмәсләр инде, алла теләсә, керерләр... Сәгать тә туктаган икән безнең, радиосы да эшләми — ни булгандыр... *(Урындыкка басып стенадагы сәгатьне боргалый.)* Сәгать ничәләр бар икән соң инде хәзер?

Ана. Дүрт тулып бишенче китте, бабай.

Әлмөхәммәт *(гаҗәпләнеп)*. Кайдан карап әйтәсең әле син аны?!

Ана. Сәгать минем эчемдә, бабай. Уколны вакытында ясамасаң, хәзер келтери башлый.

Әлмөхәммәт. Озаклады шул бүген Зөләйха... Нәрсә, авыртамы? Алай булгач, Зөләйхага әйтергә кирәк, иртәрәк чыгып салсын уколны. Укол салгач тынычланасың лабаса син, азрак йоклап та аласың. Чирен яшергән үлгән, ди. Тилмереп утыру ярамый, әйтү кирәк!.. Күрше йортта берәүләр аталарының елын уздыралар, корьән укырга чакыралар. Үзеңне генә калдырсам, куркып бетмәссең микән?

Ана. Нәрсәдән куркыйм! Ялгыз яшәп мин өйрәнгән инде, бабай.

Әлмөхәммәт. Үлгәч, аллаһы тәгалә каршысына барасылар булса, кирәге булып куяр, дим. Үләселәр бар бит әле! Хикмәт, син ул хакта бер дә әйтмисең.

Ана. Үлемнән курыкмыйм мин, бабай. Кыямәт көненнән дә курыкмыйм. Дөрес, намаз укулар күп эләкмәде. Яшь чакта яшь булын-

ды, үлем турында уйланмады. Аннары дөнья мәшәкате басты. Булдымыни соң безгә намазлар укып торырга вакыт, бабай? Шулай да үлемнән курыкмыйм. Дөрес яшәдем. Гөнаһ кылмадым, кешегә начарлык теләмәдем.

Ә л м ө х ә м м ә т. Ничек синеңчә, алла бармы икән?

А н а. Барып күреп кайтучы булмагач, кем белгән инде, бабай!

Ә л м ө х ә м м ә т. Шулай шул. Тегендә менеп очып йөрүчеләр дә күреп төшмәгәннәр. Гагариннарны әйтәм, Әндрияннарны... *(Тирән сулап.)* Адәм баласының гомере кыскарак шул! Аз да яшәмәдем кебек — исән булсам, быел яз туксанны тутырам. Шулай да гомер тиз узып китте. Сизми дә калдым!..

А н а. Дөрес! Мең дә бер кичә әкиятендәге кебек. Әле менә мин дә кичә генә бер ишектән кергән идем, инде икенчесеннән чыгар вакыт та җитте... Шулай булса да, мин үлгәндә ясин чык, бабай! Кешечә булсын!

Ә л м ө х ә м м ә т. Кайдан килде әле бу иске авыздан яңа сүз?!

А н а. Яңа түгел. Җыясы ризыгым күп калмады.

Ә л м ө х ә м м ә т. Чыкмаган җанда өмет бар! Кем белә, бәлкем терелеп китәрсең. Чайкама башыңны, чайкама! Терелерсең дә авылыңа кайтырсың. Ә мин, ходай боерган булса, сиңа кунакка барырмын. Сезнең якларда бер дә булганым юк минем. Матурмы сезнең яклар?

А н а *(кинәт җанланып)*. И, безнең якларның матурлыкларын сөйләп кенә бетерә торганмы соң, бабай! Ул Идел буйлары! Ул урманнары! Ул исәпсез-хисапсыз чишмәләре!.. И, бар иде яшь чакларым, бабай! Яшь идем. Таза идем! Ут идем! Йөрәгем бик зур иде шул минем, бабай. Кайчакларда өйгә генә сыеша алмыйча, бер йомышсыз, урманнарга чыгып китә торган идем. Тиле кеше шикелле иләсләнеп аланнарда йөрим. Ул аланнардагы мең төрле чәчәк исе, кошлар тавышы!.. Әле менә шушы хәлемдә дә күңелем белән әллә кайларга барып киләм. Көненә әллә ничә кат кызларым янына да барып кайтам, улларым янына да. Авылда да булып киләм. Күңел — канатлы кош, оча да китә. Аяклар гына йөрми!..

Ә л м ө х ә м м ә т. Йөрер әле, ходай боерган булса, йөрер! Үзең дә сизми калырсың йөреп киткәнеңне.

А н а. Үз хәлемне үзем генә беләм, бабай. Килеп җитә!

Ә л м ө х ә м м ә т. Сезнең як урманнарында чикләвек тә бармы?

А н а. Күп! Җыеп кына бетерә торган да түгел! *(Звонок.)* Кемдер килә! Сөйләшеп күрми калдым — кемдер килә! Тизрәк ач, бабай, Хафизым кайтып киләдер бәлкем!

*А л ь ф р е д керә.*

А л ь ф р е д. Исәнме, әби!

А н а. Яхшы, улым. Үзең нихәл?

А л ь ф р е д. Нормально!

Ә л м ө х ә м м ә т. Ярый, мин тегеләрнең бәлешләрен ашап чыгыйм әле. Тәмле булса, сиңа да алып чыгармын.

А н а. Хәерле юл, бабай!

*Әлмөхәммәт чыга.*

А л ь ф р е д *(кесәсеннән берничә конфет чыгарып куя)*. Мә, конфет аша, әби!

А н а. Мин конфет яратмыйм, улым, үзең аша! Эти-әниең тазасаумы?

А л ь ф р е д. Нормально!

А н а. Хафиз абыеңнан хат-хәбәр юкмы? *(Альфред иңбашын сикертеп куя.)* Үзең ни эш бетереп йөрисең?

А л ь ф р е д. Нормально! *(Машина тавышы, Ана торып тәрәзәгә бара башлый.)* Ул мин утырып килгән такси, әби!.. Әби! Синең бер биш сум акчаң юкмы? Әнә шул таксига түлисе бар иде.

А н а. Трамвайлар йөрмимени бүген?

А л ь ф р е д. Әй, ашыгыч булгач, такси алган идем шул. Беләсеңме, бер бик чибәр генә кыз бала бар, әби. Сәгать алтыда киногa барырга булган идек. Синең янга да килеп өлгерәсе бар!.. Утыруын утырган идем дә, инде менә төшеп калып булмый — түләргә акча юк. Акча кошелегем өйдә онытылып калган! *(Ана мендәр астыннан төенчек алып чишә башлый.)* Ну, хәлләр ничек соң, әби, терeләсеңме инде?

Звонок

А н а *(төенчеген учына яшереп ишеккә күрсәтә)*. Улым!

А л ь ф р е д. Әби, дим!

А н а. Бар инде, тизрәк ач, улым! Хафиз абыең кайтып килмиме.

Альфред ишек ача. И н с а ф керә. Кулында гади генә сумка. Ана белән кочаклашып исәнләшә.

А н а *(Инсафка урындык этәреп)*. Утыр! Утыр, улым, утыр!.. Озак яттың ла инде, улым, бальниста!

И н с а ф. Туеп беттем, әни, үзем дә! *(Сумкасыннан берничә ак хризантема чыгарып Анага суза.)* Менә, әни! Син чәчәк яратасың бит, чәчәк алып килдем әле сиңа...

А н а. И, салкын тидермичә кайларда гына саклаганнар!

А л ь ф р е д. Бу безнең як чәчәкләре түгел, әби! Моны грузиннар китереп сата, Кавказдан!

А н а *(иснәп)*. Әрем исе килә! *(Гаять дәрәҗәдә гаҗәпләнеп чәчәкләрне Инсафка суза, тагын исни.)* Әрем исе килә! *(Бик кадерле нәрсә кебек итеп тотып, йотыла-йотыла чәчәкләрне исни.)* Үзебезнең яклар исе!.. *(Кинәт күңеле тула, башкаларга сиздермичә генә күз яшьләрен сөртеп ала. Альфредка.)* Улым, берәр савытка су салып кертсәнә! *(Альфред чыга.)* Рәхмәт сиңа, улым!

И н с а ф. Я, нихәл соң инде, әни, терелмисеңме әле?

А н а. Зыянлы түгел, улым, зыянлы түгел!.. *(Альфред сулы ваза күтәреп керә.)* Сәярнең хатынын практикага җибәрделәр! Яңа елсыз кайтып булмас, дип яза инде ул!.. *(Чәчәкләрне суга утырта.)*

А л ь ф р е д. Кемне — Римманымы?!

А н а. Әйе!

А л ь ф р е д. Син нәрсә, әби, Римманы мин әле генә капка төбендә күрдем!

А н а *(бәхәсләшергә урын калдырмаучы тон белән)*. Син башка берәр кешене күргәнсең! Римма Казанда юк ул, Римма практикада! *(Инсафка.)* Өеңә кайчан китәсең соң инде, улым?

И н с а ф. Азрак кибетләрдә йөреп кирәк-яракны алырмын да, кайтырмын инде, әни. Бик озакка китте бит, югыйсә, өч ай тула! *(Альфредка.)* Ну, синең эшләр ничегрәк соң әле, егет? Миңа акча кирәк булыр бит.

А н а *(Альфредның аптырап калуын күреп)*. Нәрсә, синнән дә алып тормагандыр бит?

И н с а ф. Әллә синнән дә сорыймы?!

А н а. Таксига түлисе бар, ди бит!

И н с а ф. Акчасы булмагач, таксига утырмасын! Минем кырык җидегә җитеп тә таксига утырып караганым юк, агач аякларым белән дә!

А л ь ф р е д. Юк, болай килеп чыкты ул, Инсаф абый...

И н с а ф. Эшкә кердеңме әле?

А л ь ф р е д. Менә эш эзләп йөрим шул!

И н с а ф. Таба алмыйсыңмы? Казан хәтле Казанда сиңа яраулы эш юкмы? Әнә анда урамга чык та кара — почмак саен язып куелган. Мең җиргә кирәк кеше!

А л ь ф р е д. Аз түлиләр!

И н с а ф. Тик яткан өчен күп түлиләрме соң? Болай хөрәсән ялкавы булып йөрсәң, картайгач пенсияң дә булмас әле синең. Атаң белән анаң да булмас ул вакыт сине ашатып ятарга!

А л ь ф р е д. Мин картайганчы әллә нинди законнар чыгар әле!

И н с а ф. Чыкты, ди, көтеп тор! Эшләмәгән кешегә беркайчан да почет булмаячак аңа!

А н а. Шушындый баһадир хәтле гәүдәң белән эшләми йөрисеңме, улым?! Көнеңне ничек уздырасың соң син? Әле менә мин булып мин тик ятканга күрә көнемне уздыра алмыйча аптырыйм!

А л ь ф р е д. Хәзер яшьләр сезнең кебек түгел шул, әби. Без башкачарак яшәргә яратабыз.

А н а. Ничек яратасыз?

А л ь ф р е д. Ну, ничек дип аңлатыйм инде сиңа...

И н с а ф. Синең кебекләр әнә тегендә очып йөриләр. Космоста!

А н а. Күңел ачуны һәркем ярата аны, әмма күңел ачып булсын өчен эшләү кирәк. Кешедән алып торган биш тәңкә белән генә ерак китеп булмый... *(Төенчеген чишеп Альфредка акча бирә башлый.)*

И н с а ф. Бирмә, әни, син аңа! Бирмә!

А н а. Бирә алмыйм шул, улым, рәнҗемә. Ашарыңа булмаса бирер идем, таксига бирмим. Йөрмә болай җан көеге булып, эшкә кер! *(Инсафка күрсәтмичә генә Альфредка акча төртә.)*

А л ь ф р е д *(акчаны тиз генә яшереп)*. Сау булыгыз! *(Чыга.)*

А н а. Кемгә генә охшап мондый буш чәчәк булып үскән бу бала? Әтисе дә кечкенәдән эш яратып үсте, олы бала булгач, эшнең иң авыры аңа эләкте...

И н с а ф. Эх! Моңарда булган саулык миндә булса!

А н а. Терелтеп чыгардыларммы соң инде, улым?

И н с а ф. Азрак ремонтлаган булдылар, әни, тагын күпмегә җитәр. Йөрергә ярамый миңа, әни. Аз гына йөрдең исә, протез астыннан тишелә дә чыга. Йөрмичә дә булмый — яшисе бар.

А н а. Килennән хат бармы?

И н с а ф. Бар, әни! Исән-саулар. Минем балалар әйбәт, әни! Кыз сәгать заводында эшли, кичке техникумда да укып йөри. Илдус быел унны бетерә, инженер булам, ди. Исән булсам, укытырга исәп. Балалар үсеп бетте инде, әни! Кечкенәсе дә быел алтынчыга керде!

А н а. Үзең һаман шул эшеңдә эшлисеңме?

И н с а ф. Шунда, әни. Фотолабораториядә.

А н а. Эшең әйбәт синең үзеңнең, җиңел!

И н с а ф. Әй, төкерим лә мин аның җиңеллегенә, әни!.. Авыр булсын иде ул! Сөякләрне шытырдатып, җиде кат тиргә манчый торган эш булсын да, ир-егеткә лаек эш булсын иде! Иртәдән кичкә кадәр баз шикелле караңгы бүлмәдә проявительгә фото-кагазь тутырып утырасың. Шул кәгазьләрдә кемнәрнеңдер йөзләре килеп чыкканны көтәсең. Бүген дә шулай, иртәгә дә шулай, бер елдан соң да шулай. Гомер буе шулай!.. Шул турыда хыялланган идеммени соң мин, әни! Саулыгым булса, әнә тегендә очып йөрисе кеше идем бит мин!.. Самолет тавышын ишетә алмыйм. Ишетсәм — бөтен йөрәкләрем әллә нишли башлый!.. *(Җирәнү белән тагын атып бәрә, егылып китмәс өчен стенага тотына.)* Туналмаган җирең калмагач, минем хәлне сорама инде син, әни! Тәнемне кеше күрүдән куркып, су коенырга да төшмим бит мин — оят чөнки!

Ана. Ә син оялма! Ватан өчен сугышканда алган гариплек — хурлык түгел ул, балам! Күкрәгеңдә орденнарың, йөрәгеңдә намусың — нәрсәдән ояласың! Башыңны югары тот, улым! Син минем йөз аклыгым! Горурлыгым син минем! *(Инсафның таягын алып бирә. Артта аяк тавышлары.)* Кемдер килә! Тынычлан, улым!

Максуд белән Саймә керә.

Үзегез генәме? Кайтучылар юкмы?

Саймә. Шушы көннәрдә Мәйсәрә кайтып төшәргә тиеш, әни! Отпускымны алам да бер айга әни янына кайтам, дип язган!

Ана. Хафиз турында хәбәрегез юкмы, дип соравым минем! Сәяр телефонга чакырам, дип киткән иде, кайтмый да кайтмый...

Саймә. Тоташтыра алмыйлардыр, әни, ерак җир бит... Хафиз өчен син борчылма, әни! Менә күрерсең, погоннарын елкылдатып кайтыр да төшәр, алла боерса! *(Инсафка.)* Син чыктыңмыни?

Максуд *(кесәсеннән кәгазь чыгарып).* Әни, безгә яңа квартирга ордер бирделәр! Иртәгә күченәбез! Берничә көннән сине үзебезгә алып китәбез, әни!

Ана. Барып күрдегезме соң әле, әйбәтме?

Саймә. Яман да әйбәт квартир, әни, искиткеч! Ике бүлмәле, тәрәзәләре кояшка карап тора! Инде сине үзебезгә алып китәбез, әни! *(Сумкасыннан целлофан капчык чыгарып.)* Әни, менә ашарсың, сиңа кош теле китердем. Сары майда гына пешердем, бик тәмле булды!.. *(Сумкасыннан ап-ак ефәк яулык чыгарып Ананың башына каплый.)* Менә монысы, әни, сиңа туган көн бүләге!

Ана. Туган көн бүләге? Кемнең туган көне соң бүген?

Саймә. Синеке, әни, бүген синең туган көнең!

Ана. Үзем дә белмәгән туган көнен кайдан белдең әле син аны?

Саймә. Белдек шул менә, әни!

Максуд. Исеңдә юкмыни, әни? Әби сине урысларның Пукрау бәйрәме көнне таптым, дип сөйли торган иде. Бүген Пукрау көне! Шулай булгач, синең туган көнең була бит инде!

Саймә. Әйе! Бүген синең туган көнең, әни! Бу сиңа туган көн бүләге!

Ана. Рәхмәт, кызым! Кул-аягың сызлаусыз булсын!

Саймә. Башыңда тузсын, әни-җаным! *(Ананың чәчләрен төзәткәләп.)* Әле нигә бу ак ефәк кулмәгеңне киеп куйдың, әни, туган көн икәнен белдең мәллә?

Ана. Юк! Әүвәл-әүвәлдән туган көннәрен үткәреш булмагач, уйлаган да юк инде аны, кызым. Юк иде бит ул безнең заманда. Болай гына кигән идем, берәрсе кайтып килсә, дип...

Саймә *(Ананың башына үзе алып килгән яулыкны бәйләп).* Максуд! Инсаф! Күрәсезме, әни нинди матур булып китте! Ак төс бик килешә сиңа, әни!

Ана *(Саймәнең соңгы сүзеннән сагаеп, ләкин аны-моны сиздермичә).* Алты килен арасында синнән тәмлерәк теллесе юк, рәхмәт, кызым. Шулай да беркөн бер авыр сүз ычкындырдың.

Саймә. Минме, әни? Кайчан?

Ана. Гөлчирә кайткан көнне. Тәмле ризыкны ирләргә бирергә ярамый, алар аның тәмен белеп ашамый, дидең.

Саймә. Шаярып әйткән сүз ич ул, әни!

Ана *(Саймәнең кулын кысып).* Улымны тамактан аерма!

Саймә. Мәзәк итеп сөйләшкән сүз ич ул, әни! Безнең Максуд авызыңнан тартып алып ашый ул. Әнә ич авызын ерып тора!

Ана *(Максудның башыннан сыйпап).* Кечкенәдән тәмлене яратучан булып үсте шул ул. Кайчак әтисе сорый торган иде. Улым, нигә бу хәтле тәмлене яратасың, тәмле ашап ни була? — ди торган иде.

Авызга рәхәт була, ди торган иде Максуд. Ул конфеттыр, җимештер кебек нәрсәне тотмады инде. Кая гына яшерсәм дә эзләп табар иде!

С а й м ә. Хәзер дә шулай ул, әни! Эзләп тә таба, ашап та куя!

А н а. Яшергән урыннан тапкач, әйтә торган иде тагын үзе. Әни, фәлән җиргә яшергән фәлән нәрсәңне эзләп таптым. Инде икенче җиргә алып яшер, югыйсә, чыдап тора алмыйм, ашап бетерәм, ди торган иде.

С а й м ә. Һай, җаным, ни гомердән бирле шуларны онытмыйсың син, әни! Бутамыйсың да тагын! Бик күп булганнар бит алар, унау булганнар!

А н а. Унысы ун төрле шул аларның.

С а й м ә. Ул бер көтү баланы ничек үстереп бетердең икән син, әни? Безнең монда берсе белән дә башлар катып бетә. Ун баланың унысын да кеше иткәнсең бит, һай, җаным!

А н а *(тирән сулап)*. Унысын да булмады шул, кызым!

С а й м ә. Кемне әйтәсең, әни? Исламнымы?.. И, әни, үз балаң булгач, нинди генә булса да яратыладыр күк ул миңа. Менә безнең Альфред. Чукынган малай, кайчак шул хәтле ачуларымны китерә, әни! — барыбер яратам шуны. Әллә балаларың күп булгач башкачамы ул, әни?

А н а. Әй, кызым! Менә ун бармак — кайсын гына тешләсәң дә авырта!..

Посылка күтәреп С ә я р керә.

Сөйләштеңме абыең белән?

С ә я р. Әһе!

А н а. Соң?

С ә я р. Хафиз абый өйдә юк, Халисә җиңги белән сөйләштем... Менә, әни, Рәшидә апа сиңа посылка җибәргән!

А н а. Күземә кара әле! *(Сәяр Ананың сынаулы карашын күтәрә алмыйча, күзләрен читкә бора.)* Алдашасың!

С ә я р. Юк, әни!

А н а. Алдашасың! Әйт дөресен! Ни булган абыеңа? Авырыймы?.. Әллә яралаганнармы?.. Үтергәннәр!

С ә я р. Юк, әни!

А н а. Үтергәннәр! Үтергәннәр! Харап кына иткәннәр икән бәбекәчемне!..

С ә я р. Әни, сөйләп бетергәнне көт!

А н а. Үтергәннәр! Күңелем сизгән иде! Бальниста чакта ук күңелем сизгән иде!..

С ә я р. Хафиз абый исән-сау, әни!

А н а. Алайса, нигә күземә туры карый алмыйсың? Ни булган абыеңа?

С ә я р. Берни дә булмаган!

А н а. Икмәк белән ант ит! Хафиз абый исән-сау, диген!

С ә я р *(беравык икеләнеп торганнан соң)*. Ялганласам, икмәкнең чыраен күрмим, Хафиз абый исән! Командировкага җибәргәннәр аны.

А н а. Командировкада гына булгач, нигә хаты юк?

И н с а ф. Армиядә дисциплина каты, әни...

А н а. Сөйләмәгез! Ул инде үнике ел армия хезмәтендә, ун көннән ун көнгә хаты килмичә бер генә тапкыр да калмады!

И н с а ф. Армиядә төрле чак була, әни!

М а к с у д. Сәдәп кадарга да вакыт булмый, әни, анда кайчак!

А н а *(азрак үзен кулга алып)*. Ерак җибәргәннәрме?

С ә я р. Ерак. Чит илгә!

А н а. Озаккамы?

С ә я р. Бер... биш айга!

А н а *(өметен җуеп).* Биш ай!..

С а й м ә. Биш ай, дип, биш ай күп түгел инде ул, әни, хәзер үтә дә китә... *(Сәяр алып кайткан посылканы караган булып.)* Һай, җаным, нинди бәхетле карчык син, әни! Посылканы яудырып кына торалар бит үзеңә!

А н а. Берни ашый алмаган әниләрен посылка белән күмделәр, үзләре кайтмыйлар!

С а й м ә. Кайтмыйлар, дип, әни-җаным, җае чыкмый торгандыр...

А н а. Мин аларга бөтен гомеремне бирдем. Алар әниләре өчен бер көннәрен кызганалар!..

Ислам, Расиха, Рәйхан керә. Рәйханның өстендә мәктәп формасы. Исәнләшү.

А н а *(Рәйханны кулы белән чакырып).* Кил, кызым!

Р а с и х а *(Анага таба бара башлаган Рәйханны тотып).* Юк-юк, әбисе, Рәйханга синең янга барырга ярамый! Грипп булган Рәйханга! Әбисенә грипп иярер, дип курка ул! Шулай бит, кызым?

А н а. Грипп булгач, баланы урамга алып чыгасың калмаган. *(Сәяргә.)* Улым, азрак су агызып кертсәнә! *(Сәяр чыга.)*

Р а с и х а. И, әллә әнигә коры су эчерәләр инде?! Кем инде авыру кешегә коры су эчерә! Варенье болгатып бирергә кирәк! Менә бит кара карлыган вареньесы алып килдем, витамин гына! *(Сумкасыннан бер банка варенье чыгарып өстәлгә куя. Сәяр су алып керә.)*

А н а. Кирәкми, кирәкми, шул көе генә эчәм!

Р а с и х а *(йөткергәләп).* Үзем дә йөткерәм, нинди бетмәс грипп булгандыр инде бу!..

М а к с у д *(Расиха алып килгән банканы карап).* Да, витамин күп инде монда — алтмыш бишенче елгы урожайдан ясалган, сигез ел тому назад!

А н а *(су эчеп).* Рәхмәт! *(Расиханың Рәйханга сугып җибәрүен күреп.)* Әллә балага суктың инде, Расиха?

Р а с и х а. Сүз тыңламый, әни, үләм инде мин бу бала белән! Әбисе иркәләп бозып бетергән! *(Рәйханга тагын бер сугып җибәрә.)* Җитте, диләр сиңа! *(Рәйхан кычкырып елый башлый.)*

А н а. Йодрык хәтле балага сугарга ничек кулың бара синең?!

И с л а м. Суксын, суксын, әни! Бик иркәли башласаң, әнә абыйларның Альфреды кебек була ул аннары!

С а й м ә. Ник, ни булган безнең Альфредка?

И с л а м. Булмаган! Миннән биш сум акча сорап кергән, таксига түлисе бар, ди. Ничә сәгать инде малаегыз таксидан төшеп китә алмыйча Казан буйлап чаба, хы-хы-хы!

Р а с и х а. Хә-хә-хә!

С а й м ә. Бирдеңме соң?

И с л а м. Нишләп бирим!

С а й м ә. Котың очкан икән, мескен! Биш сумыңны алып Казаннан чыгып качар, дип курыккансың шул! Бурычка сорау гаеп түгел ул, кеше кесәсенә генә кермәсен!

И с л а м. Сорап-сорап та таба алмаса, кеше кесәсенә керә башлый инде ул!

С а й м ә. Шуның шулай икәнен дә белгәч, нигә биш сумыңны кызгандың соң?

И с л а м. Йөрмәсен дуңгыз дагалап! Аңа бит утыз тулган!

С а й м ә. Тулса! Утызны тутырып, законга сыймаслык эш эшләгәне юк ич әле аның! Син үзеңне бел! Утыз яшьтә чагында кайларда булганыңны онытгыңмыни?

А н а. Кызым!

Максуд. Барып чыкмады, әни, безнең малай! Институтка кереп укый алмады. Утыз ике яшькә җитеп юньләп эшләгәне дә юк. Бер-ике генә атна эшли дә ташлый, бер-ике генә атна эшли дә ташлый. Хатыны куалап чыгарды, алимент түләп тора!

Ислам. Хы-хы-хы! Алимент түләп торабыз, диген син, абый! Аны бит Альфред түләми, Саймә белән син түлисең! *(Анага.)* Милиция килеп эшкә керергә кушкач, Альфредны дворник итеп урнаштырган булганнар, әни! Ә Альфред себерми ишек алдын, эшкә киткәнче абый белән Саймә себереп китә. Менә шул акчадан Альфредның малаена алимент тотып калалар инде, хы-хы-хы!

Расиха. Хә-хә-хә!

Саймә. Бик килешә инде, о! Балалы кешегә кеше баласыннан көлү ярамый ул. Әнә үзегезнеке үсә, аның кем буласын белгән юк әле! Шулай түгелме, әни?

Ана. И, кызым, ана кешенең күңеле бик күпне сыйдыра. Кайчак балаңны ярамас эш өстендә тоткач та тизрәк итәгең белән каплыйсың, кеше-кара күрмәсен, дисең. Тик кайчак балалар итәк астына гына сыйдырып булмаслык эшләр дә эшләп ташлыйлар.

Максуд. Әнисе яклап бозып бетерде, әни, Альфредны!

Саймә. Бер дә бозмаган! Бер дә бозмаган! Аңа карап кына бозылмый ул бала! *(Елый-елый.)* Тик кенә торыгыз! Үзем дә беләм ич мин, сездән башка да!.. Аның бит башында бер уе бар!

Ислам. Хы-хы-хы!

Расиха. Уе бар! Хә-хә-хә!

Саймә *(тәмам чыгырыннан чыгып).* Һай, җаным, менә сине кем бозды икән! Сугышның беренче көнендә дүрт туган повестка алдыгыз. Абыең белән ике энең китте, Закир әнә әйләнеп тә кайтмады, ә син сугышка бармыйча качып ятkансың! Кем өйрәтте соң сине шуны эшләргә? Әниме?!

Ана *(битен куллары белән каплап).* Аһ!..

Сәяр *(Ананы кочаклап).* Кухняга чыгып талашыгыз, әнә тегендә! *(Максуд, Саймә, Ислам, Расиха, Рәйхан кухня ягына узалар. Аларга Инсаф иярә. Пауза.)* Мин тәмәке тартуны ташладым бит, әни!.. Исеңдәме килеп төшкән көнең? Син минем улларым аракы да эчми, тәмәке дә тартмый, дип мактанып торганда, Саймә җиңги «Сәярның тарта!» дип кычкырды. Шул сүзне ишеткәч синең йөзең куырылып китте, әни. Һәм мин аңладым. Ана кеше өчен балаларының тәүфыйклы булуыннан да зуррак мактаныч юк икәнлеген аңладым. Шул көннән бирле минем тәмәке тартканым юк, әни, ташладым! Шул вакытта сине уңайсыз хәлдә калдырган өчен гафу ит мине, әни, кичер! Икенче мин һичкайчан синең йөзеңә кызыллык китермәм! Кичер!..

Ана *(Сәярны күкрәгенә кысып).* Балам ла соң инде минем!..

Сәхнә әйләнә. Зөләйха квартирасының кухнясы.

Инсаф. Кешедән оят! Тугыз баласы була торып, әни кеше өендә үлеп ята! Бөлүдән курыксагыз, түләгән булыр идек үзегезгә, акчалата!

Ислам. Төкерәм мин сезнең акчагызга! Акча минем үземдә дә менә моннан! *(Муенын күрсәтә.)* Теләсәм, мин әнине үлгәч каберrouteә куймыйча, акча белән күмеп куя алам!

Саймә. Һай, җаным, акча да акча, дип үлде бит шушы бәндә! Акчадан кыйммәтлерәк нәрсәләр дә бар бит бу дөньяда!

Ислам. Нәрсә ул акчадан кыйммәт нәрсә?

Саймә. Әнә әни!

Инсаф. Бик күп ул акчадан кыйммәт нәрсә, аны син генә белмисең.

Саймә. Тәре урынына куеп чукына бит шул акчага, нишләп буладыр аның белән?

Ислам. Акча беләнме? Акча белән барысын да эшләп була, аны без бик яхшы беләбез!

Саймә. Булса! Терелт минә әнине, нигә терелтмисең? Терелт тә, бер егерме яшькә яшьрәк ясап куй!

Максуд. Менә әни рәнҗеп үлсә, әзләп кара син үзеңнең акчаңа әнинең хәер-фатихасын — табарсыңмы икән!

Ислам. Сез минем өчен борчылмагыз! Әни миңа фатиха бирәчәк. Соңгы елларда, понимаешь, аңа миннән дә күп акча җибәреп торган кеше булмады. Менә мин төрмәдән чыккач унбиш ел шахтада эшләдем. Шул унбиш ел эчендә син, абый, әнигә күпме акча җибәрдең?

Саймә. Тагын акча!

Ислам. Күпме җибәрдең?

Максуд. Санамадым.

Ислам. Ничә посылка салдың?

Максуд. Анысын да санамадым.

Ислам. Былтыр Рәйханны алырга кайткач, карап йөрдем мин анда. Лапаста посылка ящиклары аунап ята. Күбесе, понимаешь, Магаданнан мин салган посылкалар!

Максуд. Без якын торабыз, үзебез еш кайттык.

Ислам. Анысын булдырасыз! Кайтып әнинең итләрен, бәрәңгеләрен төяп килергә сезне куш! *(Инсафка.)* Ә син, герой, күпме җибәрдең?

Инсаф. Санап бармадым.

Ислам. Ә менә мин санап бардым! *(Кесәсеннән бер төргәк почта квитанцияләре чыгара.)* Менә! Менә болар бөтенесе соңгы унбиш ел эчендә әнигә мин салган посылкалар һәм акчалар. Менә, ай саен унбишәр, егермешәр сум салып барылган!

Саймә. Барсаң! Рәйханны әнигә кайтарып атканда сигез ай да тулмаган иде, әни шуны алты яшькә тиклем тәрбияләп үстерде. Бала караучы нәнкеләргә аена алтмышар сум түлиләр. Җибәреп бардыңмы соң әнигә алтмышар сум?

Инсаф. Әнигә язган хатларыңны да санап барасың калган. Аларның да бит һәркайсына дүртәр тиенлек марка киткән!

Саймә. Җитте! Туктатыгыз акча турында сөйләшүне, башыма капты!

Максуд *(Расиханың Рәйханга шап иттереп сугуын күреп).* Нишләп көйсезләнә соң шул бала?

Расиха. Әби янына керәм, дип аптырата! Кереп, әбинең башыннан гына сөеп чыгыйм әле, ди!

Саймә. Керсен!

Расиха. Кермәсен!

Саймә. Һай, җаным, бала әбисе янына керим, дип тилмерә, әбинең башыннан гына сөяр идем, дип — шуны кертмиләр! *(Расихага.)* Йогышлы авыру түгел ич ул, нигә котыгыз чыкты!?

Расиха. Йогышлымы-түгелме — белгән кеше юк, врачлар үзләре дә белми! Саклану зыян итми, Саймә апа!.. *(Рәйханга.)* Бар, әнә урамга чыгып уйный тор, кайтышлый кычкырырбыз! Кара аны, әбиең янына керәсе булма! *(Рәйханны төрткәләп чыгарып җибәрә.)*

Максуд *(Инсафтан).* Син Казанда озак буласыңмы әле?

Инсаф. Министр янына керәсе бар әле, коляска алып булмый.

Максуд. Синең коляскаң бар лабаса!

Инсаф. Ватылып бетте инде ул! Яңасын сорап язган идем дә, чират җитми.

Ислам. Ничек инде чират җитми, понимаешь! Ватан сугышы инвалидларына почет зур лабаса аларга, хы-хы-хы!.. Әле менә гараж түбәсен капларга калай кирәк булды. Бер җирдә юк калай! Шуннан, военторгка кереп, биш-алты орден колодкасы сатып алдым да, күкрәккә кадап, киттем райсобеска. Хы-хы-хы! Анда бер яшь кенә малай утыра икән. Бер кулны менә болай асылындырып барып кердем мин моның янына. Алдына пенсия книжкесен чыгарып салдым. Анда язылган инде, аена йөз егерме сум пенсия ала, дип. Шуннан бу бер минем кулга, бер орден колодкаларына, бер книжкегә карап торды торды да, заявлениема кул куеп, базага җибәрде. Мине сугыштан кайткан берәр полковник дип уйлады бугай. Хы-хы-хы!

Расиха. Хә-хә-хә!

Максуд. Андыйга син оста!

Ислам. Яши беләм!

Сайм ә. Кайда соң бу дөньяда справедливость?! Менә син, Инсаф, сугышның башыннан ахырына кадәр йөреп, ике аягыңны өздереп кайттың — инвалид машинасы ала алмый йөрисең. Ә сугышка бармыйча дезертир булып йөргән кеше «Волга» мшинасына утырып әйттерә!

Ислам. Справедливость? Тапкан сөйләргә сүз — справедливость! Юк ул справедливость, эзләмәгез сез аны! Менә син ничә яшьтә инде абый? Илле өчтәме? Пенсияга чыкканчы тагын җиде ел бөкреңне үстереп эшлисең бар икән әле. Күпме булачак инде синең пенсияң?

Максуд. Күпме булса да үземнеке булачак!

Ислам. Җитмеш сумнармы? Ул җитмеш сумны сиңа әле җиде ел эшләгәч кенә бирәчәкләр. Ә үзең сугышта булдың! Мин бармадым сугышка, шуның өчен төрмәдә утырдым. Төрмәдән чыккач унбиш ел шахтада эшләдем дә горняцкий стаж белән илле яшьтән пенсияга чыктым. Үзем шул унбиш ел эчендә бер мәртәбә дә шахтага төшеп карамадым! Хәзер менә аена йөз егерме сум пенсияны алып, түшәмгә төкереп ятам, понимаешь! Менә сиңа справедливость! Юк ул справедливость! Эзләмәгез сез аны!

Инсаф. Нигә булмасын — бар ул справедливость.

Ислам. Бар, хәзер китереп тоттыралар сиңа! Көтеп утыр әле син аны, ә мин ул арада яшәп калам!

Инсаф. Ә мин әйтәм, бар ул справедливость! *(Көч белән Исламга китереп суга.)* Менә ул справедливость! *(Тагын суга.)* Менә ул справедливость, гад!.. *(Ислам идәнгә ава. Инсафны Максуд белән Саймә килеп тота.)* Бөтен ил, бөтен халык ил өстенә ташланган дошман белән сугышканда дезертир булып йөрүең генә җитмәгән, әле син без фронтовиклардан көлеп маташасыңмыни? Без анда илнең бер карышы өчен кан коеп йөргәндә, син монда нәрсә уйлап яттың? Син бит, сволочь, безнең җиңелүне теләп яткансың!

Ислам *(чигенә-чигенә)*. Син кара, авызыңны үлчәп ач!..

Инсаф. Ә нәрсә? Дошманны тизрәк җиңеп, үзеңне кулга алуны көттем, дияр идең мәллә? Юк, син безнең җиңелүне теләп яткансың! Шулай булмаса үзеңә көн булмаячагын аңларлык кына синдә баш бар! Әгәр дошман Казанга килеп җитсә, син бит фашист ялчысы булачак кеше идең, падла!

Ислам. Әйтәм ләбаса, танавыңны чамалабрак ач, дип. Минем судимость снята! Минем документларым чиста! *(Кесәсеннән кәгазь чыгарып.)* Менә күрәсеңме? Укы да танавыңны үлчәп ач! Юкса, мин сине бу сүзләрең өчен җавапка тарттырырга да күп алмам!

Инсаф *(Исламның кәгазен ертып)*. Тарттырып кара! Тарттырып кара мине җавапка!

Ислам *(идәндәге кәгазь кисәкләренә ташланып).* Минем судимость снята дип яздырып алган справкамны ертты! Үтерәм бит мин сине моның өчен, галах!

Максуд. Кычкырма, әни ишетер!

Расиха. Кычкырсын, кычкырсын! Аңа врач шулай кушкан! Ачуың килгәндә ачуыңны чыгарып бетер, шулай итмәсәң, ачуың чуан булып бөтен тәнеңә тарала, дигән! Кычкыр, кычкыр!

Ислам. Үтерәм! Валлаһи, үтерәм мин син галахны!

Инсаф. Әтәчләнмә! Син мине үтерә алмыйсың! Мине үтерсәң, синең үзеңә үлем җәзасы булачак бит, ә син моннан куркасың! Ох, ничек куркасың син үлемнән! Сугышта үлүдән куркып, үзеңнең менә моның хәтле җаныңны саклап калу өчен Ватанны саткан сволочь бит син!

Сәяр керә.

Максуд. Безнең тавыш әнигә ишетелмиме анда?

Сәяр. Әни йокыга китте... Бүген мин Халисә җиңги белән сөйләштем. Сугышчан заданиены үтәгән вакытта Хафиз абый һәлак булган...

Сәхнә әйләнә башлый. Залда Рәйхан күренә. Ул курка-курка артына карангалап, Ана яткан бүлмәгә таба бара. Безнең алда Ана яткан бүлмә. Рәйхан керә. Ул акрын гына Ана янына килә дә тиз генә Ананың башыннан сөеп ала. Йөгереп ишеккә бара, ишекне ачып кухнядагы тавышларга колак салып тора. Яңадан Ана янына килә, яңадан Ананы сөя башлый. Ана күзләрен ача, Рәйхан тиз генә читкә йөгерә.

Ана. Кызымны төшемдә күрәм дип торам, өнем икән ләбаса! Ник анда качтың, кызым? Кил яныма! Кил инде, бер сөйим әле үзеңне!

Рәйхан. Синең янга барырга ярамый!

Ана. Ник?

Рәйхан. Синдә рак бар!

Ана. Нәрсә? Нәрсә бар?

Рәйхан. Рак бар!

Ана. Кем әйтте?

Рәйхан. Әти әйтте. Әни дә әйтте. Әбиең янына барсаң, үләсең, диделәр. Син биргән әйберне дә ашарга ярамый.

Ана *(үзен кулга алып).* Миндә рак юк, кызым! Әтиең сиңа дөрес әйтмәгән. Дөрес әйтмәгән сиңа әтиең! Кил!

Рәйхан *(кулларын җәеп йөгерә-йөгерә).* Әбием, алайса син үлмисең! *(Ананың итәгенә сикереп менеп, муенына урала.)*

Ана. Үләм, кызым!

Рәйхан. Үлмисең, әбием, үлмисең! Терeләсең! Миңа Саймә апа әйтте! Терeләсең, әбием! Терелгәч бергә авылга кайтабыз!..

Расиха йөгереп керә.

Расиха. Рәйхан! *(Йөгереп Рәйхан янына килә башлый, ләкин Ананың Рәйханны күтәреп тора башлавын күреп, коты чыгып кире йөгерә.)* Ислам! Ислам! Кер әле тизрәк, Ислам!..

Бүлмәгә Ислам, Максуд, Саймә, Сәяр һәм Инсаф керәләр.

Расиха. Нәрсә карап каттың — ал инде тизрәк баланы!

Ана *(Рәйханны күтәргән килеш).* Минем йогышлы авыруым юк, мин врачтан сорап чыктым. Артыграк кыланасыз.

Расиха. И, әни, карт кешедә йогышлы авыру булса да гаеп түгел инде. Сакланганны саклармын, дип әйткән, ди бит алла да. Шуңа дип инде Рәйханны синең янга җибәрмәвебез иде. Бала җәл бит!..

А н а. Бала җәл була шул ул!.. Егерме беренче елның көзендә балалар арасында тамак чире чыкты, минем дә бер балама йокты. Укымаган дога, ясатмаган им-том калмады. Бу бала кеше булачак түгел, кәфенлек әзерлә, диде абыстай. Килешмәдем. Эт тә чыкмаслык бер кичтә баламны төреп күтәрдем дә авылдан илле чакрымдагы Тәтеш бальнисына киттем. Мин барып җиткәнче таң атты. Бальниска барып керсәм — бөтен бальнисларына бер сестра. Күп-күмгәк булган баламны ачып кына карады да, бу баланың җаны чыгасы гына калган, ярдәм күрсәтүдән узган, диде. Синең balaңда дифтерит, кара аны, берәр җиргә кермә, югыйсә, башкаларга да дифтерит ияртерсең! — дип кычкырып калды. Нишлим? Баламның суына башлаган гәүдәсен күкрәгемә кыстым да кайтырга чыктым. Каршыдан ачы җил исә, өстән юеш кар ява, аяк асты бозлавык. Кайта-кайта аягымдагы оек-чабатам тузып төште, аяк табаннарым бозга суелып канга батты... Ярты юлга җиткәч, балам гаргарәгә килде. Ичмасам, җирәнкәнең куенында үлсен инде, дип, башымдагы шәлемне салдым да, бозга җәеп, баламны шунда куйдым. Ә балам көчкә тын ала! Бу авырудан шулай буылып үлгәнне күргәнем бар иде. Нишләп болай авыр сулый соң бу бала, әллә тын юлына берәр нәрсә кергәнме? — дип авызын ачып карасам — авызы тулы лайла! Менә ни өчен!.. Аптырагач, баламның авызына авызымны куйдым да шул лайланы суырдым!.. Ничек өйгә кайтып җиткәнемне белмим. Үпкәм кабарудан савыга башлап аңыма килгәндә, балам инде йөгереп йөри иде!

Р а с и х а. И, менә бит! Кайсы балаң иде ул, әни?

А н а. Ул бала — синең ирең. Башка балаларыма бер генә тапкыр яшәү бирсәм, аңа мин ике мәртәбә тормыш бүләк иттем. Шуңа ул әнә шулай яхшы булып чыкты, тугач та мендәр каплап үтерәсе нәрсә!..

*Ислам башын түбән иеп чыгып китә.*

Р а с и х а. И, алай димә инде, әни! Вакыты җиткәч барыбыз да үләрбез!

А н а. Ул инде минем өчен күптән мәет. Аналар өчен балалар шулай. Кайберләре вафат булсалар да, мәңге исән, чөнки алар намус белән үлгән балалар. Кайберләре икмәк черетеп яшәсәләр дә — мәет!

И н с а ф. Әни, сиңа борчылырга ярамый! Ятып тор, әни!

А н а. Мин бик күп яттым инде, улым, алда — ятасыларым тагын да күп. Азрак басып торасым килә. Менә сез өч айдан бирле минем белән курчак уены уйныйсыз. Әни карчык кеше, янәсе, ничек ялганласак та ышана. Ә мин сезнең ялганнарыгызны белеп торам, сезне борчымас өчен әйтмим генә. Сәярның хатыны нинди практикага киткәнен дә, ни өчен кеше өендә ятуымны да, авылга ник җибәрмәвегезне дә — барысын да беләм бит мин. Ана кешенең колагы ишетмәсә, йөрәге ишетә... Үзегез миннән яхшырак беләсез, минем күп яшисем калмады. Васыятем шул: кеше булыгыз! Куркак җан булудан сакланыгыз! Кеше куркак булса, үзенең җанын саклап калу өчен теләсә нинди түбәнлеккә бара. Атасын да, анасын да, хәтта Ватанын да сата!..

П ә р д ә.

1968 ел.

## Гамил Афзал

### Уйланулар дәфтәреннән

●

Ничә буын күңелләрдә сагыш тоеп,
Җырын җырлап, иген игеп яшәгәннәр,
Бабайларның каберенә башын куеп,
Минем җырым аяк терәп яшәгән җир —
Күзем ачып сиңа бактым, сине күрдем,
Сүзләреңнән, уйларыңнан моңнар үрдем,
Гүзәл иде язың-көзең, иртә-кичең,
Рәхмәт сиңа мең бизәкле төсең өчен!

●

Тынмый күңел авыз йомып калган белән,
Чын кешегә авыр булыр — алдан беләм;
Җил-давылсыз үтәр идең гомер юлын,
Тешне кысып тату торсаң ялган белән.

●

Тормыш тутәленә чәчәк өстә,
Дәшми генә өстә, дускаем,
Бер кешегә бер яхшылык эшлә,
Бер изгелек эшлә көн саен!

●

Тагын да яз килер,
Назланып кар эрер,
Ярсулы кар суы йөгерер.
Чияләр өлгерер,
Алмалар өлгерер;
Без йөргән юллардан кем йөрер!

●

Мин оттырмам, барыбер отармын, дим,
Җылы кояш нурын тотармын,
Орлык булып кышын кичәрмен дә
Чәчәк булып язда шытармын;
Мин үлсәм дә, барыбер отармын.

●

Тау күтәреп бара-бара,
Талпына да сүнә йөрәк.
Үлеп күрсәтү — бер чара,
Яшәп күрсәтергә кирәк!

●

Кышын да, язын да
Тынгы юк җаныма,
Кар кебек ак кәгазь алдымда;
Уйларым-моңнарым
Еракта, якында
Яңгыраган авазлар хакында.

●

Ару-талу, талчыгулар
Таралып китте бүген.
Талгын гына, таман гына
Кар явып китте бүген.

Күңелләр дә, урамнар да
Агарып китте бүген.
Ялындырып, ялкау гына
Кар явып китте бүген.

●

Гөл кебек елмая күз нуры,
Моң булып тарала күз нуры,
Сүрелә, сагая күз нуры,
Ук булып кадала күз нуры.

●

Кырлар сары, яфрак — алтын.
Кайдадыр моң сузыла.
Урамнар буш, урманнар тын,
Көзләрем моңсу гына,
Күзләрем дымсу гына.

●

Борчылу һәм шатлык алып килгән
Көннәр үтә күңел аша.
Кеше үзенең бала чагы беләч
Уйнап-көлеп саубуллаша.

Бу дөньяда кем барын да белгән!
Тәҗрибә җый, хата ясә;
Кеше үзенең ахмак чагы белән
Ачы көлеп саубуллаша.

●

Җил исте,
　　　　үләннәр сөрлекте
Кыеклап җил искән уңайга.
Карагай бер ылыс селкетте,
Бер күркә төшерде тугайга.

●

Бер вакытны хәйран калып
Гомерләрнең узганына,
Утырасың уйга талып,
Китерәсең күз алдына:

Үткән җәй искән җилләрне,
Үткән кыш яуган карларны,
Сөенми үткән көннәрне,
Сөелми калган ярларны...

●

Лирик төшләр күреп уянам да
Уйлап ятам күргән төшемне:
Тере итеп күрдем күк аланда
Әллә кайчан үлгән кешемне.

Күл буенда сер сөйләшеп йөрдек,
Гөл-чәчәкләр кая карама!
Бер нәрсә дә үзгәрмәгән кебек,
Үлем генә кергән арага...

## Гөлшат Зәйнашева

### Мәңгелек сакчы

*(Җыр)*

Исәндер ул, бер кайтыр ул, димәгез,
Мине юатмакчы булып.
Чик буенда, җир куенында калды ул
Мәңгелек сакчы булып,
Мәңгелек сакчы булып.

Чик буеннан очмагандыр кошлар да,
Бер хәбәр дә, хат та килмәде
Ул мәңгелек сакчы булып калды дип,
Баеп барган кояш кына сөйләде.

Еллар үткәч, кабере дә табылды,
Чик сызыгы белән янәшә.
Күкрәк киереп басар кебек ул кабер,
Дошман безгә сугыш белән янаса.

Исәндер ул, бер кайтыр ул, димәгез,
Мине юатмакчы булып.
Чик буенда, җир куенында калды ул
Мәңгелек сакчы булып,
Мәңгелек сакчы булып!..

## Фатих Хөсни

# МИЧЧЕ ГЫЙНИЯТ

хикәя

I



Зур эшләр башкара торган авылларда сирәк-сирәк кенә кечкенә эшләр дә булгалап куя. Гыйбрәте яки кызыклыгы ягыннан нинди дә булса төше-орлыгы бар икән, мондый хәл-әхвәлләрне халык үзе үстерә, үз фантазиясе белән дә тутыра.

Җанкилде авылында да шундый кызыклы бер әкәмәте булды. Ләкин аннан авыз ерып көләргә түгел, мыек астыннан елмаерга гына мөмкин. Елмайганда да уңга-сулга күз сал: якын-тирәдә ул вакыйганың герое үзе күренмиме? Чөнки ул бик гарьчән кеше, үз бәясен югары тота, кулыннан килмәгән эш юк, бигрәк тә мич чыгарырга дигәндә, син аның кебек башка останы тирә-як авыллардан тиз генә таба алмассың. Күккә чөясем килеп түгел, гади бер фактны әйтәм: кулы бер тисә, хәер, чыгара инде Гыйният мичне. Авылдашларына да, күрше авыллар чакырса, аларга да, ферма тирәсе каралтыларына кирәк булса, — аларга бөтенесеннән дә әүвәл! Бер караш ташлау белән иң элек бинаның кубатурасын чамалап алыр, шуңа карата эшен көйләр. Янәсе, соңыннан бер пүлән артык, бер пүлән ким якма. Өйдә артык эссе дә булмасын, шул ук вакытта җил дә уйнап тормасын.

Бу әйткәннәрдән тыш, янә бер өстенлеге бар: аракы эчми. Ялгыш аңлашылмасын: эчә аракыны, ләкин бетергәннән соң һәм хуҗа үзе куйса гына эчә. Башкалар кебек эш арасында да темтенеп йөрми.

— Әллә морҗаң өй кыегына чыгып утырганмы? — дип кырт кисә ул, әгәр берәрсе вакытыннан элек куштанлык күрсәтә башласа, — сперва морҗаң өй кыегына чыгып утырсын, төтенен чыгарып күрсәтсен, мичең җылысын бирсен, аракы җылысына аннары да өлгерербез, потомнан соң да...

## II

Кешене берөзлексез әрләп-тәнкыйтьләп тору файда китермәгән кебек, кешене артык иркәләү дә боза икән. Гел мактау, яхшы данын таратып тору бер заман безнең атаклы миччебезне дә боза башлады. Дөрес, ул моны эшендә, ил арасында сиздерми. Өенә, сөекле Хәмдиясе янына кайткач, борын үзенекен итә. Үзегез үк чамаларга тиешсез, гел мактау сүзләре ишетеп торудан, аннары тагы эшен эшләп бетергәч, үзе әйтмешли, «потомнан соң» мыек чылаткалаудан,— бәлки шуңа Хәмдиясен өзелеп сагыну да өстәлә torгандыр,— үтә дә очынып кайта кеше. Бусы өзелеп сагынып кайткан, ә Хәмдиясе акыл сатып маташа:

— Карак мәче күзләре кебек елтыраган күзләреңнән күрәм, бүген тагын чәк кенә сыйланып кайткансың, Гыйният. Көн дә-көндәгә киткәч, күз тия күрмәсен. Мин синең сәламәтлегең өчен кайгыртып әйтәм, җаным.

— Йомырка тавыкны өйрәтми, — ди Гыйният, сүзен өзеп кенә, — әйдә, табыныңны тизрәк җыеп ал да ятарга урын әзерлә. Уйнап йөрмәгән кеше.

Шулай да үтә кырыслыгын чак кына йомшатмакчы булып һәм, ихтимал, сагынып кайтуын яшерә алмаганнандыр, өсти аннары:

— Урынны мамык түшәк-ястыклардан эретеп җәйм.ә. Күңелем дә каты, телгә дә осталыгым юк, йоклар өчен урын-җирнең чүт кенә каты булганын яратам.

Шулай да бөтенесе Хәмдиянең исәбендә: абзаң соңгы вакытларда елтыраган күзләрен аскарак яшереп кайта, сүзгә-өнгә дә саранланды, урын-җирне йомшак җәйгәнне дә өнәми, ашый-эчә, кайда эләксә — шунда башын куя да хырлап йоклап та китә иде. Җитмәсә тагын, колхоз эшендә йөргәндә читләтеп-читләтеп кенә Хәмдиягә сүз дә ишеттергәли башладылар. Әлбәттә, белеп, ни дә булса ишетеп яки, һич югы, нигезле шикләнү белән әйтелгән сүзләр түгел, тел тик тормаганнан.

— И, күп эчә дә соң ир-ат заты хәзер, — ди берсе.

— Үз янымда булганда, мин үземнең бияләй авызыма йөгәнен салырга ирек бирмим. Шундый боргычлап алам, әлләзи булып сыгылып төшә агаең, — ди икенче бер заһәррәге.

Болганчык суда балык тотарга яратучы өченче берсе, юри төрттерергә тырышкандай, ялгап куя:

— Ярый ла, синең мүкләгең ындыр артына да чыкмый. Атналап китеп, күрше авылларда мич чыгарып йөрүчеләр дә бар дөньяда.

Моны шәрехләп торасы юк: ачыктан-ачык Хәмдия бакчасына таш ыргыту бу. Ишетмәгәнгә салышуын салыша Хәмдия, ләкин күңел дигәнең бөтенләй үк буш та калмый. Бик тә тели шул Хәмдия Гыйниятенең үзенеке генә булганын. Сөйләмәсеннәр иде юкны-барны, тел чайкамасыннар иде аның Гыйнияте белән.

Болай уйланулар, көнләшү сиздереп, Гыйниятка сүз ташлауга хәтле үк, әлбәттә, барып җитмәде. Шулай ук Гыйният үзе дә вакытында кайта, эшләгән акчасын тиененә хәтле кайтара тора. Бөтенләй эчмичә кайткан кичләре дә булгалый иде. Ләкин Хәмдия өчен шунысы табышмак: Гыйниятнең үтә төкселеге, авызыннан сүзе чыкмавы нәкъ әнә шул эчмичә кайткан чакларында аеруча сиздерә иде.

Тыштан караганда, дөньялары күпме генә түгәрәк булмасын, сизенгән кешегә сизенерлек бар: ныклап бер сөйләшер вакыт бик-бик житеп килә иде. Гыйниятнең теле ачылсын, Хәмдиясенең күңеле басылсын — түшәмнән туфрак коймыйча гына сөйләшсеннәр иде бер.

## III

Сөйләштеләр. Шактый ук югары дәрәҗәдәге сөйләшү килеп чыкты.

— Ник теленне йоттың син, Гыйният, соңгы вакытларда? — дип башлады Хәмдия кичләрнең берендә. — Ичмасам, эчеп кайтсаң, шуны яшерергә маташуы дип уйлар иең, ап-аек килеш «ә» юк, «җә» юк.

— Ни әйтим, менә исән-сау кайттым, бер җирем дә кителеп калмаган... — ди тегесе тупас кына итеп. Күренеп тора: Гыйнияте арып кайткан, шул хәлендә хатынының сөйләнгәләп торуы аның тупаслыгын кузгаткан иде. Бер кавым сүзсез калдылар.

— Беләсең ич, Гыйният җаным, синең өчен янган утка керергә торуларымны. — Бу юлы Гөлшаграк, хәтта беркадәр юмалый тәшебрәк тезде Хәмдия. Үзе тыз-быз аш-чәй урыны әзерли, шул арада Гыйниятенә астыртын-хәйләкәр караш ташлап алырга да өлгерә. Янәсе: үттеме таш күңелле миччегә аның бу тәмле сүзләре?

Инде Гыйнияте, кәмит күргәндәй, Хәмдиясенә күтәрелеп, көлемсерәп бер мәл карап торды. Аннары чын ихластан шаяртып әйтте:

— Берәр шигырь китабы укыдың мәллә, шомлык? Шигырь китапларында гына шулай сайрашып сөйләшәләр. Тамагыңда берәр төерең булса, әйт тә сал, ничу төер саклап йөртергә.

— Төерем бар шул менә, дөнья булгач төер дә җыела икән. — Шундук сиздe тагы үзе: юк, Гыйниятне болай алдырып булмый, Гыйниятне алдырсаң тәмле тел, ачык чырай белән генә алдырырга мөмкин. Көйләрәк җайга күчәсе итте: — Бар бәхетле кешеләр дөньяда, колхоз эшенә бергәләп китәләр, бергәләп кайталар. Мин генә шул кайтыр юлларыңнан күземне алмыйча көтеп торам. Күрше авылларда мич чыгарып йөргән чакларыңда бигрәк тә.

Болай әйләнеп-тулганып озакка китәр, дип уйлапмы, әллә берни дә уйламыйчамы, әлеге юма сүзләргә ялгап әйтте дә салды аннары:

— Ташла син, Гыйният, пычракка батып, шулай мич чыгарып йөрүеңне. Давай, икәү бергәләп колхоз эшенә йөрик. Бутән кешеләр кебек.

— Мин болай да колхоз эшендә, — диде тегесе, һәр вакыттагы кебек берничә сүз белән өзәргә тырышып. — Күрше авылларга баргалыйм икән, беренчедән, алар безнең «Правда» колхозының ук бригатлары. Икенчедән, шабашник булып түгел, эшем өчен колхоз миңа просинт түли.

— Кирәк түгел миңа синең просинтларың! — Кинәт берничек тә уйлапамичә, җан ачигысы белән кычкырып җибәрде Хәмдия. — Миңа синең просинтларың түгел, миңа син үзең кирәк. ишеттеңме шуны, син үзең кирәк, өлешләргә бүлгәләмичә, ни ходай биргән — бөтен килеш кирәк.

Ашый торган кашыгын бер якка куеп, житди, үтә житди итеп беравык хатынына карап торды Гыйният — үз эшенең кадерен белү дә, әйтәчәк сүзенең ныклыгын аңлатырга теләү дә, узган ел гына салып кергән шушы алты почмаклы өйдәге тыныч тормышның түгәрәклеген бозмыйча сакларга тырышу да, Хәмдиясенә мәхәббәт тә, бер үк вакытта аны аңлап житкермәү дә бар иде бу карашта.

— Беләсеңме син мич чыгаручының кем икәнлеген? Нинди эш башкарганлыгын? — Гыйният кырыс кына түгел, хәтта каты иде бу минутта. Күп сүзлелектән курыкмыйча, соравын янә дә кабатлады: — Беләсеңме мич чыгаручының нинди зур эш башкарганлыгын, ә?

— Белмим дә, беләсем дә килми! — диде тегесе үҗәтләнеп.

Гаепләп булмый, нишләсен бичара хатын, аның шул үз Гыйниятен үз янында гына тотасы килә иде.

— Белмисең икән, тик утыр. Кысылма ирләр эшенә, — дип, тегенең авызын томаламакчы булды Гыйният. Ләкин моның белән генә чиклән-

мәде, бер сүз чыкканда хатынына мич чыгаручының кем икәнлеген иҗекләбрәк төшендерәсе итте: — Тагы шуны да бел: мич чыгаручы ул — кешеләргә җылылык китерүче. Мин, кәнишны, адәм рәтле пичниклары күздә тотып әйтәм бу сүзне.

Һәм папиросын авызына кабып, ләкин ишекне бәреп ябарга һич ашыкмыйча, баскыч төбенә чыгып китте. Сүзне шуның белән беткәнгә санап, үзара солых урнашуга юрарга да бик мөмкин иде бу чыгуны. Ләкин...

## IV

Болай текә сөйләшүләр булмыйча берара тыныч тордылар, ләкин чын солых урнашты дип әйтеп булмый. Хәмдия — шул элеккеге Хәмдия, ирен читкә җибәрәсе килми, ишетелгән юк-бар сүзләргә колак салмаска тырышса да, алар керәләр, җанны үртиләр иде. Сүзсез кайтса да, Гыйният гаепле, кәефле кайтса да, авыз йомып кала алмый хатыны:

— Ай-һай, кәеф син бүген, әтисе. Мичең бик шәп чыктымы, дигәнем? Әллә... кем әйтмешли, шулай дуамал акаеп кайтырлык бүтән шатлыкларың булдымы?

— Мать якасына, кире ягың белән торган булсаң, мин сине момент икенче ягыңа — үземә кирәк якка әйләндереп салырмын, — дип кинәт кабынып китте Гыйният, җилтерәтеп хатынын кочып алды, җеңләнү катнаш комагайланып, күзләренә карады.

— Китсәнә, теге... ни. Балчык, кирпеч тотып катып беткән куллрыңны әйтер идем, — шулай дип итенгән була Хәмдиясе, ә үзе — эчендә май ае утыра диярсең,— әри бара, әри бара, яшәрә, әйтерсең чәчәк ата... Өйдә тынычлык, өйдә солых, өйдә татулык канат җәйгән, урынны да теләсә кайда, теләсә ничек җәйсен...

Ләкин тормыш дигәнең тормыш, аның шундый тыныч, тату, кызык кичләре белән нәүбәтләшеп этле-мәчеле кичләре дә килә. Хәмдиясен үлеп яратканы хәлдә, мондый төксе каршылауларны бер дә өнәми Гыйният, шулай да, имән күмере белән кайнаткан самавар кебек, дәррәү кайнап-ташып чыккан чакларын да күрсәтми иде — ир бит, җитмәсә, мичче ир, ил өстендә абруйлы исеме йөри.

Әмма һәр түземлекнең бер чиге була! Кичләрдән бер кичне, болай да арып-талып кайтылган чагы иде, әлеге шул гадәттә кимерә торган балык башын кимерергә тотынды Хәмдиясе: янәсе, кеше йөри парлы-парлы, ул гына моңлы-зарлы. Янәсе, бөтен тирә-як авылларын бер Гыйният кенә мичле итә алмас, ката башласалар, үз миччеләрен булдырсыннар һәм башка, һәм башка үпкә-сапкалар. «Һәм башкалар»ына эндәшми-тынмый гына түзгән дә булыр иде Гыйният, кызып киткәч, Хәмдиясе үйламыйчарак бер сүз ычкындырды:

— Тиле дигән саен тигәнәк буе сикереп, син йөрисең балчыкка-тузанга катып!

Бөтен хәрәкәтеннән туктап, сәерсенеп һәм аңлап җитмәгәнгә салышып, чынлыкта исә бик тә колакларын торгызып, Хәмдиясенең каршына «үсеп чыкты» Гыйният, җитмәсә, моңарчы ләм-мим дигәнне — сүзен дә тапты:

— Я, я... әйтеп бетер әйтәсе сүзеңне. Мин йөримме балчыкка-тузанга катып? Тиле дигән саен тигәнәк буе сикереп, ә?

— Син шул, — диде тегесе аны-моны абайламыйча. Шуннан соң иң хәтәрен өстәде: — Мичче һөнәре дә булдымы һөнәр! Кочаклаганда да тән исе түгел, балчык-ком исе килә үзеңнән.

— Балчык-ком исе, дисең, алайса? — дип мыгырданды Гыйният, юаш кына итеп. Аның бик нык хәтере калган иде бу сүзләрдән. Беравык әйтер сүз тапмыйча, шул ук вакытта күтәрелеп карарга да ашыкмыйча,

какшаган баганадай басып торды. Аннары гына телгә килде, анда да күтәрелеп карамыйча гына: — Бик авыр сүз әйттең әле син, Хәмдия җаныкай. — Салмак, сабыр, бер үк вакытта рәнҗүле иде ул бу минутта.— Мин, Хәмдия үскәнем, үземне хурлаганга түзәм, әмма да һөнәремне хурлаганда түзә алмыйм. Шуны белеп тор, җәме?..

## V

Ике-өч көн күрше авылда мич чыгарып йөреп, ниндидер берәр сүз ишетепме, әллә хуҗаның мич юлын тиешенчә «юдырмавыннан», нишләптер көйсез кайткан иде бүген Гыйният. Хәер, бер Гыйнияттән генә калмаган, бу дөньяда көйле булырга да, тапкан көеңне югалту өчен дә сәбәпләр чыккалап тора... Мичче Гыйниятгә бу соңгысы көчәя бара иде соңгы вакытта. Шулай булмыйча соң! Имештер, «кочаклаганда да тән исе түгел, балчык, ком исе килә» Гыйнияттән. Кем әйтә моны диген? Җан сердәше күргән Хәмдиясе әйтә. Икенче яктан, шул Хәмдиясе күзгә бәреп юк-бар гайбәт сүзләр ташый башлады. Имештер, аның Гыйнияте ике көндә бетерердәй эшне юри өч көнгә, дүрт көнгә суза — күрше авылда, чит-ят кеше җәйгән урында аунау кызыграктыр шул, күрәсең. Сәер бер карасаң, үзләре бер-берсен чат ябышып, яратышып-җан атышып торалар, шул ук вакытта арадан әле эт, әле мәче йөгереп уза...

Бу кайтуында, әйткәнебезчә, көйсез иде Гыйният. Эндәшми-тынмый гына чишенде, эндәшми-тынмый гына битен-кулын юып керде — сабынлап. Балчык исе калмасын, янәсе. Аннары, бусын инде бөтенләй хатыны күрмәгәндә, мыегына, битенә одеколон да сипте. Хәер, уйламыйчарак эшләнгән бу юк эш кире нәтиҗә бирде: одеколон исен сизеп алган Хәмдия әллә ниткән шомлы уйларга батты.

— Ник бер сүз дә дәшмисең? Шул өч көндә телеңне йолкып алып калмаганнардыр ич?

— Сүзем юк, сүзем юкка дәшмим, — диде Гыйният, күтәрелеп карамыйча гына. Бераздан күтәрелеп карады, ай-һай ла, мондый күтәрелеп карауны һич көтмәгән иде Хәмдия. Бу юлы җене күзләрендә иде Гыйниятнең:

— Сүзем бар, сүзем шул, — дип, тавышын яхшы ук күтәрә төшеп ялгап алып китте ир, — болай этле-мәчеле булып артык тора алмабыз, менә шул сүзем! Миннән алай гел балчык исе дә килә башлагач... Балаларга тиешлесен алып калырлар, мин шабашник булып йөрүче түгел, бар эшләгәнем колхоз чутында.

Моңа хәтле сүзсезлеге белән Хәмдиясенең теңкәсенә тигән миччедән чыга башлагач чыкты сүзләр — кургашын төсле авыр, кургашын кебек салкын сүзләр:

— Миңа өйдән шушы иске кожанымнан бүтән берни дә кирәкми, бөтенесе сиңа калыр. — Ул кереп утырган өстәл яныннан дәррәү сикереп торды, ышанычлырак чыксын өченгәме, әллә артык дәрәҗәдә хәтере калганлыктан берни дә уйламыйчамы, чөйдә эленеп торган кожанын алып селкеде, аннары аны бер якка тотып атты, ләкин кызуы көчәя генә бара иде.

— Мәгәренки хәләл көчем белән чыгарган мичемне сиңа калдыра алмыйм, бигайбә анысы өчен.

Һәм мичкә каршы ян тәрәзәне төбенә хәтле каерып ачып куйды да, шундук кулына чүкеч-калакларын алып, мичне ватарга, куптарган кирпечләрне — берәм-берәмләп тә, катламы-катламы белән дә тәрәзәдән тышка бәрергә тотынды. Хәмдия бер урында катып калган, өнен югалткандай телсез, — я хода, балчык-тузан исе дип зарлана торган иде башка вакытта, менә кайчан икән балчык-тузанның кузгалыр чагы!

Малай-салайны гел бертөрле уеннар туйдырып бетергән, Гыйният абзыйларының тәрәзәсеннән очкан кирпечләрне күреп, иң элек ул таш-башлар җыелды. Аларга ияреп кәчекләре дә шул тирәдә буталган, күрәсең, Гыйниятнең җенләнеп атып бәргән бер кирпече ул гөнаһсыз мәхлукка эләккән, анысы дөнья бетереп чыйнап китте. Кич җиткән чак булса да, җәйге көн караңгыланырга ашыкмый, бу тамашаны күреп, әкренләп олылар да җыела башладылар. Бигрәк тә шунысы шаккатыргыч: җәнҗалның нәрсәдән чыкканлыгын белгән кеше юк, ачык тәрәзәдән анда-санда Гыйният үзе күренгәләп калса да, аңарга сорау бирергә җөрьәт иткән кеше шулай ук юк, чөнки күреп торалар: мунча ташы кебек кызган Гыйният, бу минутта аңардан нинди дә булса рәтле сүз алырмын димә. Якынрак барып, кызыксына башлар иден, алла сакласын, ипи шүрлегенә кирпеч эләгеп, тешенне җимерүләре бар. Шуннан нишләсен инде җыелган халык? Арткы плангарак күчеп, һәрберсе үзенчә фараз кылырга, белгән атлы булып күренергә, остарырга тотына.

— Мичен яңартып чыгарырга ниятләгәндер, үз хөкеме үз кулында, башкортның Кылый кантоны кебек, сүз әйтмә Гыйнияткә, — ди берсе, әллә Гыйниятне яклап, әллә бу кызыклы тамашадан әйтеп бетергесез тәм табып.

— Алай дип әйтер иең, дуамал-нык оча, кирпечләрне әйтәм. Көпәкөндез, панимаешь.

— Нишләп көндез булсын, дөньядамы син? Көтү кайтты, тузаны басылды.

— Көтү тузаны басылды, ә Гыйният тузаны купты. Нәрсәдән икән? Син менә шуны әйт егет булсаң.

— Хәмдиясе белән ике арада берәр дау чыккандыр дисәң, моңа тиклем ләм-мим ишетелгәне юк, күрше торабыз лабаса.

Ул арада берсе, бу билгесез тамашага үзеннән нинди дә булса өлеш кертергә тырышкандай, авызын ерып куясы итте:

— Әй, юкка шаккатмагызсана: көндез эшләнәсе эш беткән, йокларга әле иртә, сугышыр өчен иң җайлы вакыт.

Күзләре белән ашардай булып, бөтенесе әлеге шаркылдык авызга карап куйдылар.

— Сөйләмә иске авыздан яңа сүз! — дип, ачуланып шелтә белдерде арадан бер өлкәнрәге, — Гыйниятне белмибезме дә, Хәмдияне бүген генә күрәнме?

Чынлап та, Җанкилде авылы кешеләре үзара бик тату яшиләр, кулыннан эш килә торган Гыйният оста белән аның Хәмдиясен чын-ихластан хөрмәт итәләр, аларның талашып китүләренә һич тә ышанасылары килми, шул ук вакытта ачык тәрәзәдән кирпечләр оча тора... оча тора...

## VI

Юк, уен гына булмады бу. Мичен сүтеп атканнан соң, Гыйният, күрше-тирә кешеләрен кайсын хафага салып, кайсыларында аңлаешсыз кызыксыну уятып, ә кайбер озын телле гайбәтчеләргә кабартып сөйләргә азык биреп, кожанын култык астына кыстырган хәлдә чыгып китте. Кая китте? Нинди ният белән китте? Бөтенләйгәме? Әллә Хәмдиясен өркетүе генәме? Бер сүз дә әйтмәде. Әйткән бердәнбер сүзе шул булды:

— Бәлкем балчык исе килми торган бүтән берәүне табарсың?

Әйткәнебезчә, кайберәүләрне аптырашта калдырса да, тулаем алганда, мичче Гыйниятнең тора торгач (кешегә шулай күренә, кешенекен кеше белми!) өенең мичен сүтеп, семьясын ташлап китүе тын гына яткан Җанкилде авылын бер мәл телгә китерде.

Атнамы, ун көнме күренми торганнан соң, Гыйният гадәттәге тын кичләрнең берсендә, эңгер-меңгер төшкәч, әлеге шул аерылмас кожаны култыгына кыстырган килеш кайтып кермәсенме. Аның кайчан, нинди-рәк кыяфәттә кайтып керүен, Хәмдиясе белән ике арада нинди сүзләр булганлыгын, әлбәттә, берәү дә күрмәде, ишетмәде. Шуңа да карамас-тан, мәсьәләнең нәкъ әнә шул ягын күпертеп, үзенә бер театр кордылар Җанкилде авылында.

— Синнән башка торыр әмәлем юк, Хәмдиям-җанкисәгем, чәпче-мичә генә кабул ит, мин кайттым, —дигән, янәсе, Гыйният, ишектән ат-лар-атламас ук.

— Сүтеп ташлаган мичеңне төзәтеп чыгарганчы гына торып кара, аннан күз күрер,— дигән тегесе, имеш.

Аннары бер кавым сүз таба алмыйча югалышып калганнар, имеш. Иң әһәмиятлесе: шул кичне үк берсен-берсе тапканнар ди тагын. Мичне яңадан чыгару Гыйният өчен чүп тә түгел, мич чыккан, Хәмдия юкка-барга бәйләнми башлаган, Гыйният тә мәчет картыдай тәкъвагә әйләнгән, акча да кайта, вакытында үзе дә кайта, кайтканда авызыннан юк-бар ис тә килми, кыскасы, хәйран тамаша ди боларның тормышы. Әлбәттә, гайбәт сүзләренә дә урын калмаган, өреп тутырылган мәзәк-ләр дә беткән һәм, дөресен әйтергә кирәк, алар беткәннән соң Җанкилде авылында бер мәл ничектер күңелсезрәк тә булып калган, имеш.

Әмма озакка бармаган бу «ООН» тынычлыгы. Көз җитәрәк киткән яңа өйләр җиткезү. Яңа өйләргә мичләр кирәк, бөтенесенең дә мичне Гыйнияттән чыгартасы килә — авторитет зур Гыйниятнең. Әлбәттә, күрше авыллардан да сорау юк түгел. Күрше авыллар дигәннең дүрте-бише шушы «Правда» колхозының күрше бригадалары. Гыйниятне сорарга, мичне Гыйнияттән чыгартырга тулы хокуклары бар. Тегеләк-мык килә башласа, мәсьәләне идарә алдына куялар. Идарә кушса, ык-мыкка урын калмый...

Тыштан болай бөтенесе үз урынында, өйләр салына, мичләр чыга, Гыйниятнең дан үскәннән-үсә бара. Дан үскән саен борын да үсә, җаен кожанын култык астына кыстырып, песием генә кайтып кергәнен оныт-кан кеше, Хәмдия алай-болай сүз кузгата башласа: «Тыгылма ир эшенә. Минем авторитетны итәк астыңа яшереп куя алмассың. Кулыннан килә Гыйниятнең, Гыйниятне сорыйлар, значит, сүз әйтмә Гыйнияткә!» дип кенә җибәрә. Кыскасы, икеме-өчме айдан соң, көзге дымык кичләрнең берендә Гыйниятләр өенең ян тәрәзәсе тагын төбенә хәтле каерылып ачыла, тәрәзәдән тагын кирпечләр оча башлый. Көзге көн кыска, бу юлгысы күз бәйләнгәчрәк була, бусын ул чаклы ук «театрга» әйләнде-рергә өлгермиләр.

Аның каравы, бу юлысын Хәмдия бик тирәнтен кичерә. Беренчедән: «Әти кая китте? Әти ник кайтмый?» — дип, балалары йөдәтә, теге юлгы-сын «командировкага китте» дип котылган иде, бу юлы да шулай дисә, ышанмаслар кебек. Икенчедән, көз җитте, мичне сүтелгән килеш ята, утын, терлек азыгы турында кайгыртасы бар. Өченчедән, бусы — иң үзәк өзгәне — сагындыра шул мичче ләгънәт. Теге вакыт кайтып кергәч күрсәткән иркәләүләре исенә төшә, әйткән булган, бәлки кызып китү аркасында төчеләнеп ычкындыргандыр: «Тезеп куйсыннар каршыма берьюлы йөз хур кызы, берсенә дә әйләнеп карамыйм. Кочагымда син булганда, былбылым!» дигән булган, имеш. Шул сүзләре искә төшеп, Хәмдиянең үзәген өзә.

Ләкин Хәмдия дә каты серле. Авызын ачып, кешегә ләм-мим зар чыгармас. Бик куерта башласалар, бер дә исе китмәгән атлы күренеп, шаркылдап көләр генә.

— Кайтыр. Ашаган җиренә сыер да кайта, минем Гыйниятем сыер түгел ич.

Кеше арасында «минем Гыйниятем!» дә «минем Гыйниятем!», колхоз эшенә дә элек ничек чапкан булса — хәзер дә шулай чаба. Бригадир: «Болай ни... балаларың да бар, өең дә ялгыз... Гыйният абзый өйдә юк чакта, теге ни... Кай көннәрне балаларың янындарак торсаң да дөньясы җимерелмәс не» дип, турыдан-туры ымлаулар ясаганда да серне бирми: «Минем балалар зурлар хәзер, үзләре дә курыкмыйлар», белән бетерә, ә йөзенә чыкканын яшерә алмый: эчтән сыза бара, сыза бара Хәмдия.

## VII

Башта мәзәк итеп маташканнар иде, соңга таба чынлабрак уйланмыйча булдыра алмый башладылар. Күршеләре, туган-тумачалары, дус-ишләре бар, колхоз идарәсе, партоешма, авыл Советы бар, ниһаять, тулаем алганда тату яши торган Җанкилде авылында, гомумән, күренгән хәл түгел бу. Имештер, кеше, ике бала атасы, тора торгач, мичен сүтеп ташласын да өйдән чыгып качсын. Акылга сыймаган, күренмәгән-ишетелмәгән хәл бу. Районга ишетелүе мөмкин, авыл даны, кеше тормышы, балалар язмышы дигән төшенчәләр бар.

Колхоз председателе белән партоешма секретаре иң элек Гыйниятнең үзен чакырып сөйләшеп карадылар.

— Акыл җыйсын әле бер көз,— диде дә бетерде Гыйният сүзне. Хатыны Хәмдия турында әйтте булса кирәк. Аннары, председатель белән партоешмадан алай гына ычкынып булмаслыгын төшенеп булса кирәк, йомшартыбрак һәм сузыбрак болай дип тә өстәде: — Миңа нәрсә? Авыл дип тормыйм, күрше авыл дип аһ ормыйм, биргән нәрәтләрегезне үти барам. Эшемнән зарланган кеше юк. Эшләп арыганнан соң, төнен мин башны итек кунычына куеп та йоклыйм.

Сүзгә саран Гыйнияттән бүтән бер сүз дә ала алмадылар. Аннары Хәмдияне чакыртып төпченеп карадылар: янәсе, тора торгач нинди корт чакты сезне? Ичмасам, бала-чага ата-анасы булмасагыз икән.

Горурлыкта, сер бирмәүдә бусы тегесенә караганда да тешләгрәк булып чыкты.

— Бала-чага дип сүз тидермәгез, минем балаларым сезнең ишегегезгә барып егылмагандыр ич? — дип берьюлы кабынып китте Хәмдия.— Өсләре бөтен, тамаклары тук балаларымның. Инде килеп, Гыйният турында сүз кузгатсагыз, ул минем балам түгел, кушып тыңлата алмыйм. Чынлап торыпка китсә, сез дә тыңлата алмыйсыз. Кайтуы-кайтмавы Гыйниятнең үз эше.

Күреп тора башлыклар: ничек сөйләшергә икәнен белә хатын. Кайбер сүзләрендә, дөрләп кабынып китүләрендә ачыну, эчке тигезлеген югалтуы сизелеп-сизелеп киткәләсә дә, администрацияне бу җитди эшкә тыкшындырырга һич исәбе юк. Сүз арасында шулай да йомшак кына бер ымлавы ишетелеп калды:

— Көз җитте, өебез суык. Сез әйтсәгез, бәлкем бер ара табып, үзе сүтеп ташлаган мичне чыгарып китсен иде.

Башлыклар хатынның инәлеп әйткән шушы бер сүзеннән чамалап алдылар: тәзәтергә була бу семьяны, ләкин дуамаллык белән түгел. Кушу, үгетләү юлы белән шулай ук түгел.

Ә менә нәкъ шул кичне йомышсыз-нисез, хәтта чак-чак кына кызмача да иде булса кирәк, идарә йортына, туп-туры председатель кабинетына басып кергән бригадир Җәми дуамаллык белән тотынды:

— Кара әле, Җангир абзый,— дип, үгезне мөгезеннән алмакчы булды ул,— сез уйлыйсызмы? Озаккарак китте бит мактаулы Гыйниятегезнең бу кәмите. «Алмаш юк Гыйниятка», «алтын куллы печник» дигән булып, салпы ягына салам кыстырып, борынын үстердегез дә, кара хәзер кәмит корып йөрүен. Ике баласын ташлап, панимаешь. Мин

бигрәк Хәмдия апаны жәлләп әйтәм бу сүзләрне. Минем бригада члены бит, көн саен диярлек күз алдында. Күреп торам: аяк өсли корый бара кеше. Ә үзеннән ник бер сүз алып булсын. Кыскасы, шул: нинди дә булса чара күрергә вакыт бу эшкә.

— Я, әйтеп кара алай бик оста булсаң, — дип башлады председатель. Ул бригадир Җаминың кызмачарак икәнлеген күреп тора, башка вакыт булса икенче төрлерәк сөйләшкән булыр иде, ә бу юлы Җами кеше кайгысын кайгыртып кергән, ачулана алмады председатель, дустанә елмаеп сөйләште: — Әллә мичче Гыйният белән аның хатыны Хәмдия мәсьәләсен тикшерү өчен правлениенең махсус утырышын җыярга кушар идеңме? Административ юл белән тыкшына торган эш түгел бит бу, Җами дус.

Әлбәттә, председатель Җиһангирныкы да дөрес, сүзне сузып торуның хаҗәте юк.

— Аптыраганнан башланган сүз инде, Җангир абзый,— диде Җами күндәм рәвештә, — минем бригада члены бит, Хәмдия апаны әйтәм. Әле нинди эшчем, беләсегез килсә!

Җами, чарасыздан кул селтәп, ишеккә борылды, чыга башлады. Ләкин чыгарга ук өлгермәде, председатель, бармак изәп, аны яңадан чакырды.

— Күреп торам, шәп синең настроениең бүген, Җами, — дип көлемсерәп ялгап китте, теге якынрак килеп баскач, — минем дә начар түгел. Чынлап та дөрес, Гыйният белән Хәмдия кәмит корганны нигә безгә дә кәмит корып карамаска?

Ул, заговорга әзерләнгән кешедәй, Җамины авызы төбенәрәк тартты.

— Беләсеңме, нәрсә? Синең анда телгә дигәндә эт ашаган Хәйбүшең бар. Хәйбүшкә күп аңлатып торасы юк, намек кына бир. Җибәр шуны Гыйнияткә, только ни... минем исемне бутамагыз. Барсын, әйтсен, примерно, менә болайрак башласын: «Сине шәп печник дип мактыйлар мактавын да, Гыйният абзый,— дисен,— минем өйдә син чыгарган мичнең кылыгы китеп тора бит әле, парин. Мич юллыгы төтен кайтара, хатыннан көн дә сүз ишетәм, янәсе. Аннары дуамал гына менә болай дисен: әллә барып, үзең чыгарган шул мичне үзең үк сүтеп ташлыйсыңмы? Мич сүтәргә дигәндә, сине өйрәтеп торасы түгел, дисен. И больше бер сүз дә кирәкми. Төшенденме моның астында нинди хәйлән-шәргый качып ятканлыгын?

Төшенмиме соң Җами, ун ел рәттән бригадир булып торып! Җитмәсә тагын, кәефләнеп тә алган көне. Ә председатель, хәерсез, «заговор»ны бер башлагач, Җами белән генә дә чикләнеп калмаган. Шуннан соң ике көн үттеме икән, бер атна эчендә берсе артыннан икенчесе, өч кеше дәгъва белән килә Гыйнияткә. Сүзләре өчесенеке өч төрле әйтелә, ә мәгънә бер: мичләрен сүттерергә чакыралар. Өчесе дә Гыйният чыгарган мич. Бигрәк тә шунысы бәгыренә без булып кадалды Гыйниятнең: «Сине инде мич сүтәргә өйрәтеп торасы түгел, Гыйният абзый, тәҗрибә бар», дип кенә җибәрәләр. Аннары күрше авылдагы бригададан дүртенчесе килде, анысының да шул бер сүз — мич сүттерергә, янәсе, ул яктан тәҗрибә бар Гыйниятта.

Вакыты-вакыты белән кәмит корырга яраткач та — ул бит борын күтәрелгәннән генә. Шул ук вакытта борын астында шәп кенә мыек та бар Гыйниятнең. Шундук мыекка урады: көлә башладылар бит Гыйнияттән. Ә ул гарьчән кеше, үзеннән көлгәнне һич күтәрә алмый. Димәк, ошатмый халык аның болай фокус корып йөрүләрен.

Шул тынгысыз атнадан соң, бер дә бер кичне, әлбәттә, күз бәйләнгәч, бүреген култык астына кыстырып, үзенең Хәмдиясенә кайтып кермәсенме Гыйниятебез.

Әмма бу кайтуында, теге вакыттагы кебек, дөньяда юк хур кызларын телгә алып, хатыны алдында төчеләнеп торуны кирәк тапмады.

— Күз житте, өегез мичсез утыра, балалар туңа торгандыр, — диде ул һәм, паузадан соң, үзе өчен дә, хатыны өчен дә кистереп, нишләптер русчалатып өстәп куйды, — и вообще хватит дурака валять!

Һәм, йөри торгач, эшлекле бер тәкъдим дә ияреп кайткан иде аның башында. Чакырганны көтмичә, председательгә үзе барып керде, сәламнән соң ук сүзне кистереп башлады:

— Эш болай тора, Жиһангир, то-есть, болай торырга тиеш дип табам. Моннан соң мине күрше авылларга мич чыгарырга йөртмәгез. Хәмдия сүзләрендә дә резон бар: имештер, мин икешәр-өчәр көнләп күрше авылларда мич чыгарып йөр, ә Хәмдия монда бер ялгызы түшәк жылытырга тиеш. — Ул, артык кызмадыммы дигәндәй, чак кына тынып торды, аннары шундый ук кызулык белән яңадан ялгап алып китте: — Тиеш түгел Хәмдия бер ялгызы түшәк жылытырга и ул чагында сүзгә дә урын калмаячак. Ә нишләп әле безнең күрше бригатларда үз печниклары булмаска тиеш? Кайдан чыккан закон ул бер Гыйният кулына гына карап тору? Мин менә болай дим и правление моны кабул итәр. Табып жибәрсеннәр күрше бригатлар үзләреннән берәр кеше, желательно яшьрәкләрдән. Өч көннән Сидкый Жаббарында, аларның яңа салып кергән алты почмаклы өйләрендә мич чыгара башларга тиеш мин. И килсеннәр шунда күрше бригатныкылар, торсыннар карап, өйрәнсеннәр. И показательный мич килеп чыгачак. Жаббарның бу эшкә гупчи дә каршылыгы юк, хәтта үзе кычкырып тора: кем мичен чыгарганда әзерләнде яшь кадрлар? — Жаббар мичен чыгарганда әзерләнде яшь кадрлар! Тозы бар моның, тозы...

Гажәп-хәйран эшләр чыккалап тора бу дөньяда, шул жөмләдән Жанкилде авылында да. Кәмит корды Гыйният китеп-кайтып йөрүләре белән. Шул ук вакытта әлеге кәмиттән мәгънә дә сыгып чыгара белде: хәзер тирә-күрше авылларның бөтенесенең дә миччеләре бар. Тик, зинһар, уйлый күрмәгез: моның өчен һәр очракта да иң әлек үз мичеңне сүтеп ташлау һич шарт түгел!

1974

Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ЧОҢГЫЛЛАР

РОМАН

## 18



Ун ел гомерен Себер урманнары кисеп үткәрде Гайзулла. Әйе, гизмәде түгел ул дөньяны, гизде, күрде. Басмачылар арасында да булды. Шул уңайдан Әфганстанга да чыгып керергә өлгерде. Әмма сары алтын аны һаман өенә тартты. Совет власте аны ун елга хөкем итте. Дөресен белсәләр, яңадан күрәсе түгел иде Гайзулла бу дөньяны. Ун елын утырып авылга кайтканда ул танымаслык булган иде. Бөкресе чыккан, калак сөякләре беленеп торган арык этка охшап калган иде. Әнә шулай талкыды аны төрмә. Авылына ул төнлә кайтып керде. Документлары рәт-җайда булса да, кеше-кара күзенә күренергә курыкты. Чөнки суд булганда Әюп турында бер нәрсә дә сөйләмәде. Аны тик аклар ягында булганы өчен, басмачыларга кушылганы өчен генә утыртканнар иде.

Әюп өчен атулары бар иде аны.

Ләкин Гайзулла юкка курыккан булып чыкты. Өйгә кайтып керү белән Таҗылбанаты аны шатландырды. Әюпнең Гөлзифасы шул китүдән кайтмаган, хәтта хат-хәбәре дә юк икән. Хәер, аның Карамалыда чыбык очы кардәшләреннән башка кешесе дә калмаган иде бугай.

Әнә шуларны ишеткәч, Гайзулланың эченә җылы йөгерде. Атна чамасы ял иткәч, дөньяны кайгырта башлады. Иң әүвәл документларын рәткә салырга булды. Район үзәгенә барып, учетка керде.

Таҗылбанат белән киңәш-табыш иткәч, колхозга да керергә кирәк дигән карарга килде.

Ике елдан Таҗылбанат малай тапты. Гайзулланың түбәсе күккә тиде. Инде менә зар-интизар булып көткән дәвамы да булды. Үзләрендә үскән ятим Талипны детдомга алдылар.

Үткән гомер үтә — Таҗылбанат та, Гайзулла да картайдылар. Картлык аларга да килде. Сугыш елларыннан соң Таҗылбанат авырып алды, ябыкты, йөзенә лимон сарысы иңде, күзләрендә яшәү дәрте сүнде. Алай да өметен өзмәде, бераз хәле арулануга намазлык өстеннән тормас булды. Чыбык очы агай-энеләренә, күрше-күләннәргә корь-

---

Дәвамы. Башы 5 санда.

эн чыкты. Өйрәнә тора, акмаса да тамуын сизеп алды. Шунда ук кисәк тормыштан ямь тапкандай булды. Бер табын кешене авызына каратып утыру — кызыкмаслык нәрсә түгел иде. Иөри торгач, тагын бер нәрсәне төшенде: ире Гайзулла корьәнне ике-өч тапкыр укыган иде, яттан өйрәнә башлады. Тәмам йокыдан калды карты. Гайзулланың бу сәләтен белми иде ул. Укыган китапларын сүзгә-сүз сөйли ала, бик тиз ятлый. Тажылбанатның башына бер уй килде. Карамалының болай да законсыз мулласы картаеп килә, рәтләп корьән дә чыга алмый, тыны буыла. Гайзулланы муллалыкка хәзерләргә кереште. Тәмәке оны суыруын ташлаттырды, корьәнне кат-кат, кайта-кайта укытты, яттан сөйләтте, телен, тавышын чарлады. Гайзулла аңа шәкертләрдәй буйсынды, аятен-аятькә укып бирде. Тәмам күңеле ышангач кына бераүләргә илтеп, корьән чыгарттырды, ягъни яттан корьәнне укытты. Гайзулланың бу сәләтен белмәгән авыл картлары шаккаттылар. Ә инде карт мулла авырып киткәч, Гайзулланың мулла буласына бераү дә шик тотмады. Тажылбанатның ел буе тырышуы бушка китмәде, Гайзулласы хәзер иң түрдә утыра. Диннең кеше күңеленә никадәр нык тәэсир итүенә шунда төшенде Тажылбанат. Талип үзләрендә торган чагында ул аны да корьән укырга өйрәтә башлаган иде, укытучысы сизеп, авыл Советына житкерде һәм Талипны район үзәгенә балалар йортына алып киттеләр. Тажылбанат дәгъвалашып тормады.

Сәдака хакына гына торсалар да, житешле яшәделәр. Бер нәрсәгә дә мохтаж түгелләр иде, шулай да колхоз биргән һәр өлешләрен ала килделәр. Теге көнне дә бит шул карчыгының сүзен тыңлап бигән ертып кәнсәләргә барды. Инде онытылды, инде котылдым дип гүр түренә бер аягы белән басып торганда, үз шәүләсеннән үзе куркып йөрсен диген син аны. Ике-өч ел элек Гөлзифасы белән очрашкач, тәгаен телсез калган иде, бүген менә малае, гөнаһ шомлыгы, идарәдә утыра. Барысына да Тажылбанат гаепле...

## 19

Кәнзел бу төнне йоклый алмады. Кичә ул хатыны белән ачуланышты, фанатик картларга хас үжәтлек белән шәригатьчә «талак» дип әйтте. Хатыны Зәйтүнә моңа каршы кычкырып көлде генә.

— Абау, мәхәббәтсез! Атаң урынына мулла булдыңмы әллә? Нинди талак ди ул, тиле. Китче янымнан, килмә якын, жан өшеткеч нәмәстә!

Кәнзел торган саен зәһәрләнә бара, әмма тамак ертып кычкырырга күрше-күләннән курка иде. Шуңа күрә ул хатынына якынрак килергә тырышты һәм тешен кысып тагын:

— Талак, талак! Талак!! — дип гыжлады.

Зәйтүнәнең күзләре түгәрәкләнде. Кәнзелне ул бу кадәр жүләр һәм надан-томана булыр дип уйламаган иде, күрәсең.

— Тукта әле, тукта, нишләвең бу? Менә сиңа! Синең сасы аягыңны юып торыр дип беләсеңме әллә мине! Иснә менә, ни исе килә! — Зәйтүнә Кәнзелнең борыны төбенә үк «тәкә мөгезе» китереп терәде.

— Чат оятың юк икән, битсез! Чыгып кит хәзер үк, дүрт ягың кыйбла! — дип жикерде Кәнзел.

— Хәзер, хәзер, китәм лә. Алдыма тезләнеп аягым үпсәң дә, бүгеннән каласым юк син кипкән чабак янында. Төн түгел, сәгать тормаячакмын. Сәгать тә!..

Шул вакыт урамда машина төрелтесе ишетелде. Зәйтүнәнең күзләре елтырап китте. Ул бер мизгел генә тавышны кабат тыңлап торды да, ике кешелек киң караваттан жәймәсен сыдырып алып идәнгә жәеп, мендәрләрне бәйләргә керешге.

«Бусы да чын-чынлап китәр микәнни?» — дип кисәк кенә өметен өзде Кәнзел.
— Бер әйберемне калдырмаячакмын сез чабакларга. Талак, имеш, һай алла, ни ди бит, ни ди! Талак ди! Егылып үләрсең сүзләренә, — диде Зәйтүнә зәһәрләнә барып. — Кадим замандагыча куркытмакчы, гыйбат тилесе.
Кәнзел дәшмәде. Аның инде дәшәр чамасы юк. Ул аптыраган, шаккаткан, хәйран калган иде. Аңардан өченче хатын китә бит инде. Өченчесе!
Зәйтүнә Кәнзелгә бик үк теләп килмәде. Әнисенең яманатыннан шүрли төшкән иде. Тажылбанатны Карамалыда гына түгел, тирә-як авылларда да беләләр иде. Алай да Кәнзелгә килде. Тажылбанат үзе килеп сөйләште. Беренче күрүгә карчык йомшак кына табигатьле кебек тоелды. Кабаланмый гына, үз дәрәҗәсен белеп кенә сөйләр, мактанмас, шапырынмас. Килен булып төшкәч тә, яшьләр арасына кысылмады, һәр чак килене яклы булды.
Зәйтүнә эшчән, кулыннан килмәгән нәрсә юк, чая, кыю, тапкыр, җор телле, шулар өстенә табигать аңа зифа буй-сын да биргән иде. Ни галәмәттер, моңа кадәр хатын-кыздан тәм дә, ямь дә тапмаган Кәнзел Зәйтүнәне үлеп яратты. Нигә китә бу Зәйтүнә? Әллә ни дә әйтмәде бит ул аңа. Әйтик, бераз көнләште, сөйрәлчек дип сүкте ди. Шуннан ни? Ул бит аңа кул күтәреп сугу түгел, бармак белән дә чиртмәде. Танмый, баштагы хатыннарына кул яккалады, яратмаудан булса кирәк. Шуңа түзмәделәр, шуңа киттеләр. Моңа ни җитмәде?
— Тукта әле Зәйтүнә, Зәйтүнә дим!
Кәнзел кинәт идәнгә тезләнде дә Зәйтүнәнең аякларын кочты.
— Зәйтүнә җаным, китмә! Мин сине яратам, өзелеп яратам, Зәйтүнә!..
Хатын тынып калгандай булды, кулындагы төенчеген караватка ташлап, баш түбәсе пеләшләнә башлаган Кәнзелгә карап торды.
— Мескен әдәм син, Кәнзел, бичара!..
Кәнзел куырылып куйды. Бу сүз яшен суккандай тәэсир итте аңа. «Улмы, Кәнзелме мескен?! Кәнзелме бичара?!»
— Зәйтүнә, син аның белән чынлап та йөрдеңме? Дөресме шул? Дөрес, дөрес, кеше юкны сөйләмәс!
Зәйтүнә аны аягы белән этеп җибәрде. Кәнзел кул белән таянып чак кына егылмый калды.
— Кәнтәй! Үтерәм!..
Шунда өйгә Тажылбанат килеп керде.
— Ни бар, балалар? Нигә талашасыз болай?
Кәнзел, корт чаккандай, торып басты.
— Инәй, Зәйтүнә китәм, ди.
Тажылбанат чибәр йөзле килененә җирәнгеч бер караш ташлады, иренен бөрештереп, авыз читен кыйшайта төште.
— Кая китә?
— Наратбашка, бөтенләй, ди.
— Шуңа тезләндеңме, шуңа хатын алдында тез чүктеңме?
Кәнзел әнисенә ялварып карады.
— Кая синең ирлегең? Кая? — дип тавышын күтәрә төште Тажылбанат һәм: «Ни әйтергә тели тагын бу убырлысы!» дип аптырап калган килене янынарак килде. Тажылбанат, куе дегет кебек күзләрен чекерәйтә төшеп, бер мизгел килененә карап торды.
Чибәр иде килене. Кәнзел Зәйтүнәне төшергәч, Тажылбанат куанып бетә алмаган иде. «Ичмасам, чибәр-чибәр балалар китерер», дип уйлаган иде. Аннары аңа килененең җебеп тормавы, төшү белән фермага эшкә керүе, көрәп булмаса да, иш янына куш китереп, шактый мул итеп акча алуы ошаган иде. Янә тагын ул күпне күргән ха-

тын-кыз буларак шуны да күрде: Кәнзел Зәйтүнәне ярата, әйләнә-тулгана да, сәбәп табып, гел хатыны янында бөтерелә, өрмәгән җиргә утыртмый. Ләкин ул Зәйтүнәнең йөзендә, килеш-килбәтендә тагын бер нәрсә күргән иде: килене улын яратмый. Улына ул бу турыда әйтмәде. «Тота белмәс бу мәми авыз моны. Үз ишен табар да китеп барыр әле», дип юраган иде. Күңеле дөрес тойган икән.

Күзләрендә очкын уйнатып, зәһәрләнеп Зәйтүнә янына килеп басуга һәм килене күзләрендә курку түгел, нәфрәт чаткылары күргә, Тажылбанат үз гомерендә беренче тапкыр диярлек шүрли төште. «Тагын бер сүз әйтсәм, битемә чат иттереп төкерәчәк. Аннары килене абыстай битенә төкереп чыгып киткән дип авыз чайкаучыларның бетәсе булмас. Кирәкмәс, китсен. Минем умач бурзаена тиң түгел бу, май чүлмәге тышыннан билгеле».

— Китсәң, җәнҗалсыз гына кит инде, килен. Күрше-күләннән яхшы түгел бит,— диде Тажылбанат, кинәт йомшарып.

— Ярый,— диде Зәйтүнә кырт кына.— Сез дигәнчә итәрмен.— Һәм Кәнзел ягына шундый иттереп карап алды, тегесе хәтта куырылып куйган кебек булды.— Әйберләремне калдырмыйм, комачаулама, әнкәй.

— Иа аллам, бир сабырлык, бир сабырлык бәндәңә, — дип кабатлый-кабатлый, Тажылбанат борылып чыгып китте.

Бу хатыны да киткәч, Кәнзел аптырады да калды. Биткә-йөзгә чибәр генә, гәүдәгә таза гына ир-егет ич ул. Нишләп соң ул гына күңеленә охшаган кеше таба алмый?

Кулы эш белә иде аның, авылда үзен бик үк яратып бетермәсәләр дә, хаҗәте төшкәч, Кәнзелгә киләләр, ул аларга булыша, һәммәсенә ярарга тырыша иде.

Быел авылда электр тегермәне салып яталар. Су тегермәне киләсе елдан да калмас, диделәр. Ыкны буып мәшәкатьләнәсе булмаячак. Кәнзел кая барыр?

Иртәнге кояшның чыгуын күзәтеп, Кәнзел, яр өстенә баскан килеш, әнә шул турыда уйланды. Буа өстендә үрдәкләр бакылдый, казлар каңгылдап куя. Аръяктагы әрәмә өстендә, кош-корт оясы күзәтеп, өч-дүрт ябалак әйләнә иде.

Кәнзел бер турбинның капкасын күтәреп куйды да, кавызга су тулып шкиф әйләнә башлауга, икенче кавызның чыгырына ябышты. Терсәк буйлык ике тимер белән ул аны да тиз генә ачып җибәрде. Кичә кичтән үк мөшкәгә фураж тутырган иде, фуражер килгәнче шуны тартып куясы бар. Чыгырны нығытып куюы булды, күзе кавыз читендә ярда утырган балыкчы картка төште. Ул карт таң беленер-беленмәс һәр көнне диярлек шушында балык тотып утыра. Кәнзел аның каян икәнен белми, кызыксынганы булмады. Бүген исә аның тәмәке тартасы килә иде, гөнаһ шомлыгына каршы, кесәсендә сигарет юк, ә бу карт һәр вакыт тәмле-тәмле сигаретлар тарта. Кәнзел шул картка таба китте. Картның өстендә күк бәрхет пинжәк, башында саргая башлаган, читләре сәлперәйгән капрон эшләпә. Кәнзелнең күргәне бар: картның башында бер бөртек тә чәче юк. Иртәнге кояш нурларында ул пеләш башын кыздырып алырга ярата. Бүген нигәдер эшләпәсен салмаган. Кәнзелнең карт белән сөйләшкәне юк диярлек. Кайчак ул яр кырыена килеп баса, чоңгылланып бөтерелгән су күбеге эчендә кайнашкан калкавычка карап тора. Карт та калкавычтан күзен алмый. Шампан шешәсе бөкесеннән ясалган калкавыч кайчак чоңгыл уртасына килеп эләгә дә бер урында бөтерелеп тора башлый. Нәкъ шунда балык каба. Калкавыч суга кереп чума. Картның шул чак кармак сабын җиңелчә генә тартып куюы бик җитә. Айкалып

бөтерелеп торган, шуңамы аксылланып калган судан балыкның яшькелт башы күренә, аннары көмеш кебек тәңкәләре ялтырый... Кило чамасы кушбашны балыкчы карт аяк янындагы брезент капчыкка сала. Янә ашыкмый гына кармагына суалчан кидерә һәм иплэп кенә җепне күбекләнеп торган суга ташлый. Шуннан соң гына ул Кәнзелгә дәшә.

— Әйдә, утыр, Кәнзел, көйрәтеп җибәр.

Кәнзел бер сигаретны авызына каба, икенчесен колак артына кыстыра.

— Ал тагын. Ал, ал, оялма!

Кәнзел тагын өч-дүрт сигарет ала һәм җайлап кына түш кесәсенә салып куя.

— Кичә хатыныңны аергансың дип ишеттем. Хакмы шул?

— Бусысын аермадым, үзе китте. Бер тракторчы белән сөйрәлдесөйрәлде дә шуңа ябышып китеп барды, кәнтәй.

— Шәп түгел, — диде карт.

— Кая инде шәп булсын...

— Ничек соң, авыл Советы председателе бик бәйләнмиме?

— Дәшми әле, теге вакытта талкыган иде бераз. Нигә язылышмыйча өйләнәсең дип. Ә мин бәлкем аны сынап карар өчен язылышмыймдыр. Никах укытасың да — вәссәлам!

— Ай-һай. Китә-нитә калса, судлашып торасы юк дисең инде?

— Шулай дисәм, ни әйтерсең?

— Шәп түгел.

— Нигә?

— Мин авыл Советы председателе булсам, сине әллә кайчан судка бирер идем. Икенче хатыныңны аергач та.

— Син түгел шул, Фәхри Бәдриев утыра анда. Ә ул үзе дә салып биргәнне читкә куймый.

Балыкчы карт Кәнзелгә өнәми генә карап алды. Кәнзел аңарда ниндидер усал, әмма таныш усаллык чалымнары күреп, шүрли калды, бу чит-ят кешегә артыграгын әйтеп ташлавын абайлады.

— Син минем кем икәнемне белмисең булса кирәк, егеткәй?

— Кем дип... Пенсионердыр.

— Пенсионер шул.

— Һа-һа-һа! Их, картлач, картлач, — Кәнзел аның җилкәсенә кулын салды. — Мин сине белмим, син мине белмисең. Бәлкем син үзең дә бер белән генә канәгать булып яшәмәгәндерсең әле! Ә?! Шулаймы? Әллә гомерең буена әүлия-дәрвиш идеңме?

Картның күзе батып барган калкавычка төште. Кармак сабы дугаланып сыгылып килде, әмма калкавыч судан чыкмады.

— Тот! — диде карт, Кәнзелгә кармак сабын сузды. — Тот, төшеп савып алам.

Балык яр кырыенарак килгәч, карт яр астына төшмәкче итте, ләкин Кәнзел аның җиңеннән тотты.

— Үзем. Биредә кимендә дүрт метр бар. Әҗәл эзләмә.

Кәнзел, сыек тал чыбыгына тотына-тотына, иплэп кенә баса-баса, яр астына төште. Биредә зур-зур ташлар, кайчандыр кагылып һәм сынып калган субайлар чыгып тора иде, Кәнзел балыкны кыя белән яр кырыенарак тартып китерде дә калкып торган таш өстенә басты, аннары түше белән икенче ташка ятты һәм кинәт яр кырыенда кайнашкан балыкның саңагыннан эләктереп алды.

Бу саргая башлаган терсәк буе сазан иде. Кәнзел шуңа аптырады: камыш арасында, тыныч буа өстендә йөзә торган сазан нигә турбин астына төшкән?

— Әйдә, мен тизрәк,— дип кычкырды карт. Аның авызы колагына җиткән, тез өстендәге эшләпәсен кавыз буена ук ташлаган иде.

Кәнзел башта балыкны болгап яр өстенә ыргытты, аннары тырмашып үзе менде. Менгәндә үк үзләренә таба килүче авыл Советы председателе Фәхрине күрде. Кәнзелнең эче жуу итеп китте. Фәхрине күрмәмешкә сабышып, ул тез башын каккалап торды, дәшми генә китмәкче итте. Шунда Фәхри аны туктатты.

— Сабыр ит әле, Кәнзел, — дип хәйран калып балыкка карап торган картка кулын сузды. — Исәнмесез, Шакирҗан абый! Иртәләгәнсез бүген, әй! Иртәнге якта каба шул балык.

Кәнзел кавызга табарак китте, күперчеккә басып, үрелеп юынып алды.

— Өйгә керә тор, мин хәзер, — диде Фәхри, аңа таба борылып.

Кәнзел киткәч, ул балыкчы картның терсәгеннән алды, яр кырыннан бер читкәрәк әйдәде.

Тагын күңеле нидер сизенеп, уфтана-көрсенә башлады Кәнзел. «Ник килде икән?» Тегермән өенә керүгә, тәне кинәт бөтәннән эсселе-суыклы булып китте. Менә шунда булган хәл исенә төште аның. «Тәзкирә?» — дип пышылдады ул. Тукта, нигә курка соң әле? Тәзкирә моннан ике ай элек кияүгә чыкты инде, Зөфәр белән тора. Һәм без аның белән квиты. Нигә курка соң әле? Ни гаебем бар минем бу Фәхри алдында? Шулай ук Зөфәр?..

Кәнзелнең күз алдына Тәзкирә белән булган хәл килде. Тәзкирә һәр көнне тегермән янындагы чишмәгә суга йөри иде. Көн саен Кәнзел аны яр башына басып каршы ала, бер сүз әйтми, кызның су алганын күзәтеп тора, аннары карашы белән умартачы өенә кадәр озатып кала. Кызның тулышып, чибәрләнеп, буй житкереп килгән чагы Тегермәннән ике йөз метрда гына торучы умартачы Халикъ кызына Кәнзелнең күзе әнә шулай төште. Башта кызга Кәнзелнең күзәтүе ошамый иде. Тора-бара ул моңа иялөшә төште.

Бу вакытта Кәнзел тол ир сыманрак яши иде. Тәзкирә ишле семьяда туып үскән, аннары ул кадәр күзгә бәрелеп торырлык чибәрлеге дә юк, әмма яшьлек бит ул үзе чибәрлек, Кәнзел моны күрә иде.

Бер тапкыр ул Тәзкирәне тегермән өенә чакырды. Кич иде, ут алып сөйләшеп утырдылар. Кәнзел аңа ялгызлыгы, бәхетсезлеге турында зарланды. Шунда кинәт ут сүнде, Тәзкирә курка калды, торып ишеккә таба китмәкче итте, әмма Кәнзел шунда аны кочаклап алды. Аннары Тәзкирәне кулына ук күтәрде дә жилтерәтеп зыр-зыр әйләндерә башлады.

— Мин сиңа өйләнәм, мин сине менә шулай гел кулымда гына күтәреп йөртәчәкмен...

Аннары барысы да төштә кебек кенә булды. Түр яктагы лампочкадан сәкегә тонык кына якты төшә, Тәзкирә сулык-сулык итеп елый. Кәнзел тезләнгән килеш аны юата: өйләнәм, ди, син — минеке, ди.

Ләкин Кәнзел Тәзкирәгә өйләнмәде. Кызны флоттан кайткан таза, чибәр, хәрби хезмәткә киткәнче үк Тәзкирәне яратып йөргән Зөфәр ошатты һәм, күп тә йөрмичә, өйләнеп тә куйды.

Икенче көнне иртә таң белән ул тегермән янына килде. Килде дә Кәнзелне чакырып чыгарды һәм аны култыклап яр кырыена алып китте.

Кәнзел сизенде: акланырга жыенды. Ләкин Зөфәр аңардан берни сорап тормады, киерелеп торып Кәнзелнең яңагына сугып жибәрде. Күзләреннән утлар чәчрәгән Кәнзел таллар арасына ташланды, әмма Зөфәр житезрәк булып чыкты, аны биленнән эләктереп алды да, күтәреп, яр астына атты. Кәнзел бил тиңентен суга барып төште һәм кабаланып ярга менә башлады:

— Зөфәр, туктале, тимә миңа, зинһар...

— Мен, мен әле, тизрәк! — диде Зөфәр, бер ни булмаган кебек, тәмәке кабызды.

Кәнзел курка-курка яр өстенә менеп җиткәч, аның күкрәгенә типте. Кәнзел тагын яр астына очты. Бу юлы инде авыз-борынына су тулып, ярга чыга алмыйча маташты. Ниһаять, көч-хәл белән аягүрә басты, дер-дер калтыранып, яр кырыена килде дә елар дәрәҗәгә җитеп:

— Зөфәр, мин гаепле түгел, ул... үзе килде.

— Мен әле, мен бире, эт аламасы. Инде алай икән, еламый гына сөйлә!

— Якынрак кил, болайрак дим!

Кәнзел, яр кырыеннан кузгалырга куркып, ике кулын алга сузды да җиргә тезләнде.

— Энем Зөфәр, алла хакы өчен.

— Якынрак кил дим!

Кәнзел тезе белән шуышып Зөфәргә таба килә башлады.

— Зөфәр дим, зинһар!..

Кәнзелнең кыяфәте ямьсез, куркыныч иде: аның башындагы кепкасы суда калган, чәченә балчык сыланган, иреннәре күгәреп киткән, күзләрен кан баскан.

— Кил, кил, курыкма! Тәзкирәне җәберләгәндә курыкмагансың бит! Я, кил диләр сиңа!

Зөфәр аны изүеннән эләктереп алды, аягүрә бастырды.

— Әйт әле, хәшәрәт, син ул турыда берәрсенә сөйләдеңме? Сөйләдеңме дим?!

— Берәүгә дә әйтмәдем, Зөфәр, беркем дә белми.

— Ант ит, җир упсын диген!

— Беркемгә дә әйтмәдем. Беркемгә дә. Кичер мине, Зөфәр. Кичер. Ипи йөзен күрмим менә...

Кәнзел чыраен сытып елар дәрәҗәгә җитеп ант итте.

— Инде мактанып аның яманатын сатып йөрсәң, әҗәлең менә шунда булыр, белеп тор!

— Зинһар гафу ит, гомер ишетмәссең, каберемә кадәр ишетмәссең. Ипи тотып ант итәм! Ике күзем чәчрәп чыксын.

Зөфәр аны каты итеп ярга таба этеп җибәрде. Кәнзел артка китәкитә, туктап кала алмыйча, тагын аска очты. Бу юлы ул:

— Үтерәләр! — дип аваз салды.

Зөфәрнең моңа җен ачуы чыкты. Кәнзел артыннан ул да яр астына сикерде. Тез тиңентен суда килеш, ул Кәнзелне чәченнән эләктерде дә яр кырыенарак тартып китерде, судан башын гына чыгарды.

— Кычкырасыңмы?

— Һе... һе... ут...

Зөфәр аның башын тагын берничә секунд суга батырып тотты. Аннары Кәнзелне яр буенарак китерде.

— Кычкырасыңмы тагын?

Кәнзел дәшмәде, кисәк бата башлады. Зөфәр аны тагын җилкәсеннән алды да яр башына сөйрәп мендерде, тегермән өенә өстерәп керде, идән уртасына сузып салды.

— Фуу, эт җан! Тор!!

Кәнзел күзләрен ачты, бәбәкләрен акайтып, түшәмгә текәлде.

— Әгәр дә мәгәр ишетәм икән, — диде Зөфәр һәр сүзенә басым ясап, — әҗәлең кавызда булыр, эт җан!

Зөфәр киткәч, Кәнзел идәндә бик озак ятты, аның колак төбендә өзлексез нидер чыңлый, күкрәге чәнчешеп әрни, бер аягы берни тоймас хәлгә килгән иде.

Менә ул көч-хәл белән торып утырды, башын аска иеп, пычрак итекләренә карап катты.

— Моның өчен мин сине гомергә кичерәчәк түгелмен, мир хәерчесе, гомергә!..

Кәнзел берни Тоймаган аягына сукты да гарьлектән еләп җибәрде. Күзләре кызарганчы, тамак төбе әчеткәнче елады, аннары өнсез калып тик утырды. Бу хәлнең чын булуына ул ышанмый, гүя бу төш кенә, уяну белән бар да юкка чыгар һәм барысы да онытылыр дип уйлады. Әмма утыра торгач ышанды ул: бу төш түгел. Зөфәр, Тәзкирәнең ире, Кәнзелне эт итеп кыйнап китте.

... Ишектә Фәхри күренде. Ул түр яктагы өстәл янындагы озын эскәмиягә утырды.

— Кил әле бирегәрәк, Кәнзел.

Кәнзел дәшмәде, ул яңа гына кичергән тәэсирдән айнып җитмәгән иде әле.

— Ишеттеңме әле Зөфәр Бадыйковның хатынын ташлап Карамалыдан ук китүен!..

Кәнзел, йөзенә кайнар су бөркелгәндәй, башын күтәрде, күзләрен шарландырып Фәхригә карап катты. «Минем каргыш төшкән», — дип эчтән генә сөенеп куйды ул.

— Ничек? Кайчан?

— Бүген төнлә. Шәп егет иде, кулыннан килмәгән эш юк иде, алтын куллы иде. Беләсеңме, мин бирегә ни өчен килдем? — диде Фәхри.

Кәнзел, җилкәсен җыерып, куырыла төште, тез өстендәге кулы биеп тора башлады. Фәхри моңа игътибар итте, аңа таба борылыбрак утырды.

— Тәзкирә Зөфәрнең китүенә Кәнзел абзый гына гаепле дип бара. Ул төнне Зөфәр тегермәнгә килгән булган икән. Ләкин биредә син булмагансың, Хафиз гына булган...

— Зөфәрне ул көнне күрмәдем дә, белмим дә. Яла бу!

— Ашыкма, ул турыда беләбез. Синең биредә булмавыңны да беләбез. Мине менә нәрсә кызыксындыра: синең хатының Зәйтүнә аның белән булган.

— Мин берни дә белмим. Ул миннән аерылып китте. Минем ни эшем бар аңарда. Кәнтәйлеге бар иде, эзләгәнен тапкан, күрәсең.

— Мин Зәйтүнәне акламыйм, ләкин сине дә якларга исәп юк. Тәзкирә әйтә...

Кәнзелнең йөзе кинәт үзгәреп китте. Күз төбендәге капчык биеп тора башлады.

— Ни дисәң дә, инде буласы булган. Соң инде, — диде Кәнзел.

— Соң түгел, Кәнзел. Ә бит теге вакытта Тәзкирә килеп әйткән иде. Әшне һичкемгә әйтми, кузгатмый тордым. Чөнки Зөфәр кайтты, аның артыннан йөри башлады, өйләнде. Торып китмәсләрме дип өмет иткән идем, — Фәхри, тирән сулап, көрсенеп куйды. — Ә ул алай булмады, язмышлар, чылбыр боҗралары кебек, берсе-берсенә бәйләнгән икән шул. Хатынының шундый икәнен белгәч, синнән үч алу нияте белән, Зәйтүнә белән йөри башлаган. Шул гарьлегеннән синең Зәйтүнәне алып киткән. — Фәхри бераз сүзсез калып, бармак буыны белән өстәлне шакып утырды. — Менә мин күзәтәм-күзәтәм дә сине, Кәнзел, шаккатам. Кая таба тәгәрисең син? Ничәмә хатын аердың, алма кебек кызга кызыккансың... Ә үзең һаман иректә әле. Сөяген төрмәдә черергә тиеш синең кылган бу явызлыкларың өчен!..

Фәхри китүгә, тегермән өенә балыкчы карт килеп керде. Ул өстәлгә бер ярты аракы, берничә пешкән йомырка, өч-дүрт кисәк колбаса, калай кружка, ярты тавык чыгарып тезде. Шуннан соң гына, азык төялгән биштәрен читкәрәк куеп, сәке башында утырган Кәнзелгә дәште.

— Әйдә утыр, Кәнзел туганый, капкалап алыйк. Югыйсә, балык белән мавыгып, тәмам ашаудан калынды.

Кәнзел өстәл янына теләр-теләмәс кенә күчте, ә башында һаман шул бер уй бөтерелде: «Тагын китәргә туры килер микәнни «закон

йортына?» Кәнзел аның кунак йорты түгел икәнен яхшы белә. Кайтуына ике ел гына бит әле.

Балыкчы карт кружкага бер йотым гына аракы салды, күтәреп куйды да бер кисәк колбаса капты.

— Усал да соң, каһәр. Җитеш әйдә, тартынып торма. — Кәнзел дәшмәде. Шуннан карт аңа карап-карап торды да: — Хатының өчен уфтанасыңмы, әллә башка берәр кайгы башыңа төштеме? — дип сорады.

— Барысы белән дә кызыксынасың үзең, картлач.

— Мин белмәгән нәрсә юк иде бу районда, — карт тагын аракы салды, кружка белән колбаса кисәген Кәнзел алдынарак этәреп куйды.

— Әйдә, тот, кайгың онытыла төшәр, кайгыңны ю.

Картның соңгы сүзе Кәнзелнең колак төбендә зыңлап торды. «Кайгыңны ю, кайгыңны ю.»

Кәнзелнең тизрәк эчәсе, исерәсе килде. Ул кружкадагыны бер тын алуда эчеп җибәрде. Аннары башын иеп уйга калды, хәтта колбасага да үрелмәде. Карт аңа гаҗәпләнеп карап торды-торды да:

— Авызыңа ризык кап, үтең янар, — диде.

— Кирәкмәс, моны гына эчеп караган бар. Күпсенмәсәң, салып бир тагын берне.

Кәнзел икенче кружканы да бушатып куйды.

— Җилле эчәсең үзең. Кайда өйрәндең?

— Закон йортында өйрәттеләр.

— Әйтәм, гел Себер зимагурларыча кыланасың, — диде карт. — Анда да булырга өлгердеңмени инде?

— Сиңа соң барыбер түгелмени?

— Түгел шул. Син, туган, бер хакыйкатьне аңламыйсың, ахры. Тормыш ул, энем, чәбәләнгән йомгак кебек — бөтерелә, бутала, айкала. Менә син миңа хатыным китте дидең. Өч хатынга өйләнеп карадым дисең. Синең соң яратып караганың бармы? Әллә чын мәхәббәтне табу өчен җиде хатынга өйләнү зарурмы? Ул, энем, бер генә буладыр инде, югыйсәң, очсызланыр, кадере калмас иде. Яңа мәхәббәт искене үтерә дип тә сөйлиләр. Юк сүз ул, энекәш, яңасы да юк мәхәббәтнең, искесе дә юк, чын мәхәббәт искерми ул. Чын мәхәббәт ул саф алтын кебек, йөргән саен шомара, ялтырый, гүзәлләнә генә бара. Әйе, әйе, син авыз ерма, ул дөньяда иң изге табыш. Ә синең кылганың? — Карт тез өстендә яткан, буыннары кантарланып каткан кулларына беравык карап торды. — Кыргыйлык ул көчләү, вәхшилек.

Балыкчы карт, колбаса кисәге кабып, иренеп кенә чәйни башлады.

— Ә бит сине чынлап та утыртып куюлары бар, — дип дәвам иттерде ул. — Булмас димә. Әтиең кем синең, әниең кем? Әниеңне гаепләмим, ир бала гадәттә әнисенә охшамый. Ә менә әтиеңне гаеплим. Әллә соң ул да синең кебек хатын-кыз артыннан өстерәлдеме?

Кәнзел дәшмәде. Аның күкрәгеп нидер көйдерә иде. Үкенү идеме бу, болай да җәрәхәтле җанга тоз сибеп, акыл сатып утырган картка карата туып килгән ачу зәһәре идеме — зиһене чуалды, аңламады. Әмма бөтен дөньясына каны кайнавы хак иде. Ул буыннары агарганчы йодрыгын йомарлады, көрсенеп-ярсып тешен шыгырдатып куйды.

— Салып бетер әле!

— Эч әйдә, эчеп кал. Анда бирүче булмас...

Кәнзел йодрыгы белән өстәл почмагына сугып алды. Буш кружка сикереп куйды.

— Менә-менә, чат җүләр син, чат тиле. Язылышмыйча өч хатын белән торып карагансың, закон сиңа тимәгән, хакы юк кебек иде. Ә менә хәзер уфтан инде.

— Кем мине судка бирә алсын. Кияүгә чыкты, ике айдан артык тордылар. Юк инде, картлач, алай булмас ул!..

— Дулама, мин сиңа судья түгел, тикшерүче дә түгел. Хатыннарыңа кем никах укыды?

Кәнзел сүрелә төште, башын иеп, итек очларына карады.

— Әтәй, Гайзулла мулла.

Ярый әле, Кәнзел балыкчы картның йөзен күрмәде. Югыйсә, исе-акылы китәр иде. Гайзулла исемен ишетүгә, карт агарынып китте, калтыранган бармакларын тыярга теләп, кулларын ике тез арасына кысты.

— Димәк, син Гайзулла малае?

— Үзе, — диде Кәнзел һәм торып басты. Балыкчы аның беләгенә ябышты.

— Тукта, сабыр ит!

Балыкчы карт нидер әйтергә җыенды, әмма соңгы мәлдә капыл тукталып калды. Тегермән өенә Тажылбанат килеп керде. Керде дә каударланып Кәнзел янына килде.

— Балам, бәбкәм, бөтен авыл синең турында сөйли.

— Инәй, кирәкми, — диде ялварулы рәвештә Кәнзел.

Тажылбанатны ишектә күрүгә, балыкчы карт арты белән борылып утырды. Тажылбанат аңа игътибар итмәде, аның үз кайгысы кайгы иде. Ләкин ниндидер бер мизгелдә аның карашы балыкчы картка тукталды. Юк, юк, бу кешене ул башын киссәләр дә таныр иде. Тажылбанатның күз алдында моннан күп еллар элек булган хәлләр яңарды. Үзенә текәлгән күз карашын тоеп, балыкчы карт та аңа таба борылды.

— Йа аллам, йа ходаем, Шакирҗан! — диде Тажылбанат һәм буыны йомшап, хәлсезләнеп караватка барып утырды. — Күпме еллар үтте, килмәдең, күренмәдең...

Кәнзел һични аңламыйча бер әнисенә, бер балыкчы картка карады.

— Инәй, нәрсә сүлисең син?

— Тамагым кибеп китте, су бирче, улым.

Кәнзел аңа чүмеч белән су китерде. Чырае агарынып калган Тажылбанат калтыранган куллары белән чүмечкә үрелде, әмма алмады, эчмәде, балыкчы картка карап, күкрәк түреннән чыккан әрнүле тавыш белән:

— Шакирҗан, коткар баламны! Ит ярдәм. Аны утыртмакчылар, — диде.

Кәнзел кулындагы чүмеч шап итеп идәнгә төште. Абыстайның апак күлмәгенә, кызыл читегенә, бөрмәле бала итәкләренә су чәчрәде.

Балыкчы карт әле Тажылбанатка, әле чырае үзгәргән Кәнзелгә күз ташлап алды һәм, утырган урыныннан кузгалып, нидер әйтмәкче булып авызын ачты, мәгәр кузгала да, дәшә дә алмады, очып китәргә торган кошны әләктерергә теләгәндәй, йөрәк турын учлап тотты да акрын гына идәнгә шуып төште...

## 20

Туган авылы Карамалыга Гөлзифаның беренче генә кайтуы түгел иде инде. Шулай да туган як басуларын күргән саен, ул дулкынлана, теле языла, күз алдына бала чагы, житкән кыз чагы, Әюбе белән гомер иткән еллары килә.

«Москвич»ның арткы урындыгында Гариф белән Әдилә утырган. Гөлзифаны алга, шофер янәшәсенә урнаштырганнар. Кыр ышыклау урман полосасы юлның әле бер ягына күчә, әле икенче ягына. Басулар өстендә рәшә дулкыны тибрәнә. Зур күл артындагы усак урманы да рәшә эчендә калган.

Машина Чәчәганак тавын төшә башлады. Чишмәгә житте.

Чәчәганак чишмәсенең терекөмеш кебек чиста суы вак ташлар арасыннан һаман чылтыр-чылтыр ага да ага. Күп хәлләргә шаһит-тыр бу чишмә. Болгарлар килгәнче биредә Чәчәк Ана кабиләсе яшә-гән, имеш. Ык буйлары Бөек Болгар дәүләтенең бер төбәге булып киткәч тә, Урта Азия сәүдәгәрләре Болгарга йөргәндә дә, аннан соң да юлчылар һәр вакыт шушы чишмә янына туктап, кунып, ял итеп китә торган булганнар.

Аклар өй-каралтыларын яндыргач, Әюбен юк иткәч, Карамалыдан баласын алып чыгып киткәндә Гөлзифа да шушы чишмә янына тук-тап, әнә шул ташка утырып соңгы тапкыр Карамалыга карап торган иде.

Печән җыярга килгәч, Әюбе белән шушы ташка утырып ял иткән-нәр иде. Шомырт, карлыган, балан, бөрлегән өлгергәч, балыкчы Кор-бан бабалары аларны көймә белән башкорт ягына чыгарыр иде. Көй-мә ярга төртелүгә, Әюп сикереп төшәр иде дә Гөлзифасын көчле кулларына күтәреп, әрәмәгә алып кереп китәр иде. Корбан карт аларга:

— Кайтыр якта сөрән салырсыз, чыгып алырмын, — дип, мыек астыннан гына елмаеп, үзенең дә яшьлеген исенә төшереп, озатып ка-лыр иде. Шул көнне алар ике капчык балан җыйганнар иде. Һәм шул көзне Әюпне солдатка алдылар.

Өч ел гомерен патша окопларында бурсып, немецларга каршы су-гыша-сугыша бетләп, интегеп беткәч, бер изге бәндә аның күзен ач-кан — качып китәргә һәм авылдашларын байларга каршы көрәшергә өндә дип өйрәтеп җибәргән. 1917 елның җәендә Әюп хат-хәбәрсез генә авылга кайтып төште. Белгәне белде аның Карамалыга кайтканын, белмәгәне белми дә калды. Әюп нииндидер революция турында, патша тәхеттән төшерелгәннән соң Россия белән идарә итүне вакытлыча кулына алган Керенскийны тиздән большевиклар себереп ташлая-чаклары турында сөйләде. Имеш, озакламый хөкүмәт эшче һәм крестьяннар кулына күчәчәк. Алпавыт утарларын, бай-мулла җирлә-рен крестьяннарга бүлеп бирәчәкләр.

Шуннан соң Гөлзифага таныш булмаган агайлар, алар өенә җые-лып, ни турындадыр озаклап киңәшә торган булып киттеләр.

Әюбе Вакытлы хөкүмәтне эт итеп сүккәндә, озакламый Рәхим байның үкчәсенә басабыз дип өндәгәндә, Гөлзифаның коты алынды, ялгыз калган минутларда бишектәге баласын күкрәгенә кысып, алла-дан мәрхәмәт сорады.

Без капчыкта ятмый, ә Әюп без генә түгел иде, кемдер качкын солдатның Карамалыда яшеренеп ятуын ил өстенә чыгарды. Рәхим бай белән староста этлекләрен тиз күрсәттеләр: волостька атчабар җибәреп хәбәр иттерделәр һәм Әюпне тотып алып янә солдатка озат-тырдылар. Ләкин бу юлы инде ул озак йөрмәде. Беренче кар белән, чанага кырын ятып, көпә-көндез кайтып төште. Халык аһ итте.

— Тимерче Әюпне влач ясаганнар ди!

Әюп Латыйпов бүрегенә кызыл тасма бәйләгән, билендә наган, куенында мөһерле кәгазь, газеталар.

Ул кайту белән үк Гөмберт Фәризунны авыл буенча йөреп җыен җыярга җибәрде. Җир турында сөйләшү була дигәч, халык, янгынга килгәндәй, тиз җыелды. Гөжләп торган халык арасыннан мондый сүзләр ишетелде:

— Рәсәй тагын дәүләт башын алыштырамы әллә?

— Патша февральдә үк төшерелде, нинди патша алыштыру ди ул һаман: авызыңнан җил алсын! Тфу, тфу, тәүбә, диген...

— Сөбханалла, сөбханалла, ахырзаман җитәдер...

Гөлзифа да, баласы янында күрше Галимәне калдырып, Әюбе бе-лән җыенга килде. Мәдрәсәгә җыелган халык эчкә сыймады, ишек-

тәрәзәләр алынды. Күрсәң, тәмам мәхшәр дияреең. Менә Әюп җыеи өстенә калкып чыкты.

— Җәмәгать, авылдашлар! Вакытлы хөкүмәт таратылды. Дәүләт башына Ленин җитәкчелегендәге эшче-крестьяннар власте килде. Шушы көннәрдә генә Питердә эшчеләр Вакытлы хөкүмәтне бәреп төшерделәр һәм властьны үз кулларына алдылар. Яңа дәүләт җир һәм тынычлык турында Декрет игълан итте. Менә ул!

— Укы, укып күрсәт! — дип шаулаштылар.

Әюп кайда укып, кайда аңлатып, яңа дәүләт тарафыннан игълан ителгән бу Декретны халыкка җиткерде.

— Җир-урманнарны, ишан, алпавыт, бай, мулла җирләрен ярлыларга бүлеп бирергә. Рәхим байга да җирләреннән колак кагарга туры килер.

— Хак әйтәсең, күп имде Карамалы халкын!..

— Кайчан сугыш бетә, шул турыда әйт син безгә, Әюп туган. Яшәр әмәлләр калмады...

— Җәмәгать, туганнар, — дип күтәрелде берсе. — Рәхим байның җирен-малын бүген үк ярлыларга өләшик. Әюп туган әйтә: Ленин үзе кушкан, ди. Җәмәгать, әйдәгез Рәхим бай утарына!..

Халыктан бу хәлне көтеп бетермәгән Әюп дулкынланудан бер мәлгә каушый калды. Аларны болай тиз кузгатып булыр дип уйламаган иде ул. Халык ишек-тәрәзәгә ташлануга, Әюп янәшәсендә басып торган Гөлзифага:

— Бар, бала янына кайт, ирләр арасында йөрмә, — диде һәм, кузгалуга, Гөлзифа аның шинель чабуына ябышты.

— Җибәрмим, җибәрмим мин сине бер кая да!..

Ләкин Әюпне аңардан тиз аерып алдылар. Урамга чыгуга, Әюп төркем алдына йөгерде, һәм җил-җил атлап Рәхим бай утарына таба киттеләр.

Әюпнең шинеле җилбәгәй киткән, ул, эсселәп, бүреген салып кулына тоткан иде.

Аның шулай шәбәеп китүен күреп, Гөлзифа: «Атасы, башыңа ки, салкын тияр!» — дип кычкырырга теләде, хәтта төркем артыннан йөгермәкче итте, ләкин шул мәлдә аның каршында, җир астыннан чыккандай, Гайзулла пәйда булды.

— Үләсе мал баз эзләр, диләр, шуңа ашкына Әюбең, — диде Гайзулла, күзләрен алаландырып, һәм тиз генә китеп барды.

— ...Менә, әни, Карамалыңа да килеп җиттек, — диде моңа кадәр Әдилә белән сөйләшеп барган Гариф.

— Әйе, шушы авылда туып үсте инде, шушында атаң белән гомер итте әниең, балам. Әй, улым, килгән-килгән атаң күмелгән җирне тапсаң икән син. Теге вакытта эзләп-эзләп тә тапмадылар бит. Шуңа җаннарым әрни, ичмасам, каберенә чәчәкләр салыр идем...

— Куй инде, әни, елама, шатлан, туган авылыбызга кереп барабыз түгелме соң...

— Авыл авылдыр инде, — диде Әдилә, бер дә исе китмәгәндәй.

Әдилә шулай диюгә, шофер аңа әйләнеп карады һәм юлга күзен төбәп, үз алдына сөйләнгән кебек тезеп китте:

— Асфальт юллар юк шул әле бездә. Аның каравы, келәмдәй яшеллек, сулап туймаслык саф һава, буы чыгып торган яңа сауган сөт бар. Аяк очында гына елга. Телисең — төшәсең дә коенасың, телисең — кер чайкыйсың, телисең — балык тотасың. Карамалы халкы ул бит борынгы халык. Чәчәк Ана әбинең ыруы яшәгән тау куышы әле дә булса бар. Кызыксынсагыз, барып карый аласыз. Куышның диварларына хайваннар рәсеме төшерелгән, борынгы бабаларыбызның сәнгате...

— Хәйран икән. Сез, алай булгач, Чәчәк Ана токымнары буласыз инде?

— Һәм син дә, Әдилә. Онытма, әтиең бит шушы авылда туган кеше, — диде Гариф, Әдиләнең иңбашына кагылып.

— Ничек бер ел гомеремне үткәрермен икән мин монда?

— Теләмәсәң, китә аласың, дускаем.

Әтисенең сөйләшү рәвешендә үпкә тоеп, Әдилә аның җилкәсенә башын салды.

— Артык яхшы күңелле кеше син, әти. Тыңлыйм-тыңлыйм да үзеңне — шаккатам. Намусыңа тузан кундырырга да куркасың кебек.

— Ә син аны, намусыңны диюем, пычратып юуны мәртәбәрәк күрәсеңме? — диде моңа кадәр дәшми утырган Гөлзифа әбисе. — Әбиеңне санга сукмаган гына җитмәгән, атаң белән үртәшәсең инде хәзер...

Ул арада машина Гарифларның чыбык очы карендәшләре булган Фәһимәләр турына килеп туктады.

— Кайтып җиттек кебек, кордашлар, — диде шофер.

Фәһимә аларны капка төбенә чыгып көтеп тора иде инде. Гөлзифа апасын ул гөр килеп каршы алды. Исәнлек-саулык сораша-сораша, Гөлзифаның әйберләрен, кунакның кулын да орындырмыйча, өйгә алып кереп китте.

Әдилә түргә үтте, тәрәзә каршындагы кечкенә диванга барып утырды. Килер-килмәс борын әтисе белән әбисе үгетен тыңлау аның ачуын китергән иде, шуңа бераз турсаеп торды. Әмма аңа игътибар итүче булмады. Әдиләнең күзе тәрәзә каршындагы сәрби агачына төште. Җил исеп куюга, агач яфраклары тәрәзә пыяласына тиеп-тиеп китә. Сине генә дәшкән, сине генә күрергә теләгән берәү тәрәзә чиртә кебек.

Самавар өлгерде. Гөрләшеп бергә-бергә чәй эчтеләр. Чәйдән соң Гариф эшенә китте. Гөлзифа карчык карендәшеннән кәҗә мамыгы турында белеште. Ахирәте Хөббениса карчык кайчандыр алар гомер иткән нигездә тора иде. Күрше булмасалар да бергә үстеләр, кичке уеннарда бергә булдылар, абыстайга сабакка йөрделәр, Рәхим байга уракка бергә чыктылар. Заманында бик якыннар иде алар. Узган кайтуында барып килергә вакыт тимәде. Мамык сылтавы белән барып күрим, ичмасам, үзен дип, Гөлзифа урамга чыкты.

Һәй, гомер дигәнең, кайчан гына әле шушы урамнан каюлы алъяпкыч бәйләп, ояла, тартына, — гүя бөтен авыл аңа карап тора — түбән очка, Идрис абзыйларына төшәдер иде Гөлзифа. Алар да әнә Гөлзифа киткәч икесе тиң гүр иясе булганнар. Егерме беренче елгы ачлык алып киткән үзләрен. Ә менә бу йорт авыл халкын калтыратып торган Ахун старостаныкы иде. Ахунны Себергә сөргәннәр, диделәр, кем тора икән хәзер монда? Өе һаман шул, бүрәнәләре генә каралган да түбә калайлары купкалаган. Урам яктагы карт тупылларны төптән үк кисеп, яшь үсентеләр утыртканнар.

Үзгәргән авыл, үзгәргән. Яңадан-яңа өйләр, һәммәсе шифер яисә калай түбәле, һәммәсендә телевизор антеннасы. Кешеләренең киенүләре дә шәһәрнекеннән ким түгел, бар да чәчкә кебек киенгәннәр, күзләрең камашыр. Казанда һич кайгысыз торса да, күңеле һаман шул туган авылга тарта бит. Бөтенләй булмаса да, бер-ике елга торып калыр иде, кайтыр карендәшләре юк. Фәһимә дә кышны шәһәрдә яшәгән малайларында чыга, җәйләрен генә авылда тулгана, бер аягы авылда, бер аягы шәһәрдә, дигәндәй.

Үткән-сүткәннәр Гөлзифаны олылап исәнләшеп китәләр.

Бәрәкалла, үзе яшәгән нигезгә утыртылган йорт янына да килеп җиткән түгелме соң? Өе башка булса да, нигезе аныкы бит. Таш өй белән агач келәт исә әле дә исәннәр икән. Узган кайтуында йөрәгемә ярамас дип килмәгән булган иде. Нигә бу тикле йөрәге тибә соң әле?

Әллә, ходаем, үз башыма йөримме шулай алгысынып, булган-беткән хатирәләрне яңартып?! Нигә бу хәтле яман булып китте?

Йорт-каралты тирәсендә кеше-фәлән күренми. Капканы сак кына ачып ишегалдына керде. Таныш нәрсәләрне күргәч, ярсып тибә башлаган йөрәген тыюдан гаҗиз калып, келәт янына үтте, таш өйнең ишек яңакларын сыйпаштырды. Бите буйлап яшь акты, илле еллар элек булган хәл күз алдына килеп, яңарып китте.

Кан эчендә яткан Әюбен келәт астына тартып кертергә тырышуы, биләүсәсенә төргән килеш йорт уртасында калдырган баланың ярсып-өзгәләнеп елавы, ат тояклары тавышын ишетүе һәм ни кылырга белми әле балага, әле Әюбе гәүдәсенә ташлануы, нәниен күкрәгенә кысып, кадала-каплана бәрәңге бакчасына йөгерүе... Ул хәлләрне яңадан дошманына да кичерергә язмасын.

Өйдән ак яулыгын карлыгачлап бәйләгән какча гәүдәле карчык чыкты һәм, кулын маңгай өстенә куеп, таш өй янында басып торган Гөлзифага карады. Һәм таныды булса кирәк, болдырдан төшә башлады:

— Сөбханалла, Әюп Гөлдифасы димме? Гөлдифакаем, син нч, син, ахирәтем! — дия-дия килде дә, кулларын алъяпкычына сөртеп, күрешергә сузды. — Һәй, китче, бер дә картаймагансың бит син. Һәй, танымый торасыңмы әллә тагын?! Ихластыр, танымый тора Гөлдифакаем-ахирәткәем, мин бу, мин — Хөббенисаң. Бәрәкалла, өйгә керик, нигә аяк өсте торабыз...

Хөббениса җәһәт кенә мич каршына үтте, шаулатып самаварга су салды һәм аннары Гөлзифа янына килеп утырды.

— Һәй, сөйләпләр торасымы, үткән гомерләр диген син аны, Гөлдифакаем! Үтте инде, үтте гомеркәйләр, картайдык. Япа-ялгыз диярлек, бер онытым белән генә торам. Кыдыммы? Улы хедмәттән кайтыр елда гына йөрәге чәнчешүдән дөнҗа куйды, Гөлдифакаем. Бигрәкләр дә үкенечле булды инде менәтерәк. Ирләрне алышып булса да, тәкъдирләрне алышып булмый шул, нишләмәкләрең кирәк, аллаһы тәгаләдән удыплар булмый. Оныгыммы? Өйләнмәгән әле, өйләнми. Солдаттан кайтуына да биш былтыр инде. Бәй, мин үстерми ни, кем үстерсен, үдем үстердем, үдем кеше иттем. Нинди бәхеткәй ди инде ул, Гөлдифакаем. Камалетдинне, Әюп югалгач, председатель итеп куйган булдылар. Яман кыдыл иде бит, кулаклар белән бугадга-бугад килде, күпләрен Себер сөрде. Ахырында үден дә тушында кереп күд алдымда суеп чыктылар. Ушым китеп егылдым. Кемнәр булсын? Шул Рәхим бай белән Ахун калдыклары инде. Син киткәч, седнең нигедне бедгә бирделәр. Рәхим байның Гайзулла киявенә дип суктырган бурасын күчереп, менә дигән өй җиткереп кергән генә иек. Булды инде, булды, Гөлдифакаем, үч тотучылар да булды. Әнә әле булса онытканнары юк. Былтырларны староста Ахунның малае Магнитагурдан кайтып китте. Мәгәдингә кергән дә күденә чагылган бер кешене эчерә икән. Әүвәлтен ата-анасының исемен сорый, ди. Минем Дарифуллам да килеп кергән. Син кем нәселеннән, атаң-анаң кем дип сорый икән, Дарифуллага ни, әйткән дә биргән. Шуңа теге, Гөлдифакаем, тоткан да Дарифулламның битенә аракы сипкән. Киткәннәр әләгешеп, тешләрен коешканчы сугышканнар... Әнәтерәк, син тыңлай дип тәмам онтылып киткәнмен, самаварым кайнап та чыкты.

Чәй янында Хөббениса, ахирәтен кыстап, ризык-нигъмәтләрне Гөлзифа каршынарак күчерә торды.

— Җитеш әле, Гөлдифа, җитешеп утыр. Әнә кагыннан да авыд ит, бал-кәнфитенә дә үрел. Аллага шөкер, бик рәхәт торабыд. Еллар гына имин булсын инде.

Үткән гомерләрне искә төшереп, сөйләшеп, елашып утыра торгач, кич җиткәнне сизми дә калдылар. Хөббениса ахирәтенә мамык сорар-

га баруы турында Фәһимә кардәшләренә кайткач кына исенә төште Гөлзифаның.

— Нигә, әбекәй, озак йөрдең? — дип сораган Әдиләгә:

— Иртәгә тагын барырмын әле, сүзебез дә бетмәде, — диде ул.

Иртән аны әбисе уятты.

— Әдиләү, Әдилә дим! Тор инде, балам, тор. Әтиең эшкә китә әнә. Сине дә уятырга кушты. Эш урынын күрсәтер идем, ди.

Әдиләгә түр як өйнең кечкенә бүлмәсенә урын җәйгәннәр иде. Юлдан килгәнгәме, ул изрәп йоклаган, әтәчләр кычкырганны да ишетмәде, көтү куганны да күрмәде. Ә кичке якта Фәһимә апасына көтү киткәнне күрәсем килә, мине дә уят әле дигән иде. Фәһимә апасы кызганган, күрәсең, уятмаган.

Җил дә уянган, сәрби агачының ябалдашлары белән уйный: яфраклар арасыннан төшкән кояш нурлары Әдилә яткан караватта биешә.

— Әдилә, Әдилә дим!

— Тордым, торам, әбкәй.

Әдилә караватка торып утырды, юрган астыннан аякларын чыгарып идәнгә басты. Күрше ишегалдында ярсып-ярсып үрдәкләр бакыралар, алар тынган арада көтүдән калган яшь бозауның мөгрәве ишетелеп китә, бакча башындагы болында трактор гөрелди иде.

— Әбекәй, чүәкләр бирче!

Такта белән бүленеп алынган бүлмәнең ишеге ачылды, әбисе килеп керде.

— Менә боларны гына ки дә ишегалдына чыгып юынып кер. Әтиең ашыга.

— Әти гомере буена ашыкты инде ул, — диде Әдилә һәм, иске чүәкләрне аягына элеп, халатын кия-кия, ишегалдына чыкты.

Кояш нурларыннан күз чагыла. Ишегалдын хәтфә кебек каз үләне каплаган. Әдилә салкын чыклы үләнгә ялан аяк кына басып карады. Тәнне кымырҗытып ниндидер рәхәт йөгерде. Кинәт аның сабый чагындагы кебек йөгереп китәсе килде. Менә инде Әдилә йорт буйлап йөгерә дә башлады. Рәхәт иде аңа. Бөтен күкрәкне тутырып иртәнге тыгыз һава иркәли, күңел әллә нинди ашкыну тоя, җилпенеп, кош кебек күккә ашасы, ак болытларга кадәр менәсе килә.

Әтисе Әдиләне ашыктырды.

— Әнә сине бирегә китерергә үтенгән партком секретаре килә. Эюп бабаңны үз күзе белән күреп белгән кеше.

Харисов бер егет белән сөйләшеп килә иде. Әдилә белән Гарифны күрүгә, әлеге егет тукталды, балаларча бер урында таптанып алды һәм, гаепле кеше сыман, башын түбән иде. Аннары борылып китеп барды. Киң җилкәле, шактый эре сөякле егет иде бу.

Әдһәм абыйсына Әдилә үзе кул бирде. Партком секретаре аңа сынаулы караш ташлады.

— Исәнме, исәнме, Әдилә. Талип абыең сине анда дүрт күзләп көтә. Җиһазларын да тапты, һәммәсен дә эшләп куйды инде. Үзем алып киләм дигән иде, эш чыгып кына калды. Хәзер килеп җитәр ул. Лабораториягә таба атлый торыйк.

Лаборатория болдырына менгәч, Гариф алдан партком секретарен уздырып җибәрде дә кызының кыска күлмәгенә, күтәрмәле аяк киеменә күз ташлап:

— Җәйләүгә чыгарга булсаң, кайтып киенебрәк килерсең, — диде.

— Алай пычрак булса, мин анда, әти, барып та йөрмәм, туп-туры Казанга кайтып китәрмен.

— Бер дә урынсыз болай сөйләшүең. Калырга ниятең булса, анда да барырга туры килгәләр шул.
— Калырга ният итсәм, эти жаным, барырмын да. Резин итек киярмен дә барырмын,— диде Әдилә, коридорда туктый төшеп.
— Я инде, ярсымасана, кешедән яхшы түгел, Әдһәм абыеннан.
— Нигә соң әле, эти, мин аңардан оялырга тиеш. Каласыңмы, калмыйсыңмы, имеш. Оят түгелме?.. Тәмам бала-чага урынына күрә башладың мине!..
— Үртәлмә юкка. Мин синең турыңда кайгыртам, ә син үзеңчә аңлыйсың.
Эчке якка үткәч, Әдилә һәр тәрәзә төбенә утыртылган гөлләрне күрде. Коридорны узып, иң түр бүлмәгә керделәр. Биредә аларны кечкенә буйлы, нәрсәсе беләндер чегәнгә охшаган бер кыз каршылады.
— Таныш булыгыз, — диде Әдиләгә Әдһәм абыйсы. — Тамчы атлы кызыбыз, биредә эшли.
Кечкенә буйлы, чегән чырайлы кыз мөлаем елмаеп аңа кулын сузды, Әдиләгә ул нәниләр кулын хәтерләтте.
Бүлмә иркен иде. Аппарат-приборлар әйбәтләп урнаштырылган. Тәрәзә төпләрендә матур-матур гөлләр.
— Гөлләрне Тамчыбыз үстерә, аның һоббие.— диде партком секретаре.— Ярдәмче кирәк дип табасың икән, Талип абыең жайлар.
Әдилә әйләнмәле түгәрәк урындыкка утырды, бер әйләнеп алды да гамьсезрәк кыяфәттә, шул ук вакытта чын-чынлап:
— Хезмәт хакы күпме булыр? — дип сорады.
— Анысын Талип абыегыз әйтер. Минемчә, шәһәрдәгедән ким алмассыз.
— Ферма-жәйләүләргә дә үзем йөрерменме?
— Ярдәмчеңне йөртерсең. Кирәк тапсаң — үзең дә. Бер иләшеп китсәң, сеңелем, авылдан китәсең дә килмәс әле.
Әдилә башын чайкаган булды, бераз кыланчыкланып торып китте, прибор-аппаратларга кагылгалап бүлмә буйлап йөреп килде.
— Шулай да минем бүген үк жәйләүне күрәсем килә.
— Анысын Талип абыең живо оештырыр. Хәзер килеп житәр ул,— диде Харисов һәм тамак кырып куйды.
Ул арада коридорда ир-ат тавышы ишетелде, аның көр сөйләшүеннән кем икәнен белеп була иде.
— Каяле-кая, күрсәтегез әле чибәркәйне үземә. Казан чаклы Казаннан килеп, нигә башта председательгә күренмәде? Ниткән башбаштаклык бу?! — дип көлә-елмая килеп керде Талип. Керүгә ул гөрлигөрли симез-таза кулын сузды һәм Әдиләнең нәфис кулларын уч төбенә алып, күзләренә карады.
— Я, исән-имин килеп життекме, Әдиләкәй? Һәй, исемнәрең дә исемнәрең. Юк, мин бу исемне болай гына Карамалыдан жибәрмим, композиторларны чакыртып жыр яздыртам. Я, ничек, лаборатория ошыймы? Әллә башта жәйләүне карап киләбезме?.. Хозурлык анда, жәннәтең бер якта торсын.
— Аргамакка утырып.
— Әйдәгез, — дип кузгалды Әдилә, председательнең кинаяле эчкерсез сөйләшүенә кушылып. — Жәйләүгә!
Талип, аның колагына үрелә төшеп:
— Карамалыга килгән интеллигенциянең моңа кадәр кире киткәне булмады әле. Моннан соң да булмас дип ышанасы килә. Бигрәк тә хатын-кызның. Егетләр бездә буа буарлык. Балсыз кабып йотарлыклары бар! — диде.
Әдиләгә председательнең бу мөнәсәбәте гажәп сәер тоелды. Ләкин бераздан ул үзенең дә шул үенга кереп китүен сизми дә калды.

— Аргамаклар, ак тулпарлар тотардай егетләрегез бармы соң әле, Талип абый?

— Менә дигәннәре, такта чәйдәй катылары, урта бармак кебекләре бар.

Шаяртуны бик үк чынга алмыйча, Талипка ияреп болдырга чыкса, Әдилә ишек төбендә чынлап та тарантаска җиккән ат күрде.

— Минем бит гомеремдә тарантаска утырып йөргәнем юк, — диде ул, хәлнең чын булуыннан уңайсызланып.

— Алайса, йөртеп күрсәтим үзеңне бер. Рәхим ит, утыр!

Талип, атның башыннан тотып, Әдиләнең менеп утыруын сабыр гына көтте. Тарантаска кеше утыруга, ак тулпар түземсезләнеп бер урында тыпырдарга тотынды.

— Мин калам инде алай булгач,— диде аларга ияреп чыккан партком секретаре.

Әмма Талип аны гүя ишетмәде дә. Ул атның башын җибәрде һәм үзе дә тарантаска менеп утырды.

— На, Иркә! Киттек!..

Колак төбендә җил уйный, дәртләнеп юртып киткән ат күңелле генә пошкырып куя, борынга әчкелтем ис бәрелеп китә, тояклардан балчык чәчри. Моны күреп, Талип плащын салды һәм Әдиләнең алдына япты. Һәммәсенә дә игътибар итәргә гадәтләнгән һәм тормышындагы һәрбер үзгәрешне җиңел генә, җай гына, ә күп вакытта уенкөлке белән уздырып җибәрә торган кешегә охшаган иде председатель. Әдилә председательне кай ягы беләндер Җәвиткә охшатып куйды. Юк, килеш-килбәте белән түгел, холык-фигылеме шунда, мөнәсәбәтеме... Ул да шулайрак кылана иде. Һәр эшкә батыраеп тотына, җиренә җиткерәме ул аны, юкмы, анысы аның өчен әһәмиятле түгел, тотынуы хак булсын. Семья тормышына да шулайрак карады бугай ул. Үтә җете кызылдан башлады, әмма тора-бара дәрте сүрелде, баштагы кызыллыкның әсәре дә калмады.

— Матур безнең яклар. Кырымнарың бер якта торсын, — диде председатель тирә-юньгә күз ташлап. — Әнә, күрәсеңме талларны, җәйләү шунда.

— Матур урында икән. Якларыгыз ямьле, Талип абый.

— Киләсе елга әнә тегендә, Зур күл башындагы калкулыкка, ял йорты салырга ниятлибез. Күл аша асылмалы күпер сузачакбыз. Күпердән чыгуың була — урман, әрәмә, болын китә, Ык елгасына ярты чакрым гына кала.

Алда ике вагон күренде, арырак җәйге абзарлар, сыер сава торган җайланма, улак-утлыклар. Җайланма юан кәүсәле таллар арасына күләгәгә урнаштырылган. Шуннан чишмә агып ята.

Талип тарантастан сикереп төште, атны вагон почмагындагы бөҗрага бәйләп куйды.

Җилдә тузгыган чәчләрен рәтләштереп, Әдилә дә төште. Ат шундый ак иде, хәтта Әдиләнең малкай тәненә кагылып карыйсы килде.

— Әкрен, исеме Иркә булса да, усаллыгы бар аның. Тешли күрмәсен,— дип, председатель Әдиләнең терсәгеннән эләктереп алды.— Башта вагонга кереп чыгыйк.

Вагонның бер башында — кызыл почмак кебек нәрсә, икенче башында — караватлар. Чисталык, пөхтәлек, тумбочка өстендәге пыяла банкаларга чәчәкләр куелган. Әмма җәйләү урнашкан урын вагон эченнән күп өлеш матуррак һәм ямьле күренә.

— Гариза язып биримме, болай гына алырсызмы? — диде Әдилә, вагоннан чыккач.

— Калу ниятегез хак булса, гариза язмый булмас...

— Карагыз әле, Талип абый, нигә сез миңа бер «сез», бер «син» дисез?

— Авылда гадәтләнгән инде. Онытылып китәм дә «син»гә күчкәнемне сизми дә калам. Әллә «син» дигәнгә үпкәләдегезме?
— Юк, Талип абый, болай гына соравым.
— Ничек дәшим соң?
— Ничек телисез — шулай.
— Ярый, килештек, алайса. Ярдәмче кирәк булырмы, юкмы? Без бер кызны укырга җибәргән идек инде. Ләкин аның әле ике ел укыйсы бар. Хәер, ярдәмче табарбыз, риза гына булыгыз.
— Килештек,— Әдилә, председательне шаккатырып, ирләрчә кул сузды. — Мин риза!
...Карамалыда калу-калмау мәсьәләсен ул үзе хәл иткән булса да, этисенә бу турыда сүз әйтмәгән иде әле. Гариф, кызында ниндидер үзгәреш күреп, ахрысы, юри дәшми, сорашмый торды. Ләкин әбисе түзмәде.
— Ниме соң, кызым, председатель белән сөйләштегезме?
Бирегә килергә чыккач та, Казанда чакта да: «Син авылда үскән кеше түгел ич, нигә шунда ашыккан буласың!» — дигән әбисенең тел төбен аңламый торды Әдилә. Әбисеннән мондый сүз ишетү бераз сәеррәк иде сәерен. Әдиләнең авылда каласы хәл ителгән инде, этисе моны сизеп тора булса кирәк, шуңа дәшми утыра.
— Ике яше дә тулмаган баланы бер әбиең кулына калдырырга исәбеңме әллә, кызыкай? Карамалыда торасың килсә, әнә Чәчкәнне дә алып кил.
— Алып килермен, әбекәй.
Гөлзифа әбинең күзләрендә ачу чаткылары уйнаса да һәм Әдиләнең авылда калуына риза булмаса да, ул яңадан дәшмәде, ашын ашады, чәен эчте. Фәһимә апасы гына:
— Карамалыда калырга ниятләп бик әйбәт иткәнсең, Әдилә. Шәһәр генә димәгән. Анда әнә урамга чыгам димә, юлга тәңкә төшеп ун минут ятмый. Һавасы авыр, урамнары тар...
— Житте-житте, туганым, — диде кардәшен бүлдереп Гөлзифа. — Үзең әнә бер дә алай итмисең әле. Авылны мактыйсың, шәһәрдә торасың. Салма бала күңеленә яман коткы. Болай да иләс-миләсләнеп китәргә генә җай эзләп йөри.
Ләкин Әдилә аларны тыңламый инде. Күңеле утырып житмәсә дә, китү турында уйламый иде ул. Алдагы көндә башкарасы эше турында уйлады ул һәм, келт итеп әллә нигә Җәвит исенә төште. Тәрәзә төбенә килеп утырды, һавага карады. Аксыл болытлар төньякка таба ашыгалар. «Тагын шул Җәвитме? Һаман шуны оныта алмавыңмы? Ничек онытырга? Ничек онытырга шуны?! Йөрәк пәрәләремне ярып чыккан балам бар бит минем аңардан!.. Инде авылга килде, онытылыр дип ерак китте, Казаннан өч йөз километрда яшиячәкмен. Ә ул, мөртәт, һаман күңелдән китми...»
Ике карчык дөнья кайгыртып сөйләшәләр, этисе Ык буйларын әйләнеп кайтам дип чыгып китте. Ичмасам, аңа эчен бушатыр иде.
Әдилә тәрәзә аша гына бакчага төште. Сәрби куагы төбендәге кечкенә эскәмиягә утырды. Кайдадыр, бик еракта, мотоцикл тырылдый. Кинәт кенә янәшәсендә диярлек мәче чинап куйды. Әдиләнең тәне буйлап кымырҗу үтте. «Абау!» дип кычкырып җибәрүен сизми дә калды.
Фәһимә апасы тәрәзәдән башын тыкты.
— Һәй, бәләтләр, нинди туй инде һәр көнне! Кичә булды кичә ызгыштыгыз. Перес-с, мыркыргырлары! — Әдиләне яңа гына күргәндәй:— Ә син нишләп утырасың биредә? — дип сорады.
— Авыл белән сөйләшәм, Фәһимә апа.
— Кем белән?
— Авыл белән.
— Песиләр белән диген. Кер әйдә, я талап китәрләр үзеңне.

— Авыл песиләре кеше талыйлармыни?

— Зрә дә усал безнең Карамалы песиләре!..

Өйгә кергәч, Фәһимә апасы аны алгы якта туктатты да колагына пышылдады:

— Гөлзифа түткәй юри генә кылынган була икән. Үзе торса торсын авылда, баланы бирәсем юк, өмет тә итмәсен, ди.

— Баламны бик сагынсам кайта-килә йөрермен, Фәһиматтәй.

— Тап дөрес әйтәсең, Әдиләкәем, бер дә исең китмәсен, рәхәтләнеп тор, яшә. — Фәһимә Әдиләнең муенын пешердәй булып якынлашты. — Кияү дә табып бирермен үзеңә, менә дигәнен, урта бармак кебеген.

— Фәһиматтәй җаным, минем ирем бар лабаса. Без аның белән аерылышмаган да бит әле.

— Анысын тиз эшлиләр хәзер, бер дә кайгырма, гариза гына язып бирәсең дә... Һи, җүләр, бер кискән икмәк ябышамы! Аллаһы боерган булса, жаның теләгәнгә димлим үзеңне. Гомерегез буена гөрләшеп торырсыз һәм Фәһиматтәгезгә рәхмәт укырсыз менәтерәк. Кул артым зрә дә җиңел минем.

— Юк инде, Фәһиматтәй, рәхмәт, әлегә җитеп торыр, берсеннән дә арынып җиткәнем юк. Инде бер бәхеткәйләрең булмагач.

— Исең киткән икән, иләгенә күрә чиләге табыла аның. Күңелең генә ир-аттан бизмәсен. Бизсә харап кыналар булырсың...

Әдилә бик озак уйланып ятты, күзенә йокы кермәде.

Мәхәббәт аңа, язгы ташу кебек, көтмәгәндә килде. Җәвит аңардан тәҗрибәлерәк, өлкәнрәк иде. Әдилә Казан зооветеринария институтына укырга кергәндә, ул аспирантурада иде инде.

Җәвит... Әдилә аңа бер күрүдә гашыйк булды. Кирәк бит шулай, су буенда арка кыздырып ятканда таныштылар. Әле булса хәтерендә, ул башта Җәвитнең оста йөзүенә игътибар итте. Кайчак шулай су коенучыларны гамьсез генә күзәтеп, кайнар комда оеп ятасың. Тәнгә рәхәт, эссе. Шунда синең күзеңә оста йөзүче берәү чалына. Аны гына күзәтә башлыйсың. Җитезлегенә, осталыгына хәйран каласың. Ул гынамы, имеш, инде аның белән бергә йөзәсең.

Кыюланып китеп, Әдилә егет судан чыгып волейбол уйный башлаган җиргә килде. Уенга аның белән янәшә басты. Нииндидер мизгелдә күзгә-күз карашып алдылар. Уйнап туйгач, коенырга инде бергә төштеләр.

Егет аны озата килде, юл өстендәге кафега кереп морожный ашадылар. Шунда белде Әдилә: Җәвит исемле егет зооветеринария институтында аспирант икән.

Менә ни өчен әбисен шаккаттырып зооветеринария институтына укырга кергән иде Әдилә. Чөнки Җәвит шулай теләде.

Икенче курста ул Җәвиткә кияүгә чыкты. Җәвит Әдиләнең этисенә ошады. Аспирантураны тәмамлагач, ул аны хәтта министрлыкка эшкә урнаштырырга ярдәм итте.

Кешенең мәхәббәттә яньш-көю чоры була. Утка ташланган көя күбәләгедәй, мәхәббәт кочагына чумган чаклар була. Ул гына. Ул, ул, ул! Аның өчен яшисең, аның өчен эшлисең, аның өчен үләргә ризасың. Әдилә дә бу чорны кичерде. Тәҗрибәсе юк, яшь иде. Ә Җәвит күпне күргән, тәҗрибәле кеше булып чыкты. Бәлкем шуңа күрәдер ул:

— Безгә әлегә бала кирәкмәс, әүвәл институтны тәмамла, аннары да өлгерербез, — диде.

Бу көнне Җәвит аны ресторанга алып керде. Әдилә йөкле иде инде.

— Юк, Җәвит, табам, — диде Әдилә.

Җәвит вино китертте. Эчте, исерә төште, теле язылды.

— Мин китәм синнән, Әдилә...

— Ярый, Җәвит, иртәгә үк врачка барам. Китү сәбәбең шул гына булса...

— Сытылып утырма. Соң инде. Аннары сәбәбе дә ул гына түгел. Минем яшьтән үк яратып йөргән кешем бар. Мин ансыз тора алмыйм, Әдилә. Аңла мине... — диде Җәвит.

Әгәр дә мәгәр менә хәзер Әдиләгә йөрәгеңне йолкып ал да өстәлгә сал дисәләр, мөгаен, ул моны эшли алыр иде. Ир бирмәк — җан бирмәк диләр ич. Ул аның сүзләренә башта ышанмады. Ни сөйләмәс кызмача баштан. Ләкин Җәвитнең күзләрендә сәер, бөтенләй аның өчен ят булган караш күрүгә, йөрәге кысылып куйды.

Әдилә агарынып китте, өстәл читенә тотынып тормакчы булды. Ләкин буыннары буйсынмады.

— Мин кайтыйм, Җәвит, соң инде.

— Син мине гафу ит, Әдилә. Син акыллы ич, аңла, без барыбер бергә тора алмас идек.

«Нигә, ни өчен?!» — дип сорыйсы килде Әдиләнең, ләкин сорамады, дәшмәде, әкрен генә күтәрелде дә, исерек кеше сыман аякларында ныклык тоймыйча, ишеккә таба китте.

... Җәвит белән алар әнә шулай аерылыштылар. Җәвит бар булган әйберләрен алды да китеп барды. Кая китте, кем янына — Әдилә кызыксынмады.

Ул чакта Әдилә үзен язгы ташкынга эләккән йомычкадай хис итте.

Аерылышуларына бер ай дигәндә әтисе кайтты. Диванда бәйләү бәйләп утырган Әдилә янына килде, башыннан кочып чәчләрен сыйпап-сыйпап алды.

— Борчылма, кызым. Ана кешедән бала артмый ул, бергәләп үстерербез... — диде.

Әдилә, әтисенең күкрәгенә башын төртеп, үксеп-үртәлеп елап җибәрде. Менә кем житмәгән икән аңа, менә кемнең йомшак сүзләренә зар-интизар булып яшәгән икән ул бу көннәрдә!

— Елама, сабыр ит. Институтыңа барырга теләмисең икән, академик ял ал. Соңыннан җайланыр. Читтән торып укырсыңмы, башка институтка күчәрсеңме, күз күрер. Тынычлан. Кем белә, бәлкем әле акылына утырып әйләнеп тә кайтыр...

Юрган астында уйланып ята торгач, Әдилә йокыга талды. Покысында да уйлары гүя дәвам итте. Әле ул болында ялан аяк йөгерде, әле Җәвит белән су коенды. Менә, имеш, ул текә ярга таба йөгерә. Ләкин нигәдер туктый алмый. Гүя аны кемдер куа. Менә яр чите, менә ул хәзер аска, түбәнгә очачак. Инде суга сикерәм дигәндә генә кинәт аңа канатлар үсте. Һәм ул очып китте. Әйе, әйе, ул оча ала бит әле. Их, рәхәт тә икән очулары! Аста ямь-яшел болын, урман-кырлар, бормаланып аккан елга.

## 21

Талип иртә уянды. Кичә кичтән сызлаштырып торган тешенең авыртуы сизелми иде. Ул гадәттә уяну белән урыныннан кузгала иде, бүген исә Кафиянең кем беләндер төшендә сөйләшеп ятуын, дугаланып килгән иреннәрен кыймылдатып, ниндидер сүзләр әйтергә тырышуын күреп, үзалдына уйланып ятты. Шунда ул, үз-үзен яман бер фикердә тоткандай күрсенеп, Минниса белән бәйләнеп китүенә эчтән генә үкенү кебек бер хис тойды.

Аннары фикер җепләре комплекска килеп ялганды. Шуны салып ходка җибәрсә, үлсә дә үкенмәс иде. Комплексны салу чорында Талип шактый кыен хәлләргә калгалады. Изге алдау дигән булып, авылдагы хуҗалык сыерларын бер атна буена кырда саудыртып дәүләткә сөт озаткан иде, колхоз исәбенә колхозчыларның сыерларын саудыра дип Хөснетдиновка житкереп өлгергәннәр. Күрәсең, Карама-

лыда «дуслары» да күп әле. Ә комплекс кирәк. Талип яткан урынында ярсу аттай башын чайкап куйды.

Кояш чыкты, тәрәзәнең югары өлгесеннән нур бөркеп керде һәм Кәфиянең маңгаена кунды. Кәфия, чебен кунгандай, кулы белән маңгаена кагылып алды.

Талип, хатынын уятмаска тырышып, иплән кенә торды да аяк очларына гына баса-баса чыгып китте, салкын су белән юынып алды. Алгы өйдә Миңлекамал карчык чәй эчеп утыра иде, Талипның юынып керүен күргәч, ул аңа да бер чокыр китереп куйды. Талип түр стенадагы барометрга чирткәләп карады, әмма прибор аны куандырмады, ук «коры як»ка таба калтыранып китте. Айлык прогнозда да явымтөшем күрсәтмәгәннәр, бу атна-ун көн эчендә яңгыр яумаса, игеннәр күзгә күренеп көя башлаячак, иген белән бергә Талипның җаны көяр, чөнки быелгы уңыш аның өчен аерата кыйммәт иде. Авыл хуҗалыгының төп экономиясен билгеләүче чара — иген игү бит. Терлекчелек исә бер продукцияне икенче төргә әверелдерүче чара гына. Икмәк булдымы, терлеге дә була, башкасы да.

Уйлана-уйлана чәй эчте. Янә агрономны исенә төшерде. Әлегә егет басыла төште, ару гына эшләп килә, ләкин Талип барыбер аңардан канәгать түгел әле. Өлгерә алмыймы? Комбайннарны кырдан-кырга күчерүгә кадәр үзе чаба. Бәлкем ярдәмче бирергә кирәктер үзенә? Юк, ярдәмче бирү белән генә бу хәлдән котылып булмастыр. Ниһаять, ике-өч ел буена хәзерләнеп, тикшереп, инде экономик яктан ныклы тәртипкә китерелгән системага күчәргә вакыттыр. Талип аңлый: аның бу тәкъдимен хупламаслар, ләкин аның кулында ул ысулны исбат итә алырлык хуҗалык бар бит. Сына, кат-кат тикшер, аннары күтәреп чык. Әйтергә ансат — сына. Райидарә моңа барырмы, Хөснетдинов хупларлмы? Ә бит болай начар уйланмады. Миңнисаның да ярдәме тиде, исәп-хисапларны шундый итеп төзеп бирде — Талип шаккатты аның шулай нык итеп колхоз экономикасын белүенә. Әйе, Миңниса аның һәр планын ярты сүзеннән үк аңлады.

Ә колхоз белән идарә итүнең яңа ысулы болай иде: һәр тармакны аерып исәп-хисапка куярга. Ягъни, иң әүвәл, промышленностьтагы кебек, һәр тармакны цехларга бүләргә. Әйтик, игенчелек цехы, ә аның белән идарә итүне тулысынча агрономга йөкләргә, терлекчелек цехы — цех начальнигы зоотехник, бөтен җаваплылык аңарда, ярдәмче кирәк икән, махсус белемле кеше куярга. Төзелештә — инженер-төзүче, мастерскойда — инженер-техник баш, яшелчәчелек үзенә һәм аларның барысы да председательгә буйсыналар. Һәр тармакта — ныклы хуҗалык исәбе. Шунда, тик шунда гына күренәчәк кайсы тармакның ничек, ни бәрабәренә эшләве. Орлыклар начар — моңа агроном гаепле. Машина-трактор паркы җайда түгел — баш инженер җаваплы. Җирне начар эшкәртәләр — механизаторлар...

Һәр эш җиренә житкереп башкарылырга тиеш, һәркем җаваплылык тойсын. Әйе, рентабельлелек тик шунда гына килер бу колхозга. Кыскасы, һәр кеше эшенең нәтиҗәсен һәм житештергән продукциянең үзкыйммәтен белсен. Башкаларның да ничек эшләүләрен күреп, белеп торсын. Моның өчен планлаштыру һәм исәп-хисап цехы булдырырга. Бәлкем аны цех дип атап та булмас. Ләкин хикмәт анда түгел, хикмәт аның булуында. Ул үз мәгълүматларын районлагы ЭВМга бирер, ә аннан төгәл исәпләнгән перспектив күрсәтмәләр килер. Без аны колхозчыларга, белгечләргә житкерербез. Анда инде, мәсәлән, агроном белән комбайнчы юк кына нәрсә өчен бугазга-бугаз килмәсләр... Ә Зарифны яңа кайткан «Колос» комбайнына утыртырга кирәк булыр, дип кинәт кенә күктән җиргә төште Талип.

— Катыгын да капкала, куе сөтнеке, күрше Сәрбиҗамал кертте, рәхмәт төшкере, — диде Миңлекамал карчык.

— Рәхмәт, кыстама, мин кунак түгел. Үзең аша, бер ай уразадан шактый ябыктың, анә.

— Катык-сөтебез булмагач, нишләмәк кирәк. Сыерны колхозга илтеп бик шәп эшләдең инде...

«Астыртын да соң бу хатын-кыз, билләһи. Кем карар иде ул сыерны? Яшең җитмешкә житкән синме, һәр көнне битенә кояш төшкәнче йоклаган килененме? Юк инде, сезнең икегездә дә сөт кайгысы калмады. Балалар киткәч, тәмам иркенәйдегез, хәерле булсын. Ә сөт эчәсегез килә икән, сатып алыгыз».

— Гарьләнәм мин авылда торып кешедән сөт сатып алып эчәргә, — диде Миңлекамал карчык, Талипның фикерен укыгандай.

Талип дәшмәде, чәй өчен рәхмәт әйтеп урыныннан торды да, пинжәген жилкәсенә салып, ишегалдына чыкты. Миңлекамал әбисе сөйләшә башласа, көн үткәнне сизми дә каласың. Үз язмышыннан башлый, Себердә күмеп калдырган Кадерматә белән тәмамлый. Ярый ла әле, тәмамлый алса, Тажылбанат карендәшенә күчә, аннан Гайзулла жизнәйгә...

Кояш инде шактый күтәрелгән. Күлмәк аша арканы кыздыра. Ә һава чиктән тыш коры. Беркөнне аңа райком секретаре Хөснетдинов: «Ел коры килә дип зарланасыңмы! Коры елны сынала председатель. Шуңа карап бәяләнә аларның эше. Яңгырлы елны бар да үстерә аны уңышны. Ә син менә тиңдәшләреңне шаккаттырып коры елны да түбән уңыш алма»,— диде. Ә бит дөрес әйтә. Тик аның өчен председатель сыналса, минем өчен коры елны агроном сыналачак».

Аяк астында күпереп торган юл тузаны. Печәнгә төшәргә дә күп калмады, ә яңгырлар һаман юк та юк. Житәр кебек, моннан ары болай эшләп булмастыр. Сугарулы жирләр булдырырга. Йөз гектар гына түгел, өч, кирәк икән — биш йөз гектар.

Бер атна элек Талип Кыяр тавы каршындагы кыңгырау чишмәне буарга дип дүрт үзбушаткычны билгеләгән иде, ни сәбәпледер инженер ике трактор гына жибәргән. Көпчәкле тракторларның арбалары белән күпме генә балчык ташырга мөмкин. Үзбушаткычлар кая? Юк, юк, төгәл жаваплылык тойсыннар өчен, әлеге цехларны булдырырга. Башкача һич мөмкин түгел. Колхоз белән искечә идарә итү ул бер урында таптану дигән сүз.

Бу фикергә килер алдыннан Талип Казан галиме Гариф Латыйпов янына кереп утырды. Сүз ара сүз чыгып, басуларны сугару мәсьәләсенә кагылдылар. Гариф Әюпович аңа Кыяр тавындагы кыңгырау чишмәне буып, андагы биш йөз гектар жирне сугарып игәргә куша. Нинди культуралар чәчәргә кирәген әйтте, фәнни яктан нигезләде. Унбиш гектар сугарулы жир йөз гектар мәйданның продукциясен бирә ала икән.

Алда Харисов күренде. Ул болын ягыннан кайтып килә иде. Талип аны юл чатында көтеп алды.

— Исәнлекме! — диде партком секретаре кулын биреп. — Механик жиңел машинаны рәтләде. Бюро уникедә башлана. Печән һәм урыпжыю мәсьәләләре каралачак.

Талип янагына ябышты.

— Ни булды?

— Теш сызлаштыра. Нервылар какшый, шайтан, — диде председатель йөзен чытып.

— Талип, син теге Хөббениса әбинең оныгы Зарифны кая булса да эшкә куй инде. Рәнжегән егет, китеп баруы бар.

— Мин аны яңа кайткан «Колос» комбайнына утыртам. Ә бригадир кирәкми миңа. Тиздән колхоз белән идарә итүне яңача үзгәртеп корачакбыз.

— Райидарә ни дияр соң?

— Яңаны буа алмаслар. Гуляев үзе яңа өчен яна торган кеше. Мин аның тел төбен чамалап карадым инде. Язып китер, райкомда, аннары Казанда карарбыз, диде. Хуплый болай. Сез шуны тагын бер укып чыгыгыз әле, Әдһәм абый. Килешмәслек нәрсәләр юк анда. Югыйсә, һичнигә җавап бирмичә, күләгәдә генә йөргән белгечләр күбәеп бара колхозда. Быел тагын орлык буенча бер агроном, зоотехник алырга кушалар. Һәм кирәк тә. Һәркем үз эше өчен тулысынча җавап бирсен. Менә ни телим мин, Әдһәм абый...

## 22

Сабан туйларына иртәрәк иде әле. Язгы эшләр азая төшкәч, бер якшәмбе көнне ял оештырып алырга булдылар. Бу — яшьләр инициативасы иде, Талип та, Харисов та каршы килмәделәр. Теләгән кеше, сумкага салып, ризык-нигъмәт алып төште, чормага ташланган иске самаварларның да кирәге чыкты.

Гади генә ял көн бөтенләй бәйрәм төсе алды. Әтисе белән бергә Әдилә дә болынга төште. Бу тамаша хозурлыкны, чуар-чибәр киенгән Карамалы халкын күргәч, Казандагы сабан туйларын хәтерләп, ул тәмам әсәрләнеп китте. Яшьләр бер тирәгәрәк җыелган иде, дәртсенгән күңеле Әдиләне шунда тартты, яшьләр анда бии, төрле уеннар уйныйлар иде. Алар арасында Тамчы белән Вафа да күзенә чалынгач, әтисенә:

— Әти, мин дә әнә тегендә киттем, — дип кузгала башлады.

— Китә бир, — диде әтисе.

Әдиләнең Карамалыга килүе һәм колхозга эшкә урнашуы турында яшьләр арасында имеш-мимеш йөрсә дә, күбесе аны күреп белмиләр иде әле. Әдилә алар янына килгәч, аерата егетләр болганыбрак алды сыман. Колактан-колакка пышылдашулар, «Әйе, шулай икән шул», «Эһем, чибәр икән, шайтан!» дигән «ым»нар да булмый калмады. Бер караганда, моңа бер дә шаккатырлык түгел дә бит, юк шул, яңа кешене күздән ычкындырмыйлар.

Егетләр:

— Кияүдәме? — дип кызыксынсалар, кызлар:

— Үзе генә килгәнмени, кияве кайда икән соң? — дип сораштырдылар.

Дөрес анысы: килгән-киткәннәр белән генә Карамалы яшьләрен әллә ни шаккаттырып булмый хәзер. Саф һава суларга дип авылга кайтучыларның исәбе-хисәбе юк диярлек.

Ләкин бу бит Карамалыга эшкә килгән. Җитмәсә, Әюп Латыйповның оныгы, ди. Ә Әюп Латыйпов Карамалыда беренче председатель булган кеше, аклар тарафыннан җәзаланып үтерелгән...

Егетләр тыштан Әдиләгә игътибар итмәскә тырышсалар да, кыюраклары табылды тагын, берәүсе танцыга чакырды, бөтерелеп, кызны көлдерә-елмайта биеде, нindидер кызык сүзләр дә әйткәләде бугай. Әдилә тыенкы гына кеткелдәп көлеп-көлеп алды.

— Күрегезче бу Зариф абыйны. Күрде дә капланды, яныннан да китми Әдиләнең.

— Чәчләрен күрче син аның. Иңбашларына ук таратып җибәргән. Килешә тагын үзенә! — диде берсе, кызның чәчләренә күзе төшеп.

Әдиләне сәер бер тойгы биләп алды. Егет аңа шаярткан булып:

— Мин сезне бүген төнлә ак аргамакка атланып урларга киләм, — дип куймасынмы.

— Килегез, урлагыз, — диде Әдилә көлә-көлә, — мин сезне тәрәз ачып көтеп торырмын.

Менә бит син аны, дөньяны!

Шулай үз-үзен онытып, шаяруга каршы шаяртып, кыланчыкланып,

кемгә булса да ирәя алырмын дип уйламаган иде, ә монда исә күңелен шундый хис биләп алды, гүя ул әле кияүгә дә чыкмаган, гүя аңа нибарысы унҗиде яшь.

Яшьләрдән берсе:

— Әйдәгез Зур күл буена! — дип сөрән салды.

— Әйдә, Әдилә, син дә! — диде Тамчы, аның янына килеп. — Зариф абый, чакырыгыз инде партнершагызны.

— Бармыйм дисә, мин Ыкка ташланам! — диде Зариф.

— Алай булгач, бармыйча да булмастыр, — дип, Әдилә Зариф ягына сирпелеп алды. — Көтеп торыгыз, мин этигә генә әйтеп киләм.

Шулай диде дә ул яр буенда чәй эчеп, гәпләшеп утырган этисе янына йөгерде. Табындагылар кызып-кызып бәхәсләшәләр иде. Әдиләгә игътибар да итмәделәр. Аның каравы, Әдилә аларга игътибар итте. Бигрәк тә этисе белән янәшә утырган ак чырайлы, зәп-зәңгәр күзле, мөлаем гына йөзле бер хатын аның игътибарын җәлеп итте. Этисе аңа ни турындадыр мавыгып сөйли, ә теге апа дикъкать белән тыңлый. Самавар бу бөркеп гөҗләп утыра, ашъяулык өсте тулы тәмле-тәмле ризыклар. Әдиләнең авызына сулар килде. Тик ашау белән мавыгырга вакыт юк, аны бит көтеп торалар...

— Эти, мин Зур күл буена барып киләм.

— Бара бир, — диде этисе сөйләвеннән туктамыйча гына.

Әдилә әйләнеп килгәндә, яшьләр төркем-төркем булып тарала башлаганнар иде инде. Тамчы, Вафа, Зариф аны көтеп торалар иде. Әдилә алар янына килеп басты да, Зарифка күз сирпеп, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды.

— Әйдәгез, мин әзер, кузгалдык.

Зариф аны култыклап алды. Әдилә башта беләген тартып алмакчы иде дә, нигәдер яхшысынмады, терсәген җыя гына төште. Егеткә күз чите белән генә тагын карап алды. Киң кара кашлы, тулы гына йөзле, ияк уртасы чокыраеп торган бу егет күрер күзгә сөйкемле генә иде болай. Янәшә атлаган кызның җылы карашын сизүгә Зариф та кыюлана төште.

— Мине Зариф диләр. Әбекәй Дарифулла ди. Минзәлә ягыннан ул минем әбекәй, «д» белән «з»ны буташтыра.

— Минем исемем — Әдилә.

— Паспортыгызда да шулаймы? Минем паспортта Зарифулла. Нәкъ мулла кушканча...

Әдиләгә аның нык муены, уйнап торган беләк мускуллары күренә. Карале, әллә ниткән сәер тойгы били бара Әдиләнең күңелен. Үзен тәкәллефсез генә култыклап алган бу егеткә ни әйтергә тиеш соң инде ул? Нишләптер аңа күңелле. Кем алып килде аның боега башлаган күңеленә бу бәйрәмне. Шушы егетме әллә тагын?

Әдилә күккә карап-карап ала. Күк йөзе чалт аяз, көн җылы, хәтта бераз бөркүрәк тә кебек. Алар хәтфәдәй яшел болын буйлап Зур күлгә таба атлыйлар. Аяк астында хисапсыз күп чәчәкләр. Әнә иссез ромашка, күгәрчен күзе, кыңгырау чәчәк, тамчы чәчәк, тимәс борын очып таралырга торган тузганаклар.

Зариф барган җайга бер чәчкә өзеп алды да Әдиләнең чәченә кадады.

— Сезгә урман кызы булу бик тә килешә икән. Әйдәгез, мин сезгә чәчәкләрдән такыя үреп бирәм. Хәзер...

Шулай дип, ул тиз-тиз генә чәчәкләр җыя башлады. Тамчы белән Вафа да җыештылар. Әдилә дә калышмады. Зариф, бәйләм бәйләгән оста куллы кызлардай, чәчәкләрдән такыя үрергә кереште. Әзер булгач, аны Әдиләнең башына кидерде.

Тагын күңелле булып китте Әдиләгә. Ул, назлана төшеп, Зарифка елмаеп-елмаеп алды. Бераз шулай көлешә-сөйләшә баргач, Вафа

белән Тамчы бер читкә тайпылдылар. Зариф белән Әдилә икәүдән-икәү генә калды.

Ык буйларында жыр, шау-гөр килеп уйнаган тавышлар яңгырап тора. Тамчы белән Вафа аерылып китүгә, аларга таба карап-карап алган Әдиләгә Зариф:

— Кирәкмәс, калсыннар, минемчә, аларның бер-берсенә әйтәсе житди сүзләре бар, — диде.

— Борылыйк, Зариф, — дигән булды Әдилә. — Зур күл бик ерак икән бит.

— Әйдәгез соң Ык буена гына төшәбез!

Әдилә иңбашын сикертеп куйды.

— Ык буена житәбез дә шундук борылабыз. Сөйләштекме?

Әдилә ризалыгын белдереп ым какты.

Зарифның йөзеннән елмаю китмәде. Бу хәлне күреп-күзәтеп барган Әдилә үз кәефенә үзе ышанмады. Күңеленә иңгән боеклык, моңсулык янында кечкенә, бик кечкенә, кесә көзгесе кадәр генә яктылык күрде ул. Әдилә шул яктылык аша яңадан дөньяга карады. Иң-жилкәне басып торган йөк жиңеләеп киткән сыман булды.

Зариф аңа нидер сөйли. Әйдә, сөйләсен. Әдилә ничектер үзенә күңел тынычлыгы кайтуын тойды. Бу вакытлы тынычлану гына иде, әлбәттә, Әдилә анысын да белә. Ләкин ул шуңа да шат иде. Күкрәк түрендәге әче төер эреп юкка чыкты, күңеленә читлектән иреккә чыккан коштай куаныч килүен тойды.

Әдилә Зарифка сирпелә-карый атлый бирә. Зариф аңа хезмәттә булуы, аннан кайткач бригадирлыкка укуы, аннары комбайнга утыруы турында сөйли. Әдилә аны тыңлый да, тыңламый да. Аның торган саен зиһене сафлана, теләкләре ныгый бара иде.

Аяк астында йомшак үлән кыштырдый. Адым саен ал, сары, зәңгәр, көрән, шәмәхә чәчәкләр очрый. Әдилә аларның хәтта исемнәрен дә белеп бетерми. Ә менә ак тажларын жәеп салган сары үзәкле иссез ромашканы белә. Яз да, көз дә чәчәктә утыра ул — болында да, юл буйларында да, кырда да, куак арасында да үсә. Һавада сәер тынлык. Әрәмәлектә, урман ягында, кызлар «ау-у!» дип кычкыралар. Бу аваз башкорт ягындагы Рә тауларына барып бәрелә дә кире кайтып болын өстендә яңгырап тора. Табигатьнең сихри көченә гашыйк итәрлек бу Ык буйлары. Күңел күтәрелә, сабый чактагы кебек, ялан аяк йөгереп китәсе килә.

— Сандугачлар сайрый. Чү, күке дә кычкыра түгелме? — дип, Әдилә туктап тыңларга кереште. — Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, жиде. Һи-и, бетте дәме? Димәк, миңа барлыгы жиде ел яшисе калган?

— Жиде түгел, житмеш.

— Ничек житмеш? — дип, Әдилә күзләрен уйнатып алды. — Жиде тапкыр гына кычкырды ич!

— Ә мин жиде янына бер нуль куям.

Әдилә рәхәтләнеп көлеп жибәрде.

— Юк инде, Зариф, жиде икән — жиде. Миңа шул гомер дә бик житкән.

— Дөньядан шулай бик иртә туеп та өлгердегезмени?

— Туйдым шул...

— Ай-һай-һай! Ярый, ялганлашмыйк. Ләкин мин барыбер бу күке белән килешә алмыйм. Сез теләсәгез ни әйтегез, күке кычкырган «жиде»гә мин барыбер бер нуль өстим...

Шунда Әдилә очып килгән энә карагын күрде һәм кызыксынудан аның күзләре түгәрәкләнеп китте.

— Әйдәгез, тотыйк әле шул энә карагын, Зариф. Ул минем энәмне урлады.

Егеткә шул җитә калды, ул энә карагын куып китте. Яшелле-зәңгәрле канатларын пыр-пыр китереп, бер күтәрелеп, бер төшеп, чәчкә-үләннәргә куна-куна, энә карагы да уенга кушылды бугай. Икәүләп куа торгач, аны югалттылар. Ләкин үлән арасыннан тагын икенчесе килеп чыкты. Зариф хәзер анысын куып китте. Энә карагы безелдәп оча, Зариф йөгерә, аның артыннан Әдилә чаба. Үзләре көләләр, үзләре йөгерәләр. Тик энә карагы гына моны белми иде, күрәсең. Ул туп-туры елгага таба юл тотты, яр астындагы камышка юнәлде. Зариф, җан-фәрман йөгереп килеп, яр читендә шып туктап калды, әмма артыннан чапкан шәпкә Әдилә аңа килеп бәрелде. Зариф, тигезлеген югалтып, яр астына төшеп китте. Ярый әле, яры текә түгел. Килеп төшүгә, бер аягы агач тамырына эләкте һәм ул, гәүдәсен тота алмыйча, йөзтүбән капланды.

— Аһ, Зариф! — дип куркынып кычкырды кинәт Әдилә.

— Аяк эләкте, — диде Зариф, башы белән камыш арасына барып төшкән җирдән күтәрелеп. Әдилә, аның канаган йөзен күрүгә, агарынып китте.

— Зариф, битегез канаган ич! Менә аласызмы?

Егет, үләннәргә тотына-тотына, яр өстенә үрмәләп менде. Бите бик каты сыдырылган, бер күзен ача алмый иде.

— Сезгә столбняк булуы бар бит...

Зариф кулъяулыгы белән ярасын каплады, чак кына арырактагы ташлыкка таба атлады. Әдилә аңа иярде.

— Хәзер юабыз аны. Берни дә булмас. Безнең әбекәй киселгән ярасына туфрак та сибә әле.

Куе таллар арасында сукмак бар иде. Шунда кереп киттеләр. Бераздан су буена килеп чыктылар.

Вак ташларга вак-вак дулкыннар килеп бәрелә. Бу урын нәрсәсе beләндер Әдиләгә диңгез буен хәтерләтә иде.

Зариф күлмәген салды да ботинкасы-ние белән тез тиңентен суга керде. Битен әйбәтләп югач, таллар арасыннан тигәнәк яфрагы өзеп алып, ярасына каплады.

— Әчетә, шайтан. Эт үләне табып булса, шуның белән ышкуга кан туктый да бит. Юк, күренми.

Зарифның күкрәк тирәсендәге кабарып торган мускуллары уйнап-уйнап ала.

— Гафу итегез, Зариф. Минем аркада булды бит бу.

— Икебез дә очкан булсак, шәбрәк буласы дисез инде? Сезне дә ияртеп очмавыма мин үкенеп куйдым әле. Ичмасам, бергә төшәр идек, үлә калсак, бергә үлгән булыр идек.

— Көлмәгез, Зариф. Салыгыз майкагызны, салкын суда булса да чайкап алыйк.

Зариф майкасын теләр-теләмәс кенә салып бирде.

— Аннары талга элеп киптерербезме?

— Хәзер җилли ул, — диде Әдилә. Майканы алды да суга кереп чайкады, юды, әмма андагы кан таплары бетмәде. Майканы чыгарып элгәч, күлмәкне юарга кереште. Әмма күлмәктән дә кан тапларын бетерә алмады. Киресенчә, таплар, җәелеп, аны саргайтты гына.

— Беләсезме, Зариф, салкын суда кан бетми икән бит.

Әдилә судан чыкты да, башын кырын сала төшеп, кояшка карады. Башына такыя кигәнгәме, бу мәлдә ул күл өстендәге төнбоекка охшап китте.

— Их, әллә коенып аласы инде?

— Әйдәгез, чынлап та! — дип хуплады Зариф Әдиләнең бу сүзен. Һәм чишенә дә башлады.

Зариф суга төшеп киткәч, Әдилә таллыкка кереп күлмәген салды да йөгереп килеп суга ташланды. Аның ак тәнендә яшькелт төстәге

коену костюмы төнбоек яфрагы кебек, гүя ул тәненә яфраклар ябыштырып чыккан иде.

Зариф, колач җәеп йөзә-йөзә, аргы якка да житте.

— Әдилә, бирегә йөзеп чыгыгыз, ком шундый эссе,— дип кычкырды ул, сыңар аягында терек-терек сикергәләп колагына кергән суны чыгарырга кереште.

Әдилә аңа таба хатын-кызларча аяк тибеп йөзеп китте. Ярга йөгереп чыкты да кайнар комга сузылып ятты.

— Их, җылы да икән ком!..

Зариф аның янына килеп утырды.

— Менә бераз кызынабыз да тагын су керәбез. Су җылы икән, мин салкындыр дип уйлаган идем.

Әдилә Зарифның таза гәүдәсенә, төк баскан күкрәгенә күз төшереп алды да үзалдына оялып күзләрен йомды.

— Әдилә, сезгә бер сорау бирергә ярыймы?

— Ярый.

— Сез лабораториягә эшкә килдегезме, әллә аппаратлар җиһазларга гынамы?

— Бер-ике елга эшкә килдем.

Әдилә күзләрен ачты һәм серле генә Зарифка карады.

— Әллә сездә шулай бик тиз танышалармы?

— ЭВМ булса, шуның аша гына танышыр идек тә бит, Карамалыда ЭВМ юк шул әле. Шуңа күрә, менә шулай танышырга гына кала. Башта әрсезләнеп танцыга чакырасың, аннары башына такыя үреп кидерәсең, кәртечкәгә төшергән булып кыланасың, ул да ярдәм итмәсә, суга ташланам дип яр астына сикерәсең. Җан газиз дә бит, нишләмәк кирәк, танышу хакына мондый яраларга гына түзәсең инде. Адәм әнә бер кабыргасын да суырып алып биргән, диләр... Хәер, сездәй сылуларның сөйгән ярлары Ык буендагы комлыкта кызынып ятмыйдыр. Аларга Сочи булсын, пальма күләгәсендә кызыл шәраб эчеп утыру булсын, капка төбендә кара лимузиннар көтеп торсын. Без ни, безгә — кара тезгә — шул Ык комнары, кәҗә таллары да ярый.

— Һәр җирнең үз яме, үз матурлыгы бар. Ык буйлары Сочидан бер дә ким түгел, Зариф.

Ык елгасы акрын гына ага да ага. Әдилә, су янынарак күчеп, талгын суга аягын тыкты. Җим дип белүләре идеме, маймычлар борыннары белән аякка төртелеп-төртелеп китәләр. Карале, бик күп икән алар бу суда. Күрче, аякны шундый итеп кытыклыйлар, рәхәтлектән кычкырып җибәрәсе килә. Комлык бетүгә, текә яр башлана. Елга өсте анда агарып китә, чоңгылланып бөтерелә башлый. Ул да түгел, су өсте җыерчыклана, минут эчендә тагы язылып, җәелеп китә һәм ялтырап кала. Ләкин бу да озакка бармый, баштагы хәл яңадан кабатлана, су тагын астан айкалып чыга-чыга да агымга эләккән чүп-чарны рәхимсез бөтерә башлый. Чоңгылның үз ритмы, үз көе бар сыман. Бу чоңгылга карап торсалар, композиторлар көй язарлар иде, дип уйлады Әдилә. Чоңгыллыктан арырак китүгәч, куе камышлык башлана. Шул яктан сандугач чутылдавы ишетелә. Кыңгырау чәчәкләр башларын суга ия-ия чоңгыл уртасында бөтерелгән яфракларга сәлам әйтәләр сыман. Тагы да арырак, тып-тын төштә, аксыл-сары таҗларын су өстенә җәеп бака чәчкәләре чайкала. Такыя дигәннән....

Әдилә башындагы такыяга кагылып алды, суга карады һәм, шәүләсен күреп, үз-үзен танымады, вак кына дулкыннарда селкенгәләп торган, әкият китапларында гына күргән ниндидер патша кызына охшатты бу шәүләне. Тәнгә кояш нурлары коела. Оеп утырудан бөтен тәне ял итә. Зариф сөйләнде-сөйләнде дә тынып калды. Күзләрен

йомыи, эссе комда ята. Әдилә үзен Зариф урынына куеп, аның күзләре белән үз-үзен күзәтте.

— Әдилә, безне эзлиләр түгелме? Тамчы кычкыра бугай.

Чын икән шул, Әдилә аз гына колак салган иде, Тамчының «Әдиләү! Әдиләү!» дип, тора-тора кычкырган тавышын ишетте.

Икесе дә күзгә-күз карашып алдылар, икесе бергә суга сикерделәр. Сикерүгә, Әдиләнең башыннан такыясы төшеп китте һәм чоңгылга эләгеп бөтерелә башлады. Әдилә анда кереп такыяны алырга курыкты. Зариф чумган җиреннән су өстенә калыкмаган иде әле. Әдилә, ирләрчә колач сала-сала, каршы якка таба йөзеп китте. Ниһаять, аның аяклары төпкә тиде. Шунда аңа нидер кагылып китте. Әдилә куркуыннан чырылдап җибәрде. Нәкъ шул вакытны аның янәшәсенә пырх итеп судан Зариф килеп чыкты.

— Уф, котымны алдыгыз...

— Курыкмагыз, Әдилә, Ык суында чуртан балыгыннан башка куркыныч балыклар юк.

— Чыгыйк судан. — Әдилә кулы белән Зарифның яңагына кагылып алды.— Сездә чынлап та столбняк булып куймасын, Зариф. Кайту белән укол салдырыгыз.

— Мин ул ярага хәзер эт үләне табып каплыйм, иртәгә үк бетәр дә куяр. Әдилә киемнәрен калдырган таллыкка кереп китте, Зариф — икенче якка. Әдилә киенеп чыкса да, Зариф юк иде әле.

— Зариф, әллә сез тагын коенырга уйлыйсызмы?

— Сабыр итегез, Әдилә, мин хәзер.

Таллар арасыннан ул кыңгырау чәчәкләре тотып килеп чыкты. Чәчәкләр күргәч, Әдилә бөтен йөзенә елмаеп җибәрде.

— Рәхмәт инде, Зариф. И-и, бигрәк матур икән, — дип, Әдилә сакланып кына чәчәкләрне күкрәгенә кысты.

— Әдилә, бүген кич клубка чыгарсызмы? — диде Зариф елмаеп. Әдиләнең канлы күлмәккә карап торуын абайлады.— Курыкмагыз, бу күлмәк белән чыкмам. Минем тагын бер күлмәгем бар әле...

— Кызык кеше икәнсез, Зариф. Танышып та өлгермәдек... Юк, чыга алмам, гафу итегез,— диде Әдилә, хатын-кызларга хас нәзакәтлелек белән елмаеп. Егет моны ризалык дип аңладымы:

— Аннары Зур күл буена төшәрбез, — диде.

— Төнлә күл буйларында йөрергә куркам мин... — Әдилә, башын болгап, керфек арасыннан гына аңа карап алды. — Килеп алсаң, күз күрер... — дигән булды шаяртып.

Әдилә күңелендә тагын ниндидер бер җиңеллек тойды. Озаккамы барыр бу? Соңы ни белән бетәр? Хәзер бу турыда уйлыйсы килми иде аның. Кемдер аңа игътибар итте, кемдер аны ошатты, кич клубка чакыра. Ә беләме икән соң ул Әдиләнең кем икәнен? Белми шул, белми. Нигә соң әле тиктомалга алгысытам мин бу егетне? Танышуларга-кавышуларга, аннары мәхәббәткә әйләнеп китсә. Җәвит белән дә әнә шулай уен-көлкедән генә башланып китте түгелме соң? Йөрәгеңә коткы салма, Әдилә! Мин аңа хәзер үк ирем, балам барлыгын әйтергә тиешмен. Мин бит әле Җәвит белән аерылышмаган да. Тукта, тукта, нигә соң әле мин шул хәтле тирәнгә кереп уйлыйм? Миңа бүген аның белән рәхәт, күңелле булды ич. Күрәм-сизәм: ул миңа карата битараф түгел. Алай гынамы, бәлкем гашыйк та булгандыр әле. Бер күрүдә үзең Җәвиткә гашыйк булган кебек.

Әмма Әдилә үз-үзен ничек кенә юатмасын, аның инде ире, баласы барлыгы күңеленнән бер генә минутка да китмәде. Шуңа күрә егет яңадан әлеге тәкъдимен кабатлагач, Әдилә: «Белмим, кирәкмәстер, чыга алмам, Зариф», — дип кенә җавап бирде.

Әйе, йөрәктәге яралар яңа шул әле. Йөрәкнең тынычланып җиткәне юк...

Болында үзләрен эзләүче күренмәгәч, Әдилә белән Зариф туптуры авылга таба юнәлделәр. Сүзсез кайта торгач, ике арадан күләгә үткәндәй булды. Баштагы дәрт Ык буенда калды, шаулап таша башлаган күңел үз ярларына кайтып төште.

Тыкрык башына җиткәч, Зариф, Әдиләнең күзләренә карап:

— Мин сезне кич көтәм, Әдилә...— диде.

— Белмим, Зариф. Кәефем булса чыгармын да бәлкем. Чыга алмасам, үпкәләштән булмасын, яме?..

## 23

Шундый кешеләр була, үземә тигән өлеш дип, үз гомерләренә язмышларына буйсынып яши бирәләр. Ниндидер дәрәҗәдә бу сыйфат Кәфиядә дә бар. Ягымлылык, кече күңеллелек, гомумән, врач кешеләргә хас игътибарлылык Кәфиянең йөзенә үк язылган. Талип исә җитди, кырыс. Хатын-кыз буларак, назлы сүз, сөю-ярату, һич югы, игътибар Кәфиягә дә кирәк иде. Читләр моны күрәләр, ир-атлар аңа җанга ятышлы матур-матур сүзләр әйтә. Кәфия, әлбәттә, аларны чынга алмый, әмма шулай да мондый сүзләр аның йөрәгенә май булып сеңә иде. Кәфия үзе ире алдында чытлыклана белмәде. Талипка исә йомшак теллелек ят сыйфат иде. Кеше кимчелексез булмый, иренең бу холкына яши-яши Кәфия дә гадәтләнде тагын. Хәзер инде ул тәмам өйрәнеп,ияләшеп бетте. Ике бала үстерделәр, ике дистә елга якын гомерләре бергә үтте. Ә менә күңел дигәнең әллә нишли дә куя шунда. Наз телиме, игътибармы, белмәссең...

Балалар биредә чакта ялгызлык аны ул хәтле талкымый иде, алар киткәч, өй тәмам бушап калды сыман. Талип йокларга гына кайта, сөйләшкән сүзе дә — комплекс та, икмәк тә төзелеш. Ярый әле, яраткан эше бар. Бүген әнә кешеләр болында ял итә, ул исә райүзәккә чапты. Талипка түгел, үз-үзенә ачуы килә Кәфиянең, күзләренә мөлдерәп яшь тула. Җәберләнә, рәнҗи башлый күңел. Кемгә? Әлбәттә, аңа, Талипка. Кешеләр кебек нигә аларга да, ичмасам, ял көнендә генә болынга төшмәскә!

Кәфия үз-үзен тынычландырырга тели, Талипның эше күплеген сәбәп итеп куймакчы була, әмма ярсый башлаган күңел инде тынычлана алмый.

Әнә шулай көяләнеп, күңеле пыскып-көеп торганда эчке якка Миңлекамал әби килеп керде.

— Һи-и, балакай-киленкәй, нәмәгә болай боегып торасың? Талипны көтсәң, кичкә дә кайтмас ул. Төзүчеләренә кирпеч юлларга китте бугай...

«Ял көнне кирпеч юлларга?» дип уйлады Кәфия, кәефе тагы да кырыла төшеп.

— Дәҗҗал димәсәң дәҗҗал инде. Көн дими, төн дими, өен ташлый да чыга да китә, кулына кулча кидерәсе нәмәстә. Әнә Мөгаллим Нәгыймәсе дә төшеп китте, боегып торма, киен дә төш. Бар-бар, ичмасам, иркенләп һава сулап кайтырсың, — диде карчык.

Кәфия, сабый баладай, Миңлекамал әбисенең сүзләренә буйсынды. Шкафтан җиңел ефәк күлмәген сайлап алды. Аксыл-зәңгәр күлмәк киеп куйгач, зәңгәр күзләре тагы да зәңгәрләнеп китте кебек. Каш-керфекләренә беленер-беленмәс кенә итеп сөрмә тартты, иреннәренә юка гына итеп иннек сөртте. Башта ул аягына туфли киярга ниятләгән иде, эссе булыр дип, җиңел босоножкасын гына киеп алды.

Урамда аңа беркем дә очрамады. Болынга төшәсе кешеләр төшеп беткән инде, күрәсең. Болын тыкрыгында аңа Кәнзел очрады. Соңгы вакытларда Кәнзел ябыгып китте, күзләрендә нур сүнде. Кәфия аны күргән саен кызганып куя иде.

— Исәнме, җиңгәчәй! — диде Кәнзел, башын иеп кенә.

— Исәнме. Нигә болай кәефсез йөрисең? Чирләмисеңдер бит? Каяле, кая?

Кәфия Кәнзелнең аскы күз кабагын тартып, күзенә карады.

— Сары чыгарырга җыенып йөрисеңме әллә син тагын? Тәмам төсең качкан...

— Чирләмим лә мин, җиңгәчәй. Эч поша. Болынга төшкән идем, анда да ямь тапмадым. Әллә башны алып бирәр кая чыгып китәсе инде? Өйгә кайтсаң, әтәй үзенә, инәй үзенә сукрана.

Кәфия аңа кызганып карады, вак-вак кына итеп ияк кагып торды.

— Зәйтүнәнне онытa алмыйсыңмы әллә һаман, җүләрем!

— Кадалып китсен лә!..

— Җитәр инде, Кәнзел, бүтән өйләнмә.

— Өйләнү кайгысымы миндә хәзер, җиңгәчәй! — Кәнзел яңак сеңерләрен уйнатып алды.— Талип абый кайда соң?

— Әлмәткәме, райүзәккәме киткән, ди.

— Ай-һай, райүзәккәме икән?! Белмисең әле син аны, җиңгәчәй, тыштан изге, эчтән бизле кеше түгелме икән ул Талип абзый?..

— Аны чәйнәүчеләр болай да җитәрлек, ичмасам, син генә канына тоз салма инде, Кәнзел. Агай-энеләр бит сез!

Җиңгәчәсенең тавышында үпкә-рәнҗү тоеп, Кәнзел кабат дәшмәде, кул селтәде дә китеп барды:

... Кәфия, Ык яры буенда табын корып утырган Харисовларны күреп, туп-туры шунда атлады.

— Җәй-чәчкә бәйрәме котлы булсын! Исәнмесез!

— Энекәем, Кәфия! — дип каршы алды аны Галимә карчык.— Әйдәле, әйдә, менә моннан утыр. Нигә төшмиләр дип борчыла башлаган идек инде. Талибулла кая соң?

— Райүзәккә киткән диме, күрми дә калдым мин аны.

Кәфияне Гариф Латыйпов янәшәсенә утырттылар. Казан галиме Кәфиягә күз төшереп алды да уелып-уелып аккан Ык суына карап уйга калды. Галимә карчык гөрли-гөрли чәй әзерләргә кереште. Юкә балын Кәфия алдынарак этәреп куйды.

— Җитеш әйдә, баллап эч. Карлыган кагыннан да, чия вареньесеннән дә җитеш.

Табынга утыргач, Кәфиянең кәефе күтәрелә төште. Ирләр арасында йомшак кына аңгәмә бара, колакка агымсу тавышы ишетелеп китә иде.

— Менә сез, Гариф туган, туфрак туклыклы булганда бер гектардан алтмыш-җитмеш центнер уңыш алып була, дисез. Моңа шартлар бармы соң әле бездә? Без аны, туфракны диюем, эшкәртергә дә яңа гына өйрәнеп килдбез бит...

«Болар да шул турыда, боларда да Талип чире!» дип уйлады Кәфия. Әмма күзе Гариф йөзенә төшкәч, ул бу кешенең эчтән генә тагын ни турындадыр уйланып утыруын сизде. Шул ук вакытта үзе Харисовны да тыңлый иде кебек.

— Шартларны без үзебез булдыра алабыз, Әдһәм абый. Хикмәт бер туфракның серләрен белүдә генә түгел шул. Туфрак ел саен үзгәрә тора. Яхшы уңышны бер ашлама гына да хәл итми, әлбәттә. Бар яктан да туйган туфракка иң әүвәл дым кирәк. Менә бу иссез ромашка,— Гариф яр читендә үсеп утырган ромашкага күрсәтте,— тәүлегенә өч йөз грамм су эчә, үзенә кирәкле дистәләрчә микроэлементларны җыя...

— Карасана син аны, шушы бер чәчкә тәүлегенә өч йөз грамм су эчсен диген, әй. Бөтен кырларны сугаруга көйләп булыр идеме икән, атасы, Ык елгасын Таз тауга күчерсәң?

— Булмаган хыяллар белән хыялланып утырма әле, әнкәсе,— диде Харисов карчыгына.
— Калхуз бөтен техникасын җиксәме?..
— Эч әле, әнкәсе, чәеңне. Тузга язмаганны сөйләп утырма.
— Чәй... житкәндер инде. Яшьләр әнә Зур күл буена киттеләр. Әйдәгез без дә әйләнеп килик.
— Кузгалсак, әйләнеп маташмабыз инде. Җый табыныц, алайса.
— Әллә безгә дә чүпләмле уйнап аласымы икән? Кәфиянең дә әнә кәефе юк кебегрәк. Әллә ул да Ык суын Таз тауга күчерергә хыялланып утырамы? — диде Галимә карчык, беркадәр ачуы килеп.
— Галимә апа, нигә алай дисез әле? Оялтмагызчы шулай. Иртән кәефем чынлап та начар иде, менә сезнең янга төшкәч, гел күңелләр күтәрелеп китте.
— Абау, ходаем, алладан каһәрләнгән кешемендер, күрәсең, кулымны пешердем бит! — диде Галимә карчык, уң кулын җилпи-җилпи.
— Кая күрсәтегез әле, Галимә апа.
Кәфия Галимә карчыкның кулын караган арада ирләр табыннан торды. «Менә ул нинди бит хезмәт кешесенең куллары», — дип уйлады Кәфия, карчыкның сырланып, кантарланып беткән кулын карый-карый.
— Зыянлы түгел, салкын чәй чүбен каплыйбыз да шундук басылыр. Тик яулык белән булса да урап куй. Инфекция кермәсен.
— Безнең кулларга карарга да куркынычтыр инде, — диде Галимә карчык, иреннәрен бөрештереп. — Томана булып яшәдек, шулай үләрбез дә инде. Минем бит шул Ык буе Карамалысыннан ары һич кая чыкканым булмады. Картым әнә ике елга бер булса да җылы якларга барып кайта.
— Юкны сөйләп торма әле, әнкәсе. Үткән ел гына Талип үзебезне Әлмәткә театрга алып барды бит.
— Мин анда кич бардым, төнлә кайттым, берни дә күрә алмадым, — диде карчык үртәлеп.
Харисов, ни әйтергә белмичә, күзләрен тирә-юньгә йөрткәләп алды, авызын учы белән каплап, тамак кырудан башка әмәле калмады.
— Әйдәгез, булмаса, урман ягына. Карчыкның чәе каты булды, ахрысы, әллә ниләр сөйли башлады, — диде Харисов һәм беренче булып кузгалып китте. Гариф аның белән янәшә атлый башлаган иде, Харисовның җиңеннән тотып, күзләре белән хатын-кызны күтәргә кирәктер дип ымлады. Ниһаять, алар да килеп кушылды. Харисов, үз гаебен сизеп, карчыгын култыклап ук алды.
Теләсәләр-теләмәсәләр дә, Гариф белән Кәфия алдан, бергә атлап киттеләр.
Яр буенда балан куаклары, шомырт, тал үсә. Һәммә җирдә яшеллек. Рә тавында сыер көтүе йөри. Ат өстендәге көтүче һай-һайлап кычкырып җибәрә дә яңгыратып чыбыркы шартлатып куя. Ул да түгел, «Ашказар»ны суза башлый. Матур җырлый.
Күк йөзендә бер болыт әсәре юк. Елга ягыннан дымсу җылы җил исеп-исеп куя. Елга исе, үлән исеннән жиңелчә баш әйләнә кебек. Больница палаталарыннан соң үтә саф, үтә шифалы болын һавасын сулаган саен сулыйсы килә.
Бер ара китүләре булды. Харисов белән карчыгы кала төштеләр. Карчыгы аңа, ым кагып, ияреп йөрмик әле, диде. Харисов башта карчыгының ни теләвен аңламаса да, ахырда, кузгалак эзләштергән булып, кала-кала кире борылды.
Яр астындагы карлыган куагында чут-чут итеп сандугач сайрый, аңа балтырган сабагында җай гына чайкалып утырган ак чәперчек кушыла.
Кәфия Карамалыга килү белән үк Ык буйларын, әрәмәлекләрне

яратты. Җәй җиттеме, ул ял саен диярлек бергә төшә һәм арып-алҗып, туйганчы йөреп, хозурланып кайта иде. Җәүһәрия укырга киткәнче алар гел бергәләп йөрделәр. Берьюлы балтырган, кузгалак, әче кабы да җыеп алып кайта торганнар иде. Аннары кич белән Кәфия балтырган ашы пешерә. Катык каткан балтырган ашын Талип икешәр тәлинкә ашый иде. Ә Минлекамал әбиләре: «Күңелемә исе ярамый шул балтырганның» дип, Таҗылбанат туганнарына китеп барыр иде. Талип аның артыннан: «Байларга балтырган ашы ярыймы соң!» дип кала, Җәүһәрия эче катып көлә...

Кәфия, уйларыннан арынып, янәшәсендә атлап барган Гарифка күз төшереп алды. Горур кыяфәт, тәкәббер йөз... Үз көченә үзе нык ышанган кешеләргә хас кыяфәт. Киноларда шактый еш күргән кемнедер хәтерләтә. Нигәдер бер кашы агарган. Киң маңгай. Чигәләре көмешләнә башлаган куе чәч, яңаклары чак кына эчкә баткан. Кысык, юка иреннәр.

— Карамалыда бик күңелсез түгелме соң, Гариф Әюпович?

Гариф аның ягына күз сирпеп алды, иелеп чәчәк өзде.

— Ничектер эш белән сизелми. Кеше бит ике очракта гына сагышка янсә төшенкелеккә бирелә: акылы артып киткәндә яки кимегәндә, икенче төрле итеп әйтсәк, хиссияткә бирелгәндә. Ә мин ул чорны кичердем бугай инде. Бу — шаяру, әлбәттә. Кайчак башка әллә нинди уйлар килеп куя. Әтинең каберен, һич югы, кая күмелүен табасы иде. Бирегә килгәнгә кадәр бу алай ук борчымый кебек иде мине.

— Ул каберне кем генә эзләмәде инде, Гариф Әюпович. Тик кем күмде икән аны? Әдһәм абый суга ташлангандыр дип бара. Ул канлы елларда эзсез югалучылар күп булгандыр инде. Кичәгенәк бер шигырь китабы кулыма төште. Шагыйрь Шамун Фидаи дин әһелләре тарафыннан унсигез яшендә җәзалап үтерелгән. Тәмам танымаслык итәләр үзен, аннары сазга ташлыйлар. Дәһшәтле еллар кемнәрнең генә башына җитмәгән. Уфадан килгән аклар ул төнне бездә дә күп кешене җәзалаганнар, ди Әдһәм абый.

— Шамун Фидаиның, ичмасам, гәүдәсен табалар һәм кадерләп күмәләр. Хәтерем ялгышмаса, халыкны ураза тотуга каршы өндәгәч була ул хәл... Ә бирерә бит бөтенләй башка нәрсә. Әтине Уфадан килеп төшкән казаклар үтерә. Ни өчен килгәннәр алар бирегә? Бер Әюп Латыйповны үтерү максаты белән генәме? Нигә әтинең гәүдәсе юкка чыга? Акларның бирегә килүенең сәбәбе нәрсә? Минемчә, алар Карамалыга бөтенләй Әюп Латыйповны эзләп килмәгәннәр. Максатлары бөтенләй башка булган булса кирәк. Әти һәм Карамалы активлары кем тарафыннандыр котыртылып юк ителгән, минемчә.

— Телисезме, Гариф Әюпович, мин сезне шул аклар отряды чыккан кичүгә илтәм. Миңа аны Әдһәм абый күрсәтте.

— Бик теләп барыр идем дә, әллә нигә яшьләр күздән югалды. Кызыма әбисе бераз йөргәч кайтырсың дип җибәргән иде, онытып китте, ахры.

— Кызыгыз бирдә, Гариф Әюпович, ә әнисенең килеп тә карагаганы юк, — диде Кәфия һәм шулай дип әйтүенә бит очларына кадәр кызарып китте.

— Әнисе... Әнисе... — диде Гариф әчке бер сагыш кичереп. — Әдилә үзе ана инде ул, кыз үстерә.

Ык буендагы усак урманында күке кычкыра, кое сиртмәседәй койрыгын бер күтәреп, бер төшереп, урман авызындагы карамада саескан шыркылтый. Кемнедер күзәтә, кемнәргәдер нидер хәбәр итә урман сакчысы. Иске юл сулга борылды. Бер тын баруга, юл тарайды, сукмакка калды. Кәфия агач ботакларын читкә ала-ала алдан барды. Карама, усак, шомырт, юкә ябалдашлары арасыннан аяк астына тәңкә-тәңкә кояш нурлары төшә. Ниһаять, алар яр читенә килеп чык-

тылар. Җентекләп карасаң күренә: кайчандыр бередән юл уткән, яр асты сөзәкләнеп, уелып тора. Яр буена житүгә, сукмак та кырт борылып, сулга, агачлар арасына кереп югалды. Иске кичү юлын тигәнәк, кычыткан, меңтармак, бояр гөле, чыпчык күзе үләннәре баскан. Суга «чәчләрен» тидерер-тидермәс таллар моңаеп утыра. Елганың тау-башкорт ягына күз ташласаң, колак салсаң — тургай моңы.

— Менә ул кичү, Гариф Әюпович.

Кәфия яр буендагы ашъяулык кадәр генә аланга туктады. Тирәюньдәге барча тавышны күмеп, таң чыпчыгы чутылдап җибәрде.

Шул мәлдә башта бик нечкә, зәгыйфь кенә булып сары сандугач моңы да ишетелде. Аннары ул көчәя төште. Бу моң ниндидер могҗизалы тылсымга ия иде, ул илаһи аһәңе белән сине сихерли, күңелнең иң нечкә кылларына кагыла иде. Алар сөйләшмәделәр. Һәркем үзенең эчке дөньясында яши иде. Сандугач сайраганда сүзләр артык шул.

— Гаҗәеп матур бередә,— диде, ниһаять, Гариф.— Ямьле Ык буйлары дип тикмәгә генә җырламыйлар икән шул.

Алар икесе дә яр читенәрәк килделәр. Яр астында су юып чыгарган колач житмәстәй агачлар, еланнарга охшап, чәбәләнеп яткан шәрә тамырлар күренә. Шунда ук кырмыска оясы. Куе камышлыкта энә караклары мәж килә.

Чак кына арырак, ниндидер могҗиза белән эләгеп калган утраучыкта, кубәләкләр биешә.

— Безне югалтмадылар микән, Гариф Әюпович?

Гариф, уй-хисләреннән арынып, яр читендә зәңгәрсу күлмәктән басып торган Кәфиягә карап алды. Кәфиянең чәчләре бер як битен каплаган иде, шуңамы, ул елмая сыман тоела, әллә шулай мөлаем итеп карый гынамы?

— Әйе, кайтырга кирәк. Юк белән йөрим бугай мин. Һәр чорның үз каршылыгы, үз фаҗигасе була шул...

Кайту юлына төштеләр. Хәтфәдәй яшел болынга килеп чыккач, моңа кадәр дәшми-тынмый барган Кәфия Карамалының тарихын сөйләргә кереште. Гариф аны дикъкать белән тыңлап барды. Ахырда Кәфия:

— Ялыктырдым мин сезне, Гариф Әюпович, әкиятләрем белән,— диде.

— Сөйләгез, сөйлә, бик рәхәтләнеп тыңлыйм мин сезне. Менә уйланып кайтам әле, эш белән мавыгып, шушы табигатьне әлегә кадәр төшеп карый алмавыма үкенәм.

Кәфия аңа үләннәр турында сөйли башлады. Сер түгел, Гариф аларның күбесен белми, ә менә бу врач хатын белә, хәтта дәвага да куллана икән. Житмәсә, «Файдалы үләннәр» дигән хезмәт тә язып ята икән.

Авыл ягында сузып-сузып машина кычкыртты.

— Бу миңа, Гариф Әюпович, мине эзлиләр,— диде Кәфия һәм күзенә сибелеп төшкән чәчләрен уң кулы белән сыпырып куйды да хушлашып китеп барды. Гариф аның зифалыгын җуймаган гәүдәсенә Кәфия тыкрык башына кереп югалганчы карап торды. Бу хатынны күргән саен аның күңеленә ниндидер бер сагыш иңә. Кемгә охшата ул аны, нигә ул шулай я сагышлана, я күңелендә җиңеллек тоя аны күрүгә? Әлбәттә инде, Саниясен хәтерләтә ул...

## 24

Тукталышта халык күп иде. Мидхәт район үзәгенә мотоцикл белән генә бармавына үкенеп алды. Көн эссе булуга карамастан, автобус көтүчеләрнең кайберләре җылы киенгән. Ул килеп сөялгән магазин ихатасы янындагы эскәмиядә ике карчык сөйләшеп утыра иде.

Картрагы, йон яулыгын маңгаена төшереп бәйләгәне, Мидхәт ягына карап-карап алгалады. Автобус күренде. Халык дәррәү шуңа таба кузгалды. Йон яулыклы карчык, халыкны ыра-ера дигәндәй, беренче булып ишек янына килеп басты. Төшәсе кешеләр төшеп беткәч, карчык иң алдан автобуска кереп утырды. Мидхәт ашыкмады. Басып та барырмын әле дип уйлады.

— Фәһимә, син кая утырдың? Менә монда, минем янга күчеп утыр, — дип кычкырды карчык. Фәһимә дигәне Мидхәт алдындагы урындыкта бер яшь кыз белән янәшә утыра иде, кузгаласы килмәде — бик яхшы урнашкан иде әбекәй.

— Күчмим, Хөббенисаттәй, анда бензин исе килә.

Алда утырган карчык, бу хәлне яңа гына аңлагандай, торып басты, борынын тартып иснәп карады, чынлап та бензин исен тойды, ахры — түенчеген култык астына кыстырып, Фәһимә карчык янына күчеп килде.

— Үскәнем, — диде ул сердәше янәшәсендә утырган кызга, — минем урынга күчеп утырчы. Алда әллә нәмәгә башым әйләнә.

Кыз, сүзсез генә торып, карчыкка урын бирде. Ләкин ул карчык бушаткан урынга таба кузгалырга да өлгермәде, алгы ишектән берәү керде дә шундук буш урынга чүмәште.

— Утырыгыз, — диде аңа Мидхәт, урыныннан тора-тора. Кыз аңа сирпелеп алды, рәхмәт әйтеп Мидхәт урынына утырды.

Шофер билет сата башлады.

— Син, үскәнем, Карамалыга тагын бер юллыйсыңмы? — дип сорады тынгысыз карчык шофердан.

— Киләм-киләм, әбекәй. Шәлеңне сатып өлгерерсең әле, — диде шофер көлемсерәп. Ул кайтарып биргән тиеннәрне карчык иреннәрен кыймылдата-кыймылдата санады, ә аннары билетның хакын әйләндерә-тулгандыра тикшерде.

— Карале, Фәһимә, җитмеш тиенлек дигәнме?

Фәһимә дигәне билетка күз дә төшермәде.

— Җитмеш, Хөббенисаттәй, җитмеш.

Мидхәт мотоцикл белән генә китмәвенә янә бер үкенеп куйды. Вафа бик сорагач, кырга чыгасым бар дип үтенгәч, «өчтәгәрмәчен» аңа калдырган иде. Райүзәктә көне үтеп, Мидхәт Тамчының туган көненә кайтып җитә алмаса? Чакырды бит ул аны, атлап килеп чакырды.

Мидхәт янәшәсендә утырган кызга күз төшереп алды, аны Тамчы белән чагыштырды. Чем-кара күзле, чибәр генә йөзле кыз иде бу. Күз тирәләренә шәмәхә иңдергән, баш түбәсендә күпертеп салган чәч, әллә шиньон, әллә парик, белмәссең. Ничек кенә кыландырмый хәзерге кызлар чәчләрен. Кыска җиңле ак кофта кигән, йомры тезләрен каплаштырырга тырышып, шакмаклы йон юбкасын тартып-тартып куя, Мидхәтнең күз карашын тоя, күрәсең.

Мидхәт күңеленнән үзен ишек янына бастырды да кыз күзе белән үз-үзенә карады.

Якалары керләнә башлаган ак күлмәк, үтүк күрмәгән, тез асты гармун күрүгедәй җыерылып килгән джинсы чалбар, аягында күнгә охшатып ясалган «чабата». Култык астында тышы шомарып беткән папка, җилкәсенә җитеп үскән тузгак чәч...

Мидхәткә күршесе аның нәкъ шул керләнгән якасына карап-карап ала кебек тоела башлады. Һәм аңа колак артын кашудан башка әмәл калмады.

Автобус килгәнче үк авызларын-авызга куеп сөйләшә башлаган карчыклар, янәшә утыруга, тәмам сүзләрен үзмәс булдылар. Башлары башка тиеп-тиеп китә. Мидхәт аларның сүзләренә колак салды:

— ...дрә дә яман кылана инде, Фәһимәкәем. Иң түрдә түшен киереп утырыр, сәдаканы үрелеп алмас, — дип тезеп китте карчык. — Тә-

мам оятын җуйды инде бу Тажылбанат. Теге беркөнне, Фәһимәкәем, бер сум сәдакамны алмый. Оятымнан җир тишекләренә кереп кенәләр китәсем килде инде менә! Шул тиклем гарьләндем, Фәһимәкәем, шуннан соң ашка да дәшми башладым әле үден. Ичмасам, Гыйлаҗетдин бабайга бирермен дә, кул күтәреп фатихасын кылыр. Карале, Фәһимә, теге Әюп малаеның кыды да бармыни? Анысы да шул лабартуриягә эшләргә килгән диләр бит. Расмы шул, Фәһимә?

— Һай, Хөббенисаттәй, ул кызның ике яшьлек кызы бар инде. Кияүдә инде ул.

Хөббениса карчыкның маңгаена җыерчыклар өелде, ул авызын бөрештерде һәм, тирән хафа кичерүен сиздереп, зарланырга кучте:

— Минем тиле беркөнне шуның белән су коенган бит әле. Латыйфа Сәмигасы күргән үдләрен. — Карчык, колагын тырпайтып тыңлап торучы юкмы дип, алга-артка күз ташлап алды һәм, күршесенә таба тагын да елыша төшеп, сөйләп китте: — Анадан тума шәрә диярлек, комда кыдынып ятканнар икән, Фәһимәкәем. Үде дрә дә дифа, сылу ди.. Беднең тиле Дарифулланың авыды колак артына җиткән ди. Кияүдәге хатын белән сулар коенып йөри икән бит, тилекәй. Менә гыйбрәт димәсәң дә гыйбрәт инде. Өйләнми генә бит, җаннарыма тиеп бетте инде, нишләп кенәләр карамадым, тәмам тәкатьләремне корытты. Уйлап торам-торам да хафага калам: әллә, мәйтәм, олкып-йолкып, чит-ятлардан өлеш алып йөри микән, мөртәт? Юксам, бер садаган кыд булса да ярап торыр ие үденә. Ии, Фәһимә, синә да үпкәлим инде, син дә тапмадың үденә берәрсен. Шәһәрдән кирәкми, юка сыйраклар аңа ярамас. Наратбашта юкмы шунда тиңнәр? Наратбаш кыдлары элек-электән эре сөякле була торганнар ие. Димлә әле үденә берәрсен, син бит аңа дрә дә һәвәссең..

— Мин синең ул гыйбадыңа кыз димләмим хәзер, Хөббенисаттәй. Нурыйхан Тәслиясе ярамады, Исламгали кызының буе кечкенә дип сайланган була. Сабирҗан Фирдәүсәсе белән йөреп карады, боткалары пешмәде. Синең ул җан көегең үзе гаепле, Хөббенисаттәй. Чакма таштай чәчрәп торса икән. Эшен эшли, дәрте-дәрманы аңа җитә, беләге талусыз булсын. Ә менә кызлар янына килдеме зрә дә тарау бит синең Зарифуллаң. Кызлар бит алар чәчрәп торган егетләрне ярата. Юк инде, юк, Хөббенисаттәй, синең ул тешәмәгән нәмәстәңә мин кыз димләмим яңадан, үзе тапсын...

Хөббениса карчык хурланды, дәшмәс булды. Ирен читләрен сөрткәләп, утырган урынында борсаланып алды, шуннан соң гына, тамак кырып:

— Исламгали Дәмиләсен мин үдем яратмаем. Атасы чи ялкау, анасы урамга чыкса, өрән салырга тора.

— Ә сез утырыгыз, сыярбыз. Утырыгыз, утыр, — диде кыз, аягын алмаштыра-алмаштыра басып торган Мидхәткә. Кыз шулай диюгә, Хөббениса карчык шул якка күз ташлады.

— Әнә бит алар ниндәйләр, үдләре үк алларына утыртырга торалар. Ә минем Дарифуллам андый түгел шул.

— Әбекәй, юкка ачуланмагызсана. Бу кыз сезгә урын бирмәсә, басып барасыгыз иде бит әле. Рәхмәтегез шулмы? — диде Мидхәт карчыкка.

— Дрә дә яман дур идгелек эшләде инде, егылыплар китәрсең...

— Сез аңа бөтенләй игътибар итмәгез, карт кеше ни сөйләмәс, — диде аннары Мидхәт, карчыкның зәһәр сүзләреннән кызарынып киткән кызга.

— Ә мин аны тыңламыйм да.— Кыз итәкләрен җыя төшеп, тәрәзә янынарак елышты.

— Мин сезне Карамалыда беренче күрәм, нинди җилләр ташлады бу якларга?

Кыз, Мидхәтнең сораштыруына гаҗәпләнүен сиздереп, иңбашын җыерып куйды һәм тәксе генә:

— Әллә сез Карамалыга килгән бар кеше белән дә танышырга дип ел башыннан ук йөкләмә алдыгызмы? Биредә практика үтәм мин, больницада, — диде кыз һәм, сөйләшергә теләмәвен аңлатып, күзләрен тәрәзәгә текәде.

— Димәк, сез врач буласы кеше?

— Түгел, сестра гына, шәфкать туташы,— диде кыз, Мидхәткә карамыйча.

Мидхәт тагы да сүз башларга исәпләп, күршесенә елыша төшкән иде, күзе тез өстендәге папкага төртелде. Шушы папкада аның язмышы. Ярты сәгатьтән ул ел буе җыйган материалларын баш агрономга укыр. Агроном аның докладын, әлбәттә, хуплар, матбугатка тәкъдим итәргә кушар. Докладны Мидхәт председательгә укытып та тормады — ни аңласын белеме белән юрист булган кеше?

...Район үзәгенә автобус кырык минутлар чамасы барды. Башларын башка тереп, юл буе сөйләшеп килгән карчыклар да тынып калдылар. Һәркем үз дөньясына кереп чумды.

Баш агроном, буш җиңен кесәсенә тыккан килеш, бүлмәсе буйлап килеп сала иде инде. Мидхәт килеп керүгә, ул аңа исән кулын сузды.

— Мин инде килмисең дип торам. Я, ниең бар? Ниндидер доклад та язып өлгергәнсең анда! Утыр да укый башла,— дип боерды ул Мидхәткә, өстәл янынннан урын күрсәтеп. — Җәтрәк, ике сәгатьтән бюрога китәм,— диде.

Күтәрә алмастай нинди зур өметләр белән барган иде бит Мидхәт аның каршына. Ә нишләтте ул аны? Доклад түгел бу, председательгә каршы язылган мәкалә, диде. Гарьлегеңнән җир тишекләренә керерсең, билләһи. Ул төшеп калган автобус әнә авыл ягына борылып бара. Мидхәт папкасын култык астына кыстырып, үзе һаман баш агроном белән бәхәсләште. «Авыл хуҗалыгын звеноларга бүлгәләп кенә эш майтарып булмый», имеш!

Арыш басуына җитте. Яшькелт-сары арыш акрын гына искән җилгә чайкалып тора. Борынга әчкелтем серкә исе кереп тула. Җил исеп куйган саен башаклар сөйләшеп, пышылдашып алалар кебек.

Мидхәт яңа баш кысып, мыек типкән башакларны учына җыйды. Кош баласын кулына алгандай, аларны назлап кына сыйпаштырып торды. Бөтен тәне буйлап кымырҗу йөгерде. Басу ызанында гына кирәкмәгән юан кәүсәле бер каен үсеп утыра. Мидхәт бу каен янына еш кына тукташтыргалый иде. Яңгыр яуганда ышыкланып торганы бар. Аның калын кайрылары кантарланып, карт кешенең бит җыерчыкларына охшап калган. Корып кипкән ике ботагы, күктән мәрхәмәт сораган кебек, өскә төбәлгән.

Мидхәт, аркасын каенга тереп, җиргә утырды. Докладын алды, яңадан актарып чыкты. Кичә генә әле шушы папкага ул никадәр өмет баглый иде, йөрәге дәртләнеп тибә, күңел күгендә берсеннән-берсе матур һәм гүзәл хыяллар туа иде.

Татлы хыяллар ярты көн эчендә юкка чыкты.

Мидхәт уч төбендәге башакка карады. Аксыл-яшькелт төскә кереп, кабырчыкларга яшеренеп, бөртек туена. Ул әле сөт сыман бер хәлдә. Күп тә үтмәс, күксел-яшел төскә керер, туеныр, эч салыр һәм сихри бер көчкә ия булган батырга әверелер.

Икмәк. Һәммә нәрсәдән олы, җегәрле азык син. Синнән башка таулар киселми, җирләр сөрелми, ирләр ир булмый, яулар басылмый, җаннар үрчеми.

Меңнәрчә еллар кеше икмәк игә. Ни өсти алыр икән Мидхәт шушы кәсепкә? Меңнәрчә елларның бер чорын гына яшәүче кеше ич ул!

Бу уйлары өзелүгә, колак турында баш агрономның сүзләре яңгырады: «Бикмуллинга кыен хәзер. Ярдәм кирәк аңа».

Менә сиңа ачыш. Мидхәт Бәдретдинов аңа ярдәм итмиме? Звенолар оештырылса, уңыш алу бермә-бер артачак. Кеше һәрвакыт үз хезмәтенең нәтиҗәсен күрергә теләп яшәгән.

Буй урман юлында мотоцикл күренде. Мидхәт сикереп торды, мотоциклда Тамчы белән Вафаны күргәч, урлап тотылган кешедәй кабаланып куйды, аркасын каен кәүсәсенә терәбрәк басты.

Мотоцикл каенга җитәр-җитмәс туктады. Бишектә утырган Тамчы, сикереп төшеп, ызан буеннан берничә зәңгәр чәчәк өзде. Вафа да чәчәкләр җыя башлады. Менә алар икесе дә бер чәчәккә үрелделәр һәм башлары-башка тиеп китте. Вафа Тамчының битеннән үбеп алды.

Мидхәт, йөрәгенең тибүен тоймыйча, каенга тагы да сыена төште. Чигә тамырлары сулкылдады, аяк буыннары бушап китте. Һәм ул күзләрен йомды. Икенче мәлдә инде егет аларның, мотоциклга утырып, җилдәй очып китеп баруларын гына күрде.

Менә шулай. Берьюлы бөтен өметләре өзелде аның. Моңа кадәр күңел төпкеллегендә ниндидер ышаныч чаткысы яши иде әле, хәзер исә Мидхәт, баскан урыныннан кузгалырга, авылга таба атлап китәргә көче җитмичә башын иеп, каенга сөялгән килеш тора бирде. Нигә аны аңларга теләмиләр?

Әрсезнеке замана! Менә ул хакыйкать. «Тыйнаклык кызлар сөйгәндә генә әйбәт ул», диярга ярата иде аның бер укытучысы. Хәзер исә Мидхәт бу мәсьәләдә дә аның белән килешә алмас иде.

Вафа кыю, Вафа әрсез һәм кыз да аңа күбәләкләнә. Җор телле, кулыннан килмәгән эше юк. Әмма Мидхәт тә бит төшеп калганнардан түгел. Әле булса хәтерендә: чәчү беткән көн, алар икәүдән-икәү генә шушы каен төбендә сөйләшеп тордылар. Вәгъдәләр бирешмәсәләр дә, Мидхәт Тамчы күзендә өмет чаткылары күрде, аның йомшак кулларыннан тотып, җылы сүзләр әйтергә теләде. Тамчы аңа күтәрелеп карарга оялды. Ул кайтарылып торган озын керфекләрен түбән төшереп, Мидхәттән матур сүзләр көтте. Мидхәт, күкрәгенә сыешмыйча, шырпы кабына салган күбәләктәй бәргәләнгән йөрәген тыя алмыйча уфтанды, көрсенде. Тамчының керфекләре калтыранып, күтәрелеп китте. Кара күзләре белән Мидхәткә өздереп карап алды...

...Тамчы турындагы уй йомгагы сүтелә торды, Мидхәт юлга төште, аяк астындагы калын тузан баскан саен туфлиләренә бөркелеп-бөркелеп кунды.

— Яңгыр кирәк, бик кирәк,— диде Мидхәт. Уч төбен ачты, җан нясенә дәшкәндәй:

— Син яңгырдан мәхрүм, мин мәхәббәттән, башаккаем! — диде.

...Кунак йортына кайткач, ул диванга сузылып ятты. Бүлмәсе зур түгел, ләкин күңел тынычлыгы китерерлек пөхтәлек бар: диван, язу өстәле, радиоалгыч, «Юность» телевизоры, китап шкафы, телефон. Телефонны председатель куйдырды. Боерыкны телефон аша бирә. Җитмәсә, эшләдеңме, юкмы? дип кат-кат тикшерә.

Үчле кеше — эчле кеше. Килер бер көн, Мидхәт тә үсәр. Талип Бикмуллинның түшәме — председатель. Ул шуннан югарыга менә алмый. Ә менә Мидхәт Бәдретдинов үсәсе кеше. Димәк, баш имәскә, көрәшергә, җиңәргә кирәк. Тормыш, яшәү көрәштән гыйбарәт.

Егет күңеленә әнә шундый татлы уйлар йөгерде. Тик бераздан инде ул үз-үзен тиргәргә кереште. Их, син, катык борын, кая үреләсең? Кем белән тиңләшәсең?.. Авыр булып китте аңа. Мидхәт үзен кыйнап ташлаган кешедәй итеп сизә. Докладына нинди генә өметләр багламады бит ул. Юк инде, булмады болай булгач.

Мидхәтнең күңел кыллары нечкәреп китте. Балаларын явыз песи туздырып ташлаган кош оясына охшап калган иде аның күңеле.

*Ахыры бар.*

## Галимҗан Латыйп

### Күкләрем шундый биек

Төннәрем йокымнан уятып,
Шакый да бүлмәмә керә җыр.
Көтми ул таңнарым атканны,
Әйтә ул: җыр көтә безнең чор.

Калсыннар иң татлы йокылар,
Калсыннар җырларым хакына.
Янымда җыр булса һаман да,
Таңнарым иртәрәк яктыра.

Күңелемә җыр килгән чакларда,
Чын-чынлап яшим мин дөньяда.
Ә җырсыз көннәрдә, беләмсең,
Көн яна, мин янам, төн яна.

И дөнья! Аерма син мине
Канатлы тулпарым-җырымнан.
Мин синең учагың янында
Гөнаһсыз сабыйдай җылынам.

### Хәерхаһ булсын

Американың мәшһүр җырчысы
Дин Ридка багышлыйм.

Дәүләт бинасы
Каршында егет
Кушма Штатлар
Байрагын юа.
Мана да сыга,
Мана да сыга
Чип-чиста суга.

Тебәлгән аңа,
Тебәлгән мең күз.
Егет янына
Җыелган халык.
Әйтә Дин Рид:
Дәүләт байрагын
Калыйк коткарып.

Керле байракны,
Таплы байракны
Йөртүе безгә
Оят ул, оят.
Чистартыйк әле,
Бер чайкыйк әле,
Бар көчне җыйнап.

Әнә, күрәмсез,
Байрак дигәнем
Каралган ничек.
Мондый эш белән
Бер вакытта да
Булмый килешеп.

Ябь-яшь егетнең
Күңелен аңлау,
Йөрәген аңлау,
Юк, кыен түгел.
АКШ байрагын
Зур мәйданнарда
Чайкый ул бүген.

Чайка син, Дин Рид,
Чайка байрагын,
Американың
Йөзе ак булсын.
Туган халкыңның
Кылган эше дә,
Әйткән сүзе дә
Хәерхаһ булсын.

## Җил искән саен

Җил искән саен
Бөгелә каен,
Сыгыла каен.
Шул каенга сәләм мин
Шатлыгым, кайгым саен.

Шатлыклар кайчак азырак,
Кайгылар артып китә,
Кайгылар кубәйгән саен,
Шатлыклар килеп җитә.

Шатлыклар килеп җитә дә
Чөяләр югарыга,
Гел кояш нурлары гына
Сибәләр юлларыма.

Ачыла күгем, таңнарым,
Яп-якты киләчәгем.
Мин беләм, беләм һәр җирдә
Гаделлек, хаклык хакына
Шатлыкның җиңәчәген,
Бәхетнең киләчәген.

## Бер дустым бар иде

Бер дустым бар иде — күптәнге,
Хәтерләтә миңа үткәнне.
Ил иңенә салган йөкләрне
Алып батыр кебек күтәрде.

Булдымы икән берәр кешегә
Берәр тапкыр гөнаһ кылганы.
Мәшәкатьсез генә бер көнне
Калдырды да китте дөньяны.

Ничә күреп, ничә сөйләшсәк,
Сүзләр бетми иде һаман да.
Гашыйк иде җиргә, күкләргә,
Гашыйк иде шушы Казанга.

Ал-ял фәлән диеп тормады,
Мәңгелек дип белде дөньяны.

Эчендәге тышта. Нәкъ сабый.
Булса булыр икән ир җаны.

Язмыш аны салды утларга,
Язмыш аны усал сынады.
Корыч сынды, тимер бөгелде,
Ә ул түзем булды, сынмады.

Олы җанлы затны очратсам,
Мәхәббәтем артып дөньяга,
Сорау бирәм, сәер кешедәй:
«Дус идеңме әллә син аңа?»

## Ир уртасы чагың гына

Самат Шакирга

Адымнарын тормый санап,
Дөнья гизә безнең Самат,
Гел походта, армый, талмый,
Солдатларын җыя, барлый.

Яуда үлгән батырларның
Каберләрен таба эзләп,
Саный китсәң, алар хәзер
Бер Саматка алты йөзләп.

Егетләрчә туры басып,
Атлыйсың син сабыр гына.
Йөре, Самат, тынма, Самат,
Ир уртасы чагың гына.

## Кем синең дусларың

Катлаулы бу дөнья,
Мактаулы бу дөнья,
Мәкерле бу дөнья,
Саф җанлы бу дөнья.
Җылыта, туңдыра,
Егет бул, егылма!

Туктаусыз сыный ул —
Сине дә, мине дә.
Тырышма күп алып,
Азрак бирергә.

Сорый ул, тикшерә:
Кем синең дусларың?
Егыла башласа,
Торырмы икән ул
Иңенә күтәреп
Җир шарын.
Кем синең дусларың,
Кем синең дошманың?..

## Башыңны ия күрмә

Ничә яз,
Ничә көз үткән,
Чал кергән чәчләреңә.
Юк шул, мин карый алмыймын
Кайнар күз яшьләренә.

Ялгыштым,
Гаепле дисең,
Кадереңне белмәгәнмен.
Әй, яшьлек, үз бәхетемне
Үземнән көнләгәнмен...

Елама,
Гафу итәм мин,
Ләкин ни файда аннан?
Вәгъдәләр үтәлмәсә дә,
Мәхәббәт инде янган.

Яна ул, янмыйча калмый,
Дөрләп я пыскып яна.
Ахырда бер үк нәтиҗә,
Көл кала, күмер кала.

Берни мәңге түгел җирдә,
Яна да сүнә, димәк.
Тик янар учакларыңны
Яндыра белү кирәк.

Яндыңмы?
Яндым диярлек,
Сагынып сөйләрлек булсын.
Шатлыгың җир күкрәгенә
Сыртлап өярлек булсын.

Сөрт яшең, язмышыңны да
Каргама, кирәк түгел.
Синдә дә йөрәк, беләмсең,
Таш түгел, сөяк түгел.

Юата диеп уйлама,
Кызгана дия күрмә.
Йолдызлар ничек яналар,
Башыңны ия күрмә.

## Печәннәр чапкан җирем

Җиләкләр җыйган җирем бу,
Печәннәр чапкан җирем.
Күкләргә карап сокланып,
Ял итеп яткан җирем.

Чылтырап аккан чишмәдән
Учлап су эчкән җирем.
Покослар өстенә ятып,
Яшьлегем калды минем.

Кошлары шул ук һаман да,
Юк, алар картаймаган.
Кемнәрдер монда яңадан
Әйләнеп кайталмаган.

Тургайлар сайрый тибрәлеп:
— Саумы дип, исәнме дип,
Ялгызың гына йөрисең,
Дусларың килмәде ник?..

Эзләре калган аларның,
Тургайлар тоя аны.
Сизә бит, сизә барын да,
Белә ул тургай җаны.

Кошларның җыры һаман да
Шул ук та, шул да түгел.
Моңнары, сагышлары тик
Артарак төшкән бүген.

Тургайлар бала очырган
Көннәрдә булды бу хәл.
Чишмәләр, кырлар, урманнар
«Эһ!» итеп куйды бер мәл.

Киттек без,
Калды аланнар,
Сөйгәннәр калды елап.
«Сау кайтыгыз!» дип озатты
Тургайлар безне җырлап.

Аннан соң ничә кыш үткән,
Ничә яз кабатланган,
Сәламнар алып килгәндәй
Кайтмаган солдатлардан.

1974.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

## ИЮНЬ, 1974 ЕЛ

Машинага утырып автоҗыю цехы буйлап барганда, үзеннән-үзе күз спидометрга төшә: чыннан да бу корпусның озынлыгы 1240 метрмы икән? Корпусның түбәсе 135 футбол кыры мәйданы кадәр икәнен ишеткәч, КамАЗга килгән кунакларның күзләре шар була. Бу КамАЗның төп конвейеры!

...Әлегә бу конвейер төзеләчәк урын — гаять зур котлован. Без котлован янында торабыз. Аста, еракта дүрт бульдозер, алты кран, экскаватор кыймылдый.

Бүген «төп конвейер»да көн бик кызу. «Иң катлаулысы алда әле», — ди А. М. Шитиков, җитди һәм кырыс итеп. Александр Михайлович — балта осталары-бетончыларның комсомол-яшьләр бригадасы башлыгы.

Бригаданың яртысы булачак заводта эшләячәк. Төзелеш барышында завод эшендә кирәк булачак һөнәрләрне үзләштергәннәр. Яз көне бирелгән барлык комсомолецлар үзләренең бар көчләрен бер үзәккә тупларга карар кылалар һәм шундый чакыру игълан итәләр: «Вакытыннан элек төзеп бетерергә — вакытыннан элек үзләштерергә!» Комсомол штабы берләштерелгән 10 комсомол-яшьләр бригадасы оештыра. Аңа күптән түгел ВЛКСМның XVII съезды исеме бирелде.

«Комсомольская правда», Мәскәү.

Чаллыда Мәскәү вузларының бер төркем галимнәре: академик Б. М. Пантекоров, профессорлар В. Л. Якуб, А. С. Ушаков, А. Ф. Писаревлар булып китте. Алар КамАЗ төзүчеләренә, автозаводның производство коллективларына хәзерге физика һәм космик тикшеренүләр, космик очыш вакытында яшәү шартларын тәэмин итү, хәзерге фәнни-техник революция чорында илебезнең чит илләр белән экономик һәм фәнни бәйләнеше буенча актуаль проблемалар турында лекцияләр укыдылар.

«Комсомолец Татарии», Казан.

Кама автомобиль гиганты төзелешендә уннарча миллэт вәкилләре эшли. Бу дус интернациональ семьяның бер вәкиле — эстонлы Владимир Эльблаус, комплекслы бригада башлыгы.

— Күп еллар элек, революциягә кадәр үк, минем бабайлар туган җирләрен калдырып Себергә күчеп киткәннәр,— дип сөйли ул.— Кеше аягы басмаган, әмма бай, көчеңне кызганмасаң туклыклы тормыш вәгъдә иткән бу җирләргә алар зур өмет баглап килгәннәр. Әмма чынбарлык хыялга туры килмәгән. Казна төрле юл белән мал җыю ягын тапкан байларга гына акча биргән, башкалар буш кул белән калган. Землячество таркалган.

Омск янындагы ат заводында эшлиләр алар. Әмма алар арасында чын-чынлап туганнарча мөнәсәбәтләр Совет власте елларында гына урнаша.

Владимир туганнарының язмышы төрлесеннән төрлечә. Апасы Омск өлкәсендә элемтә инженеры булып эшли, ә абыйсы Омск мәктәпләренең берсендә мате-

матика укыта, туганнан туган абыйсы Казагыстанда агроном, тагын бер абыйсы — диңгез корабльендә капитан.

КамАЗга Владимир Эльблаус Новосибирскидан килгән. Ул үзенең эше турында горурланып сөйли.

— Миңа Яңа шәһәрдә беренче нигезне монтажлау эшен ышанып тапшырдылар,— ди ул.— 1971 елның язы иде. Ә хәзер анда нинди кварталлар үсеп чыкты. Йортлары нинди матур! Ә тагын күпме төзеләчәк әле. Мин монтажлаган нигез өстенә 2/01 номерлы йорт корылды. Аны Мәскәү төзүчеләре салды. Ленинградлылар, башка шәһәр вәкилләре салган йортлар да күп...

Нигез кору эшендә В. Эльблаус бер ел эшли. Аннан ТЭЦ төзи, Яңа шәһәргә җылылык үткәрә. Ә хәзер үз бригадасы белән заводларга җылылык трассалары уздыра.

— Безнең бригаданы «Автозаводстрой»га беркеттеләр.— дип сүзен бетерде Владимир.— Бригадада алты милләт вәкилләре эшли. Дус яшибез. Ә КамАЗда башкача булуы да мөмкин түгел!

«Советская Эстония», Таллин.

Ярославльдә төзүчеләр һәм монтажчылар дизель аппаратурасы заводының беренче производство корпусын «отлично» билгесенә эксплуатациягә тапшырдылар. Завод эчендә алтмыш биш мең квадрат метр мәйданда тагын бер завод — автомат, инструменталь, стандартлаштырылмаган җиһазлар заводы салына. Бу — КамАЗ иярчененең «старт мәйданы» һәм ул 65 гектар территорияне биләячәк.

«Труд», Мәскәү.

КамАЗ турында бик күп мәкаләләр, китаплар язылган. Кама елгасы буендагы бу төзелешкә күп кенә капиталистик илләрнең эшлекле даирәләре һәм матбугаты аеруча игътибар юнәлтәләр. Чөнки Көнбатыш илләрендә дә зур заводлар һәм төзелешләр шактый. Әмма мондагы кебекләре юк. Безнең газеталарда булачак заводның проект куәтен гәүдәләндерүче саннар басылып чыккач, көнбатыш экспертлары ышанмадылар. Аларның бер өлеше әле хәзер дә моңа ышанмый. Күптән түгел бер төркем чит ил хәбәрчеләре Чаллыда булып, төзелеш белән таныштылар. Алар «колоссаль», «грандиоз» сүзләрен бик күп кулландылар, әмма бер үк вакытта төзелешне дә, проект-эзләнү эшләрен дә, җиһазларга заказ бирү белән бергә монтаж эшләрен алып баруны һ. б. ларны һич тә башларына сыйдыра алмадылар. «Нью-Йорк Таймс» газетасының шеф хәбәрчесе: «Кушма Штатларның иң куәтле фирмасы да мондый зур эшне башкарып чыга алмас иде»,— дип, чын күңелдән таныргa мәҗбүр булды.

«Комсомолец Таджикстана», Дүшәнбе.

Сайлаулар көнендә Кама буендагы бу шәһәр иртә уянды. Сәгать алты да тулмаган иде әле. Кояш, офыктан күтәрелеп, эшче тулай торaклары тәрәзәләренә мул итеп үзенең алтын нурларын сибү белән, урамнар бәйрәмчә киенгән кешеләр белән тулды. Төш вакыты җиткәнче үк инде меңнәрчә КамАЗ һәм автоград төзүчеләре үзләренең гражданлык бурычларын үтәделәр.

Монтажчыларның да, сварщикларның да, кран машинистларының да, шоферларның да — сайлау урнлары янына килгән һәр кешенең күңеле күтәренке. Кама автогиганты үзенең баһадир көчен көннән-көн арттыра. Гүзәл Чаллы шәһәре көннән-көн үсә. СССР Верховный Советына узган сайлаулардан соң аның халкы биш мәртәбәгә артты.

Чаллы кешеләре Яңа шәһәр дип йөртә торган зур торак микрорайонындагы 196 номерлы сайлау участогына өлкән прораб Шәүкәт Газизов белән аның хатыны, китапханә хезмәткәре Галия яшь ярымлык кызларын күтәреп килделәр. Эльмира зур үсәр, батырлык-кыюлык символы булган шәһәрдә туын белән горур-

ланыр. Сайлаулар көнендә Эльмираның әти-әнисе аның бәхетле киләчәге өчен тавыш бирделәр.

**«Труд», Мәскәү.**

Латвиядә туып-үскән Эрнст Стахович КамАЗда кранчы булып эшли.

Совет Армиясендә хезмәт иткәндә үк Стахович зур төзелештә эшләргә теләгән иде. Ул Армиядән Идел буендагы автомобиль заводына кайтты. Анда эшләр беткәч, Кама буена килде.

Шулай да Стахович үзенең туган җирен — Кулдиганы онытмый. Күптән түгел генә ул туганнарының хәлен белү өчен өенә кайтып килде, әтисенә үзе яшәгән, эшләгән урындагы яңалыклар турында сөйләде.

— Мин үземнең язмышымнан бик канәгать,— диде ул.— Кою заводын корабыз. КамАЗда халык бик яхшы.

КамАЗны бәхетле кешеләр иле, диләр. Бу бәхетле илдә Совет Латвиясе улы, бәхетле кеше — Эрнст Стахович яши.

**«Советская Латвия», Рига.**

КамАЗның беренче карлыгачы — ремонт-инструмент заводында ике мең ярым төрле агрегат: автомат линияләр, уникаль станоклар эшли. Җиһазларның күбесен кичәге төзүчеләр, бүген шул заводта эшләүче эшчеләр монтажлады. Быел алар шундый йөкләмә алдылар: тагын биш йөз станок монтажларга, ә аларны көйләү операцияләрен срогыннан бер ай элек тәмамларга!

Завод эшләп чыгара торган продукция күләме үскәннән-үсә бара. Проект куәтенә ирешкәннән соң, РИЗ һәр елны 30 миллион сумлык стандартлаштырылмаган барлык төр төгәл инструментлар, махсус станоклар, эретеп ябыштыру машиналары эшләп чыгарачак.

Ремонт-инструмент заводында 14 милләт вәкилләре эшли. Илле мең кешелек коллективта һәркемнең шәхси социалистик йөкләмәсе бар.

**ТАСС, Чаллы.**

20 июньдә «Энергетик» культура сараенда Борис Васильевның «А зори здесь тихие...» пьесасы белән Мәскәүнең Таганкадагы театры гастрольләре башланды. Премьерадан соң икенче көнне артистлар КамАЗның төзелеш мәйданнары белән таныштылар...

Театр Чаллыда тамашачыларга «Антимир» дигән поэтик күренешне һәм «Үлгәннәр һәм исәннәр» спектаклен тәкъдим итәчәк.

**«Комсомолец Татарии», Казан.**

1970 елның февраленнән бирле КамАЗда Коми АССРның атказанган халык хуҗалыгы хезмәткәре Леонид Станкевич эшли. Башта ул төзү базасында эшләде, хәзер — автоҗыю заводы төзелешендә бригадир.

КамАЗга ничек килеп чыккан ул?

Башта Макунь — Кослан тимер юлын салуда эшләгән, аннан Сыктывкар урман промышленносте комплексын төзегән. Шундагы хезмәтләре өчен аңа Коми АССР атказанган халык хуҗалыгы хезмәткәре исеме бирелә.

— Минем биографиядә гадәттән тыш берни дә юк,— ди ул.— Кайда гына эшләсәң дә — Коми АССРдамы, Татарстандамы — сиңа мактау һәм ихтирам. Син үзеңнең, балаларыңның, бөтен илнең киләчәге өчен тырышасың.

**«Красное Знамя», Сыктывкар.**

**Касыйм Фәсәхов**

# ТУГАН АВЫЛ, ТУГАН ҖИР...



Стена сәгате уникене сукты. Төн уртасы. Ә Нургаяз һаман да әле йокыга китә алмый. Өй эче тып-тын. Янәшәдә хатынының тигез сулавы ишетелә дә, ачу китереп, сәгать тыкылдый. «Әллә торып туктатырга инде»,— дип уйлап алды Нургаяз. Ләкин, хатынын уятырга теләмичә, бу уеннан кире кайтты.

Тышта җил көчәйде, буран дулый. Вакыты шул, февраль бураннары. Җил ыжылдавы аның йокысын бөтенләй ачты. Хет торып киен дә, йортка чыгып, хәлдән тайганчы кар көрә. Арыгач, шәт, йоклап та кителер иде.

...Нургаязның йоклый алмау сәбәбе кичә партком бүлмәсендә председатель Фәттәхов белән булган сөйләшү, дөресрәге, ярыйсы ук әйткәләшеп алу иде. Сәләхов кичәге бу күңелсез сөйләшүне яңадан исенә төшерде, председательнең һәм үзенең сүзләрен кабат-кабат анализлап карады. Ләкин барыбер Фәттәховның үзенә халык ышанып тапшырган җаваплы эшкә шулай искитмичә каравын, председатель була торып, үзе җитәкчелек иткән колхозда эшләрнең алга бармавына һич тә пошынмый йөрүен аңлый да, аклый да алмады.

Партком секретаре буларак, Сәләхов күптән инде председатель белән ачыктан-ачык сөйләшергә җыенып йөри иде. Ләкин ничектер җае чыкмады, әллә инде сүз башларга уңайсызландымы, һаман иртәгә, берсекөнгә, киләсе атнага дип, кичектерә килде. Ниһаять, кичә сөйләшергә булды, чөнки тагын кичектерер мөмкинлек калмаган иде. Озакламый колхозчыларның отчет-сайлау җыелышы, хуҗалыкның яңа җитәкчеләрен билгеләү. Фәттәхов белән коммунистларча, җитди итеп сөйләшергә тиеш иде партком секретаре. Җыелышка кадәр председательнең киләчәккә уй-фикерләрен, тотачак позициясен ачыкларга кирәк иде. Чынлап торып эшкә тотынырга уйлыймы ул, әллә һаман да Әлмәттә яшәп, Әмзәдә кунак булып кына йөрергә исәплиме? Председательнең берничәшәр көн колхозда күренмәве, булганда да тизрәк Әлмәткә семьясы янына кайтып китәргә ашыгуы һич тә килешле хәл түгел иде. Төрле вакыт, төрле эш була, төн уртасында торып та ашыгыч мәсьәләләрне хәл итәргә туры килә. Ә ул, председатель, кызу

урак өстендә дә йокысын туйдырып, инде кояш байтак күтәрелгәч кенә идарәгә килә.

Мондый «җитәкчелек»нең нәтиҗәләре күз алдында. Элегрәк Октябрь районында алдынгылардан саналган «Комбайн» колхозы үз позицияләрен югалта бара, аның исеме сводкаларда һаман да арттагырак урынга күчә. Игенчелек буенча да, терлекчелек буенча да башка хуҗалыклар яңадан-яңа үрләргә менәләр, ә «Комбайн» колхозы бер урында таптана. Башкалар алга барганда бер урында таптану артта калу дигән сүз ул. Соң уйлап кара: узган елда колхоз бөртекләрнең гектарыннан нибары — 8,3 центнер, шикәр чөгендереннән 72 центнер уңыш үстерде. Бер сыердан нибары 1360 килограмм сөт савылды. Бу — колхозның мөмкинлекләреннән бик күп түбән. Уңышны да, терлекләрнең продуктлылыгын да бермә-бер арттырырга мөмкин бит. Бары тик хезмәтне фәнни нигездә оештыра белергә дә, һәркемнең үзенә тапшырылган эш өчен янып йөрүенә ирешергә генә кирәк...

Кичә председатель белән шул хакта сөйләште Сәләхов. Кызмыйча, сабыр гына аңлатырга тырышты. Әйткәннәрнең үз уйлары гына түгел, партком һәм барлык коммунистлар фикере булуына басым ясады. Сүз уңаенда: «Миннәхмәт, семьяңны да Әмзәгә күчерергә, кунак булып түгел, хуҗа булып эшләргә һәм эшләргә кирәк»,— диде. Фәттәхов аңлар, чын күңелдән сөйләшербез дип уйлаган иде, ләкин барып чыкмады. Председатель аның сүзләрен теләмичә, үпкә белән тыңлады, ә аннары бөтенләй кабынып китте, иптәшләрчә сөйләшүне рәсми тонга күчерде.

— Менә нәрсә, иптәш Сәләхов, партком секретаре булдым дигәч тә, үзегезне һәркемнән өстен куеп, акыл өйрәтүче булып сөйләшмәгез әле. Секретарь булуыгызга ничә генә ай үткәнен дә онытмагыз. Әлегә үзегезнең дә телгә алып сөйләрлек эш күрсәтә алганыгыз юк. Сездә булган акыл бездә дә бар... Аннан соң, үз семьямны Әлмәттәме, әллә Әмзәдәме яшәтүне сездән башка да хәл итәрмен, безнең шәхси тормышыбызга кысылмасагыз иде. Инде янә дә килеп, үзегезне генә эш өчен янучы, теләсә нәрсәне дә булдыра алучы дип уйлыйсыз икән, рәхим итегез: озакламый җыелыш, тотыгыз да дилбегәне үз кулыгызга алыгыз. Күрербез, ничек председательлек итәрсез икән... Менә шул. Ә хәзергә хушыгыз, ашыгам. Әнә буран күтәрелергә тора, шактый ара үтәсе бар. Семьям янына кайтырга, шәт, хакым бардыр...

Һәм Фәттәхов ишекне шапылдатып япты да идарә каршындагы «газик»ка ашыкты...

«Әйе, сөйләшү барып чыкмады,— дип куйды Нургаяз үз-үзенә. — Аңламады ни әйтергә теләгәнне. Күңеле монда түгел шул аның. Туган авылы булмагач, барыбер моннан китәчәкмен, дип фикер йөртә. Туган-үскән җире булса, бүтәнчәрәк уйлар иде».

Инде йокыга киткәндә Нургаязның колак төбендә Фәттәховның: «Тотыгыз да дилбегәне үз кулыгызга алыгыз. Күрербез, ничек председательлек итәрсез икән»,— дигән сүзләре яңгырагандай булды.

«Ә нәрсә, колхозчылар ышаныч күрсәтсәләр, мин каршы килмәс идем... Һәм болай эшләмәс тә идем»,— дип елмайды Сәләхов инде йокы аралаш.

*

* *

Колхозчыларның отчет-сайлау җыелышы Сәләхов өчен һич көтмәгәнчәрәк килеп чыкты.

Әле отчет докладын партком белән идарәнең берләштерелгән утырышында тикшергәндә үк, Фәттәхов:

— Иптәшләр, мине идарәнең яңа составына кертмәгез, киләчәктә «Комбайн»да председатель булып кала алмыйм,— дип белдерде.

Партком һәм идарә членнарының:

— Иптәш Фәттәхов, бу ни дигән сүз инде? Сәбәбен аңлатсагыз икән,— диюләренә каршы ул:

— Семья хәлләрем шуны таләп итә,— дип кенә җавап бирде.

Күрәсең, Фәттәхов бу турыда партиянең район комитеты җитәкчеләре белән дә сөйләшкәндер. Булачак председатель кандидатурасын да тәкъдим иткән булса кирәк. Беркөн киңәшмәдән соң райкомның икенче секретаре Сәләховны үзенә чакырды да:

— Иптәш Сәләхов, председателегез сездән китәргә җыена. Аның урынына сезне тәкъдим итәргә дигән фикер бар,— дип әйтте дә салды.

Сәләхов башта:

— Әле минем партком секретаре булуыма да берничә ай гына бит. Эшнең җаена да кирәгенчә төшенеп өлгермәдем,— дип сүз кузгатмакчы булган иде дә, секретарь ике сөйләшмәслек иттереп:

— Бу хакта бюрода да сүз булды. Бюро членнары бик хуп күрәләр сезнең кандидатурагызны,— диде.

— Колхозчылар ни әйтер бит әле? — диде Сәләхов.

— «Комбайн»да булганым бар, кешеләр белән дә сөйләшкәләдем. Колхозчылар каршы килмәсләр дип уйлыйм,— диде секретарь, бу хакта сүз беткәнлеген белдереп. Сәләховка:

— Партия кая кушса, шунда эшләрбез анысы. Тик менә...—диюдән башка чара калмады.

...Менә җыелыш та үтте. Нургаяз Сәләхов партком секретаре түгел, колхоз председателе инде. Партия эшләрен Гәрәй Мусинга тапшырды. Төпле егет күренә, йөкне бергәләп тартырга булдылар аның белән. Хәер, таянырдай кешеләр аз түгел колхозда. Яңа Әмзә авылындагы иң зур бригаданы җитәкләүче Зөлкарнәй Галиевны гына ал. Кешеләр белән эшләүдә дә, хуҗалык эшләрен оештыруда да бай тәҗрибәсе бар аның. Бригада колхозда һәр вакыт алдынгы, күрсәткечләре башкаларныкыннан гел югары. Теләсә нинди эштә таянып була аңа. Ә механизаторларыбыз Гомәр Хуҗин, Ильяс Корбанов, Әдһәм Насыйбуллин, терлекчеләребез Фәнүзә Мәсгутова, Вәсимә Галиева, Фәния Кәлимуллина! Эш өчен янып йөрүче шундый намуслы кешеләр азмыни бездә! Әгәр күңелләренә юл таба алсаң, алар белән тауларны күчерергә була.

Тик менә кешеләр күңеленә туры юл табу, коллективның ышанычын казану җиңелдән түгел. Нәрсәдән башларга эшне? Кайсына тотынсаң да аварга торган читән кебек. Кызу эш өстендә эшче куллар җитми. Ә күпме егетләребез «шабашниклык»та йөри. Җиң сызганып эшләрдәй күпме яшь-яшь хатыннар өйдә утыра, чөнки балаларны калдырырга урын юк. Ясле ачып җибәрсәң, рәхәтләнеп эшләрләр иде, югыйсә... Терлек абзарлары тишек-җимерек, колхозлашу елларында төзелгән килеш. Кичекмәстән яңа абзарлар салырга кирәк. Ләкин ничек? Колхозда балта осталары юк түгел, төзүчеләр бригадасы оештырып булыр иде. Агачтан салсаң, урман да кул төбендә генә. Тик менә терлекчелек биналарын агачтан салдырмыйсы иде. Усак бүрәнәләр күпмегә чыдый соң ул. Таштан, кирпечтән күтәртсәң икән. Ләкин материалын каян аласың? Якын-тирәдә табигый таш ятмалары юк. Кирпеч сатып алыр идең, акчасы кая? Үзебездә кирпеч заводы төзеп җибәрсәң менә дигән булыр иде дә бит. Кирпеч өчен яраклы балчык та җитәрлек, авыл янында ук. Эшне башлап җибәрү өчен ак-

ча каян алырга? Колхозның экономикасы турында сөйләп торасы да юк, бер миллион ярым сум бурычы гына бар...

Шундый һәм шуңа охшашлы бүтән сораулар көндезен дә, төнен дә тынычлык бирмәде яшь председательгә. Хәтта: «Булдыра алмам, авылдашларым алдында көлкегә генә калырмын. Юккарак ризалаштым, ахры, шундый җаваплы эшкә. Фәттахов та шулай нәрсә эшләргә дә белми аптырый торган булгандыр. Бәлки аңа юккарак каты-каты орынганмындыр»,— дигән чаклары да булды Нургаязның. Ләкин, тәртәгә бер җигелгәч, чыгымчылаудан файда юк инде, барыбер камчылаячаклар. Булдыра алган хәтле, камчылатмыйча гына тартырга кирәк. Бәлки бер җаена төшкәч, ул хәтле авыр да түгелдер әле йөк?!

*
* *

Ныклап, кат-кат уйлагач һәм җентекләп исәпләгәч-чутлагач, намуслы хезмәт ветераннары — колхозның аксакаллары белән киңәшләшкәч, Сәләхов, беренче чиратта, башкарылырга тиешле эшләрнең планын төзеде. Партком секретаре Гәрәй Мусин да бу перспектив планны яклавын әйтте. Шуннан соң Сәләхов бу мәсьәләне идарә утырышына куйды.

Һич тә көтмәгәндә, идарә утырышы бик шау-шулы булды. Нургаяз идарә членнары перспектив планны бердәм яклarlar дип өметләнгәндә, аңа ачыктан-ачык һәм катгый каршы төшүчеләр табылды. Бәхәс колхозчыларның хезмәт көннәренә гарантияле акчалата түләүгә күчү мәсьәләсен тикшергәндә кабынып китте һәм, колхозда башланырга тиешле төзелешләр турында сүз кузгалгач, Сәләхов өчен кимсетүле әрләшүгә әйләнде. Гаҗәп хәл, председательнең тәкъдимнәренә аның планнарын күтәреп алырга тиешле бухгалтерлар һәм экономистлар каршы чыктылар. Беренче булып, бухгалтер Габдулла Минапов күтәрелде:

— Яңа начальник зурдан куба инде ул,— дип башлады сүзен бухгалтер.— Шундый зур планнар белән эшкә керешү мактауга лаек, әлбәттә. Ләкин реаль планны хыял белән бутарга ярамый. Дөрес, колхозчыларга акчалата гарантияле түли башласаң, халык күңеленә бик хуш килер иде. Хәтта Нургаязга рәхмәт тә әйтерләр. Хезмәт дисциплинасы да ныгыр, председательнең дәрәҗәсе дә күтәрелер дип көтәргә мөмкин. Ләкин акча дигәнен каян алабыз соң, Нургаяз дус? Бер миллион да биш йөз мең сум бурычыбыз барын онытмагансыздыр бит? Бәлки күршеләрдән бурычка алып торырбыз?

— Кирәк булса бурычка да керербез,— диде Сәләхов, кырыс тонга күчеп.— Колхозчыларны материаль кызыксындырмый торып, хезмәт дисциплинасын ныгыту да, эшләп чыгарышны күтәрү дә мөмкин түгел. Ел ахырына кадәр бәясе билгесез булган хезмәт көненә эшләү туйдырган инде колхозчыларны. Аларның да бит эшләгәннәренә тиешлесен аласылары килә. «Шабашник»ларны гаеплибез дә, уйлабрак карасаң, аларны да аңларга була. Кемнең гел-гел вәгъдәгә эшлисе килә... Менә шуңа күрә мин яңадан кабатлыйм: хезмәткә акчалата гарантияле түләүгә күчәргә кирәк. Әгәр колхоз эшенә карашны уңай якка үзгәртергә ирешә алсак, бурычларыбызны да түләрбез, кассабызга саф табыш та туплый алырбыз...

— Һәй, әфсен укып, бурычлар урынына кассабызда миллион ярым акча ятсын, дип кенә эш барып чыкса иде,— дип кинаяле көлде бухгалтер. — Ничек итеп тиз генә бурычтан котылмакчы булабыз

соң, Нургаяз иптәш Сәләхов? Әллә, борынгыдагыча, банкротлык игълан итеп, сумга биш-ун тиен түләү юлы беләнме?

— Бу цирк түгел, Габдулла, клоунланып торуның кирәге юк,— дип кистерде председатель. — Бурычтан котылуның да, керемне арттыруның да юлы бер генә: терлекчелектән продукт алуны арттыру, игенчелекнең һәм шикәр чөгендеренең уңышын күтәрү, ел саен тотрыклы уңыш үстерүгә ирешү. Бу — бер. Икенчедән, колхозчыларның тормыш-көнкүреш һәм ихтыяҗларын канәгатьләндерү турында да уйларга вакыт җитте. Зуррак семьялы кешенең өе кадәр клуб кисәге җитми инде хәзер яшьләргә. Күңел ачар, җыелып культуралы ял итәр урын юк. Шуңа күрә күпме егетләребез һәм кызларыбыз читкә китү ягын карыйлар. Эш өсте җитсә, идарәнең яртысын ясле итәбез. Бу көлке бит. Димәк, беренче чиратта, культура йорты, балалар яслесе һәм мәктәп салырга тиешбез...

— Сыерлар җимерек абзарларда, дуңгызлар салкын аранда, ә без культура йорты салабыз? Менә хәлләр,— дип көлде экономист Кирам Җамалетдинов. — Яңа себерке чиста себерә дигәч тә, бераз чамалап селтәнергә кирәк. Бик каты бәргәләсәң, я себеркең сынар, я чүп-чарларны себерәм дип, такыр җирне дә чокырлатып бетерерсең, йөрерлек тә калмас.

— Мин сезгә себерке дә, дворник та түгел, колхозчылар сайлап куйган башлык,— диде Сәләхов кырысрак тавыш белән. — Һәрхәлдә, дуңгызлар турында кайгыртканчы, кешеләрдән башлау дөресрәк булыр. Бу терлекләр турында оныту дигән сүз түгел әле. Менә кичекмәстән кирәк булган объектларны тәзик тә, терлек абзарларына тотынырбыз. Күп елларга чыдарлык итеп кирпечтән салырбыз, типовой проектлар буенча.

— Ә кирпечен каян алабыз? — дип куйды Җамалетдинов.

— Үзебез эшләячәкбез. Башта кирпеч заводы салачакбыз,— диде председатель.

— Ай-да,— дип телен чартлатты экономист. — Үпкәләмә, Нургаяз, чыннан да хыялый икәнсең. Суга алмаган зур күтәрә, ди. Реаль мөмкинлекләрне, экономик хәлне исәпләргә кирәк башта. Эш башлаганда кешеләрне шулай шаккатырасы килә инде ул, тик юрганыңа күрә аягыңны сузарга кирәк бит. Хәтереңдә булса, мин дә председатель булып торган идем биредә. Уй-планнар зур иде дә, булдырып кына булмады.

— Менә шул булдыра алмаганга алып ташладылар да инде,— диде Сәләхов, ярсуын баса алмыйча. — Үзең булдыра алмагансың икән, бүтәннәргә комачаулама.

— Сез, иптәш Сәләхов, артык кәпәренмәгез әле, — дип сикереп торды Җамалетдинов. — Сез председатель икән, без дә идарә члены, коммунист. Малай-шалайга җикеренгән кебек кычкырмагыз миңа...

Идарәдә тавыш купты, кемнең нәрсә сөйләгәнен дә аңларлык калмады. Тынычланып, мәсьәләне объектив хәл итү мөмкин түгел иде. Сәләхов үзе дә аңлады моны һәм, яңадан кайтырбыз әле бу мәсьәләгә дип, утырышны ябарга мәҗбүр булды...

Урамда җил басылган, салкын көчәя төшкән. Саф һава Нургаязны бераз тынычландырып җибәрде. Ул идарәдә булган сөйләшүгә анализ ясый башлады, кемнең хаклы, кемнең хаксыз булуын ачыкларга тырышты. «Үземдә дә гаеп бар, — дип куйды ул, бүгенге бәхәстә тынычлыгын җуюга ризасызланып. — Идарә утырышын яхшылап хәзерләмәдем, идарә членнарының фикерләрен алдан ачыклый алмадым. Утырышны партком секретаре кайткач үткәрергә кирәк иде. Көтмәдем, ашыктым. Тәҗрибәсезлек. Киләчәктә сабак булыр».

*
* *

Колхоз производствосын күтәрүнең перспектив планы мәсьәләсе берничә атнадан соң партком һәм идарәнең берләштерелгән утырышына куелды. Камалетдинов, Минапов, Гарифуллин яңадан да акчалата түләүгә күчүгә каршы чыктылар, культура йортын, мәктәп салуны кичектерү кирәклеген куәтләделәр, ә кирпеч заводы салу хакында сүз чыккач, моның мәгънәсез эш булуын исбатларга тырыштылар.

— Нәрсәгә безгә кирпеч заводы? Кирпеч сугып кем баеган? Читтән сатып алып, подряд оешмалардан салдырсаң, байтак экономиялерәк булачак, — дип ышандырырга тырышты экономист, — «фәлән нәрсә фәлән кадәр булачак, төгән нәрсә фәләнгә төшәчәк» дип, саннар китерә-китерә.

Ләкин партком членнары да, идарә әгъзаларының күпчелеге дә председатель һәм партком секретаре тәкъдимнәрен хупладылар.

— Зур эшләр майтару бу. Баштарак читен дә булыр, аның каравы, перспективалы. Хәзер искечә, атлаган саен икеләнеп тә тукталып эш итә торган заман түгел. Партоешманың һәм идарәнең мондый перспектив план нигезендә эшләүгә күчүен хупларга кирәк, — диде Яңа Әмзәдәге бригада җитәкчесе Зөлкарнәй Галиев. — Безнең колхозчылар бертавыштан яклаячаклар моны. Кирпеч заводы кирәк. Үз базаң булмый торып, читтән кирпеч сатып алып кына әллә ни төзелешләр алып бара алмассың. Кыскасы, бу планны хупларга һәм җиң сызганып аны үтәү эшенә керешергә кирәк...

Ләкин план кабул итү, ул никадәр нигезле һәм реаль булса да, эшнең башы гына әле. Аны тормышка ашыра башлагач, һич көтмәгән каршылыклар килеп чыкты. Хезмәткә акчалата түләүгә күчүне колхозчылар шатланып каршыларлар дип уйланылган иде. Әмма гаҗәп хәл, көздән өсәкләрен ашлык белән тутырырга өйрәнгән авыл кешеләре бу яңалыкка шикләнеп карады. «Икмәгең булмагач, акча белән нишләрсең»,— диделәр. Колхозчыларга икмәкнең арзан бәя белән сатылачагы, тиешле акчаның билгеле бер өлешенә ашлык алырга мөмкинлек булачагы, акчалата түләүгә күчүнең нәкъ менә колхозчыларның үзләре өчен файдалы булуы турында бик күп аңлату эше алып барырга туры килде. Бу мәсьәлә уңай хәл ителгәч, акчалата түләгәндә эш нормаларын билгеләү проблемасы килеп басты. Бердәм кулланма юк, күрше хуҗалыклар да бу юнәлештә беренче адымнарын гына ясыйлар иде әле. Хезмәт көннәренә түләү нормативларын нигез итеп алып, яңа тарифлар эшләргә туры килде. Бу исә очсыз-кырыйсыз бәхәсләр куптарды. Экономист белән баш бухгалтерның астыртын каршылык күрсәтүләре бу эшне тагын да катлауландыра төште...

Икенче кыенлык төзелеш эшләренә керешкәч килеп чыкты. Читтә «акча сугып» йөрүче балта осталары колхозның төзү бригадасында эшләргә теләмәделәр. «Сезнең тиеннәрегезгә карап торганчы, бүтән җирдә меңләп эшлибез»,— диделәр. Аларга карата колхоз Уставы нигезендә катгый чаралар күреләчәге белән куркыткач, кайберләре теләр-теләмәс кенә «шабашник»лыкларын ташларга булдылар. Ләкин башта барыбер уйлаганча бригаданы оештырып булмады. Ирексездән, читтән «шабашник»лар ялларга туры килде. Бер үк вакытта төзү бригадасында эшләүчеләрне материаль кызыксындыру чаралары билгеләнде, идарә карары белән бу эш өчен өстәмә чыгымнар тотылды. Шул ук чакта колхоз эшенә чыкмыйча, үз хуҗалыгы, үз интереслары турында гына кайгырткан кешеләргә карата кискен чаралар күрелде.

Билгеле, күрелгән чаралар уңай нәтиҗә дә бирде. Ләкин председательнең яңа тәртипләре кайберәүләргә ошамады. Имеш-мимешләр һәм тузга язмаган гайбәтләр тарала башлады. Сәләхов башта моңа игътибар итмәгән иде дә, соңыннан ул шактый авырттыра торган шешкә әйләнде. «Яңа себерке»дән риза булмаган Минаповлар һәм Җамалетдиновлар имеш-мимешләрне үз файдаларына бордылар. Район оешмаларына Сәләховның идарә членнары белән исәпләшмәве, колхозчылар белән тупас булуы, авылда үзен хокуклары чикләнмәгән «губернатор кебек тотуы», колхоз акчасын кирәкмәгән эшләргә туздыруы турында имзасыз хатлар агыла башлады. Аларны тикшерергә редакциядән, райкомнан, район Советы башкарма комитетыннан кешеләр килде. Һәр сәгате алтындай кыйммәт булган кызу эш өстендә шул «хатлар»ны тикшерүгә күпме вакыт әрәм ителде, күпме кәеф кырылды.

Беркөн райком секретаре Нургаязны үзенә чакырды һәм, шундый хатларның берничәсен аңа күрсәтеп:

— Хатлар имзасыз, аноним булса да, утсыз төтен булмый дигәндәй, тиешле нәтиҗәсен ясамыйча булмас, иптәш Сәләхов,— диде.

Бу Нургаязның күңелен бик тә рәнҗетте. Эш дип янасың, ял-йокы белмисең, ә кемнәрдер тонык суны болгата. Бу бит йөгереп барган атның башына сугу.

Кызганычка каршы, андый «башка сугулар» һаман кабатлана тордылар. Иң күңелсезе — «башка сугучылар»ның председательгә һәр эштә таяныч булырга тиешле кешеләр булуы иде. Бу инде арттан килеп хәнҗәр кадау белән бер нәрсә. Бер мөһим эшкә тотыныр алдыннан киңәшергә теләп сүз башлыйсың, үз планнарыңны күтәреп алуны көтәсең, ә чынбарлыкта нәкъ киресе килә дә чыга. Менә агроном Яхъя Гарифуллин белән дә шулай килеп чыкты. Сәләхов аның белән игеннәрнең уңышын күтәрү, ел саен тотрыклы югары уңыш алуга ирешү юллары турында киңәшләшергә теләп сүз башлаган иде.

— Кара әле, Яхъя,— диде Нургаяз, мөмкин кадәр дусларча итеп. — Син үзең дә бу хакта уйлыйсыңдыр инде. Әйдә сөйләшик әле... Еллар яхшы килсә, яңгырлар вакытында яуса, уңыш та мул булыр дип, табигать биргәнгә генә риза булып яшәү заманнары түгел хәзер. Бер елны гектардан утыз-кырык пот уңыш алып, икенче елны алтмышка җитсә, «уңыш шәп булды быел» дип сөенеп ятып булмый. Һәр елны тотрыклы югары уңыш — колхоз буенча кимендә гектардан унбиш, ә аннары егерме центнер уңыш алуны максат итеп куясы иде.

— Шуның белән нәрсә әйтмәкче буласың инде? — диде сагаеп агроном. — Бәлки, вазифаларыңны үти алмыйсың дип, эштән куар җирлек эзерлисеңдер?

— Яхъя, юк белән баш катырмыйк әле, ирләр була белик. Җирлек эзерлисе юк, болай да әллә ни кинәндермисең. Колхоз синең ише белгечтән теләсә кайчан баш тарта алыр иде. Сүз ул хакта түгел. Заман шуны таләп итә. Табигать шартларына карамый, югары уңыш үстерүгә ирешү кирәк.

— Бик үстерер идек тә бит, ә ничек?

— Соң, факыр, агроном кеше бит син. Уйларга кирәк, эзләнергә. Бәлки бөртеклеләрнең сортын үзгәртергәдер? Бәлки уҗым арышы чәчүлекләрен киметеп, көзге бодай чәчәргәдер? Арыш, бик уңганда да, безнең шартларда унбиш центнердан артык уңыш бирми бит.

— Аның каравы, еллар коры килгәндә дә чагыштырмача әйбәт уңа.

— Кая инде әйбәт, алты-җиде центнер — уңышмыни ул?

— Сабан культуралары алай да бирми...

— Соң, начарга карап тигезләнмик инде. Алай да бирми икән,

уңдырышлы культураларны күбрәк чәчик. Без бала чакта Әмзәдә көзге бодай чәчәләр иде, әйбәт уңыш бирә иде. Тәҗрибә өчен ике-өч йөз гектар чәчеп карарга кирәктер бәлки.

— Үзең заманча дисең, үзең бала чактагы тәртипләргә кайтырга димлисең. Юк, Нургаяз, рәт чыкмаячак, уңмаячак көзге бодай безнең җирләрдә.

— Алай кырт кисмик әле, Яхъя, тәҗрибә өчен генә булса да, берничә йөз гектар чәчеп карыйк,— диде Сәләхов, сабырлыгын җуймаска тырышып.

— Юк, иптәш Сәләхов,— диде Яхъя, ниндидер бер үҗәтлек белән,— мин моңа кискен рәвештә каршы. Җир өчен, уңыш өчен агроном җавап бирә. Булмасын белә торып, урынсыз тәҗрибәләргә риза буласым юк...

Сәләхов шыкырдатып тешләрен кысты, ярсуыннан йөзенә кызыл-кызыл тимгелләр чыкты. Үзен кулга алу өчен, тәрәзәгә таба борылды, күңеленнән иллегә хәтле санап чыкты. Чынлап та, санау тынычландыра икән. Ниһаять, ул агрономга таба борылды һәм бәхәсләшеп торырга урын калдырмаслык итеп:

— Җир һәм уңыш өчен агроном гына түгел, һәммәбез җавап бирә. Мин дә колхозга зарар булсын дип тырышмыйм. Менә шулай, Яхъя иптәш, быел өч йөз гектар көзге бодай чәчәбез. Кайсы басуга чәчү турында уйлагыз һәм тәкъдим итегез,— диде.

— Карагыз инде, алайса, иптәш Сәләхов. Ләкин мин әйтеп куям, алай-болай була икән, җаваплылыкны үземә алмаячакмын, белеп торыгыз...

Нургаяз аның сүзләренә бер җавап та кайтармады, яңадан кабынып киткәнче дип, тизрәк китәргә ашыкты. Ишеген бикләп торганда, бухгалтерия бүлмәсендә көлешкән тавышлар ишетте һәм тукталып калды.

— Минапов тавышы түгелме соң анда? Авырый дигәннәр иде бит.

Бухгалтерия ишеге бикле булып чыкты. Нургаяз ишекне дөбердәтте:

— Кем бар анда? Ачыгыз әле.

Нәрсәдер шакы-шокы килде, стакан чылтерәгәндәй булды. Ләкин ишек ачылмады. Сәләхов тагын да катырак шакырга тотынды. Эчтән:«Хәзер, бер генә минутка», дигән тавыш ишетелде.

Ниһаять, ишек ачылды. Минапов өстәл тартмасына нәрсәдер яшерә иде бугай, ашык-пошык япты да Нургаязга таба атлады. Экономист та монда икән. Нәрсәдәндер каушап калган кебек күренә.

— Нургаяз... син икәнсең, кем шулай дөбердәтә дип торабыз,— диде бухгалтер, председательгә кулларын сузып. — Менә, яңа чалбарны киеп караган идем, әле яңа гына кибеттән алдым... Шуңа бикләгән идек, хатын-кыз килеп кермәсен дип.

— Һәм шул чалбарны юып, эш өстендә идарәдә аракы эчеп утырасыз,— диде Нургаяз, бүлмәдә аңкыган суган һәм аракы исеннән барысын да аңлап. Ул туры бухгалтер өстәле янына барды, тумбочканы ачып җибәрде. Анда яртылаш бушаган аракы шешәсе һәм суган белән ипи кисәкләре таралып ята иде.

— Оятсызлар,— диде Нургаяз ярсып. — Синең авыруың шулмыни? Өч көн эшкә чыкмадың, сәрхушланып ятkансың икән. Ул гына җитмәгән, инде көпә-көндез эчеп ятасыз. Бу көннәреңне прогул ясап, хезмәт хакыннан тотып калырсың. Кызу эш өстендә «бәйрәм итеп» йөрүең өчен партком утырышында җавап бирерсең.

Нургаяз аракы шешәсен алды да, тәрәзәне ачып, идарә йортындагы бүрәнә өстенә тондырды. Бухгалтер председательнең кулларына килеп ябышты, тотлыга-тотлыга сүгенергә тотынды:

— Син нәрсә... башлык булдым дигәч тә... Кеше әйберен әрәм итәргә ни хакың бар? Бәлки мин аны авыруымны дәвалар өчен дару урынына алганмын... Подожди, кулыңны кыскартырлар әле... түләтермен...

— Кырмавык кебек ябышма,— диде Нургаяз, җиңнәреннән тартучы бухгалтерны селтәп җибәреп. — Эчкәнсең икән, өеңдә генә ят.

— Әле син сугышмакчы... Кирам, шаһит бул, мине бәреп җибәрде. Мин сиңа теге чакта машинаң белән таптаткан Иван бозавы түгел. Төрмәдә черетермен...

Сәләхов, бухгалтер сүзләренә колак салмыйча, тизрәк ишеккә ашыкты. Ярсуы чигенә җиткән, йөрәге күкрәгеннән чыгардай булып тибә иде. «Я тагын берәр җүләрлек эшләрсең бу бәндәләр белән,— дип уйлап алды ул. — Тизрәк... бер... ике... өч... ун... унсигез...»

*
* *

Сәләхов, «Таер» күперен чыккач, тигезрәк болынга борылды да машинасын туктатты. Челтерәп кенә аккан көмештәй саф сулы инешкә төшеп, битен-кулларын юды. Аннары, тау битенәрәк күтәрелеп, хуш исле меӊ төрле чәчәкләр белән чуарланган үләннәр арасына ауды һәм малай чактагы кебек аунарга тотынды. Читтән берәр кеше карап торса, безнең председатель акылга җиңеләйгән, ахры, дип уйлар иде.

Нургаяз торып утырды, кып-кызыл булып пешкән бармак башы кебек җир җиләкләрен өзеп капты. Их, ичмаса, рәхәте шул авыл болыннарының! Безнең Яңа Әмзә табигатеннән дә матур җир беркайда да юктыр. Курорт та ял йорты дип, мең мәшәкатьләр чигеп, әллә кайларга барып йөрисе дә юк. Җиләкле тау битенә шалаш кор да рәхәтләнеп ял ит. Челтерәп кенә аккан шифалы суы бар. Хәтта чоңгыллар-да вак-төяк кенә булса да комкорсак һәм урман балыгы бар. Кармак чирттереп утыруы үзе ни тора! Балык шулпасы пешереп, мәтрүшкәләп-җиләкләп чәй кайнатсаң, тәннәреңә сихәт була. Кич җиттеме, әрәмәдә кошлар музыкасы башлана, тыңлап туя алмассың. Хәтта чәчәктән-чәчәккә кунып безелдәшкән кортлар, үлән арасында мәш килүче чикерткәләр тавышы да үзенә хас моң булып яңгырый, күңелләрне дәртләндереп җибәрә. Сихри бер музыка икән ләбаса бу табигать, бары тик менә шулай сокланып утырырга вакыты гына тими. Ә бәлки вакытын да табарга буладыр, табигать кочагында яшәгәнгә, аның гүзәллеген үзебез тоеп-күреп җиткермибездер.

Әнә «Таер» белән «Челтәрле» инешчекләре килеп кушылган җирдә калкулык бар. «Серле курган», «Хәзинәләр тавы» дип йөртәләр аны. Ул таучык турында әллә нинди шомлы-серле легендалар сөйлиләр иде кечкенә чакларда. Бала-чага өчен сихри бер әкият иде ул. Ә хәзер, нигәдер, бер дә искитмәслек калкулык кына булып күренә... Әнә тегендәрәк «Икара» басуы. Нигә алай дип атаганнардыр? Әллә «Челтәрле» белән «Таер» елгалары арасында булгангамы? Гомер-гомердән уңышка кинәндергәне юк ул басуның. Игеннәр саламга шаулап үсәләр дә, бөртекләре вак, ач була. «Таер» урманы күләгәләп торганга шулаймы, әллә җире шундый уңдырышсызмы?..

— Кара әле, җәйләү өчен иң җайлы урын бит бу,— дип куйды Сәләхов, бу фикернең әлегә кадәр башына килмәвенә гаҗәпләнеп.— Әнә теге атауга җәйге лапаслар ясыйбыз да сыерлар өчен туплау урыны итәбез. Тау башына терлекчеләр йорты салып куябыз. «Икара»да культуралы көтүлек булдырабыз. Ашлап җибәрсәң, су сиптереп торсаң, үлән шаулап үсәчәк анда. «Таер» белән «Челтәрле» кушылган җирдән бераз түбәндәрәк буа ясасак, су мәсьәләләре дә хәл

ителә. Менә дигән сусаклагыч барлыкка киләчәк: көтүлегеңне дә сугар, терлекләреңне дә эчер. Менә дигән булачак бит бу!

Сәләхов, яңа идея туудан дәртләнеп, машинасына ашыкты. Аның яңа туган планын партком секретаре Мусин һәм бригадир Галиев белән тизрәк уртаклашасы килә иде.

Машина басу юлы буйлап оча гына. Артыннан, һавага өерелеп, тузан болыты кала. Юлның ике ягында арыш һәм бодай басулары. Уңыш шәп булырга тиеш быел, иген арасыннан машина да күренми.

Әнә авыл да күренде. «Камышлы елга» буенда тау астында яңа салынган кирпеч заводы төтенләп тора. Искечә җиһазлы, җитештерүчәнлеге әллә ни түгел түгелен, шулай да беренче төзелешләрне башлап җибәрергә ярдәм итте. Югары сортлы он тарттыру тегермәне, механикалаштырылган ындыр табагы салынды кирпечтән. Балалар өчен ясле-бакчаны, мәктәпне һәм культура йортын да кушсаң, төзү эшләре җайга салынып бара дияргә була. Колхозның үз төзүчеләр бригадасы оешты һәм ул байтак тәҗрибә дә туплады инде. Хәзер читтән килгән «шабашник»ларга ялынып торасы юк. Яңа кирпеч заводы салынып беткәч, төзелеш эшләрен киң колач белән алып барырга мөмкин булачак. Әнә тау өстендә механикалаштырылган һәм кирәкле машиналар белән җиһазландырылган яңа заводның нигезләре калкып килә. Киләсе елдан да соңга калмыйча сафка кертәсе иде. Аннары хәзергә йөз-йөз егерме мең кирпеч урынына ел саен сигез йөз илле-тугыз йөз меңне җитештерер идек. Ул үз төзелешләребезне тулысынча кирпеч белән тәэмин итәр иде, хәтта читкә сатарга да калыр иде. Колхоз өчен өстәмә керем чыганагы булачак... Менә нишләтә бит еллар дигәнең!

«Газик» идарә янына килеп туктады. Машинадан төшүгә Сәләховка каршы ике кеше атлады. Берсен таный, район халык контроле комитетыннан. Икенчесен дә күргәне бар кебек, ләкин кайдан икәнлеген хәтерләми. Һәрхәлдә, районнан булырга тиеш.

— Сезне тотарга да юк, иптәш Сәләхов, — диде район вәкиле, кинаяле итеп. — Идарәгә кермисез дә, ахры.

— Урып-җыю якынлашканда, иртәгә печәнгә төшәргә дип торганда председательнең урыны кабинетта түгел бугай, — диде Сәләхов, район вәкилләренең ни йомыш белән килүләренә төшенергә тырышып. — Нинди җилләр ташлады безнең якларга? Әлбәттә, сер булмаса...

— Юк, сер түгел,— диде халык контроле комитеты вәкиле. — Әйдәгез кабинетыгызга. Җитди мәсьәлә бар...

— Я, тыңлыйм сезне, — диде Сәләхов, кабинетка кергәч.

— Ничек башларга да аптырап торабыз әле, — диде район вәкиле, портфеленнән нидер эзли-эзли. — Бик коры характерлы диләр сезне, я куып чыгарырсыз...

— Юк-бар белән баш катырып йөрсәгез, анысы да булыр, — диде Сәләхов, ачуы кабара башлап. — Без бала-чага түгел, нәрсә барын тотыгыз да әйтегез. Болай да эш муеннан, ашыгам...

— Ашыксагыз да бераз сабыр итәргә туры килер,— диде район вәкиле, фәрман бирүче тонына күчеп. — Менә шушы хатның күчермәсен укып чыгыгыз әле. Райком секретаре исеменә дә адресланган ул. Так что, Габбас Кыямович та белә моны.

Нургаяз машинкада басылган дүрт-биш битле хатны кулына алды да яңадан өстәле артына барып утырды. Хатны укыган саен аның йөзе җитдиләнә, ярсуы кабара барды, тыны кысыла башлады. Хатны укып бетермичә ертып ташлаудан үзен көчкә-көчкә тыеп торды.

Нинди генә пычрак өелмәгән анда председатель өстенә. Дорфа

да ул (монысы белән килешеп тә булыр иде әле), кешеләрне ата-анасы белән сүгә дә, кыйнап ташлаудан да баш тартмый, шәхси әйберләрен дә бәреп вата, эчеп-исереп атналар буе идарәгә дә килми... Тагын әллә нәрсәләр, тагын әлләниләр...

— Я, нәрсә диярсез, иптәш Сәләхов? Әлбәттә, барысы да ялган. язучылар — яла ягучылар диярсез инде.

Район вәкиленең ирония белән әйтелгән бу сүзләре Сәләховны куырып алгандай булды. Шулай да ул үзен тыеп кала алды... Бер, ике, өч... ун, егерме... «Кызып киткәнче чыгып киту хәерлерәк булыр», дип уйлады Нургаяз.

— Менә нәрсә, иптәш халык контроле, — диде Нургаяз, ягымлырак булырга тырышып. — Жалоба сезгә килгән, үзегез тикшерегез инде. Минем кирәгем юктыр биредә. Нәрсә сорасагыз да, мин үземне хаклы диячәкмен. Үземне гаепсез саныйм икән, нигә мин аны исбатлап торырга тиеш. Киресенчә, мине гаепләүчеләр язганнарының яла түгел икәнен исбатласыннар. Күрәсең, аларның бүтән эшләре юктыр. Әгәр инде монда язылганнарны фактлар белән нигезли алсалар, җавабын бирербез. Бу мәсьәләдә мин сезгә бер тиенлек тә ярдәм итә алмыйм. Партком секретарена мөрәҗәгать итүегез дөресрәк булыр. Әлегә хушыгыз...

Вакытында чыгып китте Нургаяз. Югыйсә, район вәкилләренә дорфа сүзләр әйтеп ташлап, эшне катлауландыра гына төшәр иде. Аның сабырлыгы тәмам беткән иде. Машинасын бар фәрманга куалап кырлар әйләнү дә, утарда сыер савучылар белән сөйләшү дә тынычландыра алмады аны.

«Чынлап та, нәрсә дип шулай янам да көям әле мин, — дип уйланды ул, кич өенә кайтып яткач. — Миңа гына кирәкмени барысы да? Председатель булганнан бирле һаман даулаш-бәхәс тә жалоба. Ничә ел бит инде... Тәмам туйдырды. Эш дип көн-төн чабасың, ә рәхмәт урынына — йөзеңә пычрак. Ярдәм итәсе урында — көпчәккә таяк тыгалар. Берәр яңа тәкъдим белән чыктыңмы, әле берсе, әле икенчесе каршы төшә дә тора. Бәлки шушы авыл кешесе булганга, аның бездән нинди артык җире бар, дип көнләшәләрдер, шуңа санга сукмыйлардыр? Чынлап та, нәрсә дип чытырдап ябыштым соң әле мин шул Әмзәгә? Тотарга да бүтән колхозга китәргә. Иртәгә үк Габбас Кыямовичка барам да, җибәрегез мине иң артта калган колхозга, дим. Үч итеп эшләрмен, районда иң алдынгы колхоз итәрмен».

Нургаяз сикереп торды да, тимерне кызуында сугарга кирәк дип, райком секретаре Габбас Гыйматдинов исеменә гариза язарга утырды...

Сәләхов иртән торганда әле таң атып кына килә иде. Юынып, физзарядка ясады да, хатынын уятып тормыйча, бер стакан сөт эчеп, идарәгә юнәлде. Партком секретаре да иртәләгән иде бүген. Партком бүлмәсенең ишеге ачык иде. Нургаяз туры шунда атлады.

— Ә, Нургаяз, әйдүк, — дип каршылады аны Мусин. — Сине дәниндидер борчулар тынычсызлаган, ахры, бүген, иртәләгәнсең. Я, кәефләр ничек?

— Ташка үлчим, — диде Нургаяз, кәефе кырылганын яшермичә. — Ярый, монда икәнсең әле. Синең белән сөйләшергә дип килгән идем, Гәрәй...

— Я, тыңлыйм, — дип сагайды Мусин. Председательнең ниндидер мөһим нәрсә турында сүз башларга җыенуын абайлап.

— Ничек башларга соң?...— Сәләхов, сүз таба алмый, бераз тын торды. — Озын сүзнең кыскасы, «Комбайн»нан китәргә булдым. Иң артта калган колхозга сорыйм. Менә гаризам да язылган... Туйдырды һаман-һаман әрләшүләр һәм гайбәтчеләрнең мәгънәсез жалобаларына аңлатма бирүләр.

— Да-а, бу яңалык, — диде гаҗәпкә калган партком секретаре. Аннары, ситуациягә бераз төшенгәч, председательнең авырткан җиренә чәнчү нияте белән, өстәп куйды. — Димәк, авырлыклардан качабыз, яла ягучылар алдында тез чүгәбез. Әйбәт, әйбәт... Менә дә шатланырлар. Сиңа булган бөтен ачуларын онытып, берәр коньяк та кыстырып килерләр әле. Үткәнне искә төшермик дип, сөенечләреннән рәхмәт әйтерләр хәтта..

Нургаяз моны көтмәгән иде. Мусинның бу сүзләре аны тәмам аптырашта калдырды, ни әйтергә дә белмәде.

— Соң бит, Гәрәй, туйдырды, түзәр хәл калмады... Мин бит эштән качмыйм, иң арттагы колхозга сорыйм.

— Ә биредә башлаган эшләрең, киләчәккә планнарың? Ярты юлда ташлап китәсеңмени? Юк, Нургаяз, синнән моны көтмәгән идем.

— Барыбер тыныч эшләргә бирмиләр бит... Һәм бирмәячәкләр.

— Анысын күрербез әле, — диде партком секретаре, председательгә нindидер сер ачарга җыенган кебек. — Кичә син дулап чыгып киткәч район вәкилләре миңа керделәр. Ачыктан-ачык сөйләштек. Хатны кемнәр язганы билгеле, кемнәр болгатып ятуын беләбез. Бу хатны тикшерү аларның үзләре өчен күңелсезлек белән бетмәгәе әле. Тикшерүчеләр Минаповның кайбер кыек эшләрен ачыклаучы фактларга юлыкканнар да аларны җентекләбрәк анықларга булганнар. Соңыннан бу мәсьәләгә партиячә дә бәя бирәчәкбез... Ләкин, Нургаяз, кайбер нәрсәләр өчен сиңа да җавап бирергә туры килер... Ни генә булса да, кыенлыкларга очрагач, үз позицияләреңнән чигенү коммунистларча түгел. Бу хакта ныклабрак уйла әле син...

Гәрәйнең бу сүзләре Нургаязны бөтенләй коралсызландырды. Чынлап та, кыенлыкка очраган саен икенче җиргә китә башласаң, нәрсә килеп чыгар аннары. Мин китсәм, кем председатель булыр? Инде бер тапкыр үзенең булдыксызлыгын күрсәткән Җамалетдиновмы? Әллә үз эшен дә башкара алмаган агроном Гарифуллинмы? Аңа нәрсә, бүген монда, иртәгә тегендә. Ә мин бит шунда туыпүскән, ата-бабалар таптап йөргән туфракта аунаган. Авылның һәр кешесен җиде бабасыннан башлап беләм. Димәк, кешеләрне аңлау миңа җиңелрәк бит. Ничек инде туган авылыңны, туган җиреңне ташлап китәсең, ди. Булдыра алмам, пожалуй.

*
* *

Гәрәй Мусинның сүзләре хаклы булып чыкты, хатны тикшерү авторларның үзләре өчен күңелсезлек белән тәмамланды. Бухгалтер эшендә байтак чатаклыклар табылды, ә җентекләп тикшерә башлагач, кайбер акча документларының бөтенләй ялган булулары, тиешсез кешеләргә акча бирелеп, шуны бергәләп эчеп ятулары ачыкланды. Габдулла Минаповның коммунист өчен хас булмаган тәртибе һәм эшләре партия җыелышында тикшерелде һәм ул партиядән чыгарылды. Партком һәм идарә агроном Яхъя Гарифуллинның үз эшенә салкын каравын, эштә комачаулыклар тудырып, җитәкчеләргә каршы имзасыз хатлар аша яла ягып ятуын гафу итмәслек хәл дип таптылар һәм ул да эшеннән алынды. Чираттагы отчет-сайлау җыелышында колхозчылар идарәнең эшчәнлеген бердәм хупладылар. Идарәнең яңа составына алдынгы терлекчеләр, механизаторлар, эш өчен янып йөрүче бригадирлар сайланды. Ныклы таяныч булгач, председательнең дә эше җиңеләйде. Юк-бар белән баш катыручылар кимегәч, күңеле дә күтәрелеп китте, тагын да зуррак планнар белән эшли башлады.

*
* *

— Эшләр ничек, Вәсимә? Сыерлар бозаулап беттеме?

— Рәхмәт, зарланырлык түгел, Нургаяз.

— Алай булгач, быел дүрт мең килограммнан уздырасың?

— Дүрт мең ике йөзгә җиткерергә дигән уем бар, үтәрмен дә дип уйлыйм. Унҗиде сыерым да бозаулады, чиләк-чиләк сөт бирәләр. Теге вакытлардагы кәҗә сыерлар түгел инде. Җыенысыннан бер чиләк сөт савыла иде бит.

— Димәк, беренчелекне быел да бирмәскә уйлыйсың, Вәсимә?

— Уйлавын уйлыйм да, Нургаяз, авыр булыр, ахры, быел. Әнә Сәгадәт табанга басып килә. Әкълимә дә менә-менә куып җитәргә тора...

Көндез фермада Вәсимә Галиева белән булган бу сөйләшү председательнең кәефен күтәреп җибәргән иде. Чынлап та, соңгы өч-дүрт елда зур уңышларга ирештек бит. Һәр сыердан савымны ике тапкырдан күбрәккә арттыруга ирештек, ягъни 3140 ар килограмм сөт саудык. Моңа нәселсез сыерларны Бестужев токымлы мул сөтле сыерлар белән алыштыру, витаминлы һәм сусыл азыкларны җитәрлек кадәр булдыру, терлекләрне карауда зоотехника таләпләрен төгәл үтәү нәтиҗәсендә ирешелде. Әлбәттә, сыер савучыларның да хезмәте бик зур. Вәсимә Галиева, Сәгадәт Әхмәтҗанова, Әкълимә Мәхмутоваларның исемнәре бөтен районга билгеле. Шуларның тырыш хезмәтләре нәтиҗәсендә бит инде дәүләткә терлекчелек продуктлары сатуны арттырып үтәп киләбез.

Игенчелектә дә эшләребез начар түгел. Тулысынча сортлы орлыклар белән чәчүгә кучү, ашламалар кертү һәм туфракны эшкәртүдә агротехника таләпләрен җиренә җиткереп үтәү матур нәтиҗәләргә китерде. Колхоз хәзер ел саен тотрыклы югары уңыш үстерә. 1967 елдан бирле уңышның уналты-егерме центнердан ким булганы юк. Ә былтыр һәр гектардан колхоз буенча йөз утызар пот уңыш алдык. Көзге бодай чәчүгә күчү дә зур файда бирә.

Терлекчелектән продукт алуны арттыру, игеннәрнең уңышы күтәрелү колхозның тулай керемен берничә тапкырга үстерде. Хәзер ел саен колхоз кассасына йөзләрчә мең саф табыш өстәлә тора. Бу исә колхозчыларның хезмәтләренә түләүне арттыру, төзелеш эшләрен киң колач белән алып бару өчен зур мөмкинлекләр тудыра. Димәк, моннан берничә ел элек билгеләгән планнарыбыз уңышлы үтәлә. Ә бит алда тагын да зуррак эшләр тора әле...

Нургаязның күңелле бу уйларын бүлдереп, ишек шакыдылар. Күрше малае икән.

— Нургаяз абый, Казаннан корреспондент килгән. Рәхимҗан абый, идарәдә көтә, дип әйтергә кушты.

— Ярар, көтәр әле, — диде Нургаяз, исе китмәгәнгә салышып. Ә үзенең күңеленә шик төште. «Мөгаен, тагын берәр жалоба тикшерергәдер әле. Ничә ел тынып торган идек, тагын башлана, ахры».

Аннан-моннан гына капкаладыда идарәгә ашыкты. Корреспондентның ни өчен килгәнен тизрәк ачыклыйсы килә иде Нургаязның.

Сәләхов башта партком секретаре Вәлиуллин янына кагылырга булды (Гәрәй Мусин район Советы башкарма комитеты председателе итеп сайлангач, коммунистлар үзләренең җитәкчеләре итеп Рәхимҗан Вәлиуллинны сайлаганнар иде). Корреспондент аңарда утыра икән. Партком секретаре үзе каядыр чыккан, ахры. Журналист таныш булып чыкты. Колхозның алдынгы терлекчеләре, механизатор-

лары турында «Социалистик Татарстан» газетасында матур-матур язмалары да чыккан иде.

— Исәнмесез, иптәш Сәләхов, — дип елмаеп кул сузды ул Нургаязга. — Минә килеп чыктым әле сезгә. Иске танышларның хәлен белим, мин әйтәм.

— Дусларча килсәгез — рәхим итәсез, сүгәргә булса — уртак тел таба алмабыз, — диде Нургаяз, шаяртырга тырышып.

— Анысы үзегезгә бәйле инде, иптәш Сәләхов. Мактарлык эшегез булса, тәнкыйтьләүгә караганда мактау безнең өчен дә күңеллерәк.

— Соң, ни йомыш белән алай булгач? Тыңлыйм...

— Дөресен әйтим, бу юлы мактарга дип килдем. Сезнең колхоз соңгы елларда шактый уңышларга ирешкән. Югары уңыш үстерү буенча да, терлекчелекнең продуктлылыгын арттыру буенча да, капиталь төзелеш өлкәсендә дә район күләмендә беренчеләрдән саналасыз. Минә шул уңышларны саннар белән рәк күрсәтсәгез иде миңа.

Сәләхов җиңел сулап куйды: димәк, жалоба-фәлән тикшерергә түгел икән. Аның кәефе күтәрелеп китте. Күкрәк кесәсеннән куен дәфтәрен алды.

— Саннар гына кирәк булса, бар алар бездә. Нәрсәләр кызыксындыра соң сезне? Әһә, уңыш мәсьәләсе. Былтыр бөртеклеләрне өч мең гектар чамасы чәчкән идек. Һәр гектардан 21,9 центнер, ә көзге бодайны 24,3 центнер үстердек. Ике йөз гектар җирдән 242 шәр центнер шикәр чөгендере җыеп алдык. Ике йөз илле гектар кукуруз чәчкән идек, 358 әр центнер яшел масса чыкты. Дәүләткә унсигез мең центнер урынына 20 мең 253 центнер ашлык, егерме бер мең центнер урынына 49 мең 800 центнер шикәр чөгендере саттык... Терлекчелек буенчамы? Бар беркадәр уңышлар, һәр сыердан савымны өч мең килограммнан арттырдык. Дәүләткә 9.072 центнер сөт саттык. Бу пландагыдан 1902 центнерга күбрәк. Итне дә пландагыдан 619 центнер күбрәк, ягъни 2419 центнер саттык. Әйе, моңа ныклы терлек азыгы базасы булдырмыйча ирешү мөмкин түгел иде. Ел саен 65—75 мең центнер сусыл силос салабыз. Соңгы елларда сенаж салуны арттырдык. Җәйләү чорында савым сыерларны сусыл азык белән даими тәэмин итү өчен культуралы көтүлекләр булдырдык. Нәтиҗәсе әйбәт: ике тапкыр өлгерүен исәпләгәндә, гектардан 600 центнерга кадәр яшел масса чыга. Әлегә культуралы көтүлекләр Яңа Әмзә авылында гына, нибары алтмыш гектар. Киләчәктә аны һәр савым сыер башына ярты гектарга, ягъни бөтенесен 160—170 гектарга җиткерәчәкбез. Алдынгы терлекчеләребез турында Вәлиуллин сөйләгәндер инде сезгә... Әйе, төзелеш эшләрен дә киңәйтеп җибәрдек. Соңгы дүрт елда гына да капиталь төзелешкә 570 мең сумнан артык акча тоттык. Быел тагын 400 мең сум тотачакбыз. Якындагы ике елда терлекчелек һәм производство биналары төзүне тәмамлап, культура-көнкүреш объектларын сала башлыйбыз. Мәктәп, балалар яслесе, һәр бригадада клуб, торак йортлар. Авылны үзгәртеп коруны да күздә тотабыз. Биектау районының Шәпше авылы кебегрәк. Өйләргә үзәктән ягу, су, канализация, газ үткәреп. Проект эшләнә инде... Кыскасы, планнарыбыз зур, үтәп чыгасы гына бар...

— Төзелешләрдә, алдынгы терлекчеләр һәм механизаторлар янында булачакмын әле,— диде корреспондент, председатель сөйләгәннәрне блокнотына теркәп бетергәч. — Вәлиуллин белән киңәштек инде ул хакта. Ул үзе минем белән йөрергә булды. Беренче булып, орденлы бригадир Зөлкарнәй Галиев һәм ферма мөдире Хәким Хәбибрахманов янына барырга булдык.

— Тукта, тукта, сез нәрсәдер бутыйсыз бугай,— диде гаҗәпләнеп Сәләхов. — Галиев ниткән орден кавалеры, ди?

— Ништләп бутыйм, ди, инде,— диде председательдән дә артыграк гаҗәпләнгән корреспондент. — Мин шулай ашыгып нигә килгән дип беләсез сезгә? Хезмәт Кызыл Байрагы ордены алган председатель Нургаяз Сәләхов белән бригадир Зөлкарнәй Галиев турында очерк язарга...

— Я, артистланмагыз, көлмәгез,— диде Сәләхов, ачулана башлап.

— Һәй, чыннан да белмисез, ахры, сез,— дип кул чапты председательнең бүгенге газетаны укымаганын аңлаган корреспондент. — Алай булгач, сөенече миңа... Менә Верховный Совет Президиумы Указы,— һәм ул, портфеленнән алып, Сәләховка «Социалистик Татарстан» газетасын сузды.

Нургаяз, әле һаман да ышанып җитмичә, кулына газетаны алды һәм караштыра башлады. Менә чыннан да Указ... Ленин ордены белән бүләкләргә... Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән... Чү, Галиев Зөлкарнәй... Сәләхов Нургаяз... Почет билгесе ордены белән... Хәбибрахманов Хәким...

— Юк, чыннан да белмәгән идем. Безгә газета кичкә генә килеп җитә бит. Ә иртән радио тыңлый алмадым,— дип сөйләнде Нургаяз, дулкынлануыннан ни әйтергә дә белми.

— Юкка самолет белән очмаганмын икән болай булгач... Гафу, иптәш Сәләхов, сезнең белән соңыннан сөйләшербез. Хәзер Галиев янына чабам, аңардан да сөенечне үзем алам. — Корреспондент кабаланып урамга ашыкты һәм ишектән чыкканда керeп килүче Вәлиуллинны чак кына бәреп екмады.

Партком секретаре Указ турында белә икән инде. Аңа да корреспондент әйткән. Ул каты иттереп председательнең кулларын кысты.

— Югары бүләк белән, Нургаяз... Чын күңелдән тәбриклим...

— Яшибез болай булгач, иптәш секретарь. Тауларны актарачакбыз, чишмәләрне елга итәчәкбез. Бер башак урынына икене алырбыз. Туган туфрагыбызда гөлләр үстерербез, туган авылыбызны шәһәр итәрбез. Әйе бит, Рәхимҗан...

— Әлбәттә, Нургаяз... Киләчәктә аерым кешеләребез генә түгел, колхозыбыз да орден алырлык итеп эшләрбез. Октябрь районының орденлы «Комбайн» колхозы... Шәп яңгырый бит, ә!

— Яңгыратырбыз, Рәхимҗан... Ирешербез моңа!

# ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ТАЛАНТ



Гали Халит әдәбиятка килгәндә әдәби тәнкыйть өлкәсендә беркадәр борылыш сизелә башласа да, социологик сөрем әле таралып бетмәгән иде. Заманы шундый иде: бер үк язучы турында капма-каршы фикерләр йөри, ләкин, күбесенчә, фикер көрәше идея-эстетик принципларны киңрәк һәм тирәнрәк ачу юнәлешендә түгел, бәлки бер-берсен инкарь итү, юкка чыгару төсендә бара. Бу нәрсә Гали Халитның да баштагы эшчәнлегендә сизелми калмады, билгеле. Шул ук вакытта ул әдәбиятның үз спецификасына аеруча игътибар итүчеләрнең берсе булды.

Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Ибраһимов кебек классик язучыларыбыз турында нинди генә әдәби тәнкыйть мәкаләләре күрмәдек без ул заманда. Тукайны, мәсәлән, романтик, мистик дип әйтүчеләр дә, аны динче, милләтче яки вак буржуа җырчысы итеп күрергә тырышучылар да юк түгел иде.

Халыкның горурлыгы булып, аның намусы булып әверелгән, исемнәре хөрмәт белән әйтелә торган язучыларга ябыштырылган начар тамгалардан, ямьсез исемнәрдән арындыру, аларны саф килеш халыкка күрсәтү эшенә Гали Халит актив керешә. Ул Тукайның халык шагыйре икәнлеген исбат итәргә, аның халыкчанлык принципларын ачыкларга керешә. Бу мөһим һәм бик кирәкле хезмәт иде. Шул юнәлештә аның «Тукай халык шагыйре» исемле беренче хезмәте аерым китап булып мәйданга чыкты. Бу — 1938 ел иде.

Тукай поэзиясе бүгенге көндә дә Гали Халитның игътибарыннан читләтелгәне юк. Киресенчә, ул бу бөек шагыйрь иҗатына әледән-әле әйләнеп кайта һәм төрле проблемалар яктылыгында аны күзәтеп килә.

Иҗатының башлангыч елларында ук Гали Халит, язучылар иҗат эшендә югары сәнгать критерийларын онытмаска тиешләр, дип язып чыкты. Бу бик әһәмиятле һәм кирәкле эш иде, чөнки юк-юк дисәң дә, кайбер язучылар үзләренә ташлама сорыйлар, «безнең агай-эне өчен ярый ул» принципы белән эшлиләр, әсәрне камилләштерү турында артык кайгыртмыйлар. Хәер, кызганычка каршы, хәзерге көндә дә әле таләпчәнлекне онытучылар очраклары шактый сизелә.

Яшь, энергияле, күпне иңләп алырга омтылган Гали Халит үз көченә ышанып һәм фикерләренең дөреслегенә дә шик калдырмаска тырышып бәхәсләшә белә. Мондый чакта ул, кешенең хәтере белән дә исәпләшеп тормастан, каты-каты сүзләр әйтүдән дә тукталып калмый.

Әдәби хәрәкәтнең теге я бу дәвердәге тәгәлләнгән чорын алып, иҗат процессына киң гомумиләштерү ясый белү һәм югары идея-эстетик принциплар белән эш итү,

әлбәттә, җиңел түгел. Гали Халит иҗатының башлангыч вакытында ук шундый киң гомумиләштерүгә омтылды һәм 40 елга якын вакыт эчендә бик күп җитди, кыю гомумиләштерүләр ясалган хезмәтләр бирде.

Дөрес, бу юлда аның эшләре җиңел генә бармады. Эзләнүләр, тикшеренүләр процессында теге я бу якка ауган чаклар да, тәнкыйть ителүләр дә булды. Аның «XX йөз башындагы татар әдәби хәрәкәтенең кайбер мәсьәләләре» (1950) исемле өч бүлектән торган күләмле мәкаләсе аеруча каты тәнкыйтькә очрады. Чыннан да, мәкаләдә каршылыклы тезислар да бар иде. Мәгърифәтчелек белән җәдитчелеккә карата, «милли декадент»лык, «ертыкчылык психологиясе» кебек мәсьәләләрдә ачыклык, гыйльми объективлык җитми иде. Ләкин Гали Халит бер урында туктап кала торган тәнкыйтьчеләрдән түгел. Ул үзен дулкынландырган проблеманы төрле яклап җентекләп өйрәнә, кирәк икән, шул проблемага яңадан әйләнеп кайта; татар матбугатында гына түгел, рус әдәби дөньясына да чыгып, үз авазын ишеттерә белә.

XX йөз башындагы әдәби хәрәкәткә дә ул яңадан әйләнеп кайтты һәм бер генә тапкыр да түгел. Әдәби хәрәкәт һәм шуңа бәйле рәвештә революция һәм шәхес проблемасы, реализм өчен көрәш мәсьәләләре, халыкчан поэзия, романтизм һәм аның төрле төстәге чагылышлары һәм тагын бик күп мәсьәләләр аңа тынгылык бирмиләр, ул эзләнә, тикшерена, татар, рус h. б. тугандаш халыкларның әдәбият белеме дөньясындагы хезмәтләрне җентекләп укый...

Г. Ибраһимов иҗатына бәя бирүдә дә ул соңыннан эзлекле гыйльми юлга басты. Тынгысыз эзләнү аңа проблеманың яңадан-яңа күренешләрен ачарга булыша, ул бу ноктадан торып та, теге югарылыктан торып та фикер йөртә белә. Тарихтагы социаль тетрәнүләр, шул уңайдан халык һәм культура мирасы язмышы, яңа герой, яңа эстетик нормалар перспективасы, әлбәттә, тикшеренүче галим өчен киң мәйдан. Әнә шул мәйданда без Гали Халитны әле Тукай һәм аның замандашлары белән, әле Такташ һәм аның чордашлары белән күрәбез. Алардан элегрәк ул Мәҗит Гафури иҗатын төрле яклап тикшерде һәм җитди монография язды. (Хәтеремдә: монографиянең редакторы Гадел Кутуй китапны редакцияләү процессында һәм соңыннан да аның хезмәтенә гаять югары бәя бирең, сокланып сөйли иде!)

Бу монографиягә чирек гасыр вакыт узганнан соң да галимнәр югары бәя биргәннәр икән, димәк, без әсәрнең гыйльми тирәнлеге турында авыз тутырып сөйли алабыз. Мин Гыйлемдар Рамазановның 1965 елда Уфада башкорт телендә басылып чыккан «Мәҗит Гафури иҗаты» исемле зур күләмле монографиясен истә тотам. Башкортстан галиме, фәннәр докторы Г. Рамазанов үзенең китабында Гали Халитның Гафурига багышланган монографиясенә әледән-әле күз сала һәм аңа югары бәя бирә.

Чыннан да, Г. Халитның «Мәҗит Гафури иҗаты» исемле монографиясе әдипнең иҗатын төрле яклап һәм тиешле гыйльми югарылыкта тикшергән беренче хезмәт иде әле. Бу темага керешүче галимнәр Халитны «күрмичә» уза алмаячаклар. Бу хезмәте аның филология фәннәре кандидаты дигән исем алу өчен язган диссертациянең нигезенә ятты (1948).

Көн тәртибендә татар әдәбияты тарихын язу мәсьәләсе тора иде. Бу эшне, билгеле, Мәҗит Гафури, Габдулла Тукай кебек шагыйрьләр турында монографияләр язган Гали Халит җитәкләргә тиеш иде. Ләкин шул эш белән янәшә икенче бер мөһим хезмәт — озакка сузарга ярамый торган хезмәт — дәреслек өстендә утырырга кирәк иде.

Гали Халит урта мәктәпләрдә татар әдәбиятын укыту программаларын төзүдә катнашты һәм X класслар өчен татар әдәбияты дәреслеген язучылар коллективының җитәкчесе — бригадиры булды. Х. Госман, Х. Хәйри, Х. Хисмәтуллин, Г. Халит һәм шушы юлларның авторы составында X класслар өчен дәреслек төзелде, һәм ул Г. Халит редакциясендә басылды. Дәреслекнең 1948 елдан алып 60 нчы елларның ахырына чаклы ел саен диярлек басылып килүе үзе генә дә күп нәрсә сөйли. Редактор буларак, Г. Халит таләпчән, коллективны кирәкле юнәлештә эшләтә белә, дәреслекнең гыйльми һәм әдәби сыйфаты өчен көчен кызганмый, шул ук вакытта стабильлекне саклаган хәлдә, заман сулышына ятышлы нюансларны кертергә дә онытмый. 1969 елда бу коллективка Н. Юзиев, А. Сайганов кебек яңа галимнәр килеп кушылды һәм дәреслекнең яңа программа белән төзелгән варианты шул ук Г. Ха-

лит редакциясендә басылды. Шушы коллективта эшләүчеләрнең бер әгъзасы буларак, мин Гали Халит белән уртак тел, иҗади омтылыш табуымны тирән канәгатьләнү белән искә алам.

Дәреслекләр өстендә эшләү Гали Халит өчен татар әдәбияты тарихын язуга зур этәреш булды. Бөек Ватан сугышына чаклы ул татар әдәбияты тарихын язар өчен күп вакыт кирәкмәячәген әйткән иде. Үзе инде бәлки онытkandыр, ләкин күтәрелмәгән чирәмне җиңел генә күтәрү мөмкин түгеллеген ул тиз аңлады. Тел, әдәбият һәм тарих институты (соңыннан бу институтка Г. Ибраһимов исеме бирелде) өешкан кеннән алып, әдәбият тарихын язу мәсьәләсе көн тәртибеннән төшкәне юк. Гали Халит бу институтта 1943 елдан бирле хезмәт итә һәм нәтиҗәле иҗади эш алып бара. Аның җитәкчелегендә башта әдәбият тарихына бәйле очерклар мәйданга килде. Аннан соң институт коллективының күмәк көче белән (тугыз автор катнаша) «Татар әдәбияты тарихы» (1960) басылып чыкты. Культура тормышыбызда ул зур вакыйга булды. Галимнәр, язучылар җәмәгатьчелеге ул хезмәтне күтәреп алды, кимчелекләрен әйтү белән бергә, аның әдәби фән дөньясында бер этап булуы да күрсәтелде. Чыннан да, совет власте елларында ирешелгән рухи-эмоциональ байлыкны чагылдырып, татар совет язучыларының 40 еллык художество эшчәнлегенә, нигездә, дөрес бәя биргән хезмәт иде ул. Бу хезмәтне барлыкка китерүдә Гали Халитның әйдәүче — җитәкчелек роле зур булды. Ул үзенең эшчәнлеген дә, эрудициясен дә, әдәби процессның агымына тирәннән үтеп керә алуын да күрсәтте. Ләкин эш моның белән төгәлләнеп калмады. Тагын да эшкәртелеп, төзәтелеп, «История татарской советской литературы» исемендә Фәннәр академиясенең М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты грифы белән Мәскәүдә «Наука» нәшриятында басылып чыкты. Тәнкыйть бу хезмәткә югары бәя бирде. Шул җөмләдән, Гали Халитның фәнгә салган өлеше дә канәгатьләнү белән күрсәтелгән иде.

Гали Халит — уйлана белә торган тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме. Аның хезмәтләрендә анализ белән синтез гармоник берләшәләр. Г. Тукай һәм һ. Такташ иҗатларына карата язылган хезмәтләрен генә алып карарга мөмкин.

Тукай — Гали Халитның гомерлек темасы, бик уңышлы яклаңган докторлык диссертациясе дә бу теманы читләтеп узмаган. Хәзерге көндә дә ул «Тукайдан Җәлилгәчә» исемле зур хезмәт өстендә эшли һәм, исеменнән ук күренгәнчә, Тукай монда да үзәк урында булыр дип уйларга мөмкин.

Тукай турында язылган барлык хезмәтләргә тукталмастан, бу очракта «Тукай үткән юл» (1962) исемле монографиянең кайбер якларына гына күз салмакчы булам. Бу хезмәт публицистик пафос белән язылган, Тукайга, аның поэзиясенә соклану, аңа тирән хөрмәт белән сугарылган һәм, димәк, авторның тирән хисе, ялкыны сизелеп тора. Халитның баштагы әсәрләрендә чагылган «академик» корылык та монда күренми. Гали Халит Тукайның бай мирасын яңача укып чыккан, ягъни бүгенге көн таләпләре югарылыгыннан торып, тирән, гыйльми анализ ясаган һәм Тукайны аңлавыбызның офыгын киңәйткән. Моның өчен ул Тукай мирасын өйрәнүчеләрнең барлык уңай мәкаләләрен һәм шул юлдагы барлык ялгыш, бозык яки демагогик чыгышларны күздән кичергән, аларны тарих калыбына салып караган. Аларга бүгенге көннең фәнни казанышларыннан чыгып үз бәясен биргән. Тукайның мәгърифәтчелек һәм шәкертләр хәрәкәте идеяләрен халыкның революцион хәрәкәтләренә бәйләп, халык интереслары өчен көрәшүдә файдалануы ачыктырылган. Шагыйрьнең самодержавие ялчыларын камчылавы, ватанчылык һәм гражданлык идеяләрен чагылдыруы ышандырырлык итеп тикшерелгән. Тукай һәм аның реалистик әдәбиятны үстерүдәге роле, декадентларга каршы килешмәүчән көрәше күрсәтелгән. Болар барысы да конкрет тарихи шартларда, Тукайның үз чорында, шул чактагы политик-экономик тормышның иҗтимагый фикерләр көрәше фонында биреләләр.

Гали Халит полемист тәнкыйтьче — ул бик оста бәхәсләшә белә. Кайчак аның аргументларын кире кагарлык дәлилләр табуы да читен булып кала. Шулай бервакыт аның белән Әмирхан Еники хикәяләре турында бәхәсләшергә туры килде. Хәтерлим, январь башы иде, без Ирек мәйданында аркылыга-буйга йөри-йөри төн уртасы җиткәнче бәхәсләштек. Кышның салкыны сизелмәде, чөнки без үз фикерләребезнең хаклыгына инанып яна идек. Андый бәхәстән соң, билгеле, йокы кача, оппонентның фикерләре турында уйлана башлыйсың, яңадан Еники әсәрләре өстәленә куела...

Шулай берничә ел узды һәм мин «Казан утлары» журналында Гали Халитның Әмирхан Еники иҗаты турында шактый күләмле һәм гаять кызык мәкаләсен укыдым...

Гыйсъянчылык мәсьәләсендә Гали Халит үзен кайнар канлы полемист итеп танытты. Татар совет әдәбиятының 20 нче еллардагы характерлы бер күренешен ул гыйсъянчылык дип билгеләде. Хәзер инде бу проблеманың төп принцибы белән бәхәсләшүчеләр бик аз булса кирәк, чөнки Гали Халит гыйсъянчылыкны әйдәгән мотивны «дөньяга яңача караш һәм яңа мораль өчен көрәш идеясе»н дә күрә. Шул ук вакытта ул аны «традицион-романтик агым» [14 б.] дип атый. Ләкин баштагы чыгышларында Гали Халит ачык формулировка бирмәгән иде әле һәм гыйсъянчылык рамкаларын да гаять киң күләмдә алган иде. 1971 елда аның «Шагыйрь. Чор. Герой» исемле китабы басылып чыкты. Нигездә бу әсәр Һади Такташның иҗатын өйрәнү тәҗрибәсенә йомгак ясый һәм Халит, үз принципына турылыклы буларак, шагыйрь турында язылган хезмәтләргә тулы анализ ясый һәм үз ачышын күрсәтә кала. «Егерменче еллар дәвамында җитлеккән Такташ иҗаты аша әдәби метод һәм әдәби герой проблемалары ничек ачыла баруын иң калку нокталары белән күрсәтүдән гыйбарәт» [4 б.], ди ул үзенең төп максаты турында һәм үз максатына ул ирешә дә. Г. Халитның бу әсәре дә язучылар җәмәгатьчелегендә киң рәвештә тикшерелде. Н. Исәнбәт, Х. Туфан, Н. Юзиев, Г. Минский, Х. Хәйри, С. Хәким кебек танылган язучылар һәм әдәбият белгечләре китапның бик күп уңай якларын күрсәттеләр, шул ук вакытта бәхәсле моментларга да тукталдылар.

Әсәрне киң җәмәгатьчелек каршына чыгарып тикшерү фикерен автор үзе куәтләп куйган иде, гата, чөнки хаклык бәхәстә генә туарга мөмкин. Аның өчен каләмдәшләренең фикерләрен белү бик мөһим, чөнки ул ирешелгән ноктада туктап кала торган тәнкыйтьче түгел.

Әсәрдә әдәби методлар турында, яңа герой туу процессын яктыртуда кызыклы күзәтүләр бар. Жанрлар үсешендәге яңа тенденцияләр, шигырь техникасына карата күзәтүләр, Такташ чордашларының иҗатларына экскурсияләр укучыларның игътибарын җәлеп итә. Алар кызыклы һәм полемик пафос белән язылганнар. Билгеле, Гали Халит белән монда да бәхәсләшергә мөмкин, ләкин сүз ул турыда бармый.

Без Гали Халитның катлаулы иҗатына һәм күп санлы әсәрләренең һәркайсына тукталуны максат итеп куймадык. Бары тик бүгенге актив тәнкыйтьче һәм әдәбият белгеченең эшчәнлек биографиясенә беркадәр күз салырга тырыштык.

Проза, поэзия Гали Халитның стихиясе, ул анда үзен бик иркен тота. Театр, драматургия мәсьәләләренә ул бик сирәк килә (Г. Камал драмаларындагы характерлар турындагы хезмәтен искә алырга була), ләкин ул театрны да ярата. Г. Минский, Г. Халит һәм мин, өчәүләп, бер елны Мәскәүдә без бер-бер артлы С. Образцовның курчак театры спектакльләренә йөрдек. «Салам эшләпә», «Гадәттән тыш концерт» һ. б. постановкалардагы чын сәнгать үрнәкләрен, үткен сатира, кинаяләрне тирәннән аңлап, рәхәтләнеп көлеп утыручы Гали Халит иде. Гомумән, тормышта да ул җор сүзле, уен-көлкене күтәрә торган, шат табигатьле, киң күңелле бер кеше. Язучы һәм тәнкыйтьче проблемасы, белмим, хәл ителә торган нәрсәме, түгелме. Ләкин алар бер-берсен тынгысызлап торырга тиешләрдер. Бу зарури бер нәрсәдер. Ләкин тормышта тәнкыйтьче өстенә хаксыз әйтелгән сүзләр күбрәк ява. Әнә шундый вакытларда, ачуы кабарган Гали Халитка бер шаян сүз әйтсәң җитә, аның юмор, ирония кыллары хәрәкәткә килә башлый һәм аның йөзе яңадан шатлык белән балкый.

Гали Халит — үзенчәлекле талант. «Тәнкыйтьче таланты бик сирәк була торган талант ул», — дип язган В. Белинский. Аның карашынча, тәнкыйтьче талантында «тирән хис тә, сәнгатьне ялкынлы сөю дә, төрле яклап җентекләп өйрәнү дә, акылның объективлыгы да бар».

Бөек тәнкыйтьченең бу билгеләмәсе Гали Халит талантына туры килә дип әйтер идем мин. Талант ул иҗади процесс, ул һәр вакыт эштә, хәрәкәттә генә үзен чагылдыра ала. Гали Халит инде 40 ел диярлек әдәби хәрәкәтебезнең алгы сафында торып эшли һәм аның барышына тегә я бу күләмдә тәэсир итә. Аның тәнкыйть таланты җулап алынган теоретик белем нәтиҗәләре белән баий бара һәм иҗат практикасында үзенең яңа чагылышларын күрсәтеп килә.

Гали Халитка яңа иҗади уңышлар теләгәннән соң тагын бер теләк белдерәсе килә: безнең әдәбиятта әдәби тәнкыйть методы һәм методология проблемалары бөтенләй кул тимәгән килеш ята. Бу мәсьәләләр тирәсендә уйлансын иде ул һәм аның эрудициясе, таланты бу мәсьәләләрне хәл итә алыр, шулар турында язар дип ышанырга нигез бирә.

ГАЗИ КАШШАФ.

Җәмил Гыйльманов

# ЯКТАШЛАРЫБЫЗ ДОШМАН ТЫЛЫНДА

Фашист илбасарлар үзләренең мәкерле планнарында Советлар Союзы халыкларына коточкыч язмыш юрадылар. Аларның «Ост» планында СССР территориясенең Уралга кадәр булган киңлекләре немец милләтенең яшәү пространствосы булачак дип игълан ителә. Ә андагы халыкларны башка җиргә куып җибәрү яки кырып бетерү күздә тотыла. Бу планда рус милләтеннән булган кешеләрне юк итүгә аеруча зур игътибар бирелә. Безнең өчен, диелә анда, рус халкын Европада безгә немец дәүләте төзергә комачауламаслык итеп көчсезләндерү зарури.

Украина һәм Кырым, Кавказ һәм Идел буе, Балтик буе һәм Карелия немецлар ватаны дип аталырга тиеш була. Гитлер Идел буенда басып алыначак җирләрне герман империясенең бер өлкәсе итү турында хыяллана. Идел буе районнарының гауляйтеры итеп ул доктор Отто Шульманны билгели. Германия монополистлары илебезнең экономик байлыкларын кулга төшерү һәм талау буенча исәпсез-сансыз планнар коралар. «ИГ Фарбениндустри» концерны безнең химия предприятиеләребезгә алдан ук үзенең директорларын билгеләп куя. Шул җөмләдән Казан синтетик каучук заводына да директор билгеләнә.

Сугышның беренче көннәреннән үк гитлерчылар вакытлыча басып алынган совет җирләрендә үзләренең пычрак планнарын тормышка ашыра башладылар. Алар совет кешеләрен мөмкин кадәр күбрәк юк итәргә тырышты. Солдаттан алып генералга кадәр һәр гитлерчы, бернинди җаваплылык турында уйламастан, совет кешесен үзе теләгәнчә мәсхәрәләде, мыскыл итте.

Изге Ватан җирләре басып алынуга, фашистлар террорына җавап итеп, совет кешеләре дошман тылында илбасарларга каршы бөтенхалык көрәшенә күтәрелделәр. Алар оккупантларның барлык чараларына аяк чалдылар, алдан төзелгән планнарын өзделәр. Бу көрәш көннән-көн киңрәк колач җәя барды. Халыкның дошман тылындагы көрәшен бөек Коммунистлар партиясе оештырды. 1941 елның 29 июнь Директивасында ук инде СССР Халык Комиссарлар Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты фронтка якын өлкәләрнең партия һәм совет оешмаларына түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать иттеләр: «Дошман тарафыннан яулап алынган районнарда дошман армиясе частьларына каршы көрәшү, һәркайда һәм һәр җирдә партизан сугышлары кабызу, күперләрне, юлларны шартлату, телефон һәм телеграф элемтәсен бозу, складларны яндыру өчен партизан отрядлары төзергә...»

1941 елның 18 июлендә ВКП(б) Үзәк Комитеты «Герман гаскәрләре тылында көрәш оештыру турында» махсус карар кабул итә. Партия Үзәк Комитетының күрсәтмәләрен үтәп, дошман тылында алып барылган көрәш белән җитәкчелек итү өчен һәркайда яшерен партия оешмалары төзелә. Ифрат авыр шартларга карамастан, дошман басып алган территорияләрдә 1941 елда ук инде партиянең

яшерен 18 өлкә комитеты, 260 тан артыграк шәһәр, район комитетлары һәм күп санлы башлангыч оешмалары эшли башлый. Партиянең бу оешмаларында алтмыш биш мең биш йөз коммунист була. Бу патриотик көрәшнең төп формасы — партизаннар хәрәкәте. Партизаннар хәрәкәтенә якын икенче бер формасы шәһәрләрдә һәм авылларда легаль булмаган сугышчан группаларның эшчәнлегеннән гыйбарәт.

Партизаннар һәм яшерен оешмалар төрле шартларда эшлиләр. Шуңа күрә алар кулланган көрәш ысуллары да төрлечә. Ләкин тегеләре дә, болары да бер үк бурычны үтиләр: оккупантларны юк итәләр, диверсияләр оештыралар, халык арасында политик эш алып баралар, дошман турында белешмәләр җыялар һәм аны безнең командованиегә тапшырып торалар.

Сугышның беренче көннәрендә үк барлыкка килгән партизаннар хәрәкәте 1941 елның ахырына дошман тарафыннан яулап алынган барлык җирләргә тарала. Бу вакытта инде дошман тылында үз сафларында 90 мең кешене берләштергән ике меңнән артык партизан отрядлары хәрәкәт итә, күп санлы сугышчан яшерен группалар эшли. Тора-бара Ленинград, Псков, Калинин, Смоленск, Орел һәм РСФСРның башка өлкәләрендә, Украинада, Белоруссиядә партизаннар хәрәкәт иткән тоташ зоналар барлыкка килә. 1941 елның көзендә һәм 1941—1942 елның кышында Брянск партизаннары илбасарлардан 500 ләп торак пунктны азат итәләр һәм озынлыгы төньяктан көньякка 260, көнчыгыштан көнбатышка 40—50 километрга сузылган зона булдыралар. Болар дошман вакытлыча басып алган территорияләрдә Совет власте «оазислары» булып саналалар. Анда партизаннар көч туплыйлар, чираттагы рейдларга хәзерләнәләр, яңа резервларны өйрәтәләр, дошман әсирлегеннән качып чыгучыларны кабул итәләр. Партизаннар карамагындагы мондый зоналарда аэродромнар төзелә, алар «Зур җир» белән даими элемтәдә торалар. Сугыш елларында безнең очучыларыбыз партизаннарга ярдәм күрсәтү максатында дошман тылына 109 мең очыш ясыйлар.

1941—1942 елның кышында партизаннар 224 поездны сафтан чыгаралар, 600 чамасы күперне шартлаталар, дошманның 1850 автомашинасын, күп санлы техникасын һәм кешеләрен юк итәләр. Аларга каршы көрәшү өчен гитлерчылар 22 дивизия җибәрергә мәҗбүр булалар.

Фашистлар командованиесе тарафыннан махсус әзерләнгән белешмәдә Көнчыгыш фронттагы партизаннар сугышы турында мондый юллар бар: «Партизаннар сугышта куркусызлар, җитезләр, көтмәгәндә һөҗүм итәләр. Отрядлар урыннарын әледән-әле алыштырып торалар, һәр вакыт көчле сак куялар, төннәрендә дә коралларын әзер тоталар...»

Рус, украин, белорус һәм башка халыкларның вәкилләре белән бер сафта дошман тылында Татарстан уллары һәм кызлары да иңгә-иң торып көрәштеләр. Татарстаннан партизаннар хәрәкәтендә катнашучыларның төп массасын, дошман чолганышында калып, үзебезнекеләр ягына чыга алмаган сугышчылар тәшкил итә. Аларның күбесе партизан отрядларына хәрби үлем лагерьларыннан качып котылганнан соң килеп кушыла, ә бер өлеше дошман тылына партизаннар хәрәкәте оештыруга булышу, разведка һәм диверсия алып бару өчен махсус җибәрелгән кешеләр була.

Смоленск тирәләрендә партизаннарның шактый зур көчләре дошманга каршы көрәш алып баралар. Алар арасында Татарстанның 200 дән артык вәкиле, шул исәптән 18 нче укчы дивизиянең чолганыштан чыга алмаган сугышчылары була. Смоленск төбәгендәге Черчиковск яшерен группасы белән 18 нче укчы дивизия составындагы 97 нче укчы полкның элекке командиры майор Бари Кадермәтов җитәкчелек итә. 1942 елның 19 февралендә Кадермәтов яшеренгән Крестовка авылына көтмәгәндә полиция килеп төшә. Барлык ирләрне авыл уртасындагы мәйданга куып китерәләр. Немец офицеры яшерен оешманың җитәкчесен тотып бирүне сорый. Беркем бер авыз сүз дәшми. Котырынган гитлерчы авылны яндырырга әмер бирә. Хатын-кызлар, балалар елаша башлыйлар. Шул чагында халык арасыннан Кадермәтов үзе килеп чыга һәм горур карап палачка эндәшә:

— Гаепсез кешеләргә кагылмагыз! Кудров мин булам.

Эсэсчылар аны тотып алалар һәм Монастырщинский төрмәсендә җәзалап үтерәләр.

Смоленск районында партизаннарның «Саша» дип аталган отряды оеша. Аның җитәкчесе Әхнәф Бикбаев, штаб начальнигы Хазат Садров икесе дә 18 нче укчы дивизия подразделениеләренең элекке командирлары була. Отряд партизаннары 1942 елның декабреннан 1943 елның сентябренә кадәр вакыт эчендә генә дә дошманның 33 эшелонын һәм 1 500 гитлерчыны юк итәләр. 1943 елның сентябрендә отряд Совет Армиясе частьларына килеп кушыла.

Смоленск тирәләрендә оешкан партизан отрядларының берсенә сугышка чаклы Казанда аспирантурада укыган Назар Бирюков командалык итә. Смоленск партия оешмасы архивы фондларында саклана торган характеристикада Назар Бирюковның 1942 елның февраленнән 1943 елның сентябренә кадәр партизаннарның биш отрядын оештыруы турында әйтелә. 1942 елның 5 августында уздырылган бер операция вакытында гына да ул үзенең отряды белән немецларның корал һәм азык-төлек төягән 400 олавын юк итә. Бу эшне башкарганда 25 ләп фашист үтерелә. Назар Бирюков 78 кешелек отрядны безнең якка алып чыга һәм Кызыл Армия частьларына китереп куша.

«Батя» дип исемләнгән Бишенче Смоленск берләшмәсе партизаннары куркусыз разведчик Мәгъдәнур Гыйльфановның исемен телләреннән төшермиләр. Партизаннардан беренче буларак ул Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

«РККАның 24 еллыгы» дип аталган һәм Смоленск тирәләрендә ике ел буе хәрәкәт иткән партизан полкының комиссары Гаян Әмиров була. Полк, гитлерчыларны тар-мар итеп, Смоленск өлкәсендәге 16 авыл Советы территориясендә яңадан Совет власте һәм колхозлар оештыра.

Безнең якташларыбыз Белоруссия партизаннары арасында да күп була. Революцион бәйрәмнәр уңае белән республикабыз хезмәт ияләре партизаннарга котлаулар, бүләкләр җибәрәләр. 1943 елда, Яңа ел уңае белән, мәсәлән, Белоруссия партизаннарына Татарстаннан 15 мең аптечка җибәрелә. Татарстан хезмәт ияләренең кайгыртучанлыгына җавап итеп, Белоруссия партизаннары җитәкчеләре 1942 елның ноябренда менә мондый хат язып салалар: «Хөрмәтле иптәшләр! Татар халкының безгә җибәргән бүләкләрен алдык. Белоруссия партизаннары исеменнән ихлас рәхмәтебезне белдерәбез. Сезнең бүләкләрегез Советлар Союзында яшәүче аерым милләтләрнең бер-берләренә карата булган чиксез мәхәббәтен һәм какшамас дуслыгын чагылдыра... Совет Татарстанының данлы уллары немец илбасарларына каршы безнең белән бергә көрәшүләренә без чиксез шатбыз». Хат ахырында якташларыбызның батырлыклары турында сөйләнә.

Партиянең Покровск райкомы секретаре җитәкчелегендә Орша янында хәрәкәт иткән партизан отряды члены — Чүпрәле районының Иске Чокалы авылы колхозчысы Сөләйман Хәлиуллов дошман тылында диверсия эшләре алып бара, уннарча гитлерчыны дөмектерә. Элеккеге Биләр районында туып-үскән партизан — снайпер Гатаулла Үләнгов Белоруссиядәге партизан отрядларының берсендә була һәм снайпер мылтыгыннан атып 83 фашистны «теге дөнья»га озата. Моның өчен ул хөкүмәтебез тарафыннан Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Бөгелмә егете Борис Пахомов 1941 елның ахырында, 1942 елның язында Гродно шәһәре янында партизаннар отрядында сугыша һәм Иодичи хуторында батырларча һәлак була.

Чистай урта мәктәбен тәмамлаган комсомолка Р. Заһирова 1941 елның октябренда, үзен фронтка җибәрүләрен сорап, ВЛКСМ Үзәк Комитетына гариза яза. Ул Көнбатыш фронт штабындагы махсус партизан частенда хезмәт итә, Белоруссия территориясендәге партизаннар белән бер үк сафларда торып сугыша.

Минск шәһәреннән ерак түгел урнашкан Рудна районындагы партизаннарга Салих Хафизов килеп кушыла. Сугышчан дусты М. Д. Орловның истәлекләренә караганда, беренче операция вакытында ук алар, партизаннар группасы белән берлектә, биш полицайны юк итәләр, отряд өчен азык-төлек табып кайталар. Бу группа соңыннан 800 дән артык кешене берләштергән «Знамя» отряды булып үсә. Салих Хафизов бик күп батырлыклар күрсәтә. Минск өлкәсенең Червенск районында уздырылган бер операция вакытында ул батырларча һәлак була.

Татарстанлылар Украина җирендә дә күп була.

1941 елның октябрь аенда дошман тылына Куйбышев районының Никольское авылында туып-үскән политрук Петр Васильевич Васильев җибәрелә. Аңа Сумск өлкәсендә партизаннар хәрәкәте оештыру бурычы йөкләнә. Васильев 19 урында оборона группалары оештыруга ирешә. Ул группалар соңыннан партизан отрядлары булып үсәләр. Васильев партизаннар группасының командиры, аннан В. И. Ленин исемендәге отрядның комиссары, ахырдан Ковпак берләшмәсе составындагы Дзержинский исемендәге бригаданың комиссары була. Ул Сумск, Орел, Курск өлкәләрендә сугыша һәм үз кулы белән 35 гитлерчыны юк итә. Дзержинский исемендәге бригада 1943 елның мартында Кызыл Армиянең һөҗүм итеп баручы частьлары белән кушыла.

Партизаннар хәрәкәте торган саен максатлырак була бара. 1942 елның 30 маенда Дәүләт Оборона Комитеты Верховный Башкомандующий ставкасы каршында партизаннар хәрәкәтенең Үзәк штабын төзегәч, партизан отрядларының регуляр частьлар белән берлектә хәрәкәт итүләре тагын да яхшыра. Үзәк штабның Башкомандующие итеп маршал К. Е. Ворошилов, штаб начальнигы итеп П. К. Пономаренко билгеләнә. Фронт Хәрби советлары каршында да партизаннар хәрәкәте штаблары булдырыла.

1942 елның август ахырында Үзәк штаб Брянск өлкәсендә хәрәкәт иткән партизан отрядлары командирлары һәм комиссарларының киңәшмәсен җыя. Киңәшмә партизаннар хәрәкәтенең тәҗрибәсен уртаклаша, аның белән җитәкчелек итүдә булган кимчелекләрне ача, алда торган бурычларны билгели. Киңәшмәдә катнашучылар партия һәм дәүләт җитәкчеләре белән очрашалар. Киңәшмәнең эшенә йомгак ясап, «Правда» газетасы үзенең 1942 елгы 4 ноябрь санында баш мәкалә урнаштыра.

Партизаннар хәрәкәте көннән-көн киңрәк колач җәя. 1942 елның ахырында һәм 1943 елның башында партизаннар сафында 120 меңнән артык патриот сугышса, 1943 ел ахырына аларның саны 250 меңгә җитә. 1943 елның җәендә дошман тылындагы 200 мең квадрат километр җир совет партизаннары контрольлегендә була.

1943 ел эчендә партизаннар һәм яшерен оешма членнары дошман поездларын, гарнизоннарын, штабларын 1942 елга караганда 5 тапкыр, аның җанлы көчен 4 тапкыр күбрәк юк итәләр.

Дошман командованиесе 1942 елның җәеннән башлап совет-герман фронтындагы үзенең 10 процент көчен партизаннарга каршы сугышу өчен тота.

1943—1944 елларда да безнең якташларыбыз халык үч алучылары сафларында көрәшүләрен дәвам итәләр. Чистай районының Татар Ялтаны авылы егете Әхмәт Ситдиков башта икенче махсус партизаннар бригадасының җимерү эшләре алып бару группасы командиры була, аннан соң 3 нче партизаннар бригадасы составында Ленинград янында сугыша. 1942—1943 елның кышында бригада Псков өлкәсенең Порховск районында хәрәкәт итә. Әхмәт Ситдиков һәр вакыт иң хәвефле бурычларны үти. Партизаннар отрядында күрсәткән батырлыклары өчен ул өч тапкыр сугышчан орден белән бүләкләнә. 1943 елның башында 3 нче бригаданың партизаннар полкы командиры итеп билгеләнә. Шул ук елның 8 февраль төнендә ул командалык иткән полк дошманның бер станциядәге гарнизонын тар-мар итә, Подсевы-Славковичи юлындагы таш күперне һәм Узу елгасы аша салынган тимер юл күперен шартлата. 23 февраль төнендә исә җәзалаучылар отрядын юк итә.

1943 елның июнендә бригада авыр сугышлар алып бара. Җәзалаучы башкисәрләр белән ул 44 тапкыр бугазга-бугаз килә. Шундый тартышларның берсендә куркусыз партизан, полк командиры Әхмәт Ситдиков батырларча һәлак була.

Калинин фронтының разведка бүлеге каршындагы җимерү эшләре алып баручы группада казанлы Михаил Иванович Платонов хезмәт итә. 1943 елның маенда группага Березовка авылыннан төньяктарак үтүче тимер юлны сафтан чыгару бурычы йөкләнә. Дошманның җанлы көчләре, кораллары төялгән унбер эшелоны юк ителә. Фашистлар җәза отряды чакыралар. Аларның штаблары Березовкада урнашкан була. Группаны төрле яктан кысрыклый башлыйлар. Шундый кыен хәлдә калган разведчиклар кыю операция ясыйлар: төн уртасында фашист сакчысын үтереп, алты почмаклы өй янында торган җиңел машинаны бер

як читкә тәгәрәтәләр. Берникадәр вакыттан партизаннар тәялгән машина юлга чыга. Фашистлар тревога күтәрәләр, ләкин инде соң була. Разведчиклар группасы уннарча километрларга сузылган урманлы районга күчеп өлгерәләр.

«Үч алучы» дип аталган партизаннар отрядында безнең якташыбыз коммунист Әсгат Зәкиев дошманга каршы көрәш алып бара. Отрядның исән калган командиры Иван Федотович Елецких һәм партизан Альгирдас Гловацкас аның кыю, җитез партизан булуы турында сөйлиләр. Әсгат дошман эшелоннарын һәм дистәләрчә гитлерчыны юк итә.

Константин Заслоновның Орша янында хәрәкәт иткән «Победа» отряды составында татар шагыйре Зәки Нури разведка начальнигы булып сугыша. Сугышчан батырлыклары өчен ул Ватан Сугышы ордены белән бүләкләнә. Шәһәрне азат иткәннән соң Белоруссия партизаннары штабы аны Орша шәһәр советы башкарма комитеты председателе урынбасары итеп билгели. Татарстанга 1946 елда кайта.

Белоруссиядә Советлар Союзы Герое В. М. Неклюдов җитәкчелек иткән «Боевой» партизаннар отрядында Таһир Моратов, Шәймәрдән Бәдретдинов һәм башкалар сокланырлык батырлык үрнәкләре күрсәтәләр.

Сабуров, Ковпак, Федоров командалыгында Брянск урманнарында дошман тылына зур-зур рейдлар ясаган берләшмәләрдә дә безнең бик күп якташларыбыз булган. Николай Орлов (Гатаулла Минаев) үзенең партизанлык биографиясен Сабуров берләшмәсенең «Ватан өчен» отрядында башлаган. 1943 елның язында Гатаулла Минаев шартлатучы-диверсантлар группасының командиры итеп билгеләнә. Тимер юлларда гөрселдәү авазлары әледән-әле ишетелә башлый. Орлов-Минаев группасы Курск дугасындагы сугышлар вакытында аеруча актив эш алып бара. 1943 елның 15 июлендә бер сәгать эчендә Лукинец-Сарны тимер юлының өч километр буены тулысынча җимерелә: рельслар, күперләр шартлатыла, элемтә линияләре юкка чыгарыла. «Диверсияләр патшасы» — яшерен оешма секретаре В. А. Бегма Орлов-Минаев турында әнә шулай дип язды. Орлов-Минаев группасы ике ел вакыт эчендә дошманга искиткеч зур зыян китерә: шоссе һәм таш юлларда 27 күпер, 4 тимер юл күпере шартлатыла, 23 танк һәм бронемашина, 20 орудие, 35 паровоз, 350 вагон һәм платформа, күп санлы элемтә әйберләре һәм башка техника сафтан чыгарыла, мең ярым чамасы илбасар «теге дөньяга» озатыла һәм яралана. Актаныш районының Зөбәер авылында туып үскән Гатаулла Минаевка Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Бәйрәмгали Хәлиуллин оккупантларга каршы А. Федоров берләшмәсенең Клим Ворошилов исемендәге отрядында сугыша. Отрядта ул диверсияләр буенча танылган белгеч булып җитешә. 1943 елның җәендә — Курск дугасында сугышның иң кызган чорында — үзенең группасы белән ул гитлерчыларның сугыш техникасы һәм солдатлары төялгән 53 эшелонын мәтәлдерә. Бу хакта фашистлар газеталарында болай дип язалар: «Ковель районында партизаннар хәрәкәт итми. Гади рус Иваннары мондый хәрби хәйләгә сәләтле түгел. Анда махсус хәзерләнеп, Мәскәүдән җибәрелгән диверсантлар эш итәләр».

Бәйрәмгали Хәлиуллин отрядта штаб начальнигы, аннан партизан отряды командиры булып хезмәт итә. Батырлыгы өчен Сугышчан Кызыл Байрак һәм Ленин орденнары белән бүләкләнә.

Григорий Спиридонов дошманнан А. Федоров берләшмәсендә үч ала. 1942 елның җәендә Егор Быков отделениесе составында ул полицайларны һәм ашлык урырга чыккан сатлык җаннарны юк итүгә катнаша. Партизаннар ике йөздән артык олау кулга төшерәләр. Г. Спиридонов берүзе дошманның өч эшелонын юк итә. 1943 елның җәендә, Курск дугасында сугышлар башланыр алдыннан, җәзалаучы башкисәрләргә каршы аяусыз көрәш алып барыла. Партизаннар отделениесе командиры Егор Быков сөйләвенчә, июнь башында отряд Восточная Заря поселогы районында дошман засадасына юлыга.

— Барыгызга да урманга чигенергә! — дип әмер бирә комиссар Семенов.— Быков отделениесенә чигенүчеләрне каплап торырга!

Отделение көчле ут ача. Гриша Спиридонов берүзе унлап гитлерчыны юк итә. Ләкин көч ягыннан үзләренең өстенлекләрен сизгән бер төркем фашистлар, исән килеш кулга алырга теләп, Гришага ташланалар. Шунда ул аягүрә торып баса һәм

тагын дистэгэ якын гитлерчыны җиргә ега. Зәһәрләнгән башкисәрләр геройны атып үтерәләр. Группада исән калганнар Мамаев урманына кереп яшеренәләр.

Федоров берләшмәсенең 4 нче Клетнянск бригадасы взводы командиры ярдәмчесе М. Рогожев 1943 елның гыйнварында Жудилово станциясенә урнашкан дошман гарнизонын тар-мар иткәндә пулеметчы-партизан Фазылның зур батырлык күрсәтүен искә алып сөйли. Пулеметын тоткан хәлдә аягүрә басып, ул, ут ача-ача, алга ыргыла. Аннан соң гитлерчылар атып яткан йортка ике граната ыргыта. Ул ыргыткан гранаталар фашистларның ут ноктасын тончыктыра. Ләкин Фазыл үзе дә авыр яралана. Аны самолет белән Мәскәүгә озаталар.

А. Федоров берләшмәсендә безнең тагын бер якташыбыз — Нигъмәт Махановның батырлыгы белән дан ала. Сугышның беренче көннәрендә үк инде ул Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. 1942 елның маенда авыр яраланган хәлдә немецларга әсир төшә. Лагерьдан партизаннарга кача. Октябрь аенда разведчик итеп билгеләнә һәм бер үк вакытта фельдшерлык вазифаларын да үти.

Төрле партизан отрядларында безнең якташларыбыз Михаил Атналов, Майра Бәхтиярова, Габдрахман Баев, Сергей Быстров, Петр Белозеров, Х. Садриев һәм башкалар зур батырлыклар күрсәтеп сугышалар.

Партизаннар белән элемтә тотуда, аларга ярдәм итүдә катнашучыларның тырышлыклары да игътибарга лаек. Фронт санитар авиациясе очучысы Зәкәрия Нохов төнге ике очыш вакытында Витебск урманыннан партизаннар отрядын эзләп таба һәм аларга ярдәм күрсәтү өчен соңыннан 150 очыш ясый, партизаннарга радиостанция, корал, азык-төлек алып килә, уннарча яралыларны «Зур җиргә» алып чыга.

Татарстан уллары һәм кызларының исемнәре яшерен оешмаларда героик көрәш алып баручылар арасында да очрый. Яшерен оешмалар шәһәрләрдә, тимер юл станцияләрендә, предприятиеләрдә — дошманга зыян китерергә мөмкин булган һәр урында төзелә. Аларның нигезен дошман тылында легаль булмаган эш алып бару өчен калдырылган партия оешмалары, партия һәм комсомол группалары тәшкил итә. Ул оешмалар һәм группалар тирәсенә партиясез совет патриотлары туплана.

Фашистлар тарафыннан басып алынган Днепропетровск шәһәрендә антифашистик эшне татар халкы вәкилләреннән укытучы Фатыйма Гафурова һәм агач эшкәртү предприятиесе эшчесе Мәхмүт Калинкин алып баралар. Яшерен оешма членнары буларак, аларның заданиеләре буенча патриотлар лагерьлардан совет әсирләрен качыруны оештыралар, диверсияләр алып баралар, предприятиеләрдә саботажлык эшләре ясыйлар, партизаннарны корал һәм медикаментлар белән тәэмин итәләр, Совет информбюросы сводкаларын тараталар, листовкалар ябыштыралар. Бер төн эчендә, мәсәлән, шәһәрдә алар тарафыннан өч йөздән артык рәсемле плакат ябыштырыла. Рәсемнәр астына гитлерчыларны мыскыллаган текстлар языла.

1942 елның июлендә гестапочылар яшерен оешмада эш алып баргannarы өчен Ф. Гафурова һәм М. Калинкинны кулга алалар. 2 августта атарга алып барганда Фатыйма, машина кузовы уртасына басып: «Башларыгызны имәгез! Әйдәгез җырлыйбыз!» — дип кычкыра һәм «Интернационал»ны җырлый башлый.

Совет Армиясе лейтенанты Иван Константинович Кабушкин сугышны СССРның көнбатыш чигендә каршылый. Чолганышта кала, әсир төшә, аннан кача. Һәм ниһаять, ул Минскида. Монда ул Минск шәһәр яшерен оешмасы членнары — Исай Казинец, Дмитрий Короткевич, Константин Хмелевский һәм башкалар белән очрашуга ирешә. Яшерен оешма членнары Кабушкинга ышаныч белдерәләр, аны сатлык җаннарны табу һәм юк итү бүлеге җитәкчесе итеп куялар. Кабушкин биредә Жан исеме белән йөри. Ул шәһәрнең географиясен: ишегалларын, шәһәр читендәге бистәләрне, җимерек подвалларны ныклап өйрәнә. Боларның барысы да кирәк минутта куркынычсыз урынга яшеренү өчен кирәк була. Кабушкин үзен оста оештыручы итеп таныта. Озакламый ул партия шәһәр комитеты яшерен оешмасының оператив группасы начальнигы итеп билгеләнә.

Партия шәһәр комитеты утырышлары гадәттә Исай Казинец квартирасында уздырыла. Ул утырышларда чираттагы диверсияләр турында фикер алышалар,

таратылырга тиешле яшерен листовкаларны тикшерәләр, «Звезда» газетасы өчен мәкаләләр әзерлиләр. Иң куркыныч, иң хәтәр операцияләр Жанга тапшырыла. Ул аларны искиткеч осталык белән башкарып чыга. Үзенең ударларын Жан иң беренче чиратта гестапочыларга, башкисәрләргә каршы юнәлтә. Аларны аяусыз әзәрлекли, кичке сәгатьләрдә нинди урыннарда булуларын ачыклый. Кабушкин үз кулы белән 13 гитлерчы чиновник һәм офицерны юк итә. Бер үк вакытта ул дошманның машиналары күп йөри торган Могилев шоссесында да диверсияләр оештыра.

Фашистлар Жанны озак эзәрлеклиләр. Бер сатлык җан аның буй-сынын, төс-битен, барлык сыйфатларын хәбәр итә. Шәһәр буенча белдерүләр ябыштырыла. Жанны тотып бирүчегә зур сумма вәгъдә ителә. 1942 елның маенда яшерен оешманың күп кенә җитәкчеләре — И. Казинец, Д. Короткевич, К. Хмелевский һәм башкалар кулга алына. Гитлерчылар оешма җитәкчесез калды дип уйлыйлар. Ләкин шул вакыт Минск төрмәсе капкаларында типографиядә басылган листовкалар күренә. «Яшерен оешма яши һәм көрәшә» диелә ул листовкаларда. Аларны Жан ябыштырган була.

Ниһаять, фашистлар аны тотып алалар, кеше ышанмаслык ысуллар белән җәзалыйлар. Ләкин Кабушкин барысына да түзә, иптәшләре турында палачларга бер сүз дә әйтми. Җәзалап үтереләсе төндә аңа иреккә хат кисәге тапшырырга насыйп була. Анда болай диелә: «...Үлсәм үләм, әмма кабахәт җан булачак түгелмен... Алар бернинди яңалык ала алмадылар... Бер генә кешене дә сатмадым. Ә миңа каршы шактый зур материал тупланган... Мин нишләргә тиеш идем соң? Мин үземнең бөтен тормышымны прогрессив кешелекнең, халык һәм Ватанның бәхете өчен багышларга карар кылдым».

Минск урамнарының берсенә Кабушкин исеме бирелгән.

Язучы С. С. Смирновның эзләнү һәм тикшеренүләре нәтиҗәсендә Сещинск һәм Брянск яшерен оешмаларының сугышчан эшләре бөтен илгә билгеле булды. Фашистларның хәрби аэродромында эшләүче поляк патриотлары белән берлектә, бу яшерен оешмаларның члennары самолетларга магнитлы миналар куялар. Ул миналар я аэродромда ук, яисә очыш вакытында шартлыйлар. Шул юл белән дошманның уннарча самолеты шартлатыла. Курск сугышы вакытында гына да гитлерчылар авиациясенең полктан артык самолеты юк ителә. Сещинск яшерен оешмасында эш алып баручылар арасында Абделхак Аглиуллин исеме дә бар.

Безнең якташлар шулай ук Кырымдагы яшерен оешмалар эшендә дә актив катнашалар. 1942 елның октябрендә Тимершаех Гайнанов үзенең дүрт иптәше белән Кырымга, Зуйсктан ерак булмаган урманга самолетта очып төшә. Бу группа кыска гына вакыт эчендә Воинка авылында 12 кешедән торган патриотик оешма, якын-тирә авылларда яшерен эш алып баручы группалар төзүгә, Симферопольдәге яшерен оешма белән элемтәгә керүгә ирешә. Гайнанов Зуйск урманнарындагы группалар һәм яшерен оешмалар җитәкчеләре арасында элемтәче вазифасын үти, шартлаткычлар эзләп таба, разведка материаллары җыя. Гайнанов тапкан миналарны шартлатып, Джанкой янында немецларның хәрби составы күккә очырыла. Ул тапшырган мәгълүматлар нигезендә совет самолетлары дошман аэродромын бомбага тоталар. Тимершаех Гайнанов һөҗүм итеп килүче совет гаскәрләре өчен Симферополь картасын әзерләүгә катнаша. Гитлерчылар тарафыннан Кырымга китерелгән чех дивизиясендәге антифашист солдатларны партизан отрядларына озата. Зур куркыныч якынлашуын хәбәр итеп, Кырым яшерен оешмасы җитәкчесе И. Козловның һәм башкаларның тормышын саклап кала. Арыслан йөрәкле, салкын канлы, ифрат түземле бу кеше катлаулы һәм куркыныч хәлләрдән күп тапкырлар исән-имин котыла.

Симферополь яшерен оешмасының бер группасы белән Татарстан сәнгать техникумында тәрбияләнгән, җирле драма театры рәссаме коммунист Николай Андреевич Барышев җитәкчелек итә. Ул җитәкчелек иткән группа эшенә безнең тагын бер якташыбыз, Казандагы театр студиясе артисты Д. К. Добросмыслов та катнаша.

Симферополь яшерен оешмасы члены Е. Л. Лазарева бу группаның эшчәнлеге турында менә нәрсәләр сөйли: «Бу патриотик группа куркусыз, дисциплина-

лы, мена дигән оештыручы, үз һөнәренә гашыйк әйбәт рәссам Н. А. Барышев тарафыннан төзелде... Группа членнары листовкалар, Совет информбюросы сводкаларын, совет газеталарын тараттылар... Хәрби әсирләр белән элемтә тоттылар, аларга өс һәм аяк киемнәре, ашамлыклар табып китерделәр. Барышев театр студиясе оештырды. Студиячеләр хәйләсе астында анда группаның яшь членнары эш алып барды».

Бу студия тагын икенче бер вазифаны да үти. Совет яшьләрен күпләп-күпләп Германиягә куу башлангач, студия үзенә «яшь талантлар» туплый башлый. Бервакыт «имтихан»да кызыклы хәл булып ала. Комиссия өстәле янына яшь кенә бер үсмер килеп баса. Бактың исә, ул шигырь дә сөйли белми, көй дә чыгара белми икән. Шунда жюри аңа нинди дә булса берәр җыр җырларга куша. Үсмер егет бераз уйлап тора да «Интернационал»ны җырлап җибәрә. Имтихан алучы совет патриотлары аңа рәхмәт әйтәләр һәм студиягә кабул итәләр. Шул рәвешле патриотлар яшьләрнең күпмедер өлешен Германиягә куылудан коткарып калалар.

Симферополь яшерен партия оешмасы секретаре И. Козлов болай дип искә ала: «Аңлашыла ки, Кызыл Армиянең Кырымга һөҗүме активлашкан моментта немецлар, һичшиксез, театрны юк итәргә, артистларны һәм аларның әйберләрен алып китәргә тырышачаклар иде. Партиянең шәһәр комитеты яшерен оешмасы Барышев һәм аның группасы алдына өч төрле бурыч — театрны таркатуга юл куймау, артистларны Германиягә куып алып китүдән саклап калу, аларның әйберләрен яшерү бурычларын куйды. Группа бу бурычларны уңышлы үтәде».

Барышев группасы яшерен оешма куйган тагын икенче бер зур һәм җаваплы бурычны үти: немецларның барлык хәрби объектларын, миналар куелган йортларны күрсәтеп, шәһәрнең картасын төзи. Мондый картаның һөҗүм итеп килүче Кызыл Армия командованиесенә һәм партизан отрядлары штабына кирәклеге көн кебек ачык. Группа членнары шәһәрне районнарга бүләләр һәм чын мәгънәсендә һәрбер йортны тикшереп чыгалар, немецларның хәрби объектларын күзәтәләр. Җыелган мәгълүматлар нигезендә әлеге карта эшләнә һәм «Зур җир»гә җибәрелә.

1944 елның март урталарында гестапочылар куркусыз Барышевны, аның иптәшләрен кулга алалар һәм, илбасарларны Симферопольдән куып чыгарырга өч көн калгач, барысын да атып үтерәләр.

Еш кына очракларда яшерен оешмалар һәм сугышчан группалар, совет гаскәрләре якынлашып килгәндә, партизан отрядлары булып әвереләләр. Моңа мисал итеп Минһаҗ Тимеров группасын алырга була. Сугышчан бурычын үтәгән вакытта немецлар Минһаҗ Тимеровның самолетын бәреп төшерәләр. Очучы Украинадагы Захарино авылына яшеренә. Монда ул яшерен оешма төзи. Оешма Германиягә икмәк чыгаруга, ашлык сугуга каршы яшерен эш алып бара, авыл хуҗалыгы машиналарын сафтан чыгара. Оешма членнары телефон линияләрен бозалар, автомашиналарның шиннарын тишәләр.

1943 елның ноябрендә, совет гаскәрләре Днепрны кичкәндә, Тимеровның йөз кешелек отряды партизаннар ысулы белән эш итүгә күчә: бу районда оборона тоткан гитлерчыларга һөҗүм итә. Каушап калган дошман качарга мәҗбүр була. Захарино баш күтәргән авыл халкы тарафыннан азат ителә. Икенче көнне авылга совет гаскәрләре керә.

Сугыш елларында дошман басып алган территорияләрдә илебез партизаннары һәм яшерен оешма членнары миллион ярым немец офицерын һәм солдатын, аларга хезмәткә ялланган сатлык җаннарны юк итәләр. Дошманга китерелгән бу зыянда Татарстан уллары һәм кызларының да зур өлеше бар. Дошман тылында партизан отрядлары һәм яшерен оешмалар алып барган көрәш зур мораль-политик һәм хәрби-стратегик әһәмияткә ия булып тора. Европада икенче фронт ачылмаган шартларда партизаннар хәрәкәте фашист илбасарларга каршы көрәштә чын мәгънәсендә икенче фронт ролен үтәде.

# ХАТЛАРЫ КИЛӘ, ҮЗЛӘРЕ КАЙТА...

### ИСТӘЛЕКЛӘР ДӘФТӘРЕННӘН

Яшьлегемә кире кайтып, «Кызыл Татарстан» газетасының сугыш елларында чыккан саннарын карап утырам. Ерак үткәннәрне күз алдыннан кичерәм.

Сугыш язучыларны, журналистларны берәм-берәм ала тора. Редакциядә эшләүчеләр бармак белән генә санарлык. Бәләкәй коллектив Матбугат йортының әле уң канатына, әле сул санатына күчеп эшли. Зәһәр суыклар башлангач, батареялар туңып шартлый, тәрәзәләр бозланып ката, бүлмәләрдә утырып эшләү әмәле калмый. Типографиягә, хәреф кассалары арасына күчәбез. Әмма машиналар гүләгән шау-шулы җирдә озак утырырга туры килми. Әлеге салкын бүлмәләрнең берсенә тимер мич куябыз да иске өстәл-урындыклар ягып көн күрәбез. Бер өстәлдә ике-өч кеше. Хәер, өстәл артында озак утырып эшләргә вакыт та юк. Гел йөреп торырга, шәһәрдәге завод-фабрикаларга барырга, авыл районнарына чыгарга кирәк.

Менә шундый шартларда газета эшләнә. Әмма материалларга аптырау юк. Көн биргәнгә — юнь бирә дигәндәй, берничә генә кеше, тылдагы һәм фронттагы каләмдәшләр ярдәмендә, газетаны чыгарып килә. Иң актив катнашучылар — язучылар. Сан саен яки сан аралаш диярлек аларның ялкынлы чыгышлары басыла. Гомәр Бәширов, Кави Нәҗми, Мирсәй Әмир, Шәйхи Маннур, Әхмәт Фәйзи, Әхмәт Ерикәй һәм башкаларның исемнәре газета битләрендә аеруча еш күренә. Сугышның беренче елларында Төньяк-көнбатыш фронтыннан политрук Муса Җәлил язып тора. Аның «Яз», «Күпер», «Эз» дигән һәм башка шигырьләре басыла. Ә Фатих Хөсни, Әхмәт Исхак, Газиз Иделле, Гариф Галиев, Абдулла Әхмәт сугышның төрле вакытларында редакциядә эшлиләр. Бер эштән дә йөз чөермиләр. Кайчагында кечкенә генә хәбәрләргә дә зур исемнәрен куеп чыгаралар. Фатих Хөснинең «Яшәү даны» дигән язмалары, күңелләрне күтәреп җибәргән «Карлыгач»лары, Газиз Иделленең Казан предприятиеләреннән язган зур-зур мәкаләләре, аннары немец оккупантлардан азат ителгән Донбасстан җибәргән хатлары, Абдулла Әхмәтнең республикабызның төрле районнарыннан, ә соңыннан фронттан юллаган очерклары әле дә хәтердә.

Ул чагында фронттан язучы яки журналист кайтамы, берәрсеннән шигырь яки очерк киләме — редакциядә зур вакыйга. Иптәшләрнең исән-сау булуларына, газетага яңа материал килүенә куанабыз.

Бервакыт Фатих Кәрим яраланып кайткан, Казан госпитальләренең берсендә ята икән, дигән хәбәр ишетелә. Нәкъ шул көннәрдә без аның фронттан җибәреп, газетада басылып чыккан шигырьләрен яттан кабатлап йөри идек.

...Каһәрле дошманга төзәп
Мин мылтык аткан чакта,
Гүя син патроннар салып
Торасың минем катта...
Ә шулай да син еракта.
Мин тик хатыңны күрәм.
Хатка язган сүзләреңне
Күзләрең итеп үбәм.

*(«Син еракта», 8 декабрь, 1942 ел.)*

Редактор Ибраһим абый Үзбеков Фатыйма Сәгъдиева белән икебезне чакырып ала да:

— Госпитальгә барып Фатихның хәлен белегез, яңа газеталар илтегез үзенә, язган берәр нәрсәсе булса алып кайтыгыз,— ди.

Ленин районындагы госпитальдә ята иде ул. Каршыбызга елмаеп килеп чыкты. Калын кара кашлары тоташкандай күренә.

— Болай булгач әйбәт инде, без әле кузгалмый ятасыздыр, дип борчылган идек.

— Монда тиз торгызалар. Озакламый фронтка юл тотачакбыз.

Моңа кадәр аңардан редакциягә гел хатлар, шигырьләр килеп тора иде. Газетада басылып чыккан «Ватаным өчен», «Кошлар», «Кала яшьлек», «Хәнҗәр», «Һөҗүм», «Немец җирендә» дигән шигырьләре күңелгә сеңеп калган. Шунысы хәтеремдә, бер хатында аның «Бүген урман аша уздык... үз кулларым белән җир җиләге өзеп каптым» дигән юллары бар иде. Аннары икенче бер хатында ул «Бүген менә шушы дүрт юл башыма килде» дигән дә хәзер инде набат булып яңгыраган юлларны язган иде.

Үзең турында уйлама,
Илең турында уйла.
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

Госпиталь бакчасында шактый сөйләшеп утырдык. Фатих безгә шул госпиталь начальнигы Роза ханым Әхмәдуллинага багышланган шигырен укыды. Без аны газета өчен сорап алдык һәм ул озак та үтми басылып чыкты.

Монысы күңелле очрашу иде. Аннан соң күпме вакытлар үткәндер, йөрәкләргә авыр хәсрәт салып, Фатих Кәримнең сугыш кырында батырларча һәлак булуы турында шомлы хәбәр килде. Хәбәр генә түгел, кием-салымнарын да җибәргәннәр иде. Һай, шул чакта Кадрия ханымның солдат шинелен кочаклап үксепүксеп елаулары...

Шатлыклы каршылау, ямансу озату, югалту ачысы бер-берсенә үрелеп бара. Бервакыт редакциягә журналист Рим Баһауның частеннән вәкилләр килеп төшә. Каләмдәшебез сугыш кырында ятып калган. Күмәкләп семьясына барабыз. Хатыны Валентинага мәңгелек истәлек итеп иренең сугышчан орденын тапшыралар.

— Кутуй кайткан,— диделәр бер көнне.

— Кутуй?

Без йөгерә-йөгерә баскычтан менәбез. Әле берничә генә көн элек Мәскәү радиосыннан аның тавышын ишеткән идек бит. Ялкынлы чыгышында ул кырыклап фашистны үз куллары белән дөмектерүе турында сөйләгән иде. Менә хәзер үзен күрәбез икән.

Салкын һәм ярым караңгы коридор башыннан бер төркем иптәшләрне күреп алабыз. Стена кырыена чүгәләп утырган Кутуй тирәсенә җыелганнар алар. Башында колакчын бүрек, өстендә кыска тун. Туны чишеп җибәрелгән, гимнастеркасында сугышчан орденнары күренеп тора. Үзе ябык, авыру. Әмма күзләр, иреннәр елмая. Ягымлы, якын, үз.



Фронтовик Кутуй алдында басып торам, тыныч вакыттагы Кутуйны күз алдына китерәм.

...Зур драма театры. Әрмән халкының героик эпосы «Давид Сасунлы»ның мең еллыгына багышланган тантана бара. Докладчы Кутуй. Минә ул шикәрдәй ак күлмәктән, чем-кара костюмнан трибунага чыгып баса. Дулкынланып торган кара чәч, нур чәчкән күзләр, елмаюга тартым иреннәр. Саф рус телендә матур итеп, ялкынлы итеп сөйли башлый. Беренче сүзләреннән үк тамашачыны үзенә җәлеп итә. Күз алдына әрмән халкының ерак үткәннәре килә. Борынгы әдәбият энҗеләре күңел кылларын тибрәтеп үтә. Зал тын да алмый тыңлый. Күзләр трибунага, ораторга төбәлгән. Чыннан да, без яшь чакта кулдан-кулга күчеп укылган «Тапшырылмаган хатлар»ның авторы бик шәп оратор иде.

Хәтерләмим, бу кайтуында Кутуй редакциягә нәрсәләрдер биреп калдырды, нәрсәләредер газетада басылып чыкты. Әмма аның моңа кадәр басылган «Кочем җитсә әгәр» дигән нәсере, Мәскәү, Ленинградка багышлап язылган «Иртәнге уйлар» дигән шигырьләре истә иде.

Хыял күзем белән илгә карыйм:
Карап туймыйм — рәхәт күңелгә!
Рус шәһәрен ярсып яклаганда
Күзләремә Казан күренә,

— дип язган иде ул әлеге шигырьләренең берсендә.

Шул кайтуында Кутуй редакциягә берничә тапкыр килде. Берсендә аның фронт очеркын укып утыра идек. Фотохәбәрчебез килеп керде.

— Туктагыз, мин сезне шушы хәлдә фотога төшереп алыйм әле,— диде ул.

Һәм без өчәү — Гадел Кутуй, «Кызыл Татарстан»ның ул чагындагы җаваплы секретаре Зариф Габитов, секретарь урынбасары, бу юлларның авторы — фоторәсемгә төштек. Шул рәсемнең артына Кутуй хәзер минем өчен бик тә кадерле булган түбәндәге сүзләрне язып калдырды: «Мәрьям! Газета-журнал битләрендә сезнең исемне күрү үзегезне күргәндәй күңелле була. Фронттан кайткан сугышчыга редакциядә ачык чырай күрсәтү, аны җылы каршылау озак онытылмас. Иөэ ел яшәгез, бәхетле булыгыз! Г. Кутуй. 10. 1. 44.»

Кутуй яңадан фронтка китте. Аннан соң ул редакциягә гел хатлар язып торды. Хат эчендә я шигыре, я очеркы булыр иде. Хәтеремдә, хатларның берсендә шундый юллар бар иде: «Без Берлинга таба юл алдык. Авырлыклар инде артта калды... Җиңүчеләр булып кайтырбыз».

1945 елның язында аның «Тетрә, Берлин!» дигән мәкаләсе, майор Мөхәммәт Едихановка багышланган очеркы басылганын хәтерлим.

Шулай берәүләр кайтып китә, икенчеләрдән редакция хәбәр көтә. «Кызыл Татарстан» әле ике битле генә булып, әле бәләкәй форматта чыга бирә.

Фронтларның берсендә чыга торган татар газетасы үзенең укучыларына «Син халкыбызның наказын ничек үтисең?» дигән сорау белән мөрәҗәгать иткән. Аларның кайберләрен туплап өлкән лейтенант Гали Хуҗи редакциягә зур бер подборка җибәрә. Аннан соң аның фронтовик егетләребезгә багышланган шактый очерклары басыла.

Якташларыбыз турындагы очерклары, «Миңа җыр яз дигән сугышчыга», «Конбатышка, батыр сугышчы!» кебек шигырьләре белән Мөхәммәт Садри хатлары килә. Хатлар, хатлар... Гомерендә шигырь язмаган журналист Габделхәй Хәбиб хат эченә салып шигырь җибәрә. Төрле фронтлардан Бари Корбанов, Әхәт Эскәров яза.

Күкрәкләре тулы орден-медальләр белән төрлесе-төрле вакытта Мәхмүт Хөсәен, Әсгать Айдар, тагын кемнәрдер Казанга кайтып китә. Ленинград фронтыннан туптай тәгәрәп кайткан Мәхмүт Хөсәенгә карап хәйран калам. Казагыстанның Петропавловск мәктәбеннән «Яшь ленинчы»га язышып торган пионер, ни арада үсеп җиткән дә, ни арада орден-медальләр алырлык фронтовик булган. Ул күп юанмый, аны ниндидер бәйрәмгә чакырып алганнар иде булса кирәк. Ул газетага шигырь, очеркларын калдырып, яңадан фронтка китә.

Ә Әсгать Айдар редакциядә эшләп кала. Атаклы «Ташбай»ның авторы шушы икән инде, мин әйтәм. Аңа кадәр күргәнем юк иде үзен. Кычкырып сөйләшә, эчкерсез шаркылдап көлә. Гел йөреп тора, автор материалларын оештыра, үзе яза, бирелеп, яратып эшли. «Ташбай» повестеның әлеге сугышка багышланган дәвамыннан өзекләр бирә, Усад больницасы врачы Зөһрә Ширина турында очерк дисеңме, «Ала-кола айгыр зары» кебек фельетон язарга дисеңме — барысына өлгерә.

Миңа күңелле очрашулардан берсе. Информбюро белдерүен көтеп утыра идек. Яңа гына фронттан кайткан Шәрәф Мөдәррис гадәтенчә шаулап-гөрләп редакциягә килеп керде. Шәрәфне мин күптәннән беләм. Сугышка кадәрге елларда «Яшь ленинчы» редакциясенә килеп йөргән авыл малае. Ләбиб Гыйльми, Галимҗан Мөхәммәтшин эшләгән заманда шигырьләре белән актив катнашкан деткорыбыз. Хәзер инде ул җитлеккән шагыйрь. Фронттагы сугышчыларыбыз исеменнән татар халкына язылган ялкынлы хатлар авторларыннан берсе. «Кызыл Татарстан»да аның «Атака алдыннан», «Сапер» һәм башка күп шигырьләре, сугышка кадәр Красный бор районының Нарат мәктәбе укытучысы булган, фронтта немецның хәрби складын яндырган, берничә пулемет ноктасын күккә очырган, дистәләрчә фашистны дөмектергән өлкән сержант Әгъзам Хуҗин турындагы язмасы басылган иде.

Шагыйрьнең шул кайтуында редакциядә булган кечкенә генә бер эпизод хәтердә калган. Миңа ул барыбызны авызына каратып «Тупчы Ваһап»ны укый. Сугыш кырлары, фронтовикларның батырлыклары, таш кыяда һәйкәлдәй басып калган татар солдаты күз алдына килә. Шул чак кинәт бүлмәдә ут сүнә. Анысы инде ул вакытта еш була торган хәл.

— Әй, бер землянкадагы кебек булсын әле, — ди бу. Һәм идән уртасына сузылып ята. Яткан җиреннән каты мишәрчәләп, «Тимер мич», «Сукыр лампа», тагын әллә кайсы шигырьләрен яңгырата. Дөм-караңгы бүлмәдә бу шигырьләр чыннан да сугыш елларындагы землянкаларны күз алдына китереп бастыралар.

Ут кабынуга Шәрәф шинель чабуларын җыеп сикереп тора. Без хуплап кул чабабыз.

Сугыштан соң ул күп тапкырлар редакция штатына кереп эшләде. Күп тапкырлар дим, чөнки төпләнеп, озаклап эшләргә туры килмәде аңа. Күрәсең, башка

иҗат планнары булгандыр. Хәер, ул гына түгел. Мәсәлән, Мөхәммәт Садри, Әнвәр Давыдов һәм тагын кемнәрдер шулай кыска гына вакытка киләләр иде дә матур-матур әдәби сәхифәләр оештырып, эшкәртәсен эшкәртеп, җавап язасына җавап язып, хатлар папкасын тәмам бушатып, газетага кирәргә тиешле материаллар папкасын шактый калынайтып китәләр иде. Шәрәф тә җае туры килгәндә редакциягә килеп керер иде дә әле бүлек сотруднигы, әле әдәби секретарь булып дөнья җимереп эшләп йөрер иде. Бик шәп очеркист, публицист, памфлетист буларак, үзенең язмалары белән ул газета битләрен бизәп торды. Аның сугыш эзеннән барып Смоленск җирләреннән язган очерклары газета укучылардан күпләрнең хәтерендәдер. Мин аның киң эрудициясенә, газета эшен инәсеннән җебенә кадәр белүенә, сәләтлелегенә һәм җитезлегенә соклана идем. Шуның өчендер бәлки аның тәнкыйть фикерләре дә кыйммәт иде миңа. Бигрәк тә әдәби секретарь булып эшләгәндә, һәрбер язмам аның күзеннән үткәндә киңәшләрен яки шелтәләрен күп ишетергә туры килде. Ул хәтер саклап торучылардан түгел. Туп-туры йөзеңә бәреп әйтә, бәхәсләшеп торырга урын калдырмый. Аңа ничектер ачуың да килми, үпкә дә сакламыйсың. Материалыңны ул әйткәнчә төзәтепме, кыскартыпмы бирәсең.

...Сугыш беткәнгә утыз ел тулган бу көннәрдә фронтовик язучыларыбызның һәм шагыйрьләребезнең ут эченнән дә газетага язышырга вакыт табуларын рәхмәт хисләре белән искә аласың. Үзләренең очеркларында һәм шигырьләрендә алар никадәр герой якташларыбызны мәңгеләштергәннәр, ялкынлы сүзләре белән тылдагыларны һәм фронттагыларны рухландырганнар, явыз дошманга каршы корал һәм каләм белән сугышып, үзләре тиңсез батырлыклар күрсәткәннәр.

МӘРЬЯМ ДИБАЕВА.

# Хәсән Хәйри

# ЯЗУЧЫ ҺӘМ ФРОНТ

## ФРОНТ ХАТЛАРЫ

Бөек Җиңүгә утыз ел тулганда, утыз ел инде тыныч хезмәт шартларында яшәгән көннәрдә, илебез халыклары үзләренең батыр уллары һәм кызлары турында, совет халыкларының какшамас бердәмлеге, көче турында тагын да күбрәк белергә тели икән, бу бик табигый күренеш. Чынлап та, Бөек Ватан сугышының тарихи фактлары, зурысы һәм кечесе — һәркайсысы халкыбызның бердәмлеген, рухи бөеклеген, социалистик илнең какшамас көчен, өстенлеген раслыйлар.

Бөек Ватан сугышы чорына караган һәр тарихи факт, һәр документ, һәр җанлы истәлек аеруча кадерле. Бу мирасны барлауда без җитәрлек эшлибез, дип әйтә алмыйбыз әле. Фронт истәлекләре, фронтта төшерелгән рәсемнәр, сугышчан листовкалар, фронтовик хатлары, фронт газеталары һ. б.— боларның барысы да җыелырга һәм фәнни өйрәнелергә, халыкка җиткерелергә тиешлеген без барыбыз да яхшы аңласак та, бу тармакта практик эшләребез азмы-күпме булса да, эзлекле планга салынып җитмәгән дип әйтергә туры килә. «Язучы һәм фронт» темасы аеруча әһәмиятле темаларның берсе. Бу тема буенча фронтовик язучылар бик күп фактик материал да бирә алалар. Өлешчә алар күренә дә башладылар инде, ләкин бу өлкәдә тагын да мәйданны, проблематиканы киңәйтергә мөмкинлек бар. Мин моны бигрәк тә язучы фронтовикларның хатларын, матбугатта чыккан әсәрләрен, фронт газеталарындагы сугышчан язмаларын күз алдымда тотып әйтәм. Төрле архивларда, аерым кешеләр кулында әллә никадәр кыйммәтле истәлекләр, документлар саклана булса кирәк. Менә бер фактны гына искә төшерик: сугыш елларында үзәк газеталар һәм Совинформбюро үтенечләре буенча татар язучылары һәм сәнгать эшчеләре әллә никадәр материаллар язып җибәрделәр. Безнең язучылар фронт газеталарына даими язып тордылар. Мин, сугыш елларының бер дәверендә Татарстан язучылар союзының җаваплы секретаре сыйфатында андый эшләрне оештыручы буларак, моны бик яхшы хәтерлим. Совинформбюро үтенече буенча да күп кенә материал җибәрелгән иде, фронттагы язучыларыбыз да бу эштән читтә тормадылар. «Литературная газета» 1973 елның 9 май санында Совинформбюро архивы материалларыннан бер бит оештырып биргән иде. Анда Муса Җәлилнең дә бер хаты искә алына һәм аннан өзек бирелә. «Отвага» газетасының сотрудникгы М. Җәлил Совинформбюрога җибәргән хатында язучының фронттагы урыны, роле турында болай дип язган: «Бары тик алгы сызыкта гына кирәкле геройларны күрергә, материал табарга, сугыш хәрәкәтләрен күзәтергә мөмкин... Шуның өчен мин гади күзәтче булып кына йөрмим, кан койгыч сугышларда үзем дә катнашам».

Тылда эшләгән язучыларның да зур патриотик хезмәтен билгеләп үтәсе килә. Сугыш елларында Татарстан язучылар союзы да фронт һәм тыл бердәмлеге өчен гаять әһәмиятле эшләр башкарды, фронтовик язучылар белән һәр вакыт элемтәдә булды. Союзга язган хатлар, төрле үтенечләр, фронт газеталарының соравы буенча кирәкле материалларны оештырып җибәрү, язучыларны фронт газеталарына берничә айга ярдәмгә җибәрү һ. б. бик күп практик чаралар ул чорның җанлы эшләрен чагылдыралар. Әйтик, 1943 елда Татарстан язучылар союзы татарча чыккан барлык фронт газеталарында эшләүче һәм алгы сызыкларда сугышып йөрүче татар язучылары белән, шулай ук СССР Язучылар союзы белән иң якын элемтәдә булды. Моны түбәндә китерелгән хатлар да ачык аңлатыр, дип уйлыйм. Шул вакытта миңа, Союзның җаваплы секретарена, А. Фадеев, П. Павленко, М. Бубеннов һ. б. язган хатлар да безнең җанлы элемтәбез турында сөйлиләр (ул хатларның кайберсе матбугатта чыктылар).

Бөек Ватан сугышында безнең Җиңүгә утыз ел тулган көннәрдә янә бер артка, истәлекләргә әйләнеп карaганда, фронтовик язучыларыбызның батыр эшләрен — кечкенәсеннән зурысына кадәр — барысын да күз алдына китереп бастырасы, аларның нинди хис, теләк, омтылыш белән янып яшәгәнлекләрен бүгенге укучыларыбызга, бигрәк тә яшьләргә җиткерәсе килде. Актарып карасам, нәкъ 1943—1944 елларга караган әллә никадәр документаль материал ята икән: язучы дусларның хатлары, фронт газеталары... Шуларның бер өлешен укучыларга тәкъдим итәм. Нигездә фронтовик язучыларның хатларын.

1943 елның көзге айларында мин 3 нче Украина фронтында ГлавПУРККА командировкасы буенча «Совет сугышчысы» газетасында берничә ай эшләп кайткан идем. Шуңа күрә биредә, нигездә, шушы редакция эше белән бәйләнгән хатлар, бигрәк тә татарча газетаның редакторы Мәхмүд Максуд хатлары бирелә. Тәкъдим ителгән хатлар Ватан сугышында катнашкан язучыларның иҗади эшен дә, совет кешесе өчен хас гомуми рухны да ачык чагылдыралар.

Фронт газеталарыннан Татарстан хезмәт ияләренең, язучыларның, гомумән, сәнгать һәм фән эшчеләренең эшләре турында яңа материаллар җибәрүне һәр вакыт сорап тордылар. Татарстан язучылар союзы бу үтенечләргә зур игътибар бирде, ул материалларны тиешлечә оештырып җибәрергә тырышты. Фронт редакцияләренә республика җитәкчеләренең, аерым колхозларның һәм әдәбият, сәнгать, фән эшлеклеләренең хатлары, мәкаләләре, аерым алганда, Татарстан Верховный Советы Президиумы Председателе Г. Динмөхәммәтов, Министрлар Советы Председателе С. Шәрәфиев, Партия өлкә комитетының икенче секретаре Х. Пазиков хатлары, мәгариф министры Г. Кантюков мәкаләсе, Ютазы районы «Марс» колхозчылары, элекке Чепья районының Шаумян исемендәге колхоз, Кукмара районы «Кустарь» колхозы колхозчыларының сугышчыларга мөрәҗәгать хатлары һ. б. җибәрелде. Октябрь революциясенең 26 еллыгы уңае белән «Совет сугышчысы» газетасына «Казаннан котлау хаты» җибәрелде һәм ул 1943 елның 5 ноябрь санында басылып чыкты. Бу хатта Татарстан хезмәт ияләренең патриотик эшләре, фронтка ярдәме һәм фән, сәнгать, әдәбият эшлеклеләренең хезмәтләре турында язылды. Бу хатка профессор Г. Камай, композитор С. Сәйдәшев, артист З. Солтанов, язучы М. Әмир, скульптор С. Ахун, художник Б. Әльменовлар кул куйган иде.

Фронт газеталарына аерым язучыларыбыз да үзләренең әсәрләрен, мәкаләләрен, фронтовикларга адресланган хатларын җибәреп тордылар.

Кави Нәҗми фронт газеталарына иң актив язучыларның берсе иде. «Иҗат рапорты» дигән хатында ул болай дип язды: «...Данлы сугышчыларыбызга Ватан сугышы көннәрендәге иҗатым турында рапорт бирәм:

Немец илбасарларның безнең иркле илебезгә хыянәтчел тәстә һөҗүм итүләре турындагы хәбәрне ишетү белән үк, мин «Фашизмга үлем!» исемле беренче шигыремне яздым. Шул көннән башлап, үземнең бөтен иҗатымны Бөек Ватан сугышы темасына багышладым. Ул әсәрләр «Атакага!» «Таныш урын», «Ватан өчен» исемле җыентыкларда һәм газета-журнал битләрендә басылып килделәр.

Бер үк вакытта миңа публицистик мәкаләләр, очерклар һәм балалар өчен әсәрләр дә язарга туры килде.

Күптән түгел опера өчен очучылар тормышыннан язылган «Фәридә» исемле либреттомны тәмамладым. Хәзер мин татар халкының немец илбасарларга каршы сугышларда катнашуын чагылдырган тарихи повесть өстендә эшлим. Һәм Татарстанның 25 еллыгына багышланган «Батырлар китабы» исемле әдәби-художестволы альбомга материаллар җыям. Бөек Ватан сугышы батырлары турындагы бу зур күләмле китапны язу эшенә мин сезне, сугышчы иптәшләр, якыннан торып катнашырга чакырам.

Кави Нәҗми.

Минем адрес: Казань, Международная, 19, кв. 23.»

К. Нәҗминең бу хаты «Совет сугышчысы» газетасында (5 май, 1944 ел, № 53 (206) басылып чыкты. Шул ук санда аның «Озатучылар җыры», «Очучылар җыры», «Кызлар җыры» исемле җыр-шигырьләре дә бирелгән. К. Нәҗми фронт газеталарына публицистик мәкаләләр дә җибәреп торды. Шундыйлардан, мәсәлән, «Азатлык өчен көрәштә татар халкы» мәкаләсе «Совет сугышчысы» газетасының 17 март, 1944 ел санында басылды.

Аннары Г. Бәширов (Разин) һәм Фатих Хөснинең фронтовикларга язган сәлам хатлары басылып чыкты.

— Фаҗигалар һәм якты өметләр бергә үрелеп яши бүген. Халык гигант көч салып көрәшә һәм без инде бу көрәшнең якты нәтиҗәләрен дә күрәбез — алда җиңү факелы яна!

Язучының, художникның бүгенге бурычы — безнең халкыбыз кичергән гаять зур масштаблы, тирәнгә, әчкә киткән вакыйгаларны, кичерешләрне, тойгыларны дөрес итеп чагылдырып калу.

Мин үзем көньякта, фронтта, булып кайттым. Татарстан авылларында, күп кенә колхозларда булдым һәм, ниһаять, татар совет әдәбиятының көндәлек практикасында, авыр шартларда журнал чыгаруда катнаштым. Кайбер нәрсәләрне күрдем мин, татыдым яки татучыларны күрдем. Хәзер шуларны тәртипкә салырга, формага коярга кирәк. Күп кенә хикәяләр яздым һәм язып килям. 1943 елда минем «Урман сукмаклары» дигән җыентыгым басылып чыкты, һәм менә фронт хикәяләре һәм авыл хикәяләре циклыннан икенче бер җыентык тапшырдым. «Иөзек кашы» дигән повесть яздым. Хәзерге көндә фронт тәэсирләренә нигезләнгән «Абли авылы» дигән трагедия язып ятам. Әсәр — 1942 елның караңгы көзен, киеренке хәлләрне, Иделнең көньяк өлеше буендагы борынгы татар (мишәр) авылы, оккупацияләнгән татар авылы фонында яктыртачак дип уйлыйм. Әсәр театрга кабул ителде, ләкин эшләү процессының тукталганы юк әле.

Ф. Хөсни.

— Сугыш елларында мин нәрсәләр яза алдым? Сугыш ялкынының беренче айлары эчендә бер-ике кечкенә хикәям басылып чыкты, туган ил кичергән иң кыен чорларның кайбер күренешләре берничә очеркта сызылып калды. Төньяк-көнбатыш фронт сугышчылары белән бергә уздырган ике-өч айда сугышның берничә дәһшәтле сулышын «Гармоньчы егет» исемле очерклар китабында бирергә тырыштым.

Билгеле, болар берсе дә күңелемне канәгатьләндерә алмый әле. Совет сугышчыларының каһарманлыгы каршында культуралы бөтен дөнья зур ихтирам белән баш ия! Бу пәһлеваннар арасында татар халкының ун меңнәрчә уллары безнең халыкның батырлык данын, кардәш халыклар арасында дәрәҗәсен тагын да күтәрделәр. Алар безнең мактанычыбыз, алар безнең куанычыбыз.

Хәзер мин сугышчы туганнар турында «Татар егете» исемле бер повесть язам. Балаларың кебек газиз булып әверелгән әнә шул сөекле образлар белән бергә узган бик күп йокысыз төннәр җанга рәхәт, күңелгә чиксез дәрт бирә.

«Намус» исемле тагын бер хикәя язам (бу әсәре соңыннан роман булып үсеп китә, эпик әсәр булып формалаша — Х. Х.). Шундый авыр сынау чорында туган иле һәм сөеклесе — фронттагы газизе каршында керсез намус белән бөтен кыенлыкларны җиңеп чыгучы безнең кадерлеләребез — хатын-кызларның чын күңелен, саф мәхәббәтен күрсәтмәкче булам.

Гомәр Разин (Г. Бәшир).

Бу ике хат «Совет сугышчысы» газетасының бер санында (22 март, 1944 ел) басылды.

Инде фронт газеталарында эшләгән язучыларыбызның үзләренә сүз бирик. Татар совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе булган карт язучы, коммунист (1919 елдан партия члены), зур тәҗрибәле журналист Мәхмүд ага Максуд хатлары минем өчен аеруча кадерле һәм истәлекле. Аның фидакарь эше, иҗаты, бигрәк тә фронт чоры, иң тирән ихтирамга лаеклы һәм аерым өйрәнүне сорый.

## Мәхмүд Максуд хатлары

Хәсән!

Сагынулы сәлам сиңа. Гөлсем артыннан хат, материаллар җибәрерсең дип өметләнгән идем. Вакытың булмады, ахры. Вәгъдәңдә торырсың, элемтәне өзмәссең, дип ышанам. Гыйльметдинов хаты нишләде? Аңар җавап оештыра алсаң яхшы булыр иде. Бездә хәзер редактор Филиппов. Моны ул да бик сорады, үтенеп әйт, диде.

«1944 ел башланганда» төслерәк кыска гына бер очерк бирә алмассыңмы? Стахановчы эшченең яки колхозчының 43 нче ел турында хисабы, 44 нчегә вәгъдәләре — планнары рәвешендә. Бик әйбәт булыр иде. Бүтән иптәшләрдән дә шигырь, хикәя, очерклар оештыруыңны үтенәм.

Кыскасы, безне ташлама, сәбабы булыр.

Минем фронттан кайтырга теләмәвемне әкәмәт итеп аңлатырга уйлаучылар да бар, ахры. Һәркемнең үз ихтыяры. Шушындый моментта фронттан китүне үзем өчен, — коммунист язучы өчен, — мактаулы эш саный алмыйм. Бу — татар әдәбияты интересында да түгел. Шул фикеремне мин сиңа ачык әйткән идем. Моңардан нинди дә булса бер мәгънә китереп чыгаруның кирәген тапмыйм. Шуны әйт, зинһар, иптәшләргә.

Миндә хәзер Әхмәтшин эшли. Әсәдуллин да резерв исәбенә бездә калды әле. Ул да бөтенләй калыр төсле. Газетаны тагын да яхшыртырга тиешбез. Синең дә ярдәмең белән.

Иртәгә китәм.

23. 12. 43.

Сәлам. Мәхмүд.

Кадерле Хәсән дус, сагынулы сәлам!

Датасыз хатың (бездән киткәннән бирле беренче хатың) январь 15 ләрендә килде. Әйбәт хатың, матур теләкләрең өчен бик зур рәхмәтләр. Ләкин мәкаләң килмәде. Бүтән материалларың да килмәде. Ә мин сиңа тынычлык бирәчәк түгелмен. Вәгъдә иман, ди татар әйтә. Әллә имансыз булырга телисеңме? Сугыш тулы җиңү белән тәмам булган көнгә хәтле минем газетада актив катнашырга тиешсең. Бергә подшивканы актаруы нинди күңелле булыр!

Гыйльметдинов колхозыннан [1] җавап көтәм. Кызыл Армия көненә килеп җитсен иде. Моны Филиппов та телгә алгалады. Казанга кеше җибәрү турында сүз чыкса, анда сезнең әйбәт иптәшләр бар, үтенечегезне алар да башкарыр, дип кенә җибәрә ул.

Гомумән, син бирелә һәркемдә яхшы тойгы калдырып киттең.

Ярмигә, барлык иптәшләргә сәлам.

25. 1. 44.

Максуд.

---

[1] Балтач районы, Шаумян исемендәге колхоз.

Хәсән!

Күп сәлам. Февраль ахырында синең бер открыткаң килде. Шуның икенче көнендә газеталар һәм фоторәсемнәр килде. Бик күңелле булды. Синең егет кеше икәнлегеңә ышанычым зур иде, ялгышмавымны белдем.

Бездә яңалыклар юк. Әхмәтшин миндә эшли дип язган идем бугай, хәзер Әсәдуллинны да алабыз. Соңгы Указлар буенча берничә Героебыз бар, алар турында яза башлыйбыз.

Газеталар-материаллар өчен бик рәхмәт. Алардан файдаланырбыз. «Кызыл Татарстан»да да материалны яхшы оештыргансың (күрмәгән идем әле). Үзеңне тагын бер чакыртмый булмас, ахры.

Яхшы гадәтеңне онытма, безгә ярдәм иткәли тор. Фронтка булышу, завод һәм колхоз стахановчылары турында бик кыска очерклар җибәрә алмассыңмы? Газета турында фикерләреңне яз! Адресың Обкомда эшләвеңне әйтә, бик шәп. Алай-болай Хәбибуллинны күрсәң, миннән сәлам әйт, адресымны бир, яки, белсәң, аның адресын яз. Мостайга һәм миңа яңа званиеләр бирделәр. Эшебезне яраталар. Иптәшләргә сәлам. Эшеңдә уңыш, тормышыңда ямь теләп, озын хатларыңны көтеп калам.

28. 2. 44.

Мәхмүд.

Хәсән!

Хат һәм ике китап килде. Йөрәктә туган җылы тойгыларны «был тронут до глубины души» дип русча сүзләр белән әйтергә рөхсәт ит! Бик күңелле булды бу. Матур теләкләрең өчен дә зур рәхмәтләр. Соңгы айларда язу эшләренә вакыт калмый иде. Әле акрынлап тотынырга уйлыйм инде. Һәрхәлдә, тик торырга исәп юк. Вакыт сыйдырса-сыйдырмаса, азмы-күпме язгалый барырмын. Ә сез инде сыйпаганда-сукканда эшләнгән эшнең яхшы һәм начар якларын күрсәткәли торыгыз. Бер төрле дә күренми калуга язучының җаны әрнүчән була.

Безнең фронтның — үз фронтыңның — гаскәрләре фашист хәшәрәтләрне ниндиык тукмауларын газеталарда укып беләсең. Татар егетләре калышмыйлар.

Үзеңә, иптәшләргә күп сәлам.

Мәхмүд.

P. S. Бездән алып кайткан материаллар буенча берәр озынрак әйбер язасыңмы? Һәрхәлдә, бер җыентыкны җәй башына хәзерләп бирик инде.

15. 3. 44 ел.

М.

Хәйри!

Сәлам!

Сиңа язылган хат Әхмәтшинны көтеп китми торган иде, шуны җибәрәм. Әхмәтшинга бөтен эшләреңдә ярдәм итәрсең дип ышанып һәм үтенеп калам.

Тәбрик итәм,— синең «Үз Героең» бар хәзер — Гыйльметдинов. Аңар Герой исеме бирелүнең Татарстандагы яңгырашын чагылдырып бер очерк бирмәссеңме? «КТ» өчен дә, безнең өчен дә аның туган колхозыннан материал оештырганда яхшы булыр иде.

Эшләреңдә уңыш теләп кулыңны кысам.

27. 3. 44.

Мәхмүд.

Хәсән!

Әхмәтшин артыннан җибәргән хатың килде. Аңар күрсәткән ярдәмең өчен зур рәхмәт. Майның 4 ендә Тымытык кызларының хаты да килеп җитте. Газетада, әлбәттә, басылыр.

Синең егетлеккә чын-чынлап соклана башладым мин. Безгә килеп китүең газета бәхетенә икән.

Майдан 4 битле булдык. Һәрьяклап яхшырырга мөмкинлекләр бар. Ә син безнең хөрмәтле һәм актив сотрудныгыбыз. Менә моны аңлыйм мин!

Гыйльметдинов янында шушы көннәрдә бирәребез булыр. Аның турында сиңа материаллар җибәрермен. Бер китап бирерсең, әлбәттә.

Семьяңа, дус-ишләргә миннән сәлам.

Кулыңны кысып Мәхмүд.

P. S. Татарстанның 24 еллыгы ничек үтәр? Фронт газеталарына материаллар җибәрергә уйламыйсыңмы? М. М.

7. 5. 44.

Кадерле Хәсән Хәйри иптәш!

Күптән инде хат-хәбәрең булмагач, берәр җиргә озакка командировкага яки ялга киткәнсеңдер, дип уйлый идем. Хатларның озак йөрүләре генә икән бу.

9. 7 дә язган хатың 15. 8 ләр тирәсендә килеп җитте. «Күгәрчен» дә үзенең аруын белдермәде. Иямә кайттым, дип шатланды. Һаман да аңа рәхмәт укырга туры килә. Татгосиздат үзе никтер авторга китап җибәрүне тиеш санамый. «Үч һәм нәләт» җырының да син җибәргән экз.-ын гына алып калдым.

Хәсән, Октябрь бәйрәме дә җитә инде, берәр очерк җибәрә алмассыңмы? Шулай ук, Обком исеменнән институтка яки аерым авторга тапшырып, фронт газеталары өчен «Татарстан сугыш елларында», «Татарстан Совет власте елларында» кебек бер-ике мәкалә яздырсагыз шәп булыр иде. Бигрәк тә чит илләрдә мондый мәкаләгә сусарбыз без. Бу мәкаләләр октябрь башыннан калмыйча җибәрелсен иде.

29. 8. 44.

Сәлам. Мәхмүд.

Хәсән дус!

Үткән Октябрьны без синең белән шаулатып Днепрның теге ягында (матур җиңү шартларында) үткәргән идек. Быел безнең белән син булмадың,— үкенечкә каршы. Бәйрәмне без Югославиядә кечкенә Вршац шәһәрендә үткәрдек. Нинди зур җиңүләр обстановкасында!

Чит илдән языла сиңа бу хат. Сагындым үзеңне. Ләкин күп язарга мөмкинлек юк. Иртәгә иптәш Дәүләтшин Казанга китә икән.

Ара ерак. Айлап инде хат юк. Газеталар килми. Сугышчыларның (чит илләрдә булгач бигрәк тә) туган ил хәбәрләрен беләселәре килә. Син безнең газетаны шефлыкка алган кеше бит, Хәсән.

Материаллар көтәм синнән. Вак хәбәрләр, очерклар, фоторәсемнәр. Бүтән иптәшләргә хат язарга вакыт булмады, Дәүләтшинның китәчәген кич кенә белдем. Гази Кашшафка, Кавигә һ. б. иптәшләргә күп сәлам. Алардан хат һәм материаллар көтәм.

Үземдә яңа хәбәрләр юк. Буш араларда бер әйбер язгалыйм. Бер-ике айдан җибәрермен дип уйлыйм. Анда мин «Абыйлар турында» дигән бер әсәр җибәргән идем, язмышы ничек икән?

Исәнлек-саулык, тормышыңда бәхет, эшеңдә уңыш телим.

Кулыңны кысып, Мәхмүд.

15. 11. 44.

Хәйри иптәш!

Миннән дә күп сәлам.

Мостай.

Хәйри ага!

Миннән дә бик күп сәлам.

Г. Әхмәтшин.

Кадерле Хәсән Хәйри дус, күп сәламнәр!

25. 1. дә язган хатың — җылы сәламең, матур теләкләрең килеп җитеп, тагын бер кат туган илне, дус-ишләрне искә төшереп, йөрәккә дәрт, тәнгә дәрман бирделәр. Рәхмәт сиңа!

Газета турындагы әйбәт фикерләрең мине һәм иптәшләрне, билгеле, чиксез куандыра. Ләкин җитешсезлекләр күп әле. Яхшырак эшләргә тырышабыз.

Язарга соңгы айларда вакыт һәм мөмкинлек булмады. Аның сәбәпләрен аңлавы авыр түгел. «Татар кызы Бибизифа» дигән бер поэма башлаган идем, альманахка өлгертеп булмас, ахры, анда сез җыярга бирәсездер бит инде...

Былтыр җәй «Абыйлар турында» дигән көйле хикәя язып радиокомитетка җибәргән идем. Октябрь-декабрьда берничә тапкыр тапшырылган, дип ишеттем. Аны бастырып чыгарсак ничек булыр, дип А. Гомәргә язган идем. Радиокомитеттан кульъязманы алып рецензиягә бирермен, дип җавап килде дә, шуннан соң күптән инде хәбәр юк. Шул әсәрне бер күздән үткәрсәң, ярый дип табасың икән, редакторы булсаң, балаларга бер бәйрәм бүләге бирсәк (Татарстан юбилеена) — дигән уй туды миндә. Һәрхәлдә, фикереңне язсаң иде,— читтәге язучы өчен моның әһәмияте бигрәк тә зур.

Дибаева җибәргән рәсемнәр килде. Моның өчен сиңа да, аңар да күп рәхмәт. Моннан соң да җибәреп торсыннар иде. Бигрәк тә юбилей алдыннан моның кирәге артачак. Дибаевага хат салдым.

Бәйрәмгә кайтырбыз дигән өмет бар иде, тормышка ашмас, ахрысы. Анда безне дә истән чыгармассыз инде.

Нөз дә беренче үтенеч һәм тәкъдим: юбилейга хәзерлек, агитаторга материал рәвешендә фронт газеталары өчен хәзер үк берничә мәкалә (стандарт) яздырып җибәртсәгез, бик файдалы булыр иде. Авторлар — җитәкче работниклар, язучылар, тел, әдәбият, тарих институты работниклары, инженерлар, укытучылар һ. б. Моны тиз эшләтү кирәк, чөнки безгә, мәсәлән, сездән килеп җитү өчен генә бер ай һәм артык вакыт кирәк.

Шушы арада кечкенә генә бер җыентык җибәрергә уйлыйм,— соңгы ике ел эчендә язылып газета, журналларда басылган һәм басылмаган шигырьләрдән. Язылмаганны көтеп, язганны нигә әрәм яткырырга дигән уй борчый башлады мине. Укучыларга ул шигырьләр күпмедер йогынты күрсәтә алырлар, дип өмет итәргә тиеш бит мин. Бер вакытың булганда А. Гомәрдән ул әсәрнең язмышын сорашырсың. «Күгәрчен» синең фатиха белән канат кагынган иде бит.

Мондый комсыз хатны укып, аптырап калма һәм ачуланма, Хәйри. «Үзеңне күреп сөйләшмәгәч, хатка язып сүзләр бетәрме?» дип җырлыйлар ич. Кулга каләм алгач, анысын да, монысын да язасы килә. Икенче бер хатны һичбер үтенечсез язармын. Үземә бәйләнгән үтенечләр үтәлмәсә дә, үпкәләмәм. Тик газетаны онытта күрмә.

Үзеңә, семьяңа, язучыларга, белгән иптәшләргә сәлам!

Эшеңдә уңыш һәм саулык теләп,

Мәхмүд.

Венгрия.

22. 3. 45.

Кадерле Хәсән Хәйри дус!

Хатың мине бик шатландырды. Онытмау, искә төшерү яхшы сыйфат. Мин үзем борчылып йөри идем.

Болай булды. Яз көне (1945) мин сиңа бик озын хат яздым. Татарстан бәйрәменә материаллар җибәрүеңне үтендем. Җавап булмады,— районда чагыңа туры килде, ахры. Көз көне синнән бер хат алдым. Үзем, Казанга кайтуны өмет итеп, җавап язмый йөрдем. Декабрь 5 енә кадәр (бер ай) Москвада отпускада булдым.

Грипп белән авырдым, Казанга кайта алмадым. Кыскасы, хат язмау минем гаеп иде, синнән тагын хат килгәч, бик күңел булды.

Исән-саулык. Шактый гына арганлык сизелә. Ныклап иҗат эшенә тотынасы килә. Эффектлы булырдай итеп ҮК аркылы сорагыз инде. Тыныч чакта хәрби кеше була алмыйм мин. Язасы, язасы килә. Иртәгә миңа 46 тула. Шулай да тагын походларда булырлык көч сизәм әле үземдә. Мактанмыйм, чынлап әйтәм. Язарга теләк зур. Планнар күп. Пьеса язарга тәкъдим итүең өчен рәхмәт. Мин, әлбәттә, пьеса да язачакмын (мине нәсер яки тәрҗемә жанры белән чикләргә теләүчеләр ачуланса да һәм мин аларның ачулануларын бер дә теләмәсәм дә). Ләкин быелгы планымда юк әле.

Ике мең юллык бер җыентык хәзерлим. Абай шигырьләрен тәрҗемә итәм. Башланган бер поэма бар («Татар кызы Бибизифа»)...

Уен-муен түгел, Хәйри. Бер уйлап карасаң, тиздән биш ел бит инде, армиядә йөрим. Начар хезмәт итмәдем, 6 наградам бар (Кызыл Йолдыз, II Дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, Җиңү өчен, Белград, Будапешт, Вена медальләре),— монысын сиңа на всякий случай әйтеп куям. Бу сугыштан бер ел элек кенә (1939—1940) армиядә хезмәт иттем. Аннан элек ничәмә еллар редакторлык эшендә булдым. Ә минем төп профессиям язучылык. Язучы сыйфатында мәйданга чыгуыма чирек гасырдан артты. Минем моннан 26 ел элек язган нәсерләрем Бөек Ватан сугышы елларында актуаль табылып, радио буенча тапшырылды, район сәхнәләрендә укылды. Соңгы шигырьләрем фронт газеталарында күчереп басылды... Хәзер күбрәк эшләргә, күбрәк язарга кирәк...

Сиңа саулык, эшеңдә уңышлар телим.

Мәхмүд.

Семьяңа, иптәшләргә сәлам.

15. 1. 46.

## Б. Корбанов һәм Г. Әпсәләмов хаты

Кадерле Хәсән иптәш Хәйри!

Татар телендә чыга торган «Ватан өчен сугышка» дигән газета редакциясе күренекле татар сәнгать эшлеклеләренең — язучыларның, композиторларның, артистларның һәм профессорларның безнең фронт сугышчыларына мөрәҗәгать итеп, дошманны тизрәк тар-мар итүгә чакырып язган хатларыннан бер сәхифә оештырырга уйлый. Бу эшнең кирәклеге, аның политик әһәмияте Сезгә билгеле, әлбәттә.

Бу хат белән бергә, редакция кайбер иптәшләргә Сезнең аркылы хатлар җибәрә һәм Сездән шул эшне оештырып, мөмкин кадәр кыска вакыт эчендә безгә җибәрүегезне үтенә.

Иптәшләрдән имзаларын кара тушь яисә кызыл кара белән куюларын сорыйбыз, чөнки хатларын аларның үз имзалары белән бастырып чыгарырга исәп бар.

Хатлар кыска һәм безнең фронт сугышчыларының үзенчәлекләрен эчләренә алган булырга тиеш. Шушындый полоса безнең русча газетабызда басылып чыкты. Танышу өчен аны Сезгә җибәрәбез.

Безнең фронтта Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов сугыша, бездә дошманның 111 солдат һәм офицерын кырган снайпер С. Садретдинов, 103 ак финны юк иткән снайпер Х. Сираҗетдинов, 85 бандитны кырган Х. Сибгатуллин һ. б. бар.

Сәлам белән: редактор урынбасары Бари Корбанов,

Габдрахман Әпсәләмов.

5 июль, 1943 ел.

## Гали Хуҗи хатлары

*(«Ватан намусы өчен» газетасы)*

Хәсән дус!

Хатыңны алдым. Бик зур рәхмәт!

Бездә исәнлек-саулык, газета чыга, кәеф яхшы. Иҗат эшләре дә ярыйсы гына бара. Ишморат безнең янда. Без хәзер аның белән бик якын дуслар, һәр нәрсәне бергәләп хәл итәбез.

Менә шушы арада Хәкимне эзләп таптым. Немецлардан 200 метр гына ераклыкта, урманда бик озак итеп сөйләштек, шигырьләр укыштык. Хәкимнең шулай ук кәефе яхшы, яза, ләкин вакыты азрак. Ул Казаннан күптән хат алмый икән, андагы яңалыклар белән бик кызыксына. Аңа да хат язып торсагыз, бик шәп булыр иде. Менә аның адресы: П./п 56213 — М. Шушы көннәрдә аның янына яңадан барып, хәлен белеп килергә уйлыйбыз.

Хәйри! Мин сиңа үткән хатларда да язган идем, «Володя Ульянов»та бер төгәлсезлек киткән. Андагы «Рахмановлар» дигән сүзне «Рахметовлар» яки «Кирсановлар» дип төзәтсәң иде.

Хәйри! Без газетада әдәбиятка байтак урын бирәбез. Мәсәлән, шушы көннәрдә Ф. Кәрим һәм С. Хәким шигырьләрен урнаштырдык. Сез Язучылар союзыннан безгә шигырьләр, кечерәк хикәяләр һ. б. җибәреп торсагыз, гаҗәп яхшы булыр иде бит. Сугышчылар шуны көтәләр.

Үзегездә, Казанда һәм Союзда нинди яңалыклар бар? Журнал чыгамы? Без аны көтә-көтә арып беттек инде, ләкин һаман да юк.

Аннары, Хәйри, безгә фронттагы язучыларның адресларын җибәрсәң иде. Соң булса да, без аларның һәркайсы белән элемтә урнаштырырга телибез.

Иң якын дусларча сәлам!

Эшеңдә уңышлар телим.

2 июнь, 1943.

Гали Хуҗиев.

Шушы ук хатның ахырында Риза Ишморатның хаты да теркәлгән.

**Хәсән дус!**

Сиңа күп сәлам һәм эшеңдә уңышлык телим. Минем сәламемне Казандагы башка иптәшләргә дә (Кашшаф, М. Әмир, Ә. Камал, Разин һ. б.) ирештер. Шулай итеп, мин фронтта. Ерикәй Казанга киткән иде, минем турыда ул сөйләгәндер...

Сезгә, дөресрәге, журнал өчен, ике хикәя җибәргән идем. Белмим, барып җиттеме икән. Бигрәк тә «Зөбәйдә» исемле хикәямнең тапшырылуын теләр идем. Шулай итеп, мин пьесалар белән беррәттән ара-тирә хикәяләр дә язгалап карамакчы булам. Киләчәктә дә шулай җибәреп торырмын бәлки.

Безнең эшкә кагылган мәсьәләләр турында Хуҗи язган, мин аларны тәкърарлап тормыйм. Син инде ул турыда, һичшиксез, ярдәм итәрсең, дип ышанам.

Хат көтеп, сәлам белән: Р. Ишморат.

2. 6. 43.

Дускай Хәйри!

Хатыңны алдым. Мең, мең рәхмәт! Биредә хат бик кадерле нәрсә, үзең беләсең.

Шулай, Хәйри, үзем һаман бер килеш эшләп йөрим. Эш кызык һәм күңелле. Иҗат өчен материал муеннан. Фронт иҗат өчен күп нәрсә бирә һәм бик күп, бик күп нәрсәгә өйрәтә. Биредә эшләвем белән мин үземне иң бәхетле кешеләрнең берсе итеп саныйм. Шактый әйберләр язылды. Ләкин һәммәсе дә диярлек үземдә

әле. Хәзер бер зур гына әйбер эшләп ятам, ничек чыгар инде. Байтактан инде Таҗи исеменә «Володя Ульянов»ны җибәргән идем. Син аның язмышын хәл итсәң иде. Сезнең фикерегезчә, ул әле басылырлык булмаса, кулъязманы, зинһар, җуймагыз. Миндә башка данәсе юк. Өч еллык хезмәт бит, дускай! Ул хәзер миңа балам кебек якын...

Аннары, Хәйри, Татгосиздатта минем кечкенә генә җыентыгым бар иде. Һәм ул, минемчә, начар әйбер түгел... Ләкин аның язмышы турында миңа һичкем, һичнәрсә язмый. Хәйри, ул әсәр начар булса, турыдан-туры басылмый, дип җавап язсыннар иде. Басылырлык булса, «Совет әдәбияты»на җибәргән әйберләрне кушып, аны дөньяга чыгарасы иде. Хәйри, бу үпкәләү түгел. Кайбер иптәшләрнең шулай карауларына гына җан әрни.

Менә үзебезнең газетада басылган берничә әйберне җибәрәм (мин аларны күптән инде почта белән дә салган идем). Яраклы дип тапсагыз, файдаланырсыз.

Кыскасы, Хәйри, кәеф яхшы, эшләр ал да гөл. Эшләргә, эшләргә, тизрәк җиңү өчен эшләргә!

Союзда нинди яңалыклар бар, кемнәрдән хат аласыз, Мусаның язмышы ничек икән, белмисеңме? Сибгаттән хат бармы? Көтәм, һәммәсе турында да күп итеп яз әле!

Әхмәт Казанга кайткан икән, сәлам тапшыр. Сәламәтлеге ничек?

Мине хәзер строевой командир — өлкән лейтенант иттеләр. Әйе, бу зур ышанычны эш белән акларга кирәк.

Эшегездә һәм үз иҗатыңда уңыш телим.

Күп сәлам!

24 апрель, 1943 ел.

Г. Хуҗиев.

Хөрмәтле Хәсән Хәйри!

Якын дус!

Күптән инде сиңа хат язарга җыенып йөрим. Ләкин эшли торган әйберләрне бертөрле очламыйча, әллә ничек, урынсыз кебек тоелды. Кайчандыр үзеңнән дә кечкенә генә хат алган идем. Соңлап җавап бирүем өчен гафу ит.

Безнең тормышта әлегә зур үзгәреш юк диярлек. Һәммәбез исән-саулар. Ду килеп эшләп йөрибез. Газета чыга. Җыентыкны хәзерлибез. Ярыйсы һәм тулы чыгар төсле тора. Командование да һәм башка иптәшләр дә нык ярдәм итәләр. Тулы нәтиҗәсе соңрак күренер инде. М. Садри белән Г. Иделле алгы линиядә әле. Кыскасы, Газизнең дә һәм Фатыйманың да кәефләре шәп. Үзем бер килеш эшләп ятам һәм, күп булмаса да, язгалыйм. Газета кул-аякны бәйли. Шушы көннәрдә «Россия» дигән әйберне тәмамлыйм, бер табак чамасы. Иптәшләргә ошады. Мин аны альманахка дип эшләдем. Газизләр артыннан җибәрермен яки үземә кайтып килү бәхете тимәсме әле дип торам. Сиңа үтенечем шул, иптәш Разинны күреп әйтсәң иде, альманах өчен минем әйберем хәзер, эшләнеп беткән. «Батырлар китабы» өчен дә бездә байтак очерклар һәм рәсемнәр булачак. Монысы Кави абыйга (К. Нәҗмигә — Х. Х.)

Юнус һәм Урайский безгә язышып торалар. Бу бик яхшы, Әхмәт безнең фронт сугышчыларына хат язган иде, әйбәт нәрсә, алдагы номерда бирәбез.

Хәйри, үзеңдә ниләр бар, язарга вакыт табасыңмы, хәзер нәрсәләр өстендә эшлисең, гомумән, соңгы көннәрдә әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә нинди яңалыклар бар? Хат көтәм.

Хәзергә хуш, бик күп сәлам!

Сагынып һәм ихтирам белән,

Гали Хуҗиев.

1. XII — 44.

# Шагыйрь Шәрәф Мөдәррис хаты

Хәсән абый!

Сиңа кайнар сәлам язам. Исәнлек-саулык телим. Үзебез шулай бер көе эшләп ятабыз. Хатип та зур гына әйберләр эшли. Мин дә карап тормыйм. Менә сиңа истәлек өчен үземнең «Тупчы Ваһап» исемле поэмамны һәм рус телендә басылган әйберләремнең иң соңгысын җибәрәм («Певец русской славы»).

Хәзер Ватан турында югары аһәңле, ялкынлы рухлы олы гына бер поэмага йөкле булып йөрим. Һәрхәлдә, мин аны ике айлардан Союзга җибәрү бәхетенә ирешермен, дип уйлыйм. «Кызыл Татарстан»да җыелып куелган минем «Командир» исемле поэманың ни өчен тоткарлануы хакында белешүеңне үтенәм һәм бу хакта хәбәр итүеңне сорыйм.

11 ендә безнең газетаның берьеллыгы була. Үзара гына җыелышып билгеләп үтәргә уйлыйбыз. 12—13 июльләрдә командировкага китәм. Шул вакыт Маннур, Шамов, Әхмәт иптәшләр янына кереп чыгарга уйлыйм. Алар безнең юл өстендә.

Тагын әллә ниләр генә язасым килә кебек. Ярый инде, хатка язып сүз бетмәс диган сүз бар бит.

Хәсән абый! Минем бер тәкъдим бар, сез, язучы һәм шагыйрь иптәшләрнең соңгы әсәрләреннән, кечкенә шигырь яки поэмаларыннан бер төркем туплап, бирегә җибәрүне оештыра алыр идегез. Шуны әйтергә кирәк табам: сугышчылар әлек үзләре белгән язучының исемен газетада күрергә телиләр, бу алар өчен әйтеп бетерә алмаслык шатлык.

Фронтка тагын язучы җибәрү турында сүз булганы юкмы? Казагыстаннан язучы килде.

Шуның белән тәмам.

Тукай кабинетында күрешүне теләп: Шәрәф.

7. VII. 43.

# ГАДЕЛ КУТУЙ ТУРЫНДА КАЙБЕР ЯҢА МӘГЪЛҮМАТЛАР

А. М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтының кульязмалар бүлегендә, А. Толстой архивында, Лермонтов юбилеен үткәрүгә хәзерлек буенча төзелгән Бөтенсоюз комиссиясе члены буларак, татар язучысы Гадел Кутуйның эшчәнлеге турында сөйләүче бер документ саклана. Бөек рус әдибенең юбилеен үткәрүгә хәзерлектә күпчелек халыкларның күренекле вәкилләре, күп милләтле совет әдәбияты һәм сәнгате эшлеклеләре зур тырышлык куялар. Лермонтовның мирасын популярлаштыру эшенә һәрбер милләт үз культурасыннан лаеклы өлеш кертә. Күп санлы милли әдәбиятлар эшлеклеләренең Лермонтов әсәрләрен үз ана телләренә тәрҗемә итү өлкәсендәге уңышлары киң җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә тартты. Боларның бөтенесе дә милли культуралар арасындагы элемтәне ныгытты, күп милләтле совет әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә хезмәт итте.

Билгеле булганча, Гадел Кутуй, матбугат битләрендә бастырган күп кенә мәкаләләрендә, тәрҗемәләр аша тәҗрибә уртаклашу һәрбер милләт әдәбиятының үсешенә ярдәм итә, дип раслап чыкты. Әдәбиятыбызның күренекле вәкиле буларак, ул Советлар Союзындагы барлык тугандаш халыкларны татар әдәбияты ирешкән уңышлар белән даими таныштырып баруны әһәмиятле бурыч итеп санады.

Лермонтов юбилеен каршылау 1941 елның көзендә татар әдәбияты һәм сәнгатенең Мәскәүдә уздырылырга тиешле декадасына әзерләнү көннәренә туры килде. Шул уңайдан Гадел Кутуйның (Н. Козлова белән берлектә) «Красная Татария» газетасының 1941 елның 19 январь санында «Татар сәнгатенең чын йөзен күрсәтергә» дигән мәкаләсе басылып чыга. Бу мәкалә басылырга берничә көн элек Г. Кутуй Лермонтов юбилеен уздыру комитеты утырышында чыгыш ясый. Комитетның эшчәнлек процессында татар культурасының үсешен ничек күзаллавын анык чыгышы теркәлгән беркетмә һәм шул чордагы көндәлек матбугатта басылган кайбер материаллар аша беләбез.

Утырышта барлыгы 42 кеше катнаша. Беркетмәдә күренекле язучылар, Советлар Союзы халыклары әдәбиятларының танылган вәкилләреннән П. Г. Антокольский, И. Л. Андронников, Янка Купала, Гадел Кутуй һәм башкаларның исемнәре телгә алына. Комиссия составына әдәбиятчылар, исемнәре киң масса укучыларга билгеле булган (В. Я. Кирпотин, Д. Д. Благой) рәссамнар, кинематография, «Правда», «Известия», «Комсомольская правда», «Литературная газета», «Вечерняя Москва» газеталары вәкилләре кертелә. Бу утырышта әдәбиятчы В. Я. Кирпотин председательлек итә. Анда комитетның эш планы раслана, башкарылган эшләр турында отчетлар, урыннардан төрле докладлар, информацияләр тыңлана. Аннан соң комитетның җаваплы секретаре М. Эссен республикаларда һәм шәһәрләрдә төзелгән юбилей комиссияләренең эшенә туктала. Урыннарда алып барылган эшләр турында Әрмәнстаннан Г. Сарьян, Белоруссиядән Янка Купала, Татарстаннан Гадел Кутуй чыгыш ясый. Беркетмәдә түбәндәгеләр билгеләп үтелә: «Иптәш Кутуй Лермонтов поэзиясенең татар культура-

сына искиткеч зур йогынтысы турында сөйли. Татар теленә аның «Безнең заман герое», «Купец Калашников турында җыр» һәм күп кенә лирик шигырьләре тәрҗемә ителгән. Юбилейга шагыйрьнең татар телендә бер томлык сайланма әсәрләрен чыгару күздә тотыла. Җыентыкка «Безнең заман герое», «Мцыри», «Демон», «Купец Калашников турында җыр», «Маскарад» әсәрләре кертеләчәк. Лермонтовның биографиясен һәм аның турында язылган популяр мәкаләләрне аерым китап итеп бастырып чыгару планлаштырыла.

Казанда Лермонтов юбилеен уздыру буенча комиссия төзелгән, аның эш планы расланган, лекцияләр һәм докладлар уку билгеләнгән. «Маскарад» рус телендә зур уңыш белән барган.

Шагыйрь истәлегенә багышланган кичәдә доклад тыңланачак, махсус программа буенча төзелгән концерт булачак.

Информация игътибарга алына».

Бу — утырышның беркетмә язмасы. Гадел Кутуй ясаган чыгышның конкрет детальләрен башка чыганаклар буенча да ачыкларга мөмкин. «Красная Татария» газетасының 1941 елгы 15 февраль санында Гадел Кутуйның «Лермонтов еллыгы алдыннан» дигән мәкаләсе урнаштырылган. Ул мәкаләдә сүз Лермонтов юбилее комитетының эше, Советлар Союзы халыкларының, шул җөмләдән татар халкының, бу юбилейга ничек хәзерләнүе хакында бара. «Лермонтов поэзиясенең татар шагыйрьләренә йогынтысы ифрат зур,— диелә анда.— Габдулла Тукай, Пушкин белән беррәттән, Лермонтовны үзенең остазы итеп санаган. Тукай һәм Сәгыйт Рәмиев революциягә чаклы ук инде Лермонтов әсәрләрен татарчага тәрҗемә иткәннәр». Аннан соң автор шагыйрьнең Октябрьдан соң Ә. Исхак, М. Әмир, Ш. Маннур, С. Баттал тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләрен санап үтә.

Юбилей комитеты утырышында чыгыш ясаучылар Гадел Кутуйның белдерүе милли республикаларда башкарылган эшләр турында тирән фикер йөртергә мөмкинлек бирүен билгеләп үтәләр.

Лермонтов юбилее комитетының җаваплы секретаре М. Эссен, мәсәлән, болай ди: «Лермонтов әсәрләренең тугандаш республикалар халыклары телләренә тәрҗемә ителүе, күп кенә республикаларда аның пьесалары куелу, шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында лекцияләр, докладлар уку шикелле үк, зур казаныш булып тора». Бу утырышта М. Ю. Лермонтов әсәрләрен бастырып чыгару буенча зур эш алып барган республикалар арасында Татарстан махсус әйтелеп үтелә.

Гадел Кутуйның чыгышында китерелгән фактлар Лермонтов юбилее комитетының эшен чагылдырган материалларда да киң рәвештә файдаланыла. Мәсәлән, ТАССның Бөтенсоюз юбилей комитеты президиумының 17 апрельдә А. Фадеев председательлегендә уздырылган утырышы турындагы белдерүендә Лермонтов әсәрләрен милли телләргә тәрҗемә итү буенча Татарстанның беренче урында торуы хәбәр ителә. Бу белдерү «Красная Татария» газетасының 20 апрель санында басыла. Шул ук газетаның 1 май санында урнаштырылган белдерүдә революциягә кадәр Лермонтов әсәрләренең Россия халыкларыннан (рус телен исәпләмәгәндә) нибары дүрт кенә телгә тәрҗемә ителүе хакында әйтелә. Ул телләр арасында татар теле дә саналып узыла.

**В. СЕМЕНОВА,**
**филология фәннәре кандидаты.**



Мостафа Ногман 1941—1945 елларда Сталинград, Дала һәм Беренче Украина фронтларында хезмәт итә. Хәрби чины — юстиция өлкән лейтенанты.

*1943 елның җәй айлары иде. Татар телендә чыга торган фронт газеталарының берсендә Г. Кутуйның ялкынлы патриотик рух белән сугарылган бер шигырен укыдым. Ул миңа бик ошады. Шигырьдәге:*

*Хыял күзем белән илгә карыйм,*
*Карап туймыйм — рәхәт күңелгә!*
*Рус шәһәрен ярсып яклаганда,*
*Күзләремә Казан күренә.*

*— дигән юллары шундук күңелемә урнашып калды. Һәм ул миндә туган якларны, Казанны сагыну хисләремне тагын да көчәйтте. Шуның тәэсирендә уйланып йөри торгач, үзем дә «Казан йолдызлары» дигән шигырь яздым. Эпиграф итеп Кутуйның шушы юлларын алган идем. Минем бу шигырь үзебезнең фронт газетасында басылып чыкты. Ул шигырь менә болай иде:*

## Казан йолдызлары

Рус шәһәрен ярсып яклаганда,
Күзләремә Казан күренә.

Г. Кутуй.

Ник бу тикле ярсу син, йөрәгем,
Ашкынасың, дөрләп янасың?
Сагынасыңмы әллә ерак калган,
Туып-үскән Казан каласын?

Хәтеремдә һаман зәңгәр күлләр,
Шаулап торган зифа камышлар,
Киң кырларда алтын башакларын
Чайкалдырып торган арышлар.

Хыял күзләремә сарыла минем
Туган илемдәге урманнар.
Әле дә якын миңа
Бала чакта
Уйнап үскән таныш урамнар.

Бик еракка илтте мине юллар...
Борылып карыйм барыр ягымнан.
Каш сикертеп, җемелдәшеп янган
Казан йолдызларын сагынам.

Мин Россиям җирен яратканга,
Ашкынулы көрәш юлыннан
Килдем, Болгария, яклап сине
Коткарырга дошман кулыннан.


Тик калалмам синдә мин озакка,
Анда кәтә мине үз илем,
Минем дә бар, Дунай кебек шаулап,
Дулкынланып аккан Иделем.

Бәхетле мин — туган халкым минем
Сугыш кырларында дан алды.
Көрәшләрдә
Бөек Армиянең
Ышанычлы дусты саналды.

Һәр милләткә
Кайнар йөрәгемдә
Тирән хөрмәт саклап мин йөртәм,
Сорасалар әгәр:
— Россиядән!
Казан егете мин! — дип белгертәм.

1944

1943 елның декабренда мин госпитальдән дәваланып чыкканнан соң Мәскәүдә язучы Гариф ага Галиев янында Г. Кутуйны очраттым. Кутуйны беренче күрүем иде. Аның өстендә солдатлар кия торган кара каеры тун, башында колакчын бүрек, иңнәрендә — старшина погоны. Ул «Катюша»лар гаскәрендә хезмәт иткәнлеген сөйләде.



Шунда, сүз арасында, мин Кутуйдан ул язган шигырьнең күңелемдә берәзлексез кабатланып килгән шушы юлларын куен дәфтәремә язып калдыруны үтендем. Ул аны гарәп хәрефләре белән тиз генә язып бирде. Аның ул истәлеге миндә әле дә саклана. Журнал укучыларына шул кадерле истәлекнең фотокүчермәсен тәкъдим итәм.

МОСТАФА НОГМАН.

# Соңгы очрашу



*Гадел Кутуй белән без соңгы тапкыр 1943 елның сентябрь аенда Мәскәүдә очраштык. Ул фронттан ашыгыч командировкага килгән иде, ә мин, госпитальдән соң, Тамбовта офицерларның белемнәрен күтәрү курсларында укып, яңа хезмәткә билгеләнү өчен чакырылган идем. Аның белән ярты көн бергә булдык, бергә йөрдек. Саубуллашу алдыннан ул үзенең партбилетын алып, ачып караган иде, соңгы бите эченнән ике фоторәсем килеп чыкты. Беренче рәсемдә ул «Батырлык өчен» медале белән һәм гвардия значоклы, ә икенче рәсемдә «Батырлык өчен» медаленә Кызыл Йолдыз ордены өстәлгән иде. Аларның икесен дә миңа бүләк итте. Рәсемнең берсенә: «Мөхәммәт Садри иптәшкә, дуслык истәлеге. Гадел Кутуй. 16. IX. 43», ә икенчесенә: «Садри! Онытма мине, озак яшә! Г. Кутуй. 16.IX.43» дип язды.*

*Шулай итеп, аның партбилетында яшәгән рәсемнәр, минем партбилетка күчеп, әлегә кадәр күкрәк кесәмдә йөрделәр.*

*Аның ихлас күңелдән «Озак яшә!» дигән изге теләге хәерле сәгатьтә әйтелгән булып чыкты, тормышка ашты: миңа Бөек Җиңү белән тәгәлләнгән Бөек Ватан сугышының утыз еллык тарихи бәйрәмен күрергә насыйп булды.*

Хәбәр китерә Казанга
Балтик һәм Висла җиле:
— Кутуйлар бик күп калганга
Бәхетле Польша җире!
Май җиле аша Польшадан
Кутуй безгә эндәшә:
— Онытма мине, туган ил,
Үзең дә мәңге яшә!

**МӨХӘММӘТ САДРИ, 1975.**

# ТАТАР ТЕАТРЫНДА РОМАНТИЗМ

70 еллык юбилеена якынлашып килүче татар театры совет кешесенең рухи дөньясын баетуга, аның эстетик зәвыгын үстерүгә лаеклы өлеш керткән, күп милләтле совет театр сәнгатендә үз милли йөзе, үз иҗат стиле белән күренекле урын алган үзенчәлекле сәнгать кафедраларының берсе.

Заманның актуаль проблемаларын Бөтенсоюз фикер үсеше югарылыгыннан торып яктырткан татар театры, иҗади күренеш буларак, шул дәрәҗәдә күпкырлы һәм аның сәхнәсенә фейерверк булып күтәрелгән талантлар шул кадәр күп төрле ки, театрның иҗат юнәлеше турында фикер йөрткәндә һәм артистлар уенын анализлаганда, аларны бары тик реализм кысаларына гына кертеп карау мөмкин түгел.

Чыннан да, Г. Камал әсәрләре җирлегендә реалистик театр булып мәйданга килгән һәм профессиональ форма алган татар театрына романтизм хас күренешме һәм спектакльләрдә, актерлар уенында ул ни дәрәҗәдә чагылыш тапкан?

Татар театрының бай тарихына мөрәҗәгать итсәк тә, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының соңгы еллар репертуарын һәм актерлар иҗатын күздән кичерсәк тә, анда төп юнәлешне тәшкил иткән реалистик спектакльләр һәм артистлар иҗаты белән бергә, романтик сәхнә образлары һәм шул юнәлеш эстетикасыннан чыгып сәхнәләштерелгән спектакльләр белән очрашырбыз.

Татар сәхнәсендәге романтизмны иҗади күренеш буларак анализлауга керешкәнче, театр сәнгатендәге бу агымның кайбер теоретик нигезләренә кыска гына булса да тукталып үтик.

Билгеле булганча, сәнгатьнең төрле формаларын эченә алган театр үзенең яшәешендә драматург, режиссер һәм актерлар иҗатына таяна. Тәгәлләнгән сәнгать әсәре буларак тамашачы хөкеменә тәкъдим ителгән спектакльдә актер бер үк вакытта һәм драматург, һәм режиссер иҗатын үзендә берләштергән мөстәкыйль художник буларак чыгыш ясый. Режиссура фикеренә таянып, актер драматург тудырган образны үз хисләре, үз кичерешләре белән җанландыра, образны үз шәхси рухы аша үткәреп, үзенең иҗат арсеналында булган сәхнә чаралары ярдәмендә художестволы формага сала. Иҗат фантазиясе җимешләрен сәхнәнең шартлы чынбарлыгына күчерүдән гыйбарәт булган бу катлаулы психологик процесста төп рольне актерның сәхнә кичерешләре уйный. Ә ул кичерешләр исә, аның темпераментына, фантазия һәм хис байлыгына, образлы фикерләү тибына, иҗат процессында катнашучы тамашачы реакциясенә һ. б. бәйләнгән. Актерның уен стилен аның чынбарлыкны хис аша күрү, образлы фикерләү тибы буенча билгеләргә мөмкин.

Актер иҗатында һәм романтик, һәм реалистик иҗат тибына хас сыйфатлар — яңабаштан иҗат итү һәм кабат иҗат итү[1] башлангычларының берлеге чагыла. Иҗат

---

[1] «Яңабаштан иҗат итү» — пересоздание, «кабат иҗат итү» — воссоздание мәгънәсендә алына. Г. Халит билгеләмәсе.

процессында актер образны үзенең чынбарлыкны күрү, образлы фикерләү алымына туры килгән иҗади кичерешләре белән баета. Романтик актер драматург тарафыннан реалистик планда иҗат ителгән образда чыгыш ясаганда да, сәхнәдә яңабаштан иҗат ителгән романтик образ туарга мөмкин. Һәм, киресенчә, реалистик пландагы актер драматургик материалы буенча романтик характердагы образны үз стиленә хас сәхнә чаралары белән ачса, романтик образ да сәхнәдә реалистик тип булып гәүдәләнергә мөмкин.

Аерым очракларда сәхнә образында актерның үз рухи халәтеннән килгән сыйфатлар шул кадәр тәэсирле һәм отышлы була ки, драматург иҗат иткән образдан яңгырашы белән нык аерылып торган, тирәнрәк һәм баерак сәхнә образы туа. Бу, актерның образны гомумкешелек идеаллары яктылыгына куеп, аның аерым сыйфатларын әхлакый һәм эстетик өлге биеклегенә күтәрә белү осталыгыннан килә. Мондый очракта актерның шәхси рухы драматург иҗат иткән образ чикләрендә генә калмый, әсәр авторы күздә тотмаган яңа ассоциацияләр ачылып китә. Димәк, актер образның соавторы буларак чыгыш ясый һәм спектакльнең идея-эстетик яңгырашын бермә-бер көчәйтә, тәэсир куәтен арттыра. Моңа мисал итеп, татар сәхнәсендә Мохтар Мутин, Шакир Шамильский, Фатыйма Ильская, Камал III кебек талант ияләре иҗат иткән образларны күрсәтергә мөмкин.

Татар театр белемендә сәхнә уены алымын билгеләү юнәлешендәге фикерләр тәү тапкыр «Аң» журналында Габдрахман Кәрам мәкаләләрендә күренә. Аның хезмәтләрендә сәхнә иҗаты һәм милли театр белеменең киң һәм катлаулы проблемалары күтәрелә. Шуның белән бергә, Г. Кәрамның эстетик караш үзенчәлекләре турында фикер йөрткәндә, аның дөнья классикларыннан Шекспир әсәрләрен беренче булып татар теленә тәрҗемә итүен, «Отелло», «Король Лир» кебек мәшһүр әсәрләрнең татар сәхнәсендә яңгырый башлауларының да Г. Кәрам эшчәнлегенә бәйле икәнен истән чыгармаска кирәк. Бу мәкаләдә Г. Кәрамның эстетик карашларын анализлау, иҗади мирасын тулаем күздән кичерү максат итеп куелмаганга (революциягә кадәрге күренекле театр белгече Г. Кәрамның эстетик карашлары, милли сәхнә сәнгате өлкәсендәге иҗади мирасы махсус өйрәнү таләп итә), без аның бары сәхнә уены алымына кагылышлы аерым фикерләренә генә тукталабыз.

1912 елда С. Гыйззәтуллина-Волжская «Сәйяр»дан киткәч, труппада хатын-кыз рольләрендә «сезон буенча, бөтен пьесаларда, бөтен амплуаларда»[1] Гөлсем Болгарская чыгыш ясый. Аның уенына бәя биреп, Г. Кәрам алга табан болай дип яза: «Кызганыч бала», «Мәсхәрәләнмеш ханым», «Асрау кыз», «Кайниш» спектакльләрендә яхшы осталык илә рухлы уен күрсәткән Г. Болгарская «Җиңел хезмәт», «Бозыклар», «Мәкер вә мәхәббәт» кеби әсәрләрдә дә зарарсыз уйнады. Ләкин бондай пьесаларны уйнар өчен Болгарскаяда нәрсәдер җитми, зǟнн идэ рǟсем манера юк»[2].

Г. Кәрам билгеләмәсендәге «зǟнн идэ рǟсем манера»ны бүгенге сәнгать белеме терминологиясенә күчерсәк, уен алымы төшенчәсендә тәнкыйтьче образлы фикер һәм сәнгатьчә идеал белән рухландырылган иҗатны күздә тотуы ачыклана.

Әгәр атаклы татар артисткасы Г. Болгарскаяның иҗат стиле тормыш-көнкүреш образлары әйләнәсендә формалашуын, аның реалистик пландагы артистка булуын искә алсак, аның уенына Г. Кәрамның нинди эстетик принциплардан чыгып бәя бирүе ачык аңлашылыр.

Тәнкыйтьче 1913 елда татар театрында репертуар ярлылыгына һәм образлар бертөрлелегенә игътибар итеп: «Бездә бу көндә мокамәл вә яхшы пьесалар юк дәрәҗәсендә аз. Без пьесаларымыз хакында фәлән уендагы фәлән тип дип әйтә алмыйбыз. Чөнки бездә типлар юк. Бинаи галия[3] бөек типларны иҗат итәчәк артистларымыз да юк»[4],— дип язды. Моннан Г. Кәрамның күтәрелеп килүче милли театрны, төрле стиль юнәлешләрен үзендә берләштергән, романтик сәнгатьнең дә югары таләпләренә җавап бирерлек театр итеп күрергә омтылуы ачык чагыла.

---

[1] Г. Кәрам. Шәрык клубында театр вә музыка мөвәсеменең икүне.— «Аң», 1913, № 11, 195 бит.

[2] Зǟнн (фарсы) — фикер, караш; идэ — (фарсы) идея; рǟсем — (фарсы) сәнгатьчә сынландыру, образлы сурәтләү.

[3] Бинаи галия — бөек рухлы.

[4] Шунда ук, 195 бит.

Әлбәттә, Г. Кәрам билгеләмәләрендә анықланып җиткән эстетик принципларга таянып әш итүче бүгенге көн сәхнә романтизмының тулы концепциясен күрергә омтылу урынлы булмас иде. Тәнкыйтьченең фрагментар характердагы бу фикерләре сәхнә уенында мөстәкыйль ике юнәлешнең (монда, иң элек, актерның уен алымы һәм образлар гәүдәләнешендәге үзенчәлекләр күздә тотыла) яшәү мөмкинлеген һәм зарурилыгын раслыйлар, театр сәхнәсендә шул чорда ук романтик характердагы спектакльләрне күрүгә ихтыяҗ булуын күрсәтәләр.

Әмма татар театрында романтик агымның тууын һәм үсешен аерым актерларның сәхнә индивидуальлегенә генә бәйләп карау мәсьәләне берьяклы аңлау булыр иде.

Романтик уен алымы формалашуга актер яшәгән һәм иҗат иткән заман, чор көчле тәэсир ясый. Романтизмның татар сәхнәсендә урын алуы унынчы еллардагы яңа революцион күтәрелеш чоры, социаль һәм милли азатлык хәрәкәтенең йогынтысы белән бәйләнгән. 1905 ел революциясе татарларда сәнгатьнең яңа төрен — театрны тудыра. Реакция еллары атмосферасына каршы протест, азатлыкка, демократик идеалларга омтылыш сәнгатьнең барлык төрләренә үтеп керә. Татар театрында ул шәхес ирекен, азатлык идеяләрен алгы планга куеп тасвирлаган, күтәренке рухлы, ялкынлы көрәш пафосы белән сугарылган сәхнә романтизмы формасында мәйданга калка.

Чор таләпләре Мутин тибындагы актерларны алгы планга чыгарган, алдынгы тамашачының рухи халәтенә күтәренке хисле, эмоциональ тәэсир көче белән аерылып торган актерлар уены тулырак җавап биргән. Ул елларда Мутин тибындагы артистлар күп булган. Бу җәһәттән, ул чагында Петербургта укыган (хәзер персональ пенсионер) Гани Абызовның истәлекләре игътибарга лаеклы. Революция алды елларында Петербургта алдынгы фикерле татар яшьләренең спектакльләрендә катнашкан Г. Абызов татар студентларының Шекспир, Шиллер, Гейне әсәрләрен куюларын һәм үзешчәннәрнең Карл Моор, Әлмәнсурны, Мутинга охшатып, күтәренке пафос, кайнар темперамент белән, азатлык, иҗтимагый фикер иреге өчен көрәшүче геройлар итеп уйнарга омтылуларын сөйли.

Яңа революцион күтәрелеш чоры, барлык рухи байлыкларны алдынгы идеаллар яктылыгына куеп, яңа иҗтимагый фикер офыкларын билгеләүне таләп итә. Иҗтимагый тормышта һәм сәнгатьтә шушы прогрессив процессның уртасында кайнаган каһарманнарга ихтыяҗ туа. М. Мутин Әлмәнсур, Карл Моор, Отелло образларын шушы таләпләр яктылыгына куеп гәүдәләндерүче актер буларак үсеп чыга. Аның уенының киң иҗтимагый резонанс алуы да артистның тасвирда заман идеалларына сизгер булуыннан килә.

Чорга хас идеаллар, прогрессив иҗтимагый фикерләр театрга һәм актерлар уенына шул вакытның әдәбияты аша да киләләр. Әдәбиятта өстенлек иткән агым театр сәнгатендә барган эзләнүләргә йогынты ясый, режиссерлар яки актерлар иҗатында реалистик яки романтик юнәлешнең көчәюенә сәбәп була.

XIX йөзнең беренче яртысында рус әдәбиятында романтизмның төп юнәлеш булып мәйдан алуы сәхнәдә М. С. Мочалов йөзендә романтик уен алымының формалашуына да этәргеч ясый. XX йөз башы рус әдәбиятында яңадан романтизмга омтылыш көчәя һәм шушы күренеш театрда да романтизмның яңадан калкып чыгуына сәбәп була. Прогрессив фикерле режиссерлар Шекспир, Гейне, Шиллер, Ибсен, Л. Андреев һ. б. ларның романтик рухтагы пьесаларына мөрәҗәгать итәләр.

Татар әдәбиятында да революция алды, Октябрь революциясе һәм 20 нче еллар — романтизмның нык үсеш алып, яңа төсмерләр белән баеган чорлары. Бу күренеш «XX гасыр башы татар романтик поэзиясе әзерләгән җирлектә»[1] туды һәм бу дулкын татар театрын да яңа үзенчәлекләр белән баетты. Татарның романтик шагыйрь һәм әдипләре Фәтхи Бурнаш, Сәгыйт Рәмиев, Мирхәйдәр Фәйзи, соңрак Һади Такташ «Таһир-Зөһрә», «Яшә, Зөбәйдә, яшим — мин», «Кызганыч», «Җир уллары» кебек романтик сәхнә әсәрләре иҗат итәләр.

Театрда Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Колахметов, Ш. Камал, К. Тинчурин әсәрләре белән беррәттән, Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт», «Юлбасарлар», Г. Гейненың «Әлмәнсур», Н. Наримановның «Надир шаһ», Г. Җавидның «Иблис» трагедияләре урын алдылар.

---

[1] Г. Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы. Казан, 1926, 204 бит.

Татар сәхнәсендә романтик уен алымы формалашу турында сүз алып барганда, көнчыгыш поэзиясе романтик традицияләренең һәм әзербәйҗан драматургиясенең уңай йогынтысын да истән чыгарырга ярамый. Билгеле булганча, татарда профессиональ театр сәнгате бер урыннан икенче урынга күчеп йөрүче труппа булып туа. Г. Тукай тарафыннан аның «Сәйяр» дип исемләнүе дә күчмә талантлар йолдызлыгына ишарә булып тора. Эчке Россиянең төп шәһәрләрен йөреп чыккач, 1908 елда «Сәйяр»ның Кырымга юл алуы билгеле. Кырымнан труппа Кавказга юнәлә. Тифлистә «Сәйяр» әзербәйҗан театрының талантлы артисты Г. Араблинский җитәкләгән труппа белән очраша. Бу очрашу татар һәм әзербәйҗан халыкларының театр сәнгате үсешендә аерым урын тота, шуңа күрә бу тарихи вакыйгага киңрәк тукталу урынлы булыр.

Г. Араблинский җитәкләгән әзербәйҗан труппасында хатын-кызлар булмау сәбәпле, героиняларны ирләр, сирәк очракта әрмән артисткалары башкара. Бу хәл спектакльләрнең художество кыйммәтен түбәнәйтә. «Сәйяр»да С. Гыйззәтуллина-Волжская кебек талантлы артистканы күргәч, әзербәйҗан артистлары труппаларны берләштерү фикерен әйтәләр һәм Г. Араблинский җитәкчелегендәге «Кавказ-төрки мөселман труппасы» төзелә. Әзербәйҗан труппасының репертуарында романтик трагедияләр өстенлек итә, актерлар уены һәм режиссура көнчыгышка хас күтәренке рух белән аерылып тора. Татар артистлары әзербәйҗан драматургларының «Надир шаһ», «Ага Мөхәммәт шаһ Каҗар», «Мөсибәт Фәхретдин» трагедияләрендә әзербәйҗан артистлары белән бергә уйнап, аларның күтәренке рухлы уен алымы белән танышалар, татар сәхнәсен аларның режиссура ысулы, образларны гәүдәләндерү үзенчәлекләре белән баеталар. Әзербәйҗан артистлары «Сәйяр»ның «Бәхетсез егет», «Оят яки күз яше» һ. б. спектакльләрендә катнашып (берләштерелгән труппада әзербәйҗан драматургларының әсәрләре әзербәйҗан телендә, татар драматургларының әсәрләре татар телендә уйнала), татар театрына хас реалистик сәхнә сәнгате казанышларын үзләштерәләр. Бу турыда «Кавказ-төрки мөселман труппасы» спектакльләрендә катнашкан күренекле артист В. Мортазин-Иманский болай дип яза: «Кавказ театры репертуарында Кавказ әдипләре каләме белән ханлар, шаһлар тормышыннан алынып язылган тарихи драмалар, трагедияләр, шулай ук Европа классикларының әсәрләреннән «Отелло», «Гамлет» кебекләр зур урын алалар... Алар ул трагедияләрне **шаккатып карыйлар. Театрны да халыкны шаккатыру өчен ясала торган тамаша урыны итеп аңлыйлар»** [1] (ассызык безнеке — Ф. К.). В. Мортазин-Иманскийның бу сүзләре ул чор татар һәм әзербәйҗан театрларының стиль аерымлыкларын, әзербәйҗан тамашачысының романтик трагедияләр рухында тәрбияләнүен, алар зәвыгына «шаккатырып» уйнау таләп иткән әсәрләр җавап бирүен ачык дәлилләр.

Бу җәһәттән, әзербәйҗан сәхнәсенең талантлы артисты Вәлиев белән В. Мортазин-Иманский арасында булган бер сөйләшү игътибарга лаек.

Мортазин аңа:

— Сездә театр әдәбияты көчле дә, бик бай да икән. Бездә сездәге кебек зур трагедияләр юк бит,— дигәч, Вәлиев:

— Без моңарчы үзебезне зурга куеп йөридер идек. Сезнең эшләрне күргәч, безнең фикеребез бөтенләй егылды. Без зур трагедияләр уйнап, әллә никадәр көчләр түгәбез, шаккатырып уйныйбыз... Ә **сез халыкның тормышыннан алынып язылган әсәрләрне уйнап, халыкның алдыннан агып торган тормышын күрсәтеп бирәсез...** Безгә дә сезнеңчә бару юлына керешергә кирәк. Сез безгә башка юл күрсәттегез,— ди [2].

«Кавказ-төрки мөселман труппасы» Тифлистә, Елизаветполь (Гәнҗә), Баку, Астрахань, Казан, Нижний Новгород шәһәрләрендә спектакльләр белән чыгыш ясый. Нижний Новгородтан әзербәйҗан артистлары Кавказга кайтып китәләр.

«Кавказ артистлары кайтып китте, ләкин алар безнең театрга күп кенә яңалык бирделәр. «Сәйяр» Кавказга барып әйләнгәнче, эчке Россия татар театрларында «Надир шаһ», «Мөсибәт Фәхретдин», «Ага Мөхәммәт шаһ Каҗар» кебек тарихи трагедия-

---

[1] В. Мортазин, Т. Ченәкәй. Татар театры тарихыннан. М., СССР халыкларының үзәк нәшрияты, 1926, 72 бит.
[2] Шунда ук, 73, 74 бит.

лэр уйнау истә дә юк иде. «Сәйяр» артистлары Кавказга барып чыгып, аларны Кавказ телендә уйнап, постановкалар белән танышып кайттылар. Шулай ук Европа трагедияләренең дә Кавказ телендә уйналганлыкларын күреп, аларны татар телендә дә уйнарга була икән дигән уйга төшенделәр. Шуның өстенә Кавказның яхшы артистлары белән якыннан аралашып, алардан күп кенә сәхнә белемнәре алдылар. Шул алып кайтканнары белән татар сәхнәсенә күп кенә файда китерделәр»[1].

В. Мортазин-Иманскийның фәнни әһәмияткә ия булган бу күзәтүләреннән чыгып, шушындый нәтиҗә ясарга мөмкин: тугандаш әзербайҗан һәм татар театрлары арасындагы бу иҗади бәйләнеш һәр ике театр өчен һәм режиссура, һәм актерлар уены, һәм драматургиядә яңа иҗат мөмкинлекләре, яңа офыклар ача. Озак та үтми, әзербайҗан драматургларының «Надир шаһ», «Мөсибәт Фәхретдин», «Ага Мөхәммәт шаһ Каҗар» романтик трагедияләре «Сәйяр» репертуарында урын ала. Европа классикларыннан «Әлмәнсур», «Мәкер һәм мәхәббәт», «Юлбасарлар» тәрҗемә ителә. Татар драматургиясендә оригиналь мелодраматик пьесалар — Мирхәйдәр Фәйзинең «Асылъяр», «Ак калфак», «Кызганыч», «Галиябану» драмалары туа. Ф. Бурнаш көнчыгышның романтик традицияләре рухында «Таһир-Зөһрә» шигъри трагедиясен яза.

Татар театрының режиссура өлкәсендәге мөмкинлекләрен киңәйтү юнәлешендә С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның эзләнүләре аерым урын тота. Мәгълүм булганча, ул 1912 елда революциягә кадәрге татар культурасының икенче үзәге Уфада «Нур» труппасын оештыра. С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның бу кыю адымы татар сәхнә сәнгате тарихында хаклы рәвештә татар театрының демократик сәнгатен яңа географик киңлекләргә җәелдерү, халыкның яңа катлауларын театрга якынайтуда җитди әһәмияткә ия булган иҗади күренеш итеп бәяләнә. Шуның белән бергә, театр тарихына караган материалларда С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның «Сәйяр»дан китүен Г. Кариев белән килешә алмау нәтиҗәсе итеп күрсәткән фикерләр дә күренгәли. Әмма бу каршылык шәхси мәнфәгатьләр тарлыгыннан яки С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның үз җитәкчелегендәге труппа оештырырга омтылуыннан тумаган. («Нур»ның «Ширкәт» белән берләшеп эшләве чорында С. Волжскаяның гади артистка булып уйнавы билгеле.) Г. Кариев һәм С. Гыйззәтуллина-Волжская татар театрының иҗат йөзен, аның киләчәк үсешен күзаллауда һәм, ахыр килеп, актерлык, режиссерлык осталыгы, оештыру сәләтендә бер-берсенә тиң торырлык фигуралар. «Аң» журналы 1913 елда тикмәгә генә: «Кариев ирләр тибында безем театр галәменең иң оста егете булса, Гыйззәтуллина ханым да хатыннар галәмендә чыннан талантлы, иҗаты куәтле бер артистка иде. Ул уйнады гына түгел, сәхнәдә типлар иҗат кыйлды...»[2] — дип язмаган.

С. Гыйззәтуллина-Волжская режиссурада Г. Кариевның шәкерте санала. Әмма ул Г. Кариевның талантлы шәкерте. Билгеле булганча, талантлар үзләренең остазлары үткән юлны кабатламыйлар, аны дәвам итеп, иҗатта яңа үрләр яулыйлар. Рус театры тарихына мөрәҗәгать итик: В. Э. Мейерхольд, Е. Б. Вахтангов, А. Я. Таиров — барысы да рус театрында реалистик уен мәктәбенә теоретик нигез салган К. С. Станиславский шәкертләре. Шуның белән бергә, алар совет театр сәнгатен һәрберсе үзенә хас яңалык белән баеткан режиссерлар. Совет театр сәнгатендә В. Э. Мейерхольдның шартлы юнәлеш (бу юнәлешнең яшәүгә лаеклы булуын соңрак немец сәхнәсендә Б. Брехт раслады), Е. Б. Вахтанговның шигъри, романтик юнәлеш тудырудагы хезмәтләре, А. Я. Таиров җитәкләгән Камерный театрның баштарак символик һәм психологик, соңрак киң аудиториягә юнәлтелгән, мәйдан театрына хас эзләнүләре бүген фәнни дәлилләү таләп итмәгән хакыйкать.

Татар театрында С. Гыйззәтуллина-Волжская һәм Г. Кариевның һәрберсе мөстәкыйль юнәлешкә омтылуларын иҗат принципларының туры килмәве белән аңлату дөреслеккә якынрак булыр. С. Гыйззәтуллина-Волжская «Нур» труппасын үз иҗат принципларын гамәлгә ашыру теләге белән оештыра. Яңа труппа күп яклары белән «Сәйяр»ның тормыш-көнкүреш әсәрләренә йөз тоткан психологик юнәлешеннән аерылып тора. «Нур»ның репертуарында «Мәкер һәм мәхәббәт», «Картежник тормышы», «Яшен», «Уйнаш», «Мөгаллимә», «Кызганыч» кебек, характерлары белән үзгә әсәрләрне күрәбез. С. Гыйззәтуллина-Волжская режиссерлык эшендә, Г. Кариев белән

---

[1] В. Мортазин, Т. Ченәкәй. Татар театры тарихыннан, М., СССР халыкларының үзәк нәшрияты, 1926, 75 бит.

[2] Кара: Г. Кашшаф. Беренче артистка. Казан, 1958, 36 бит.

рэттэн, Н. Зимовой, И. Веерман һ. б. ларның иҗат тәҗрибәләренә дә таянган. Әзербәйҗан театры режиссеры Г. Араблинскийның да аңа йогынтысы зур булган[1].

Бу йогынты, югарыда күрсәтелгәнчә, әзербәйҗан труппасы белән бергә уйнаган чордан ук килә. Гәнҗә шәһәрендә Н. Вәзировның «Мәсибәт Фәхретдин»е («Фәхретдиннең фаҗигасе») уйнала. С. Гыйззәтуллина-Волжская Г. Араблинскийның партнеры булып Сәгадәт ролендә чыгыш ясый. Гәнҗә шәһәрендә әзербәйҗан телендә чыга торган газета бу хакта болай яза: «Араблинский партнеры (Волжская) бик яхшы уйнады, ул рольдә артистка шул кадәр яхшы иде, хәтта Араблинский үзе югала язып калды»[2].

Әзербәйҗан театр белгечләре Г. Араблинскийның иҗат юнәлешен билгеләп: «Ул сәхнәдә тәгәллек һәм тормыш дөреслеген яратты. Аның иҗат методына романтик буяулар белән рухландырылган реализм хас иде» [3],— дип язалар.

Шул рәвешле, «Сәйяр»ның тормыш-көнкүреш әсәрләре җирлегендәге психологик юнәлешеннән үзенең мелодраматик репертуары, чынбарлыкны сәнгатьчә бәяләүдә билгеле бер фикер яссылыгы, үзгәрәк эстетик зәвык принципларыннан чыгып эш иткән режиссурасы, артистларның күтәренке уен алымы белән аерылып торган «Нур» труппасы йөзендә татар театрында романтик юнәлеш формалаша.

Әлеге чор матбугатында «Нур» труппасы спектакльләре һәм С. Волжская иҗатына багышланган рецензияләр, асылда, шул ук фикерне раслыйлар. Мәсәлән, 1916 елда Г. Камалның «Уйнаш» әсәре буенча куелган спектакль турында «Тормыш» газетасы болай дип язды: «Труппа чыннан да «Уйнаш»ны көтелмәгән дәрәҗәдә яхшы уйнады. Үзенең хәятын башкаларны харап итү юлы белән тәэмин кыйлучы татар карчыгының хәйләсенә корбан булган яшь, матур татар хатыны Сәрбиҗамал ролен Гыйззәтуллина көтелмәгән дәрәҗәдә яхшы уйнады, бигрәк ахыргы пәрдәдә аның уены, чиккән рухани тәэссораты әллә нинди каты йөрәкле кешеләрдән дә үзен кызгандырырлык, мәзлүма өчен күзне яшьләндерерлек дәрәҗәдә яхшы чыкты» [4].

Социаль тема булган хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсенең кеше язмышы, аның рухи дөньясы, кешеләр арасындагы әхлакый мөнәсәбәтләр аша гәүдәләндерелүе «Нур» труппасының иҗат принципларыннан, С. Гыйззәтуллина-Волжская башкаруына хас үзенчәлекләрдән килә. Сәхнә практикасында Г. Араблинский иҗатына таянган С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның уен алымы «Нур» труппасындагы башка артистлар, аерым алганда, Г. Казанский иҗатына да йогынты ясый. Шул ук «Тормыш» газетасы Уфа сәхнәсендә Г. Камалның «Бәхетсез егет» әсәре сәхнәгә куелуын хәбәр итеп, Г. Казанскийның Закирны «...Араблинскийга тәкълид [5] итеп...» [6] уйнавын билгеләп үтә.

Г. Камалның «Уйнаш» әсәре куелу уңае белән язылган мәкаләдә Г. Казанскийның уены түбәндәгечә бәяләнә: «Ул үзенең әхвәле рухиясын, тойгыларын күрсәткәндә һәр вакыт шулай арттыра төшә. Бик көчле һәм фәукыйльгадәрәк [7] трагедияләрдә Казанский тоткан юл белән уйнау яхшы чыкса да... гади бер татар сәүдәгәре ролендә бик үк килешеп бетми...» [8]. Шул рәвешчә, рецензент артистның иҗат юнәлешенә күтәренке рухлы, фаҗигави образлар ятыш булуын күрсәтә.

Инде «Нур»ны сәнгать күренеше итеп дөньяга калкытып чыгарган иҗтимагый фикер җирлегенә игътибар итик.

Халыклар төрмәсе булган патша Россиясендә реакция һәртөрле азатлык чаткыларын күренүе белән үк юк итә килә. 1905 ел революциясе белән яуланган демократик хокуклар кысыла. Әмма революцион фикер үсешен, азатлык өчен көрәшкә булган омтылышны самодержавие инде туктата алмый. Хәрәкәткә чакыручы, бөек идеаллар хакына көрәш мәйданына өндәүче булып, әдәбиятта романтик агым көчәя. Тормыштагы кебек үк, әдәбиятта һәм сәнгатьтә дә халык азатлыгы өчен үзләрен корбан итәргә әзер булган каһарманнарга ихтыяҗ үсә. Шул чорга хас әдәби процесс-

---

[1] Г. Кашшаф, Беренче артистка .Казан, 1958, 31 бит.
[2] Шунда ук, 30 бит,
[3] «Әзербәйҗан сәнгате», Рус телендә, Әзер, ССР Фәннәр академиясе нәшрияты, III том, Баку, 1950 ел, 248 бит.
[4] «Тормыш» газетасы, 20 декабрь, 1916 ел,
[5] Тәкълид — охшатып, аның рухында,
[6] «Тормыш», 23 ноябрь, 1916 ел.
[7] Фәукыйльгадә — гадәттән тыш,
[8] «Тормыш», 20 декабрь, 1916 ел,

ны характерлап, Г. Газиз: «...Милли хисемез куәтләнгән, милли музыка, халык җыры вә музыкасына әһәмият биргән, үземезнең үткән көннәремезне артымызга борылып карый башлаган бер заманыбыз — бездә ник романтизм булмасын?» [1] — дип язды.

Бу дулкын, әлбәттә, театр сәнгатен дә читләтеп узмады. 1913 елда театр белгече Габдрахман Кәрам тормыш-көнкүреш темасына караган, «һәммәсе бер зәминдә [2], бертөрле» булган пьесаларда заманны рухландырган фикерләр белән чыгыш ясар өчен җирлек тар икәнен, бу «пьесаларымызда артистларымызның төрле яктан үзләренең истигъдадларыны [3] күрсәтү өчен материал юк»лыгын [4] әйткән иде.

Табигый ки, самодержавие күзәтүенә якын булган Казанда реакция кысуына каршы тору кыенлаша. Шул ук вакытта азатлык хәрәкәте дулкыннары революциягә кадәрге татар культурасының икенче үзәкләре — Уфа һәм Оренбург шәһәрләренә дә тарала. «Нур» труппасының Уфада калкып чыгуы да шул сәбәпләргә бәйле.

«Нур» труппасының романтик юнәлешен 30 нчы елларга кадәр Уфа сәхнәсендә эшләгән Ш. Шамильский, Г. Казанский, М. Мутин, Г. Уральскийлар, Оренбургта Исхак Әлмәшев һ. б. дәвам итәләр. СССРның халык артисты Мөбәрәк Арсланов шул юнәлешнең бүгенге башкорт театрында, аерым артистлар уенында дәвам ителүе хакында сөйли [5]. Үзен, В. Мортазин-Иманский, Ш. Шамильский, Г. Казанскийлар уен мәктәбен өйрәнеп, алар йогынтысында формалашкан артист итеп күрсәтә.

Ш. Шамильский, М. Мутин Казанга романтик характердагы актерлар булып киләләр. Моны аларның Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә иҗат иткән образлары да ачык дәлилли. Г. Казанский Казанда берничә ел уйнагач, Минзәлә дәүләт (ул чагында колхоз-совхоз театры) театрында эшли. Минзәлә дәүләт театрының бүгенге репертуарында «Айгөл иле», «һәйкәл» романтик спектакльләренең булуы, аерым артистлар уенында чагылган романтик күтәренкелек Г. Казанский иҗатына хас үзенчәлекләрнең яңа җирлектә иҗади дәвам итүен күрсәтәләр.

Күргәнебезчә, сәхнәдә романтик уен алымы формалашуның үзенең закончалыклары бар. һәм алар актерның индивидуаль психологик үзенчәлекләренә генә бәйле түгел. Актер иҗатына объектив һәм субъектив шартлар: чор таләпләре, әдәбиятта шул чорда өстенлек иткән әдәби агым юнәлеше, театр репертуары, артист башкарган образларның характеры, режиссура һ. б. факторлар зур йогынты ясый. Әлбәттә, сәхнәдә, теге яки бу театр репертуарында бу факторлар барысы бергә туры килгән очраклар сирәк була. Алар я драматургик материалда, я режиссура трактовкасында, я сәхнәне бизәү-җиһазлауда, яисә артист уенындагы кайбер моментларда аерым-аерым һәм берничәсе бергә чагыла алалар.

Үз чиратларында, романтик артистлар да төрле типта булалар. Шул ук төп үзенчәлекләре уртак булган М. Мутин, Ш. Шамильский, Ф. Ильская, Камал III ләр — төрле типтагы романтик актерлар. Аларның иҗат психологиясенә мөрәҗәгать итсәк, берәүләрдә — интеллектуаль романтик, икенчеләрендә — эмоциональ, ә өченчеләрендә исә һәм интеллектуаль, һәм эмоциональ романтик артистларга хас сыйфатларны күрербез.

Шулай ук, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә бүген иҗат итүче Ринат Таҗетдинов, Дания Нуруллина, Рәмзия Хисамовалар да — төрле типтагы романтик актерлар. Ринат Таҗетдинов иҗат иткән Кол Гали, Надир мәхдүм, Миркәй образлары үзләрен чолгап алган мохит кануннарына протест белдереп, аларны тулысынча кире кагалар; алар каһарман буларак гадәттән тыш ситуацияләрдә чыгыш ясыйлар һәм үзләренең рухи дөньяларын күп санлы антиидеал вәкилләренә капма-каршы куялар. Сәхнәдә авторларның образлы фикерен чагылдыру характеры, образны иҗат итү алымнары буенча болар, башлыча, интеллектуаль типтагы, аналитик планда гәүдәләндерелгән образлар.

[1] Г. Газиз. Яшь әдәбиятымызда яшь йөрәкләр.— «Аң», 1913, № 11, 191—192 битләр.
[2] Зәмин — җирлек.
[3] Истигъдад — сәләт.
[4] Г. Кәрам. Шәрык клубында театр вә музыка мөәссесенең икүне.— «Аң», 1913, № 11, 196 бит.
[5] СССРның халык артисты Арслан Мөбәрәков белән әңгәмәдән. 14 ноябрь, 1973 ел.

Дания Нуруллина башкаруында Айсылу («Миркәй белән Айсылу»), Айса («Күзләре нинди иде»), Юлия Тугина («Соңгы корбан»), Чәчәк («Кол Гали»)— символик сурәт яңгырашында ачылган образлар. Айсылу — халык күңелендә пакьлек, сафлык символы булган Зөһрә кызга тиң, Юлия Тугина — рухы, бөтен барлыгы белән шәфкать, миһербанлык идеалы, Чәчәк — шагыйрь йөрәгенә тугрылыгы белән Ләйлә, Ширин, Зөһрәләрне хәтерләтүче дала Гөле булып гәүдәләнә.

Дания Нуруллина сөйләм аша образ тудыру кодрәтенә ия. Артистканың сөйләмен характерлаучы төп сыйфат — сүзләрнең шигърияттен ачу, шагыйрь сүзләре белән әйткәндә, «авазы ширин» итеп бирү. «Кол Гали» спектакленнән бер картинаны алыйк. Уразбәк җәйләве, Гали тоткынлыкта. Монголларның яу килүләре хәбәр ителгән. Туфрак белән кан аралаш өерелгән болыт булып, дәһшәт килә. Һәркемнең күңеле менәменә убылып төшәргә торган мәгарә авызы кебек. Уразбәк Гали белән Чәчәк мәхәббәтенә фатиха бирергә мәҗбүр була. Шушы фаҗигане ярып, үлем көткән даланы яңгыратып, әле генә үзе дә өметсез сулып барган Чәчәкнең бәхет тавышы, яшәү, тормыш авазы яңгырый: «Бай бул, атам!»

Рәмзия Хисамовада бу фраза логик нәтиҗә буларак, газаплы кичерешләрдән азат ителгән күңелнең ихлас рәхмәте булып яңгыраса, Дания Нуруллина бу сүзләр белән Яшәү һәм Үлемнең эмоциональ контрастын тудыра.

Артистканың уен стилен романтик актерлар иҗатына якынайткан тагын бер үзенчәлек образлы фикерне хәрәкәт аша гәүдәләндерүдә чагыла. Шул ук «Кол Гали» спектакленнән финал күренешен алыйк. Чәчәк-Нуруллина хәрабәләр арасында чокынган Шәмсетдиннең тере мәет икәнлеген аңлап, кинәт торая, салмак адымнар белән авансценага юнәлә. Сүзләр әле әйтелмәгән, әмма горур гәүдә тотышы, һәйкәл сыман мәгърүр сын, алга омтылган караш аны шагыйрь иҗатының мәңгелек символы, сүзләр тирәнлегендәге мәгънә итеп күз алдына бастыралар.

Рәмзия Хисамова репертуарындагы Нәркәс, Чәчәк образлары исә үзләренең башкачарак сыйфатларында гәүдәләнәләр. Актриса үз героиняларының холкын үлчәп, детальләргә нык игътибар биреп уйный. Ул сыйфатлар автор һәм режиссерның образны күрү үзенчәлегенә буйсындырылганнар. Нәркәс һәм Чәчәк образларының романтик үзенчәлекләрен дә актриса авторлар һәм режиссер күзаллаган формада бирә.

Гомумән, Дания Нуруллина һәм Рәмзия Хисамова иҗатында эмоциональ романтикларга хас үзенчәлекләр өстенлек итә.

Татар театрында романтик пландагы сәхнә әсәрләре куелышында билгеле бер тарихи үсеш — эволюцияне күзәтергә мөмкин. Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә соңгы ун ел эчендә барган спектакльләргә генә мөрәҗәгать итсәк тә, шушы үсешнең дәвам итүен күрербез.

Театр репертуарында психологик драма, сатирик комедия, водевиль жанрындагы «Әни килде», «Ир-егетләр», «Американ», «Кыю кызлар», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Намус хөкеме», «Әнә килә автомобиль» спектакльләренең стиль чаралырын билгеләүдә реалистик пландагы художник буларак чыгыш ясаган режиссер Марсель Сәлимҗанов бүгенге татар театрын **романтик** характердагы спектакльләр белән дә баетты.

Әлбәттә, М. Сәлимҗанов татар театрына килү белән бүгенге дәрәҗәдәге төгәлләнгән романтик спектакльләр куя башламады. Режиссер иҗатында шушы юнәлешкә хас элементлар гәүдәләнгән беренче спектакль итеп Н. Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу» драмасын күрсәтергә мөмкин. Спектакльдә әсәрнең фольклорга якын моментлары көчәя, конфликтны образларның рухи дөньялары аша чишүгә омтылыш сизелә, аерым трагик моментлар (фанатикларның Айсылуны өшкерү сәхнәсе, Айсылуның буа өстендә Миркәй белән очрашуы) символик яңгыраш алалар. Әсәрнең нигезендә яткан романтизмга хас сыйфатлар үстерелеп бирелгән дип әйтә алабыз.

Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ын халык легендасына якынайтып сәхнәдә гәүдәләндерүе, Надир мәхдүм образының гомумкешелек идеаллары күзлегеннән карап сурәтләнүе, режиссерның «Миркәй-Айсылу» белән башланган романтизм эстетикасы принципларын дәвам итүе иде.

«Сүнгән йолдызлар»ның романтик планда сәхнәләштерелүе спектакльнең үзәгенә Надир мәхдүм образының куелуы белән нык бәйләнгән. Табигать тарафыннан кимсетелгән кешеләргә теләктәшлек итү, аларның гүзәл рухи сыйфатларын гәүдәләндерү — романтик художникларга хас үзенчәлек. Драматург К. Тинчурин каләме белән ул күренекле француз романтигы Виктор Гюгоның Квазимодосы тибында гәүдәләндерелгән. Режиссер драматург тарафыннан кабатланмаслык характер итеп иҗат ителгән Надир мәхдүмне алгы планга куеп, концепциясе һәм композициясе белән дә романтик сәхнә әсәрләренә җавап биргән спектакль тудырырга ирешкән.

«Сүнгән йолдызлар» спектакле татар театрында романтизм традициясен дәвам иттерүдә уңышлы адым иде. Бу спектакльнең, еллар үтүгә карамастан, театр репертуарыннан төшмәве, тамашачылар тарафыннан яратып каралуы күп нәрсә турында сөйли. Әмма шулай да, «Сүнгән йолдызлар»дагы Надир мәхдүмне романтик спектакльләрнең төп художество критерием тәшкил иткән романтик герой, каһарман шәхес таләпләренә тулысынча җавап биргән образ итеп карап булмый иде әле.

Сәхнәдә шушындый каһарман шәхескә хас үзенчәлекләрне күрүгә омтылыш театр репертуарына Илшат Йомаголовның «Нәркәс» романтик легендасын алып килде. Материалы белән төрки халыклары фольклорына якын торган легенданы хәтерләтүче бу әсәр бөек идеаллар, гадәттән тыш ситуацияләр, чатнап торган хисләрне гәүдәләндерүе белән татар сәхнәсендә Нурихан Фәттахның «Кол Гали» романтик трагедиясенә җирлек әзерләде.

Татар театрында романтизм табигый һәм урынлы күренеш. Рухи байлыклар матурлык һәм мәңгелек категорияләреннән чыгып бәяләнгән романтик спектакльләрдә уңай эстетик идеал өлгесе раслана. Романтик актерлар татар театрын югары сәнгать кималендәге образлар белән баетып, сәхнә иҗаты һәм актерлык осталыгында яңа үрләр яуладылар. Аларның бөек идеаллар, героик пафос, тирән шигърият белән сугарылган иҗатлары татар театр сәнгатен сәхнә натурализмыннан саклау юнәлешендә дә алыштыргысыз чара булып хезмәт итә.

Фәүзия **КАДЫЙРОВА.**

## Аркадий Файнберг

# ЯХШЫ ДА БУЛСЫН, ТӨРЛЕ ДӘ БУЛСЫН

Россия Федерациясендә рәсем сәнгате буенча беренче зональ күргәзмәләр үткәрелә башлауга ун елдан артыграк вакыт узды. Һәм шикләнмичә әйтергә мөмкин, Россиянең культура һәм промышленность үзәкләрендә дә, күп кенә зур һәм кечкенә шәһәрләрендә дә рәсем сәнгатен тагын да үстерү, аны яңа биеклеккә, заман таләпләре югарылыгына күтәрүдә ул күргәзмәләр көчле этәргеч ясадылар.

Үткән елның ноябрь аенда Горький шәһәрендә ачылган «Зур Идел» исемендәге дүртенче зональ күргәзмә анда катнашучы биш автономияле республика һәм тугыз өлкәнең рәссамнары өчен генә түгел, дистәләрчә һәм йөз меңнәрчә рәсем сәнгате сөючеләре өчен дә бер бәйрәм булды. Күргәзмәгә куелган әсәрләрнең шактый өлеше — художникларның КамАЗ төзелешендә, Татарстан нефть районнарында, Горький шәһәренең «Красное Сормово» заводында, Чувашстанның космонавт А. Николаев исемендәге колхозында аерым-аерым бригадалар булып эшләгән чорында иҗат иткән әсәрләре— күчмә күргәзмә сыйфатында быел Идел буе шәһәрләре буйлап сәяхәткә чыкты.

«Зур Идел» бәйрәмендә Татарстан рәссамнарының да ишле отряды — 57 рәсем сәнгате остасы катнашты, күргәзмә залларына аларның йөздән артык әсәре куелган иде.

Татарстанның куәтле индустрия һәм гигант төзелешләр республикасына әверелүе аның сәнгать төрләре үсешенә дә һаман тирәнрәк эз сала бара. Рәсем сәнгате буенча дүртенче зональ күргәзмәдә бу хәл аеруча ачык сизелде.

Татарстан художникларының эшчеләр сыйныфы темасына багышланган һәм хезмәт кешесе образын үзәккә куеп сурәтләгән әсәрләре «Зур Идел» экспозициясендә күренекле урын алдылар.

Рәссамнарыбыз эшче темасын һаман җитдирәк үзләштерә баралар. Сынлы сәнгать өлкәсендә ирешелгән казанышлар бигрәк тә куанычлы. Х. Якуповның «Татарстан алтыны», В. Скобеевның «Юл», «Кама өстендә акчарлаклар», И. Зариповның «Нефтьче Әхәт абый», И. Әхмәдиевнең «Безнең бригада...» һ. б. күп әсәрләр хезмәт кешесе темасын сәнгать чаралары белән гәүдәләндерүдә үзләре белән яңа табышлар алып килделәр. Бу әсәрләргә кеше характерын ачуда фәлсәфи тирәнлек, поэтик күтәренкелек хас. Композицион алымнарда төсләр палитрасын сайлаудагы төрлелек күзгә ташлана. Алар идея эчтәлекләренең җитдилеге белән дә, сынландыру үзенчәлекләре, форма тәгәллеге, яңгыравыклы мажор төсләре белән дә күргәзмәдә игътибарны җәлеп иттеләр. Шунысын да әйтеп китәргә кирәк, рәсем сәнгатебезнең төп темасы булып әверелгән хезмәт кешесенең киң масштаблы образларын тудыру процессында рәссамнарның төрле жанрларда эшләүче өлкән һәм яшь буыны катнаша. Мисал өчен. портрет жанрын гына алыйк. Соңгы ун елда бу өлкәдә бик аз кеше эшләде. Күргәзмәдә булган әсәрләр исә портрет жанрында да үзгәреш башлануын раслый. Татарстанның халык художнигы В. И. Куделькин күргәзмәдә өч портрет күрсәтте. «КамАЗ хатын-кызлары», «Монтажчы Рәис Ганиев», өлкән әдибебез Нәкый Исәнбәт портретларындагы тирән эчке динамика, композицион тәгәллек,

нечкә зәвык бу рәссамның иҗат осталыгы тагын да үсүе хакында сөйлиләр.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Е. А. Симбирин «Ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое А. Улесов портреты»нда каһарман характерны калку да һәм тирән дә итеп гәүдәләндерүгә ирешкән. Яшь рәссам Рәшит Имашевның «Хат», «Геодезистка», «Маляр Р. Рафикова» портретларында да сизелерлек алга китеш күзгә ташлана. Ул әсәрләр күңелгә яктылык һәм җылылык сирпеп торалар. Ләкин образның бөтенлеген, рухи тирәнлеген чагылдыруда портрет сәнгатенең чын нечкәлекләренә ирешү өчен Имашевка да, башка яшь рәссамнарыбызга да армый-талмый эшләргә кирәк әле.

Портретчының осталыгы, мәгълүм булганча, ике аспектта — кеше психологиясенә тирән үтеп керүдә һәм образны сынландыруның эстетик камиллегендә чагыла. Портрет жанры иҗтимагый күтәренкелек, шәхескә игътибар көчәю чорларында аеруча чәчәк ата. Художникларыбызның бу жанрны актив үзләштерә башлаулары шатлыклы күренеш, әлбәттә. Әмма портретчыларыбыз алдындагы таләпләрнең дә үсә баруын истән чыгармаска кирәк.

Урта Идел табигатенең гүзәллеге элек-электән рәссамнарны пейзаж сәнгатенә җәлеп иткән. Шишкин, Саврасов, Левитан кебек классикларның данлыклы пейзаж рәсемнәрен искә төшерик. Татарстанда да бүген пейзаж осталары шактый һәм аларның уңышлы әсәрләрен күпләп санарга мөмкин. РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Н. Д. Кузнецовның «Нефть чыга», «Кышкы көн. Миңнебай газ-бензин заводы», М. У. Усмановның «Кама буендагы яңа шәһәр» кебек әсәрләре үзләренең романтик буяулары, индустриаль пейзаж ритмнарын бирүдәге төгәллекләре белән аерылып торалар. А. Л. Прокопьевның «Язгы көн» картинасы яз табигатен сурәтләүдәге нечкә төсмерләре, сафлыгы белән күңелне иркәли. А. М. Родионов «Камада» исемле әсәрендә гүзәл елга образын лирик һәм эпик яңгырашта чагылдыруга ирешкән.

«Зур Идел» күргәзмәсе графика өлкәсендә җитди үзгәрешләр баруын күрсәтте. Эмиль Ситдыйковның «Баулы нефтьчеләре» дигән линогравюралары, В. А. Попов, Рәшит Госмановның Кама автогиганты күренешләренә багышланган акварель рәсемнәре графика жанрында художникларның эшчеләр темасына кыю борылыш ясаулары хакында сөйли. Әмма графика бу өлкәдә тәҗрибә туплау чорын гына кичерә әле. Тулаем алганда, ул сынлы сәнгать жанрыннан арттарак кала. Ә югыйсә, графика, оперативрак, хәрәкәтчәнрәк жанр буларак, юл ярып барырга тиеш иде бит.

Кимчелекләр турында сөйләгәндә, әлбәттә, скульптураны да читләтеп үтеп булмый. Соңгы еллар эчендә скульпторларыбыз сүлпәнрәк эшләделәр, эшләнгән кадәресе дә фәкать портрет жанрына гына карый. В. М. Маликов, Р. Х. Нигъмәтуллина, В. И. Рогожин һ. б. скульпторларның киләчәктә активрак иҗат итүләрен телисе килә.

Гамәли-декоратив сәнгатьнең дә тормыш таләпләреннән артта калуын әйтми булмый. Бу төр сәнгатьнең бездә күп гасырлык традицияләре бар. Хәзерге чорда исә халыкта гамәли-декоратив сәнгать әсәрләренә ихтыяҗ бик нык артты. Керамика, ювелир, металлны чокып, сөяк һәм агачны кисеп ясау осталарының эшен киләчәктә күп тапкырлар тизләтәсе бар.

Художникларыбыз социалистик реализм сәнгатенең үзәк темасы булган эшчеләр сыйныфы темасына йөз белән борылдылар. Бу борылыш сәнгатьнең идея эчтәлеген дә, художество чараларын да баетуга ярдәм итте. Художникларның яшь буыны өлгереп җитү — республикабыз сәнгать тормышында икенче куанычлы хәл. Яшьләрнең иң уңышлы әсәрләре бүген Татарстан рәсем сәнгате казанышларының мөһим өлешен тәшкил итә. Димәк, идея ягыннан өлгергән, югары профессиональ хәзерлек алган яшь алмаш үсә дигән сүз.

Татарстанда рәсем сәнгате учаклары елдан-ел арта бара. Лениногорск, Бөгелмә, Әлмәт, Чаллы, Түбән Кама, Алабуга, Чистай, Зеленодольск шәһәрләрендә сәнгать тормышының яңа үзәкләре барлыкка килде. Моның гаять зур социаль-политик әһәмияте бар.

«Зур Идел» күргәзмәсенең сюжетлы-тематик картиналар бүлегендә Татарстан художникларының рәсемнәре иң күренекле урыннарның берсен алып торды. Ә әсәрләрнең гомуми колориты исә яшьләрчә дәртлелек, күтәренкелек, яңа буяуларга бай булулары белән игътибарны тартты. Болар барысы да республикабыз рәсем сәнгатенең киләчәге өметле икәнен күрсәтә, Казан художество мәктәбенең данлыклы традицияләре дәвам итәчәге һәм яңа сыйфатлар, үзенчәлекләр белән байый барачагы турында сөйли.

Светлана Червонная

# БЕЗ КАЗАННАН, ИДЕЛДӘН

„Зур Идел» зональ күргәзмәсенә Татарстаннан килгән сәнгать әсәрләрен күз алдыннан үткәргәндә күңелдә Сибгат Хәкимнең мәгълүм шигъри юллары яңгырый башлый. Чынлап та, «Хезмәткә дан» девизы астында барган бу күргәзмә, совет Татарстаны рәсем сәнгатенең бүгенге казанышлары йөзендә, аның хезмәт сөючән кешеләренең данлы эшләрен, бөек Идел белән бәйле күп төрле киеренке хезмәт ритмнарын, аның яшь һәм төзелеп ята торган шәһәрләре панорамасын, бөтен тормыш сулышын калку итеп гәүдәләндерә. Алай гына да түгел, күргәзмәдә катнашкан рәссамнарның әсәрләре, С. Хәким шигырен куәтләп, безгә татар совет халкының милли горурлыгы хакында сөйлиләр, Ватаныбыз күләмендә башкарыла торган эшләргә аның турыдан-туры катнашы булуын, совет халкы дип аталган бөек тарихи бердәмлектә, күп милләтле зур Иделдә аның лаеклы урынын раслыйлар кебек. Без — совет Россиясеннән, халыкларның бөек туганлыгы иленнән, диләр алар, һәм шул ук вакытта, без — Казаннан, без — совет Татарстаныннан, үзебез өчен чиксез сөекле һәм газиз туган ягыбыздан, диләр.

Интернациональлекнең һәм миллилекнең, гомуми һәм хосусиның шушындый берлеген татар рәссамнарының «Зур Идел» күргәзмәсендәге бик күп әсәрләрендә күзәтергә мөмкин.

Харис Якуповның «Татарстан алтыны» дигән картинасы нефтьчеләр тормышына багышланган. Бу символик исемдә республиканың «кара алтыны»на гына түгел, ә аның төп хәзинәсе — хезмәт сөючән кешеләре, эшчеләр сыйныфына да ишарә ясала. Картина аларның образларын зур планда гәүдәләндерә.

Ачык куе төстәге буяулар әсәргә көч һәм сафлык биреп торалар. Буяуларның чиратлашуларында кыюлык, тәвәккәллек, шул ук вакытта көр күңеллелек сизелә. Олы яшьләрдәге эшченең муенындагы куе кызыл шарфы, кызның чуар чәчәкле зәңгәр яулыгы, кызарып торган кара-кучкыл йөзе, кара сумала чәчләре, фирәзәне хәтерләтүче зәңгәр күзләре, ачык төстәге киемнәр, нефть суыргычның торбаларындагы ялтырап торган кызыл лак — болар барысы да ерактан ук күзгә ташлана, дөньяның шундый күп төслелегеннән ләззәтләнү хисен алып килә.

Картина фонындагы пейзаж күренеше дә әсәрнең эмоциональ эчтәлеген баетуга хезмәт итә. Артта җәелеп киткән алтынсу киңлек, алгы пландагы көзге миләш ботагы — болар милли традицияләргә табигый ятышып торган үзенчәлекле купшы декоративлык өсти, сынлы сәнгатьне татар халык иҗаты дөньясына, милли чигү-бизәк традициясенә илтеп тоташтыра; болар барысы да милли эстетик зәвык үзенчәлекләренә туры килә.

Әмма картина эчке корылышы, сынландыру концепциясе буенча татар сәнгать культурасы традицияләрен чагылдырса, мәгънәсе, салынган эчтәлеге, фикере буенча ул — бөтенләй яңа, үзенә бертөрле күренеш.

Картинаның героен тамашачыга якынайту, кеше образын эре планда, хәтта натураль зурлыгыннан да эрерәк планда күрсәтү, фигуралар киселеше, кадрларга бүлгәләүдә кинокадрларны хәтерләткән кыю алымнар, теге яки бу детальне график төгәллек белән сурәтләү — болар бары да бүгенге совет сынлы сәнгатендә новаторларча эзләнүләрнең алгы сызыгында торучы перспектив юнәлешнең характерлы билгеләре булып исәпләнә; һәм шушындый стиль тенденцияләренең татар сәнгатенә үтеп керүе аны яңа сыйфатлар белән баетмыйча, аның эстетик һәм психологик йогынты колачын киңәйтмичә калмый.

Әнә шул рәвешчә, картинаның якты яңгырашлы колоритында, гомуми декоратив төзелешендә ачык чагылган милли традицияләр белән башка халыкларның

иҗат тәҗрибәсеннән, тугандаш милли культуралар казанышларыннан килгән стиль тенденцияләре арасындагы үзара бәйләнеш бу әсәрдә үзен сиздертеп тора. Шушы үзара йогынтыны без әлеге әсәрнең художестволы формасын билгеләүче үзенчәлекләрдә генә түгел, аның идея эчтәлегендә гәүдәләнгән миллилек һәм интернациональлекнең җанлы диалектикасында да күрәбез.

Кемнәр соң алар — эре масштаб белән картинаның алгы планына чыгарылган яшь егет, олы яшьләрдәге эшче агай һәм алсу йөзле, кара чәчле кызыкай? Җавапны ике төрле итеп бирергә мөмкин, әмма шул ике яклылыгында аның бердәмлеге чагыла.

Алдыбызда — чын совет кешеләре, замандашларыбыз, эшчеләр сыйныфы вәкилләре; һәм шул ук вакытта безнең алда, һичшиксез,— татар милләте кешеләре, рәссамның якташлары, үзләрендә татар халкының типик сыйфатларын берләштергән затлар.

Бу билгеләрнең берсен икенчесеннән аерып алырга мөмкин түгел, алар берсе икенчесе аша гәүдәләнә, берсеннән башка икенчесе яшәми. Картина геройларында ниндидер гадәттән тыш, «саф» татарныкы гына дип аерып куярлык, гомуминең, совет характерының чагылышы дип әйтеп булмаслык берни дә юк. Алар миллилектән каядыр читтә ята торган, йөзсез-төссез, абстракт төшенчә дә түгел: интернациональлек менә шушы йөз-кыяфәттә, шушы күз карашларында, җанлы кешеләрнең конкрет чалымнарында, үзүзләрен тыныч һәм лаек тотышында.

Автор геройларының милли сыйфатларын сурәтләүгә бик сак килә, түбәтәй кидереп куюя яки шуның ише штампка әйләнгән архаистик алымнардан ерак тора. Шул ук вакытта ул образларның һәр чалымында милли поэтиканы нечкә тотып ала. Авторның туган җиренә мәхәббәте, үз республикасының эшчеләр сыйныфы белән горурлану хисләре ачыктан-ачык яңгырый.

Әлбәттә, картинаның бөтен эчтәлеге миллилек һәм интернациональлек мәсьәләсенә генә кайтып калмый. Характерларны индивидуальләштерү, персонажларны группага бер бөтен итеп берләштерү, образларның психологиясен ачудагы күп планлылык h. б. мәсьәләләр анда кызыклы хәл ителгән.

Художник тормышта да, кешеләрдә дә нәрсәне дә булса артык гадиләштерергә омтылмый. Һәм «Татарстан алтыны» бары тик байлык, шатлык темасыннан гына тормый, анда көзнең күңелләрне чеметеп ала торган моңсулыгы да бар. Образларның трактовкасы исә кешенең көч-куәте, буй-сыны, батырлыгы һәм ихтыяр ныклыгына сокланугa гына кайтып калмый. Картинада художникның кеше күңеленә игътибар белән төбәлүен, күңел дөньясын тирәнтен аңларга тырышуын, нинди дә булса хәрәкәтне түгел, ә фикерне укырга, күңел талпынышын, әле шатлык-сөенечен генә дә түгел, ә моңсу бер халәтен, борчылу-уйлану, нәрсәнедер эзләнү-юксыну минутын тотып алырга теләвен, кешеләрнең рухи яшәешендәге күп яклы төсмерләрне чагылдырырга омтылуын тоясың.

Илдар Әхмәдиевнең «Безнең бригада. Туй истәлеге итеп» дигән картинасы бу художникның сынлы сәнгатьтә ирешкән иң зур казанышы дип саналырга лаек. Зур тукымалы сынлы сәнгать әсәрләренә тотынуына аның әле күптән түгел. КамАЗ төзүчеләренә багышланган беренче әсәрләре профессиональ камиллекләре ягыннан бәхәскә урын калдырсалар, хәзер инде, бу зур һәм катлаулы әсәрне күргәннән соң, Әхмәдиевнең сәләтле график, карикатурачы, иллюстрация остасы гына булмыйча, сюжетлы-тематик картина тудыру кебек катлаулы эшне уңышлы башкарып чыга алырлык нечкә, мөстәкыйль рәссам икәнлегенә шик калмый.

Миллилек һәм интернациональлекнең үзара бәйләнеше, Х. Якупов картинасы белән чагыштырганда, бу әсәрдә башкачарак гәүдәләнеш тапкан. Алда сөйләнгән картинада персонажларның үзаңы, рухи дөньялары һәм милли, һәм сыйныфый яклары белән, шушы ике сыйфатның аерылмас бөтенлегендә ачылган булса, Әхмәдиев игътибарны бу бөтенлекнең икенче ягына күчерә. Дуслык, туганлык турында сөйли аның әсәре. Безнең алдыбызда — гади бер эшче бригадасы. Җирдә үз куллары белән яңа промышленность гигантлары, шәһәрләр төзеп, тарихның яңа сәхифәләрен язучы ул кешеләрне идеаллар уртаклыгы, яңа коммунистик мораль бергә берләштергән. Алар арасындагы милли аерымлыклар художник өчен монда ул кадәр үк мөһим түгел, әсәрдә алар аз-аз гына төсмерләнә. Картинаның сюжеты итеп туй күренеше

алынган. Күрәсең, яңа гаилә җепләре рус егете белән татар кызын бергә бәйләгән — милли типаждагы сизелер-сизелмәс кенә сурәтләнгән аерымлыклар шуңа ишарәли. Әмма бу детальләрне автор мәхәббәт һәм милли романтика темасын үстерү өчен кулланмый, моның белән ул, киресенчә, милли аерымлыкларның югала баруына, кешеләрнең һәм милләтләрнең яңа гомумилек нигезендә берләшүләренә басым ясый. Туй йоласында шулай ук рус яки татар милли архаикасына алып китә торган нинди дә булса билгеләр күренми. Бу совет һәм комсомол йоласы, илебезнең миллионнарча яшьләре тарафыннан кабул ителгән йола. Картинаның фонын тәшкил итүче гаять зур төзелеш пейзажы туй атмосферасын эмоциональ яктан ача: яңа шәһәр, яңа завод, яңа дөнья белән бергә яңа, яшь гаилә туа.

Әсәрнең мотивы бик гади һәм уңышлы табылган. Бригада кешеләре, туй истәлеге итеп, группа белән фотога төшәләр. Һәм художникның табышы — күзгә күренмәгән фотоаппарат алдында торучы кешеләрнең беркатлы табигый һәм риясыз позаларын эләктереп алуында да инде. Әхмәдиевнең китап иллюстрацияләүдәге тәҗрибәсе аңа сынлы сәнгатьтә дә әдәби башлангычны, сюжет фабуласын иркен табарга һәм үстерергә мөмкинлек бирә. Әлеге әсәрдәге фотога төшү мотивы табылу һәр яктан камил, тәгәлләнгән фронталь композиция төзүгә ярдәм итә.

Бер эшче бригадасы кешеләренең рухи якынлыгы — бердәм интернациональ эшче семьясы темасын автор, шул рәвешчә, тирән һәм ышандырырлык итеп ача. Монда бәлки тик бер генә нәрсәне искәртеп үтү кирәктер. Картина безгә әйтә сыман: «Без — эшче кешеләр, без яңа дөнья төзибез һәм син русмы, татар яки башка бер милләттәнме, безгә барыбер. Безнең семья члены булу хокукын бөтен совет кешеләренә хас булган югары әхлакый сыйфатлар билгели».

Бу, һичшиксез, дөрес. Миллилек һәм интернациональлек проблемасын нәкъ менә КамАЗ кебек бөтен халык төзелешендә шушы рәвешчә хәл итүе белән художник хаклы. Әмма шулай да милли сыйфатларны берьюлы игътибардан төшереп калдыруда, ихтимал, беркадәр сабырсызлык, алга сикерү дә бардыр. Ихтимал, тормышта барысы да бераз катлаулырактыр, дәвамлырак процесста хәл ителәдер.

«Юл» һәм «Кама өстендә акчарлаклар» исемле картиналарында Валерий Скобеев шушы ук юлдан тагын да ары рак китә. Әсәрләрнең икесе дә безнең сынлы сәнгатькә көчле романтик яңгыраш алып килүе, аның стилистик чараларын поэтик символика алымнары белән баетуы, метафорик мәгънәдәге образларда хезмәт батырлыгы темасын яктыртуы белән әһәмиятле. Әмма тормышта һәм художестволы образларда миллилек һәм интернациональлек башлангычларының диалектик бәйләнеше ягыннан караганда, художник, безнең уйлавыбызча, бераз ашыга, бүгенге көннән алгарак уза һәм, ахрысы шуңадыр, тормыштагы кайбер мөһим үзенчәлекләрне күрми уза, гүзәллекнең бер өлешен югалта. Аның геройлары антик аллалар белән чагыштырырлык гүзәлләр, әмма шул ук вакытта, бездән читтәрәк, үзбашрак яшиләр. Аларга анык лык, күңел җылысы җитми сыман, аларның камиллеге ничектер салкынрак.

Гомумән алганда исә, заман темасының шушындый идеаль-романтик планда чишелеше дә, 70 нче еллар сәнгатенең үсеш юнәлешләреннән, яссылыкларыннан берсе сыйфатында, әлбәттә, яшәргә хаклы. Ләкин бу юнәлешнең бераз чикләнгәнрәк булуы бүгенге татар сынлы сәнгатенең икенче бер яссылыктагы әсәрләренә үзенә күрә бер ямь, кыйммәт өсти. Сүз — үзе белән туган җир һавасын алып килүче, анык җирлектә туган һәм шул җирлеккә нык бәйләнгән әсәрләр турында бара. Халык тормышының традицион-архаик яклары белән мавыгу һәм аны күпертеп күрсәтү сәнгатьтә икенче бер чикләнгәнлеккә алып китәргә мөмкин икәнлеген онытырга ярамый, әлбәттә. Әмма чын милли романтиканы исәпкә алмау да дөрес булмас иде, чөнки ул романтика тормышның үзеннән килә, һәм безнең яшәешебез аннан башка, мөгаен, ярлырак, төссезрәк тә булыр иде. Үз вакытында бу хакта татар әдәбияты классигы, сәнгать теоретигы һәм идеологы Галимҗан Ибраһимов чын коммунистларча ышанганлык белән язган иде. Ул пролетар революциянең милли культураларны үстерү өчен киң мәйдан бирүен, социализм шартларында аларның үсүен, баюын, яңаруын, халыкның үзе тарафыннан, үз тормыш материалында, ана

теле җирлегендә, үз ихтыяҗларына ярашлы рәвештә тудырылган кыйммәтләр милли культураның төп элементлары булуын күрсәткән иде [1].

Үз иҗатларында художникларның милли культура элементларына мөрәҗәгать итүләре, бу җәһәттән, тирән эстетик мәгънәгә ия.

Рөстәм Килдебеков «Натюрморт» картинасында Арча милли аяк киемнәре фабрикасында халык сәнгате традицияләрен дәвам иттерүче осталарның хезмәтен бик җылы һәм оста күрсәтә алган. Төрле төсләрнең чиратлашуы, идәнгә тезеп куелган читекләрнең купшы бизәкләре — болар халык иҗатының тылсымлы чишмәләре хакындагы матур поэма булып яңгырыйлар.

Илдар Зариповның «Нефтьче Әхәт абый» дигән әсәрендә дә милли форма үзенең матур гәүдәләнешен тапкан. Картинаның герое, бүгенге заманның эшче һөнәренә ия кеше, бөтен тышкы кыяфәте белән күптәнге һәм гадәти авыл тормышкөнкүрешен күз алдына бастыра. Геройның өстендәге киеме һәм килеш-килбәте, ак йон оегын киеп кровать өстендә утыруы, пөхтә итеп җыештырылган чиста өй эче, барлык җылы һәм якты төсләр гаммасы — барысы да бу кешенең күңелгәен, табигый шартларда ачылып китүенә ярдәм итәләр. Без аның күңел пакьлеген, җан җылысын тойгандай булабыз. Көлүдән йөзенең тагын да җыерчыкланыбрак китүе, соялле зур эшчән куллары — алар бу образга карата якынлык, ышаныч хисе тудыралар, чөнки монда һәрнәрсә тормыш чынлыгына нигезләнгән.

Халык культурасының бай традицияләре, көчле һәм нык характерлар белән кызыксыну, иҗат йөзләре, тәҗрибә һәм талантлары төрле булган рәссамнарны бер-берсенә якынайта. Мисал өчен, татар тематик картинасының танылган остасы, милли классикага әверелгән күп әсәрләрнең авторы Лотфулла Фәттаховның «Юллар-юллар» дигән әсәрен генә алыйк. Бу картина да шул ук теманы дәвам итә, халыкның үз эченнән совет Татарстанының яңа гражданины формалашуы, шушы җирлеккә, аның традицияләренә, кешенең рухи бишеге — туган җиренә өзелмәслек җепләр белән бәйләнгәнлеге хакында сөйли. Бу теманы рәссам әдәби сюжетта, хәрәкәттә, ана кешенең үз улын юлга озату күренешендә ачкан.

Тормышның үзе кебек үк мәңгелек игенче хезмәтенә художник Варис Хәсәнов «Икмәк» дигән картинасын багышлаган. Автор бүгенге колхоз тормышы шартларында әлеге теманың яңалыгын күрсәтүгә, югары поэтик гомумиләштерүгә ирешкән. Әсәр җыйнаклыгы, төсләрнең ачык җиңеллеге белән аерылып тора. Кояш нурларында коенучы яңа сугылган ашлык өеме, ындырдагы игенчеләр, ак җәймә өстендәге натюрморт, кайнар рәшә белән дулкынланып торган аксыл-зәңгәрсу күк йөзе бер бөтен булып күз алдына баса.

Миллилекне интернациональлектә чагылдыру проблемасын хәл итүдәге төрле юнәлешләрне бүгенге татар графикасында да күзәтергә мөмкин. Мәсәлән, акварель сәнгатендә төрле алымнар һәм тенденцияләр аеруча ачык чагыла. Гайшә Рахманкулова акварельләре төсләрнең интенсивлыгы, асылташны хәтерләтүче декоратив сыйфатлары (бигрәк тә «Татар оеч» дигән композиция) белән милли романтикага тартым. Рәшит Госмановның тыныч, йомшак төсләргә манылган, әле үтә күренмәле сафлыгы, әле көмеш томан өртелгән серлелеге белән үзенә җәлеп итүче пейзажларында патриотик башлангыч көчле гәүдәләнә («Казан Кремле стеналары янында» һ. б.). Шул ук Р. Госманов һәм Вл. Поповның КамАЗга багышланган һәм индустриаль гүзәллекне чагылдыручы акварель серияләре игътибарга лаеклы.

Индустриализация һәм техника прогрессы чоры кешеләре Эмиль Ситдыйковның да «Баулы нефтьчеләрендә» дигән график сериясе үзәгендә тора. «Юл», «Буровой янында», «Нефтьче» кебек рәсемнәр җир куенынннан байлык табучы, авыр һәм куәтле машиналарны хәрәкәткә китерүче, корыч ихтыяры, энергиясе белән тормышны һәм үз-үзен үзгәртүче, яңартучы хезмәт иясе кешесенә гимн булып яңгырыйлар. Ул кешеләр — аллалар да, роботлар да түгел, алар безнең танышлар, күршеләр, дусларыбыз, алар — без үзебез. Һәм татар рәссамнарының каһарман характерларны нәкъ менә шундый гади кешеләр арасында күрә белүләре аларның дөрес юлдан барулары хакында сөйли, иҗади мөмкинлекләренең киләчәктә дә тирән мәгънәви эчтәлектә реальләшүенә ышанычны ныгыта.

[1] Г. Ибраһимов. Пролетар революция һәм социалистик төзелеш шартларында татар культурасының язмышы, (Доклад.) Казан, Госиздат, 1927, 28 бит.

Флүн Мусин

# ЗАМАН ГЕРОЕНА ЙӨЗ ТОТЫП

**Хәзерге татар әдәбиятында коммунист образы**

Тормыштагы һәм кешеләрдәге яңаны тирәнтен тою, аны калку итеп күрсәтергә омтылу — совет әдәбиятының иң мөһим сыйфатларыннан берсе. Ул үзе дә Бөек Октябрь тудырган яңалык белән рухланып һәм шуны җырлап дөньяга килде. Беренче адымнарыннан ук аның алдына яңа кеше мәсьәләсе басты. Бу геройның җанлы прототипларын совет язучылары барыннан да элек В. И. Ленин «эпохабызның акылы, намусы һәм вөҗданы» дип атаган Коммунистлар партиясе сафларыннан эзләделәр һәм эзлиләр. Бу бик табигый хәл. Чөнки коммунист пролетар революцияләр һәм социализм заманының үзәк фигурасына әверелде. Социалистик Ватаныбыз тарихының барлык дәверләрендә — совет халкы өстенә күп тапкырлар төшкән авыр сынаулар вакытында да, тыныч хезмәт көннәрендә дә Коммунистлар партиясе җәмгыятебезгә юл күрсәтүче якты маяк, аны әйдәп баручы көч булды. Һәм хәзер дә шулай булып кала. Тарих сынауларын уңышлы үтеп, ул заманыбызның иң авторитетлы политик көченә, халык массаларының коллектив җитәкчесенә әверелде. Коммунистка хас сыйфатлар турында КПССның XXIV съезды трибунасыннан күренекле совет язучысы А. Чаковский хаклы рәвештә болай диде: «Ул, коммунист, үзендә гаделлек турындагы хыялны җиңүгә омтылыш белән, хезмәт ияләренә мәхәббәтне изүчеләргә һәм эксплуататорларга нәфрәт белән, партия оештыручысы талантын фәнни белемнәр белән бәйләде. Ул, коммунист, патша төрмәләрендә газап чикте, ул Кышкы сарайны штурмларга барды, интервентларга отпор оештырды, ач-ялангач хәлендә, ачыккан халыкка дип җыйган икмәкә кагылмыйча, ул массаларны илне аякка бастыру эшенә туплады, халык белән, халыкны җитәкләп беренче совет завод-гигантларын һәм беренче колхозларны төзеде һәм ул ук беренче булып үзенең гәүдәсе белән фашист дотларының амбразураларын каплады, ул җир орбитасына безнең спутникларны чыгарды, ул беренче булып космоска юл алды».

Шундый эшләре һәм сыйфатлары белән коммунист совет халкының тирән ихтирамын һәм ышанычын яулады. Шуның өчен дә ул совет язучыларының да һәр вакыт игътибар үзәгендә тора, аларны үз әсәрләрендә көчле һәм масштаблы характерлар тудыруга рухландыра. Моны татар әдәбияты мисалында да ачык күрергә мөмкин.

Әйтергә кирәк, большевик, заманның яңа һәм чын герое буларак, татар язучыларын революциягә кадәр үк кызыксындыра башлый. Бу яктан Габдулла Тукайның идея-эстетик эзләнүләре аеруча игътибарга лаек. Билгеле булганча, Тукай әдәбияттагы беренче адымнарыннан ук дөньяда гаделлек һәм тигезлек өчен, изелгән һәм кимсетелгәннәрнең бәхете өчен актив көрәшүче геройлар турында хыялланып язып һәм иҗат итә. Үзенең шушы хыялын чагылдырып, ул «Хиссияте миллия» исемле мәкаләсендә (1906), мәсәлән, болай язды: «Милләт... халык файдасын һәр төрле үзенең шәхси мәнафигыннан вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә газиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ... Безнең милләт тә, башка милләтләрдәге кебек, хамисез[1], мәлҗәэсез[2], фәкыйрь вә эшче

[1] Хамисез — яклаучысы булмаган.
[2] Мәлҗәэсез — сыена торган урыны булмаган.

халыкның файдаларына тырышучы, биш фәкыйрь кешене бер бай этенә алмаштырыр вакытлар үткәнлеген аңлаучы вә аңлатучы егетләргә мохтаҗ»[1].

Баштарак Тукай мондый каһарманнар турындагы хыялын шәкертләр белән бәйли, аларга зур өметләр баглый. Әмма тора-бара ул заман каһарманнарын кызыл байраклар астында патша самодержавиесенә каршы ачыктан-ачык көрәшкә күтәрелүчеләр арасында эзли башлый. Һәм ялкынлы революционер — большевик Хөсәен Ямашев йөзендә шагыйрь нәкъ менә шул үзе күрергә хыялланган геройны таба. Ямашевның халык ирекe һәм бәхете өчен куркусыз көрәшче сыйфатлары Тукайга Беренче рус революциясеннән соңгы елларда тагын да ачыграк булып күренәләр. Бу чорда, шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк, кара реакция башланып, «тик кыямәт көнгә калды хаклар истирдат кире»[2] һәм әле кичә генә: «Бу куллар мәңге, дип, җиргә салынмас», дип, халык байрагын күтәреп юлга чыккан кешеләрнең байтагысы: «Егетләр! Бездә көч юк, ахры, булмас!» дип, «ике-өч чакрым да китми» егылалар. Менә шундый шартларда Ямашев электәге энергия һәм тырышлык белән үзенең революцион эшен дәвам итә, халык массаларын царизмга каршы яңа көрәшләргә әзерли. Болар белән Ямашев Тукайның тагын да тирәнрәк ихтирамын һәм мәхәббәтен яулап, аның өчен халыкка турылыклы хезмәт итүнең үрнәге, гражданин һәм көрәшче идеалы булып тора. Шагыйрьнең бу идеалы «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» исемле мәгълүм шигырендә ачык чагылыш таба. Тукай Ямашевны әле «көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез» белән, әле «язда елмайган кояш» белән чагыштыра. Шагыйрьгә бу революционер үткен акыллы булуы, тормыш пычрагын «гәүһәр кеби вөҗдан белән» үтүе, явызлыкка каршы армый-талмый көрәшүе белән кадерле. Менә шундый сыйфатлары Ямашевны шагыйрь алдында башка бик күпләрдән өстен итәләр, якты йолдызга әверелдерәләр. Әмма биредә шуны истә тотарга кирәк: гәрчә Тукай А. Н. Бахның «Ачлык патша» дигән революцион брошюрасын татарчага тәрҗемә итсә дә, ул Ямашев алып барган көрәшнең политик асылын аңлаган, бу шәхесне большевик рәвешендә белгән дип өзеп әйтеп булмый. Шул заманда туып килгән тарихи хакыйкатьне — большевикның яңа эпоха герое төсендә мәйданга чыгуын Тукай әле күңеле белән генә сизенгәндер, күрәсең.

Революциягә кадәрге прозабызда исә большевик образына беренчеләрдән булып «Безнең көннәр» романында Г. Ибраһимов мөрәҗәгать итте һәм бу геройны сәнгатьчә гәүдәләндерүнең беренче үрнәкләрен бирде.

[1] Г. Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда, 3 том, Казан, 1956. 90 бит.

[2] Хаклар истирдат кире — тартып алынган хокукларны кире кайтарып алу.

Коммунист-революционер образы безнең әдәбиятта революциядән соң аеруча тулы чагылышын тапты. Татар совет язучыларын коммунист шәхесе башта ук, беренче чиратта, революция тудырган яңа кешене сәнгатьчә гәүдәләндерү ноктасыннан кызыксындыра. Бу кешенең тормыштагы иң ачык һәм күркәм гәүдәләнешен татар совет әдәбиятының беренче буын вәкилләре үзләренең бөек замандашлары В. И. Ленинда күрәләр. Революция юлбашчысын эпохабызның яңа көрәшче герое, дөньяны революцион үзгәртеп коручы итеп аңлау әдипләребезнең 20 нче еллар башындагы публицистик чыгышларында ук сизелә башлый. Бу яктан Ф. Әмирханның 1920 елда язылган бер мәкаләсенең исеме үк игътибарга лаеклы. Ул «Ленин иптәш — төзү, яңартып кору символы» дип атала. Анда юлбашчы болай бәяләнә: «Ленин иптәш Россия революциясенең искене вату, буржуазный тормышны җимерү дәверендә кыю фикерле, каты куллы, икеләнү һәм йомшаклыкны белмәс юлбашчы иде. Бу дәвер юлбашчыдан шуны таләп итә иде. Шул ук Ленин иптәш революция(нең) икенче дәверенең, яңартып кору дәверенең дә лозунгларын иң әүвәл ыргытучы, иң алдан ул дәвернең әләмен күтәрүче һәм үзенә генә махсус бер гайрәт белән пролетариатны шул әләм артыннан ияртә белүче булды. Әле граждannар сугышы янгыны ялкыннары басылмаган, әле революция(нең) беренче дәверенең табигый барышы акрынларга өлгермәгән бер көннәр иде. Ленин иптәш шик вә шөбһә белмәс бер энтузиазм, арулуны белмәс бер гайрәт, сүрелүне белмәс бер ышаныч белән:

— Иҗат, төзү, яңартып кора башлау! — лозунгларын ныгытты, иҗади хезмәтнең инде кан төсле түгел, бәлки офыклардагы төсле, кызыл әләмен күтәрде»[1].

Ленин шәхесен шушы рәвешле аңлап, яңа герой мәсьәләсен сәнгатьчә хәл итү эшен әдипләр байтак дәрәҗәдә революция юлбашчысының үлемсез образын тасвирлаудан башладылар. 20 нче еллар татар әдәбиятының бу өлкәдәге иң зур казанышын Һ. Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы (1924) тәшкил итте. Аңарда шул дәвердәге бөтен совет әдәбиятында беренчеләрдән булып «Ленин образында эпоханың яңа герое идеалы — үзендә акыл көчен һәм планетабызның барлык континентларында яшәүче миллионнарга якын һәм аңлаешлы булган гадилекне туплаган революционер һәм кеше күзгә бәрелеп торырлык итеп»[2] чагылдырылды.

«Гасырлар һәм минутлар»дан соң татар әдәбияты Ленин темасын сәнгатьчә

[1] «Кызыл Армия» газетасы, 1920 ел, 25 апрель.

[2] История многонациональной советской литературы. 1 том, М., 1970. 423 бит.

яктырту өлкәсендә ярты гасырлык юл үтте. Шул вакыт эчендә безнең әдипләр бу гаять күпкырлы һәм бай теманың яңадан-яңа якларын һәм аспектларын ача килделәр. Ул поэзиядә барыннан да күбрәк яктыртылды. Татар шагыйрьләре бөек юлбашчыга багышлап ике дистәгә якын күләмле әсәрләр (күпчелек поэмалар) иҗат иттеләр. Аларны конкрет анализлап тормыйча[1], биредә нәтиҗә рәвешендә генә түбәндәге фикерне әйтәсе килә. Безнең шигъри лениниана бу теманы эмоциональ кабул итүдән һәм бөек юлбашчы образын поэтик гомумиләштерелгән хәлдә күрсәтүдән анық шәхесен һәм дөньякүләм әһәмиятле эшчәнлеген тарихи-конкрет планда өйрәнүгә күчү юнәлешендә үсеп килә. Тарихи-конкрет анализның көчәюе шунда чагыла: Ленин темасына тормышның үзеннән, туган җирдән чыгып килеп, татар язучылары сугыштан соңгы чорда бу теманың үзләре өчен бик якын бер ягын актив рәвештә яктырталар. Бу нисбәттән шагыйрь С. Хәким болай яза: «Минем Казаным — Ленин юлының башы. Минем Татарстаным — бәхетле җир: ул үзендә Ленин белән бәйләнгән күпме хатирә саклый! Язучы өчен, бигрәк тә татар әдибе өчен бик тә кыйммәтле һәм мул тема бит бу![2]»

Әйе, безнең туган җиребездә яшь Ленин революционер булып формалашты. Биредә ул дөньяны социаль үзгәртеп кору өчен бөек көрәшкә юл алды. Ленинның Казан университетында һәм Кокушкино авылында үткән революцион яшьлеге татар әдипләрендә зур кызыксыну уятты. Ә. Фәйзинең «Кайту», Г. Хуҗиевның «Идел хикәясе», «Күңел яктысы» һәм «Ильичның анасы», С. Хәкимнең «Кокушкино крестьяннарының Ленинга хаты» һәм «Языгыз, җир уллары», М. Ногманның «Кокушкино таңнары» поэмалары, Р. Ишморатның «Давылга табан» пьесасы һ. б. шул хакта сөйлиләр. Иң соңгы әсәрләрнең берсе — ул Г. Әпсәләмовның «Күк күкрәр» романы. Шул ук вакытта Г. Әпсәләмовның бу темага безнең прозада беренчеләрдән булып алынуын да әйтергә кирәк. Әсәрдә күпкырлы Ленин темасын ике планда яктыртуга омтылыш сизелә. Бер яктан, автор Ульяновлар гаиләсенең Казандагы һәм Кокушкино авылындагы тормышын гәүдәләндерә. Биредә ул Мария Александровнаның хәтергә кереп калырлык образын тудыра. Ире Илья Николаевич үлеп, өлкән улы Александр җәзалап үтерелгәч, зур семья йөге тулысынча Мария Александровна җилкәсенә төшә. Әмма ул бу авырлыклар алдында югалып калмый, киресенчә, укучы алдына «тормыш кыенлыкларыннан зарлана белми» торган нык ихтыярлы шәхес булып баса. Балаларын да ул рухи «оптимизмы, якты киләчәккә ышануы, батырлыгы, сыгылмавы» белән канатландыра.

Ульяновларның гаилә тормышын тасвирлаган бүлекләрдә авторның игътибар үзәгендә студент Володя образы тора. Г. Әпсәләмов яшь Ленинның марксистик карашлары формалашуын ачуга аеруча дикъкать итә.

Романның икенче мөһим сюжет сызыгы татар хезмәт ияләренең яшь Ленин башлаган революцион көрәшкә килү юлларын сурәтләүдән гыйбарәт. Бу процесс яшь эшче Вәли һәм аның хатыны Мәрхәбә образларында чагылдырыла.

Ленин һәм Татарстан темасының тагын да мөһимрәк өлкәсе бөек юлбашчының Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзүдә катнашуына карый. Безнең тарих фәнендә, бигрәк тә М. Мөхәррәмов, Р. Нәфиков, М. Сәйдәшева һ. б. ларның хезмәтләрендә бу мәсьәлә инде шактый тулы чагылыш тапты. Галимнәр бу мәсьәлә буенча бай документаль материал тупладылар. Әмма шушы зур һәм җитди тема — Татарстан автономияле республикасы төзелү һәм бу тарихи процесста В. И. Ленинның роле — татар әдипләре өчен әле чынлыкта күтәрелмәгән чирәм булып кала. Ленинның якын көрәштәшләре яки аның идеяләрен тормышка ашыру өчен актив көрәшкән партия һәм дәүләт эшлеклеләре — Мулланур Вахитов, Сәхипгәрәй Сәетгалиев, Камил Якуб һәм башкалар турында да романнар һәм повестьлар язылуын күрәсе килә. Шул ук вакытта татар әдәбиятының һәм сәнгатенең күренекле вәкилләре, бигрәк тә Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Шамил Усманов, Салих Сәйдәшев һәм Фәрит Яруллиннарга багышланган әдәби әсәрләр иҗат итәргә дә бик вакыт. Әйтергә кирәк, бу өлкәдә без башка тугандаш әдәбиятлардан шактый калышабыз. Мисалга Урта Азия һәм Казагыстан әдәбиятларын гына алыйк. Соңгы вакытта бу республикалар язучылары үз халыкларының үткәндәге данлы улларына һәм кызларына багышланган күп кенә әсәрләр иҗат иттеләр.

Югарыда телгә алынган тарихи шәхесләр турында әдәби әсәрләр язу аларның якты истәлегенә хөрмәт һәм ихтирам билгесе булып яңгырар иде. Шул ук вакытта мондый кешеләрнең олы тормышы һәм тарихи эшләре яңа герой мәсьәләсен, беренче чиратта, коммунист образын әдәбиятта гәүдәләндерү өчен кыйммәтле материал бирәләр.

Әдәбиятта коммунист образы төшенчәсен без ничек аңлыйбыз соң? Элеккерәк елларда бу төшенчәне тарайтыбрак аңлатулар белән очрашырга туры килә иде. Ул вакытларда коммунист образында еш кына партиянең кадровой работникларын гына күрсәтү күздә тотыла иде. Һәм мондый караш өчен беркадәр

---

[1] Алар турында тулырак мәгълүматны Р. Гайнановның «Татар поэмаларында Ленин образы» исемле мәкаләсендә табарга мөмкин. Кара: «Герой, стиль, осталык». Казан, 1972.

[2] С. Хәким. Заветная книга. М., 1965, 5 бит.

нигез дә бар иде кебек. Һәрхәлдә, 20 — 30 нчы еллар әдәбияты коммунист образында башлыча партия оештыручыларын, җитәкче геройларны чагылдырды. Әсәрләрдә бу геройның иҗтимагый-политик активлыгын, эшлекле шәхес булуын һәм шундый сыйфатлары белән башка төр шәхесләрдән күзгә күренеп аерылып торуын күрсәтүгә басым ясалды. Коммунист образын шушы рухта сурәтләү ул вакытта тормышның үзе тарафыннан да беркадәр aклана иде. Эш менә нәрсәдә. Ул дәвердә Коммунистлар партиясе әле башлыча эшчеләр сыйныфы партиясе, аның сугышчан авангарды булып торды. Чөнки ул заманда эшчеләр сыйныфы совет җәмгыятенең иң аңлы, иң оешкан өлешен тәшкил итә иде. Ул еллардан соң безнең социалистик җәмгыятебез зур үсеш юлы үтте. Кешеләрнең яңа тарихи берлеге — совет халкы формалашты. Җәмгыятьнең ныклы идея-политик һәм социаль-әхлакый бердәмлегенә ирешелде. Ә Коммунистлар партиясе бөтен халык партиясенә, аның сугышчан авангардына һәм юлбашчысына әверелде. Чөнки эшчеләр сыйныфы һәм аның партиясенең эше илебездәге барлык халыкларның уртак эшенә, үз эшенә әйләнде. Җәмгыятебезнең социалистик демократияне тагын да үстерү юлыннан баруы совет кешеләренең һәм иҗтимагый-политик, һәм идея-әхлакый үсүенә китерде. Коммунистның тормышта үз-үзен тотышы — күпчелек замандашларыбыз өчен хәзер нормага әверелде. Әмма әйтергә кирәк, безнең дәвердә партия белән халыкның социаль һәм рухи бердәмлеге ныгу КПСС-ның җәмгыятьтә җитәкчелек роле тагын да үсү шартларында бара. Нәтиҗәдә, коммунист һәр вакыттагыча заманның иң алдынгы кешесе, коммунистик идеаллар өчен көрәшнең беренче сафында баручы һәм шулар белән замандашларыбыз өчен үрнәк шәхес булып кала.

Соңгы еллар совет әдәбиятында һәм тәнкыйтендә: «Заман герое нинди ул?» дигән сорауга кабат игътибар көчәйде. Бу сорауга җавап эзләп, әдипләр һәм тәнкыйтьчеләр һәр вакыттагыча, беренче чиратта, коммунистларга мөрәҗәгать итәләр. Шуңа күрә хәзерге әдәбиятның заман героен сәнгатьчә гәүдәләндерү өлкәсендәге эзләнүләре дә коммунист образын тасвирлауда аеруча ачык чагылалар.

Фәнни-техник революция заманының үзәк герое булган коммунистны әдәбиятта күрсәтү — күпкырлы һәм катлаулы мәсьәлә ул. Бу мәкаләдә аның берничә мөһим моментына гына тукталып үтәсе килә.

Хәзерге заман героеның төп сыйфатлары турында сүз чыкканда, хәтергә үзеннән-үзе В. И. Ленинның бер фикере килә. «Совет властеның чираттагы бурычлары» дигән хезмәтенең башлангыч вариантында ул Бөек Октябрьга кадәр практиклык һәм эшлеклелек лозунгларының революционерлар арасында бик үк популяр булмауларын, ә хәзер исә аларның иң мөһим лозунгларга әверелүләрен күрсәтте[1]. Тарих моның бик озак вакытка исәпләнгән стратегик характердагы лозунг булуын күрсәтте. Юлбашчы фикере безнең көннәрдә аеруча әһәмиятле һәм актуаль яңгыраш ала. КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Л. И. Брежнев үзенең бер чыгышында болай диде: «Безгә үзләрендә компетентлыкны һәм булдыклылыкны тирән партиялелек, гомумхалык интереслары турында кайгыртучанлык белән берләштерә алган социалистик формациябезнең эшлекле кешеләре кирәк, бик кирәк»[2].

Дөрестән дә, фәнни-техник революция дәвере, халык хуҗалыгы үсешенең хәзерге этабы кешеләрдән тагын да эшлеклерәк булуны сорыйлар. Әмма эшлеклелек төрле характерда булырга мөмкин. Совет кешесенең эшлеклелеге һәм практиклыгы белән буржуаз эшкуарның шундый ук сыйфатлары икесе ике нәрсә. Бу төшенчәләр бездә кешенең иҗтимагый файдалы хезмәткә җаваплы карашын, үз эшен тирәнтен белүен, аның максималь эффект бирүенә ирешә алуын аңлаталар. Хәзерге вакытта Коммунистлар партиясе замандашларыбызда шундый сыйфатлар тәрбияләүгә аеруча зур игътибар бирә. Бигрәк тә хуҗалык җитәкчесе булган коммунист партиянең хәзерге этаптагы экономик политикасының асылын яхшы белергә, хуҗалык белән идарә итүнең яңа принципларын һәм ысулларын тирәнтен үзләштерергә, иҗтимагый җитештерүнең югары эффектлылыгы өчен көрәшергә тиеш. Партиябезнең игътибар үзәгендә торган бу мөһим мәсьәлә соңгы вакытта әдипләрне дә якыннан кызыксындыра. Менә ни өчен соңгы еллар әдәбиятында һәм тәнкыйтендә эшлекле герой мәсьәләсе аеруча актуаль төс алды. Аның тирәсендә кызу-кызу бәхәсләр бара. Әдипләр аны бүгенге тормыш материалында гына түгел, бәлки үткәнгә мөрәҗәгать итеп тә яктырталар. Соңгысына мисал итеп Г. Ахуновның «Чикләвек төше» повестен алырга була. Әсәрнең үзәк герое коммунист Халикъ Саматовның эшлекле һәм практик шәхес булуын күрсәтүгә аеруча басым ясала. Үз гомерендә кайда гына булырга һәм нәрсә белән генә шөгыльләнергә туры килми аңа! Саматов байтак вакытлар милиция органнарында хезмәт итә, аннары аны Идел-Балтик каналы төзелешенә җибәрәләр. Анда бераз эшләгәч, ул туган якларына кайта һәм аңа һөнәр училищелары белән җитәкчелек эше йөкләнә. Саматов һәркайда үзенә тапшырылган эшне зур җаваплылык хисе белән һәм бөтен кү-

---

[1] В. И. Ленин. Полн. собр. сочинений, 5 басма, 36 том. 158—159 битләр.

[2] «Социалистик Татарстан», 1973 ел, 27 июль.

целен биреп башкара. Шундый сыйфатларга ия булган коммунист Саматов илленче еллар уртасында тагын бер җаваплы участокка — авылга утызмеңче итеп җибәрелә. Повестьның байтак өлешендә геройның менә шушы соңгы эшчәнлеге яктыртыла. Һәм нәкъ менә колхоз председателе булып эшләгәндә Саматовның эшлеклелек сыйфатлары аеруча калку булып гәүдәләнә. Үз хезмәтенә ул зур җаваплылык белән карый һәм «булсынга» эшли. Аның гадәттән тыш тырышлыгы белән колхоз тиз арада аякка баса. Бу яктан Саматов илленче еллар башындагы авыл прозасының нык ихтыярлы геройларын хәтерләтә кебек. Әмма үзенең принциплары буенча ул әлеге җитәкчеләрдән шактый аерыла. Ул волюнтарист түгел, бәлки акыл белән, уйлап эш итә торган җитәкче. Авылга килү белән герой эшне колхоз экономикасын өйрәнүдән башлый. Формализмның дошманы булган Саматов хуҗалыкны үстерүнең экономик яктан нигезләнгән һәм акланган принципларын алга сөрә. Бу юлда аңа еш кына гадәти карашлар һәм күнегелгән принциплар белән конфликтка керергә туры килә. Менә ул, бер яктан, колхоз экономикасын ныгыту, икенче яктан, туфракның уңдырышын күтәрү нияте белән җитен һәм күпьеллык үлән чәчәргә керешә. Ә бу вакытта үлән чәчү системасы кире кагылган була. Һәм бераздан өлкә газеталарында Саматовны тәнкыйтьләп «Травопольный король» дигән мәкалә чыга. Районнан исә аны клевер җирләрен сөреп ташларга мәҗбүр итәләр. Моның нәтиҗәсе шул була: сөт тапшыруда районда беренче урынга чыгып килгән колхоз, «яшен сугып сындырган агач төсле, кинәт артка авып» төшә. Ә менә җитен чәчү артельгә зур файда китерә. МТС техникасын колхозларга сату башлангач, бары Саматовның гына бу техниканы алырлык мөмкинлеге булуы ачыклана. Кыскасы, Саматов безнең алга аек акыл белән һәм алга карап эш итә торган хуҗалык җитәкчесе булып баса. Әмма колхоз экономикасын күтәрү аның өчен һич тә үзмаксат түгел. Саматовның алны-ялны, көн-төнне белмичә, бик күп бәлаләр һәм кыенлыклар кичереп тырышуының төп максаты — авылның тормыш хәлен яхшырту. Шушы хакыйкатьне аңлаган колхозчылар бераздан яңа председательне иң якын һәм хөрмәтле кешеләре итеп күрә башлыйлар. Ә соңыннан, үз инициативасы белән эш иткәне өчен райком Саматовның председательлектән азат итәргә теләгәч, колхозчылар аны бердәм рәвештә яклап чыгалар.

Бер сүз белән әйткәндә, Г. Ахунов бу әсәрендә бөтен рухы һәм эш принциплары белән хәзерге заман хуҗалык җитәкчесен күз алдына бастыра. Шул ук вакытта язучы мондый тип җитәкченең бүген генә дөньяга килмәвен, бәлки аның 50 нче еллар авылында җитлегүен күрсәтә. Бу яктан Халикъ Саматов «Председатель» исемле мәгълүм кинофильмның үзәк герое Егор Трубниковны хәтерләтә. Билгеле булганча, бу председатель образы үз вакытында тәнкыйтьтә капма-каршы фикерләр уятты. Берәүләр, Трубниковның 40 нчы еллар шартларында колхоз хуҗалыгын торгызырга һәм үстерергә тырышуын гадәти донкихотлык күренеше дип санап, аны уңай герой дәрәҗәсеннән мәхрүм иттеләр. Андый тәнкыйтьчеләр Трубников кебек колхоз җитәкчеләренең 40 нчы елларда була алуларын шик астына куйдылар һәм кинофильм авторларын геройны реаль шартлардан аерып күрсәтүдә гаепләделәр. Мондый карашларны алга сөргән тәнкыйтьчеләрнең берсе, А. Янов, мәсәлән, бу герой алдында бары ике мөмкинлекне, перспективаны күрде. Әгәр «бөтен район аның файдасына эшләсә, ул чираттагы «Потемкин авылын» төзи ала... яки тормышка яраклашучан кешегә, «кечкенә эшләр» апологетына әверелә ала»[1].

Трубников образын болай бәяләүгә каршы чыгып, икенче бер тәнкыйтьчеләр бу образда совет халкының сугышчан һәм революцион традицияләрендә тәрбияләнгән чын коммунист гәүдәләнүен күрсәттеләр. Соңгы фикер чынлыкка туры килә иде. Акыллы һәм эшлекле җитәкче буларак, Трубников 40 нчы еллар шартларында ук колхоз хуҗалыгы белән идарә итүнең яңа принципларын, авыл хуҗалыгын үстерүгә юнәлтелгән мәгълүм партия карарларының нигезендә яткан идеяләрне алдан сиземли. Трубниковлар башлаган эшне 50 нче елларда Саматовлар дәвам иттеләр. Саматов кебек председательләр эшчәнлеге, безнеңчә, КПСС Үзәк Комитетының 1965 елгы март Пленумы карарларына җирлек әзерләде.

60 нчы еллар авылында Саматов эшен дәвам иттерүче итеп Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын» повестендагы Рамай Вильдановны санарга була. Бу ике председательнең эш принципларында зур уртаклык бар. Саматов кебек, Вильданов та артель хуҗалыгын экономик яктан нигезләп үстерү өчен көрәшә, колхоз производствосының эффектлылыгын күтәрү юлында актив эш алып бара. Шул ук вакытта Х. Хәйруллин повесте авыл хуҗалыгындагы элекке кимчелекләрнең һәм хаталарның партия карарлары игълан ителү белән генә юкка чыкмауларын, бәлки моның өчен әле киеренке көрәш алып барырга туры килгәнен күрсәтә. 60 нчы елларда Вильданов башлыча 50 нче елларда Саматовка каршы торган кире күренешләр белән очраша. Ике әсәр арасындагы тыгыз бәйләнешне түбәндәге ситуациядә ачык күрергә мөмкин. «Чикләвек төше»нең ахырында Саматов икмәк тапшыру буенча дәүләт планын бары алдынгы колхозлар исәбенә үтәү кебек

[1] «Вопросы литературы» журналы, 1966, 8 сан, 10 бит.

ялгыш практикага каршы чыкса, «Канатлар талмасын» әсәре шушы ук хәлне тасвирлау белән башлана. Райкомның яңа секретаре Шәймиев район «ил алдындагы беренче изге бурычын» вакытында үтәсен өчен, дәүләт планын гына түгел, инде өстәмә планны да арттырып үтәгән «Беренче Май» колхозының тагын өч мең центнер икмәк тапшыруын таләп итә. Бу законсыз таләпкә Вильданов каршы чыга һәм шул нигездә аның белән райком секретаре Шәймиев арасында җитди конфликт формалаша башлый. Ул күп яктан «Чикләвек төше»ндәге Саматов белән райком секретаре Байназаров арасындагы конфликтны хәтерләтә. Үзәк конфликтның үсеше күрсәтүдә дә ике әсәр арасында зур гына охшашлык бар. Бу конфликтны хәл итү буенча исә повестьлар бер-берсеннән шактый аерылалар. Мәгълүм булганча, «Чикләвек төше» Саматовның вакытлыча эштән алынуы белән, ягъни Байназаровның җиңүе белән тәмамлана. Мондый финал белән Г. Ахунов Байназаров кебек катып калган һәм заман таләпләренә җавап бирми торган җитәкчеләргә каршы әле көрәш дәвам итәчәгенә ишарә ясый. Х. Хәйруллин повестенда исә бу көрәшкә нокта куела. Шәймиев һәм аның иярченнәре җиңелүгә дучар булалар, ә Вильданов кебек заманча эш алып бара торган җитәкчеләр тантана итәләр. «Чикләвек төше» белән «Канатлар талмасын» повестьлары арасында колхоз җитәкчесен сурәтләүдә тагын бер мөһим аерма күзгә ташлана. Саматовны полемик рәвештә эшлекле шәхес итеп күрсәтергә алынып, Г. Ахунов төп игътибарын шушы мәсьәләгә юнәлтә, героенның интим дөньясына исә бик аз күңел бирә. Х. Хәйруллинга килсәк, ул Вильдановның председатель буларак эшчәнлеген һәм эшлекле кеше сыйфатларын калку итеп һәм киң план белән сурәтләүдән тыш, аның шәхси яшәеше белән дә шактый кызыксына. Һәм укучы, геройның җитәкчелек эшчәнлеге җиңел генә бармаган кебек, аның интим тормышында да барысы да ал да гөл булмавын күрә. Автор Вильдановның семья һәм мәхәббәт җирлегендә туган каршылыклы уй-кичерешләр белән яшәвен сурәтли. Председатель, үзенең хатыны Сәкинә белән матур гына торса да, яшьлек мәхәббәте Мәрьямне дә онытa алмый. Мәрьям бер ялгызы тәрбияләп үстергән Дамирга улым дип дәшә алмавы исә герой күңеленә төзәлмәс яра сала. Ә инде бер ата балалары икәнлекләрен белмичә, бер-берсен яраткан Дамир белән Сәвиянең саф мәхәббәтен һәм киләчәккә планнарын җимерергә мәҗбүр булуы Вильдановның күңел ярасын тагын да тирәнәйтә. Кыскасы, шушындый уй-кичерешләр белән дә яшәве аркасында, Вильданов Саматовка караганда рухи яктан катлаулырак һәм купкырлырак шәхес булып алга баса.

Г. Ахунов һәм Х. Хәйруллин повестьларында тагын райком секретарен сурәтләүдә кызыклы аерымлыклар бар. Авторның үтеп барышлыйрак һәм ерактанрак торып кызыксынуы сәбәпледер, ахры, «Чикләвек төше»ндәге райком секретаре Байназаров башлыча бер яссылыкта гәүдәләнә. Ул үзенә тапшырылган эшкә чын хуҗаларча караудан ерак торган, югарыдан җибәрелгән күрсәтмәләр кулына әверелгән иске тип җитәкче булып алга баса. Секретарьлык абруена тап төшермәс өчен, мондый күрсәтмәләрне уйлап тормыйча һәм теләсә нинди юллар белән үтәргә омтылу Х. Хәйруллин повесте герое Шәймиевка да хас. Әмма Шәймиев, Байназаров кебек, үзенең иҗтимагый-рухи үсешендә катып калган һәм уй-хиссез кире тип түгел. Ул байтак уйлана, борчыла, кайчак авыр кичерешләргә дә дучар була. Автор аның мәхәббәт белән бәйләнгән каршылыклы уй-кичерешләрен ачуга шактый игътибар бирә. Гәрчә үзенең эштәге хаталарын сизә алмаса да, Шәймиев башкаларның кимчелекләрен яхшы күрә, яхшыны начардан аера белә. Менә ул районның туңга сөрү планын вакытында үтәү өчен басулардагы саламны яндырырга куша. Ә берәздән шушы күрсәтмәне берсүзсез үтәргә алынган кешеләргә нәфрәт белән карый. Геройның мондый бәндәләр турындагы уйларын автор болай тасвирлый: «Редактор да, архитектор да аңа кай яклары беләндер роботларны хәтерләтте. Билгеле бер программа белән корып җибәрсәң, бу кешеләргә кушылган эшне алар нәкъ шулай башкарырлар иде дә, архитектор кебек, эш сәгате бетүгә кайтып җитәрләр иде... Роботлар, роботлар!.. Юк, алар партия солдаты түгел... Партия солдатлары Рамай Ибраһимович, Шамил Сабирович. Аларның дөньяга үз карашы бар, партия куйган бурычларны үтәүгә үзенең уйлары, планнары бар, алар иҗат итәләр, хыялланалар. Алар кайчак синең фикереңә каршы киләләр, бәхәсләшәләр, нервларыңны соңгы чиккә кадәр киерәләр. Әмма дөреслек каршылыкларны җиңеп, бәхәсләр белән туа. Бәхәсләшер, көрәшер кешеләр роботлардан, ай, купкә өстен, өстен!» Күңеле белән шушыларны аңласа да, Шәймиев үзе эштә шундый кешеләр кебек була алмый. Аның фаҗигасе менә шунда. Әмма биредә бер нәрсәгә игътибар итәсе килә: алдынгы карашлы колхоз председателе белән консерватив райком секретаре арасындагы конфликт безнең хәзерге проза өчен яңалык түгел. 60 нчы елларда аңа башлап «Язгы авазлар» романында А. Расих мөрәҗәгать иткән иде. Һәм ул вакытта бу конфликт, беренче мәртәбә күтәрелүе сәбәпле, әдәбият өчен ачыш иде. Ә инде «Язгы авазлар»дан соң бу конфликт, гәрчә авторлар аны беркадәр үзләренчә аңлатырга, кайбер психологик детальләр белән торләндерергә тырышсалар да, үзенә күрә бер

штампка әверелде. Икенче яктан, әдәби әсәрнең тормыштагы конкрет факт турында гына сөйләмәвен, ә гомумиләштерү көченә ия булуын искә алсак, әлеге конфликтны безнең көннәрдә дә күтәреп чыгу тормыш чынлыгын исәпкә алмау булып яңгырар иде. Биредә, сүз уңаеннан, әдипләребезнең бүгенге авыл тормышын тирәнрәк өйрәнүләрен, аның яңа проблемаларын һәм конфликтларын активрак һәм кыюрак эзләүләрен телисе килә. Бу өлкәдә алар алдында зур бурычлар тора.

Эшлекле герой мәсьәләсе соңгы вакытта эшчеләр темасына багышланган әсәрләрдә шактый еш күтәрелә. Мисал итеп Г. Ахуновның «Хуҗалар»ындагы Арслан Гобәйдуллин, Э. Касыймовның «Һаваларда тургае»ндагы Госман Әхмеров, Ә. Баяновның «Ут һәм Су»ындагы Фәез Насыйбуллин образларын алырга була. Әйтергә кирәк, бу мәсьәлә КамАЗга багышланган әсәрләрдә аеруча актив күтәрелә. Д. Вәлиевнең «Дәвам», М. Захаров һәм Ю. Визборның «Автоград-XXI», Г. Бакланов белән Ю. Любимовның «Каешларыгызны элэктерегез» исемле пьесалары шул хакта сөйли. Чөнки КамАЗ кебек зур төзелешләрдә эшлекле җитәкчеләр аерата кирәк. Безнең язучылар әсәрләрендә бу мәсьәлә ничегрәк яктыртыла соң? Әдәби тәнкыйтьтә инде әйтелгәнчә, романның беренче вариантында хәзерге эре производство командирын бирүдә Г. Ахунов әллә ни уңышка ирешә алмаган иде. «Хуҗалар»ның күптән түгел дөнья күргән яңа басмасында исә автор бу мәсьәләне инде шактый уңышлы хәл итә. Г. Ахунов кебек, Э. Касыймов та «Һаваларда тургай» романының үзәк герое — зур заводның баш инженер урынбасары һәм үзәк лаборатория җитәкчесе Госман Әхмеров образында аның инициативалылык сыйфатына басым ясый. Госман берьюлы берничә идея күтәреп чыга. Әмма автор герой эшчәнлегенең ахыргы нәтиҗәләре белән генә кызыксына. Ул үзенең кызыклы идеяләрен ничек тормышка ашыра — бу нәрсә укучы өчен ачыкланмый кала. Герой характеры хәрәкәттә, хезмәт дәвамында ачылмый. Кыскасы, безнең эшчеләр сыйныфына багышланган күп кенә әсәрләрдә авторларның хуҗалык җитәкчесе булган коммунистны эшлекле герой итеп күрсәтү теләге әле тормышка ашмый кала. Бу яктан хәзергә авыл турындагы әсәрләр уңышлырак чыгалар. Бу — нефть промыселлары, завод-фабрикалар белән, КамАЗ яки Түбән Кама промышленность комплексы кебек гигант төзелешләр белән җитәкчелек итүче хәзерге эре производство командиры безнең әдәбиятта әле тулы гәүдәләнеш тапмаган дигән сүз.

Әмма бу тип геройны ничек күрсәтергә соң? Замандашларны бик урынлы рәвештә эшлекле шәхесләр итеп тасвирларга алынып, әдипләр, кызганычка каршы, еш кына мондый геройның аның образын һәм характерын шактый берьяклы аңлата башлыйлар. Бу хәл, барыннан да элек, персонажны башлыча производство өлкәсендә генә күрсәтүдә һәм аны бары эшлеклелек сыйфаты буенча бәяләүдә чагыла. Бөтенсоюз тәнкыйте мондый рухтагы тасвирның аеруча ачык мисалын И. Дворецкийның «Чит кеше» пьесасындагы инженер Чешков образында күрде. Кайберәүләр аны хәтта фәнни-техник революция заманының яңа герое итеп тә саный башладылар. Тәнкыйтьче Л. Аннинский, мәсәлән, бу инженерны элекке психолог-җитәкчеләргә үзенең салкын акылы һәм рационализмы белән каршы торган яңа заман герое итеп карый һәм без теләсәк-теләмәсәк тә, ул тормышта үз урынын яулаячак, ди[1]. Әмма эш өчен янып та, кешеләр турында бер дә кайгыртмаучы җитәкчене заман герое рәвешендә тәкъдим итү белән һич тә килешәсе килми. Чешков кебек артык рационалист һәм каты куллы җитәкчеләрне безнең хәзерге тормышта вакытлы күренешләр дип санарга кирәк. Производствоның берәр тармагын яки участогын өзеклектән чыгару өчен алар әле азмы-күпме кирәк булырга мөмкин. Ә бераздан аларның җитәкчелек стиле тормышның үзе тарафыннан кире кагылуы бик тә ихтимал. Чөнки коммунистик төзелешнең олы һәм катлаулы бурычларын уңышлы хәл итү өчен гармоник үсешкә ирешкән, үзендә эшлеклелек белән кешелеклелекне бергә туплаган җитәкчеләр кирәк. Бу катлаулы мәсьәлә безнең илдә уңышлы хәл ителеп килә. Мондый шәхеснең күркәм сыйфатлары барыннан да элек коммунистларда чагылалар.

Максим Горький иҗаты турында сөйләгәндә А. В. Луначарский бер нәрсәгә аеруча игътибар иткән иде. Аныңча, бөек язучы «тормышны киң колачлап ала: ул кешеләрнең ничек фикер йөртүләре һәм бәхәсләшүләре турында гына сөйләми, ул аларның ничек яшәүләре, яратулары, ничек өйләнешүләре, үзләренең тормыш-көнкүрешләрен ничек оештырулары, үз эшләрен ничек җайлаулары, нинди китаплар укулары, нинди обстановка тудырулары турында да сөйли һәм боларның һәркайсы бердәй мөһим һәм типик. Нәтиҗәдә уртак бер зур гармонияне, бер зур бөтенне тудыручы төсләрнең чиксез байлыгы хасил була». Биредә сүз герой образының күп үлчәнешле һәм тормыштагыча тулы канлы булуы турында бара. Әйтергә кирәк, безнең әсәрләрдәге коммунистлар образларына мондый сыйфатлар әле бик тә җитми. Алар еш кына бу герой тормышының иҗтимагый һәм шәхси өлкәләрен, аның эшлеклелеге белән кешелеклелеген, рациональлеге белән эмоциональлеген, ягъни акылы

[1] «Театр» журналы. 1972, 2 сан, 39 бит.

белән хисен үзара бәйләп карый алмыйлар. Элеккерәк еллар әдәбиятында төп игътибар коммунистның иҗтимагый йөзен һәм җитәкчелек сыйфатларын ачуга юнәлтелә иде. Бу хәл, гәрчә шул заман өчен бик мөһим булса да, гомумән алганда, геройны сурәтләүдә берьяклылыкка китерә иде. Шушындый тасвир белән бәхәскә кереп, ахры, соңгы вакытта әдипләр коммунист-җитәкченең шәхси тормышына игътибарларын арттыра баралар. Икенче яктан, бу хәл безнең хәзерге тормыштагы һәм әдәбияттагы мөһим бер тенденциянең чагылышы да булып тора кебек. Эш шунда ки, безнең җәмгыятебез әхлакый яктан нык үсте. Ул шәхеснең әхлакый яшәешенә торган саен ныграк дикъкать итә. Чөнки коммунизм төзүчеләр югары әхлакый үсешкә ирешкән шәхесләр булырга тиеш. Фәнни-техник революция заманы бу мәсьәләгә тагын да җитдирәк төс бирә. Җәмгыять тормышында бара торган тирән социаль-экономик үзгәрешләр йогынтысында хәзерге кешенең иҗтимагый һәм әхлакый үсеше тагын да катлаулана төшә. Шундый шартларда яши торган шәхеснең гражданлык һәм әхлакый йөзе нинди һәм ул үзен тормышта ничек тота? Хәзерге әдәбиятны шундый сораулар аеруча кызыксындыра һәм ул актив рәвештә аларга җавап эзли. Ә кешенең кешелек асылы, аның чын йөзе, К. Маркс әйткәнчә, ир белән хатын-кызның үзара мөнәсәбәтләрендә аерата ачык чагыла. Менә ни өчен әдипләр шушы мөнәсәбәтләргә игътибарларын арттырдылар. Әдәбиятта мәхәббәт һәм семья мәсьәләләренә дикъкать бермә-бер көчәюенең төп сәбәбе, безнеңчә, шуннан гыйбарәт. Табигый, хәзерге әдипләр замандашларыбыз, бигрәк тә яшьләр арасында мәхәббәткә һәм гаилә коруга җиңелчә карау очракларына битараф булып кала алмыйлар. Мондый күренешләрне тәнкыйтьләү белән бергә, алар әлеге мәсьәләләргә җитди һәм җаваплы карау үрнәкләрен эзләп, кайчан үткәнгә дә мөрәҗәгать итәләр. Аерым алганда, Ф. Хөснинең «Гыйльмениса» повесте шундый максат белән язылган. Әсәр героинясы Гыйльменисаны автор «колхозның нигезен корышкан» һәм картлык көннәренә кадәр җәмәгать эшләрендә актив катнашып килгән кеше булуын, авылдашларының аны шуның өчен хөрмәт итүләрен искә ала. Әдипнең үзен исә героиня күбрәк ана булу сыйфатлары белән кызыксындыра. Бик иртә тол калып, күп санлы балаларын «бер ялгызы, кешегә орчык эрләп, әвен сугып, үзе киенмичә киендереп, тамагын, өстен-башын карап, укытып, канат-каурый куеп дөньяга очырган» ана булуы белән кадерле Ф. Хөснигә Гыйльмениса. Һәм ул гади татар карчыгын шундый сыйфатлары белән замандашларыбызга үрнәк итеп куя.

Кыскасы, хәзерге әдәбиятта мәхәббәт һәм семья мәсьәләләренә игътибар арту — бик табигый һәм урынлы күренеш. Бу темага багышланган иң яхшы әсәрләр мәхәббәттә һәм семьяда мещанлыкка каршы, кешенең кеше булып калуы һәм хисләр культурасы өчен көрәш пафосы белән сугарылганнар. Мондый сыйфатлар коммунистларны сурәтләгән әсәрләргә дә хас. Соңгырак еллар прозабызда бу геройның шәхси тормышын, семьяда һәм мәхәббәттә үз-үзен тотышын үзәккәрәк куеп сурәтләүгә мисал итеп Б. Камаловның «Ялыкмаслар» һәм В. Нуруллинның «Күпер чыкканда» повестьларын алырга була. Бу әсәрләрнең үзәк геройлары — райком секретаре Хафиз Кадергулов һәм колхоз председателе Өлфәт Хәкимов җитди генә мораль сынауга дучар булалар. Яраткан хатынының бик иртә дөнья куюы Кадергуловның күңеленә төзәлмәс яра сала. Моның өстенә сугыш елларындагы беренче мәхәббәте — Еленаның исән булуын белү геройны яңа кичерешләргә дучар итә. В. Нуруллин повестенда исә Хәкимовның «бер минутлык дуамаллык аркасында бер гомерлек фаҗигага» кичерүе, ягъни үз гаебе белән үз гаиләсен җимерүе турында сөйләнә. Гәрчә мондый ситуацияләр конкрет очракта җитәкче геройның интим дөньясын һәм әхлакый сыйфатларын ачу чарасы буларак игътибарны җәлеп итсәләр дә, гомумән алып карaганда, алар күңелдә борчу тудыра башлыйлар. Эш шунда: соңгы вакытта бездә җитәкче геройның иҗтимагый һәм шәхси яшәешен контраст буяулар белән сурәтләү модага кереп китте. Беренчесен сурәтләгәндә мажор төсләргә өстенлек бирелсә, икенчесен гәүдәләндергәндә исә минор төсләр өскә чыгалар. Ачыграк әйтсәк, геройның эшендә бар да ал да гөл, ә шәхси тормышында ул адым саен уңышсызлыкка очрый. Кайбер иптәшләр бу хәлне герой язмышын җиңеләйтеп хәл итүдән качу, аны драматиклаштыру теләге белән бәйләп аңлаталар. Әмма авторларның ниятләре изге булса да, мондый чишелеш һәр вакытта да логик яктан нигезләнми, ә кайчак ул хәтта үзмаксат төсен ала. Мондый әсәрләрне укыганда укучыда җитәкче кешегә нормаль семья тормышы белән яшәү хилаф нәрсә икән дигән фикер дә туарга мөмкин. Кыскасы, соңгы вакытта безнең әсәрләрдә еш очраган чишелеш — җитәкче геройның мәхәббәттә һәм семьяда бәхетсезлеккә очравы һәр очракта да үзен акламый. Аннан соң бередә башка төр чишелешләрне дә күрәсе килә. Мисал өчен, әгәр җитәкче геройның мәхәббәте, аның матур семья тормышы корып җибәрүе тирән әхлакый эзләнүләр нәтиҗәсе итеп һәм психологик мотивлаштырып тасвирланса, бу хәл һич тә герой тормышын җиңеләйтеп күрсәтү төсен алмас иде. Бу фикергә дәлил итеп үткәнрәк еллар прозасыннан А. Расихның «Ике буйдак» романын китерергә була. Бу әсәргә барыннан да элек үзәк геройлар

тормышының иҗтимагый һәм шәхси өлкәләрен үзара тыгыз бәйләнештә күрсәтү хас. Нәтиҗәдә, романда шактый актив күтәрелгән мәхәббәт мәсьәләсе дә, безнең хәзерге кайбер әсәрләрдән аермалы буларак, герой тормышының башка мәсьәләләре белән тыгыз мөнәсәбәттә яктыртыла. Рәхим, Мәдинә һәм Заһид Сафичның үзара интим мөнәсәбәтләрен автор аларның дөньяга карашларыннан һәм тормыш фәлсәфәсеннән чыгып аңлата. Тормышка, яшәүгә капма-каршы караштa торуларын ачыклагач, Мәдинәнең моңа кадәр Заһид Сафичка булган хөрмәте юкка чыга. Киресенчә, дөньяга, яшәүгә бер төрле караш Мәдинә белән Рәхимнең тора-бара үзара якынаюларына һәм күңелләрендә көчле мәхәббәт уты кабынуга сәбәпче була. Шулай да бу хис Рәхим күңелендә җиңел генә урын ала алмый, аңа геройның җитди уй-каршылыклары аша үтәргә туры килә. Сөйгән хатыны Галияне җирләгәннән соң Рәхим балаларын беркайчан да онытмаска, алар бәхете өчен үзен корбан итәргә сүз биргән була. Һәм баштарак, Мәдинәгә өйләнсә, ул, үги ана буларак, балаларны кыерсытыр кебек тоела аңа һәм шушы уйдан чыгып, Рәхим үзенең мәхәббәтен сүндермәкче була. Ләкин ул хис бернигә карамастан үсә, көчәя генә бара һәм ахырдан әлеге шикләнүләрне җиңеп чыга. Кыскасы, әсәр «бәхетле тәгәлләнеш» ала. Әмма мондый чишелешнең герой язмышын җиңеләйтеп күрсәтү, конфликтны ясалма хәл итү белән бернинди уртаклыгы юк. Чөнки биредә җитди тормыш сынавы аша үткән олы мәхәббәтнең тантана итүе турында сүз бара. Әдип монда коммунистның әхлак мәсьәләләренә бик җаваплы каравын һәм саф мәхәббәткә корылган семья тормышы корып җибәрүен сурәтли. Моның белән А. Расих коммунистны мәхәббәт һәм семья мәсьәләләренә мөнәсәбәттә күрсәтүнең тормышчан һәм күркәм үрнәген бирде.

Тулаем алганда, коммунист, заман герое буларак, һәр вакыттагыча язучыларыбызның игътибар үзәгендә тора, аны әдәбиятта гәүдәләндерүдә аерым кызыклы гына эзләнүләр һәм табышлар күзгә ташлана. Әмма бу геройның масштаблы портретын һәм күпкырлы характерын тудыру әле киләчәк эше булып кала. Бу бурычны уңышлы хәл итү өчен әдипләрдән идея-эстетик җитлеккәнлек, сәнгатьчә кыю эзләнүләр һәм зур әдәби осталык сорала.

# «МУСА ҖӘЛИЛ» ОКЕАННАР ГИЗӘ

Уйлап карагыз, сездә, сезнең белән бергә язучы яши башлады ди. Ул инде әнә квартирагыз буйлап йөренә, сөйләшкән сүзләрегезгә колак салып тора, ишеткән берен блокнотына теркәп бара. Сез түземсезләнеп:

— Нәрсәгә бу язмалар? — дип сорыйсыз.

— Сезнең гаилә тормышыгыз турында китап язарга телим, — ди бу.

Әйтегез әле, шушы җавап сезне шатландырыр идеме?...

Чит кешенең судно экипажы тормышына килеп тыкшынуы да шундый ук хис уята. Әгәр ул кешенең кулында блокнот та булса, бигрәк тә начар. Беренчедән, блокнотлы кеше тегесенбусын язып баручан була. Ә язып баручыларны бер җирдә дә өнәп бетермиләр.

...Әйтик, вахтенный кулына яңа гына секстант алды, ди. Горизонт тонык. Кояш төссез һәм томанлы тап булып кына күренә. Төне буе судноның йөрү тизлеген күрсәтә торган прибор — лаг ватылып азаплады. Кайдадыр якын тирәдә генә каһәр төшкән рифлар сагалый. Судноны тизрәк дөрес юлга салырга кирәк... Нәкъ шул моментта рубкага әлеге иҗади шәхес — язучы күтәрелә. Авыз ерылган, йөзендә шатлык. Балаларча беркатлылык белән:

— Бу бит секстант, әйеме? — ди.

Судноның машина бүлегенә дә ул нәкъ әнә шундый бер мизгелдә — механиклар нишләргә белми аптырап торганда килеп төшә. Килеп төшә, кызыксына-сораштыра башлый. Шуңа күрә моряклар суднода чит кеше булганны яратмыйлар, ничек тә аннан ераграк булырга тырышалар. Алар командировкага килгән мондый кешеләргә я ифрат экзотик һәм героик маҗаралар сөйләп, я булмаса истәлекле әйберләр күрсәтеп котылалар. Нәкъ менә шуңа күрә дә диңгезчеләр тормышына багышланган әсәрләрдә табигать стихиясе белән көрәш, гаҗәеп штормнар бик күп, ә морякларның көндәлек гадәти тормышы ифрат аз сурәтләнә...

Инде «Полтора экватора» исемле китапның[1] авторы Рафаэль Мостафинны тыңлап карыйк. «Муса Җәлил» исемле теплоход палубасында аны менә ничек каршылыйлар:

«Дулкынланудан бер кулым белән култыксага тотынып, тирбәлеп торган шыгырдавык баскычлар буйлап өскә күтәреләм. Трап янындагы вахтенный... мин күрсәткән кәгазьләрдән бигрәк үземә гаҗәпләнеп карый һәм, ашыкмыйча гына, эчке телефон аша капитанны чакыра. Капитан килеп җиткәнче, ул минем турыда үз янында басып торган бер иптәш белән дә сөйләшеп ала:

— Кара әле, — ди ул, — синең ишеткәнең юкмы, дүртенче штурманның дублеры ниткән нәрсә була икән?

— Берәр төрле курсанттыр, мөгаен.

— Юк, — дип каршы төшә вахтенный, — ялгыштың. Дүртенче штурманның ярдәмчесе — ул инде нәкъ арбаның бишенче тәгәрмәче була» (8 бит).

Дүртенче штурманның ярдәмчесе «Муса Җәлил» экипажының ышанычын казана һәм аның тулы хокуклы члены булып китә. Китапны укыганда без шул вакыйгалар белән танышабыз. Әсәр: «Сезгә бу кадәр ияләнермен, сездән аерылу бу кадәр кыен булыр дип уйламаган идем, егетләр!» дигән сүзләр белән тәмамлана. Авторга ияреп, аларны укучы да кабатлый.

Р. Мостафин ерак рейска яңа әсәр язар өчен экзотик сюжет эзләп чыгып китми. Муса Җәлил турындагы кызыклы китапның авторын герой шагыйрьнең икенче тормышы — океан лайнерында гәүдәләнгән тормышы кызыксындыра. Җәлил тормышы беренче битләрдән үк юлъязманың сюжет тукымасына үрелеп бара. Әсәрнең төп, үзәк мотивына әйләнеп, торган саен ачыграк, ныграк яңгырый башлый: «Иптәшләр, сез эшли торган теплоходның бортына корыч хәрефләр белән ныклык, батырлык үрнәге күрсәт-

---

[1] Р. Мостафин. Полтора экватора. Путевые заметки, Казан, 1974 ел.

кән, үлемгә нәфрәт белән караган кешенең исеме язылган. Муса Җәлил шигъриятгә ахыргача янып бетте, шигъри батырлыгын тормыш батырлыгы белән ныгытты. Ул тормышның җирдәге иминлек һәм бәхет хакына, ирек хакына бирде, без бүген тыныч яши, тыныч эшли һәм шатлана алсын өчен бирде. Сез аның кебек булырга омтыласызмы? Аның исемен кадерләп сакларсызмы?»

Автор дүрт ай буена көн арты көн судно экипажының тормышын тасвирлап бара.

Менә аш осталары камбузга ягып җибәрә. Нәкъ сигез тулуга вахтенный флаг күтәрә, флагштокка бауны беркетә. Егерме минутка гына кеше белән тулып ала да ашханә бушап кала. Һәм авыр, ялыктыргыч эш көне башлана. Матрослар палубаны чистарталар, юалар, судноның тросларын ялгыйлар, йөкнең иминлеге өчен кайгырталар. Һәр көнне, рейс башланганнан алып тәмамланганчы, машинаны юалар, ремонтлыйлар. Камбузда төшке аш пешә. Радиорубкада морзе чыелдый. Вахтенныйларның игътибары тәүлек буена йөреш рубкасында. Әнә шулай ничә айлар буена вахта арты вахта, көн арты көн матрослар туганнарыннан, якыннарыннан еракта авыр хезмәт башкаралар. Чит портларда кыска вакытлы, ялыктыргыч тукталышлар төштәгедәй үтеп китә.

Шуларның һәммәсе нигә кирәк? Нигә бу кешеләр, якыннарыннан, тыныч тормыштан аерылып, айлар, еллар буе ерак диңгезләрдә, океаннарда иза чигәләр? ди автор. Һәм үзе үк җавап та бирә: хөкүмәт сарайларында, министрлыкларның кабинетларында кул куелган кәгазьләр, газета юлларында басылган хәбәрләр Бомбей причалында бушатылган машиналарга, Хайфонда салына торган кирпеч йортларга әйләнсен, сәүдә итү — тынычлык, хезмәттәшлек, дуслык тудырсын өчен моряклар ерак рейсларга чыгып китәләр.

Әгәр Р. Мостафин юлъязмаларында экипаж кешеләренең көндәлек хезмәт күренешләре, үтелгән мильләр, матрослар эшләп тапкан акчалар турында гына сүз булса, без аңа бу кадәр тукталып та тормас идек. Авторны тикшеренүче таланты коткара. «Герой шагыйрь эзләреннән» дигән китабы аны фактларның логик тирәнлегенә үтеп керергә, документаль әсәр кысаларында тулы канлы образ тудырырга өйрәткән. Диңгездә йөзүнең кыен яклары матрослар тормышыннан кителрелгән җанлы күренешләрдә ачыла.

Бер караганда, хәзерге судноларда йөзү әллә ни кыен да булмаска тиеш кебек. Команданың һәр кешесе бөтен уңайлыклары булган бер урынлы аерым каюталарда яши. Сәламәт булсаң һәм ихтыяр көчең булса, океанда еш кабатлана торган рәхимсез чайкалуларга да иялэнергә мөмкин. Ә менә туган илне, якыннарны сагыну хисен берничек тә җиңеп булмый. Моны сүзләр белән аңлатуы кыен, үзе кичергән кеше генә белә.

Беренче карашка сәер дә кебек. Хәзерге суднолардагы тормыш шәһәр кешеләре тормышыннан аерылмый диярлек. Моряклар даими төстә радио тыңлыйлар, телевизор, кино карыйлар, спорт белән шөгыльләнәләр. Ниһаять, моряк җир шарының теләсә кайсы ноктасында радиотелефон буенча якыннары белән сөйләшә ала. Әмма ни генә булмасын, чит җир чит җир инде. Радиотелефон аша хатыныңны коча алмыйсың. Кызыңның ефәктәй чәчләреннән сыйпый алмыйсың. Картайган әниеңә дә базардан ул сораган әйберләрне алып кайтып биреп булмый. Ә шулардан башка яшәве бик кыен. Хатын-кыз янында ир кеше акыллырак, киң күңеллерәк була икән. Хатыннар, күрәсең, безнең барлык уйларыбызга, эшләребезгә сиздерми генә стимул биреп торалар икән. Кызганычка каршы, без моны бик соңга калып — табигый тормыш шартларыннан аерылгач кына аңлый башлыйбыз. Ерак океаннарда йөзгәндә морякны айлар буена тупланган эмоциональ энергиядән ничек тә булса арыну инстинкты газаплый. Р. Мостафин моряк тормышының әнә шул ягын бик дөрес тотып алган. «Һәр суднода нинди дә булса җәнлек яки кош-корт була, — ди ул.— Өч ел дәвамында «Муса Җәлил»дә дә төрле-төрле җәнлекләр асрап караганнар» (35 бит). «Инде бер кат язган идем, суднода балыклардан тыш. Чарлик исемле эт бар, гап-гади урам эте, моряклар үзләренең сагышларын да, мәхәббәтләрен дә шуңа бушаталар» (122 бит).

Диңгезче дуслыгы — җир йөзендәге иң тирән һәм иң нык дуслыкларның берсе. Сагынган-саргайган минутларда, матрос күңелен шөбһәле уйлар борчыганда шул дуслык ярдәмгә килә. Әлеге мәсьәләгә тукталып, китап авторы болай яза: «Ерак сәяхәттәге экипаж зур бер гаилә кебек ул, анда кешенең кайгы-шатлыклары уртак. Бердичевскийның хатыны авырып киткән. Ул аның хәле ничек икәнен дә белми. Һәркем сүзсез генә аның кайгысын уртаклаша... Менә ике атна инде Коля Кожиновка өеннән хәбәр юк... Вахта тәмамланугa ул каютасына төшеп китә, диванга сузылып ята да, түшәмгә карап, сәгатьләр буе төтен пыскыта. Бу хәлдән аны хәтта Виктор Редько да чыгара алмый.

Кичә судноның эчке ягын буяп бетергән дә бер-ике минутка Коля каядыр китеп торган. Шул арада кемдер яңа гына буялган идән буйлап үткән. Коляның моны күреп тәмам җене чыкты» (96 бит). Егетнең нервлары какшый башлаган. Шундый моментларда аларга дуслары ярдәм кулы суза, коллектив булыша.

Дүрт айга сузылган рейс вакытында Р. Мостафин күп нәрсә күрергә өлгергән. Китапта диңгез судносының экономикасы турында эшлекле әңгәмә алып барыла, табышны күтәрү, моряклардың хезмәтен җиңеләйтү кебек мәсьәләләр кузгатыла. Әмма әсәрнең иң кыйммәтле ягы шунда, автор совет морякларының нинди идеаллар һәм нинди хыяллар белән яшәүләрен күрсәтә алган.

Экипаж членнарының яртысыннан артыгы диярлек читтән торып белем ала. Боцман Нетрусов штурман булырга җыена. Капитанның өлкән ярдәмчесе Пуринов, капитанлыкка зачет бирү өчен, экономика фәнен һәм инглиз телен өйрәнә.

Капиталистик илләрдәге суднолардан аермалы буларак, «Муса «Җәлил»-дә офицерлар кастасы һәм рядовойлар юк. Р. Мостафин дөрес күрсәткәнчә, теплоход капитаны коллективтан аерылган кеше түгел.

Роман Александрович Довгаль — 50—60 нчы елларда күтәрелгән капитаннарның типик бер вәкиле. Ул судноның экономикасын нык үзләштергән кеше, инглиз телендә сөйләшә ала, башка катлаулы мәсьәләләрне чишәргә сәләтле. Автор аның югары дәрәҗәдә интеллигент кеше булуына аеруча нык басым ясый.

Китапның соңгы битләрен канәгатьләнү хисләре белән ябасың. Тагын шул кадәресе куандыра, бездә гадәттә хәрби моряклар турында күп язсалар да, сәүдә флотында эшләүче моряклар, блокададагы Кубага азык-төлек илткән, күп айлар буе миналанган Тонкин култыгында утырырга мәҗбүр булган моряклар, күп төрле башка батырлыклар эшләгән моряклар турында әдәби әсәрләре юк диярлек.

Яңа басмаларын әзерләгәндә автор бу вариантта очраган кайбер төгәлсезлекләрне дә искә алыр дип ышанасы килә. Барлык очракларда диярлек автор судноны корабль дип йөртә. Күптән урнашкан традиция буенча, барлык сәүдә кораблары судно дип йөртелә. «Океанский сухогруз», «стою на форлике» кебек тәгъбирләр дә төгәл түгел. Һәм, ниһаять, китапның тиражын да зуррак итәргә кирәк булгандыр.

**МИРГАЗИЯН ЮНЫС.**

# ТӘҮБӘ ИТҮ — ТӨЗӘЛҮ ТҮГЕЛ ӘЛЕ

Әсгать Рәхимовның «Тәзкирәм» повестеның[1] исеме үк ничектер моңсу яңгырый. Ихтимал, бу моңсулыкны шул исемдәге борынгы җыр алып киләдер.

Ә менә Хәбир Әхмәтҗановның китап тышлыгындагы рәсемен күрүгә, моңсулык сөреме шунда ук тарала. Алгы планда икесе дә заманча киенгән көяз егет белән сылу кыз. Алар бер-берсенә сыенып кына сүзсез-тынсыз атлыйлар. Икесе дә тирән уйга чумган. Кыз бигрәк тә. Карашы җитди, күзләре барыр юлына төбәлгән... Сүз дә юк, рәссам бер карау белән игътибарны җәлеп итәрлек, әсәрне укып чыгарга өндәп торырлык рәсем ясаган. Ләкин ул әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларның гомуми характерына, повесть геройларының табигатенә туры киләме? Бу сорауларга җавап табу өчен, әсәрнең үзе белән танышыйк.

Күренекле язучыларның берсе: «Көтмәгәндә кызыклы итеп башланып киткән һәм нәкъ тиешле урында мәгънәле итеп тәмамланган әсәр генә — иң яхшы һәм иң сәнгатьчә әсәр санала», — диген.

Ә. Рәхимовның «Тәзкирәм» повестена бу яктан тел-теш тидерерлек түгел дияргә була. Әсәр Тәзкирәнең: «Эчтең. Яхшылап әйткәнне дә, үтенгәнне дә аңламадың, дәресрәге, аңларга теләмәдең», дигән сүзләре белән башлана. Һәм Тәлгатнең: «Аһ, эчмәгән булсам!» дигән сүзләре белән тәмамлана.

Повесть җыйнак-җыйнак ике бүлектән тора. Ул бүлекләрнең берсе Тәзкирә исеменнән, икенчесе Тәлгат исеменнән язылган. Әсәрне укыганда безнең күз алдыннан Тәлгат белән Тәзкирәнең берничә еллык гаилә тормышы уза, без аларның эше-хезмәте белән, характерлары белән танышабыз.

Тәзкирә белән Тәлгат җиңел генә танышалар, артык мәшәкатьләнми генә өйләнешәләр, бергә тора башлыйлар. Ләкин аларның гаилә тормышы озын гомерле булып чыкмый. Тәлгат бертуктаусыз эчә, вакытында өйгә кайтмый. Ахырдан хатынын да, баласын да ташлап бөтенләй чыгып китә... Гаеп Тәзкирәдә дә бар, билгеле. Ул алдын-артын уйламый ашыгып кияүгә чыккан өчен гаепле. Укытучы кыз Тәзкирә гаилә бәхетен саклау кебек мәсьәләгә дә җитдирәк карарга тиеш иде кебек. Әмма ни генә булмасын, кем генә гаепле булмасын, гаилә таркала, бер гөнаһсыз сабый әтисез үсә...

Мин әсәрнең эчтәлеген сүзгә-сүз сөйләп тормадым. Шулай да андагы вакыйгаларның шактый киеренке һәм катлаулы булуын сизгәнсездер дип уйлыйм. Яшь автор бу беренче повестенда ук инде тормыш материалы

[1] Ә. Рәхимов. Тәзкирәм. Повесть. Татарстан китап нәшрияты, тиражы 9000 данә.

өченә шактый тирән кергән. Әйтергә теләгән фикерләрен ачып салу өчен типажлар да сайлый алган. Әйтергә кирәк, повестьта бер генә артык кеше дә юк. Сәхнә теле белән әйтсәк, аларның һәркайсы үз рольләрендә, тиешле урында пәйда була, вакыйгага барышында, кирәкләре булмаса, югалып тора да беләләр. Шунысын да яшь авторның уңышы дип санарга кирәк: хикәяләүне ул ике шәхеснең (ир белән хатынның) аерым-аерым үз сөйләмнәре аша алып бара. Бу — шактый катлаулы алым. Яшь язучының болай яза алуы — күңелле хәл. Шулай ук табигать күренешләрен дә автор кешеләрнең кәефләренә, эчке тойгыларына бәйләп, фантазиясе белән баетып сурәтләүгә ирешә. Яшь хикәячёнең теле дә образлы, җыйнак, андагы һәр герой үзенә хас тел белән сөйләшә.

Менә егет белән кызның беренче очрашу күренеше:

«Кыяфәтең бик эшлекле иде синең. Сине күргәч тә битләрем кыза, иреннәрем кибә башлагандай булды. Мин ишектән кергәч, кулыңдагы карандашыңны уйнатып, кызышуы артә барган йөземә күтәрелеп карадың. Аннан соң күптәнге белешләр сыман елмаеп:

— Укытучы кыз Тәзкирә сез буласызмы инде? — дидең.

Мин йөземә текәлгән кара күзләрдән бөтенләй югалып калдым. Үзем дә сизми артка чигенеп бусагага бастым. Бусагага баскан өчен эти мәрхүм безне орышпа иде. Шуны искә төшереп, кыймыйча гына алга атладым. Әйтергә башка сүз таба алмыйча: «Әйе, мин», — дидем. Ул вакытта югалып калуымны әле хәзер дә аңлый алмыйм. Нәрсә иде ул? Кыюсызлык идеме? Я булмаса бүгенге шомлы киләчәкне сизенү идеме?..» (5 бит.)

Күрәсез, кечкенә генә күренештә никадәр хәрәкәт, күпме тормышчан детальләр!

Хисләрне табигать күренешләренә бәйләп күрсәтә белүнең дә мисалын китерим:

«Йөрәгем үземә ишетелерлек булып тибә башлады, чөнки бу чакыру — минем олы тормыш юлына дәшүең иде. Мин көттереп тормадым, тиз генә көзге пальтом белән мамык шәлемне алдым да апаңа ияреп тышка чыктым. Төн караңгы булган кебек, көпчәкләре бакырдыкка баткан тарантас та, китәргә ашкынып тыкрык чирәмен казучы ат та чем-кара булган икән» (7 бит).

Әсәрдәге вакыйгалар, яңа өйләнешкән егет белән кызның характерлары төрле булу сәбәпле, кискенләшкәннән-кискенләшә бара. Баштарак бу ике яшь йөрәкнең кайсы кыркурак булды соң әле дип, кемне гаепләргә дә белми пошынасың. Иң элек Тәлгатне кызгана башлаган идем, аннары Тәзкирә кызганыч тоела башлады... Кызганычлармы! Юк, укучы буларак, мин боларның берсен дә кызганырга тиеш түгел.

Инде килеп, әсәрен тәмамлап килгәндә генә автор аларның икесенең дә комсомол икәнлекләрен исенә төшерә.

Туйдан соң думбра, дигәндәй, авылда комсомол оешмасы барлыгы да ир белән хатын аерылышканнан соң гына беленә. Гомумән, бу ике яшьнең язмышларына халыкның, җәмәгатьчелекнең катнашлары әсәрдә чагылмый диярлек. Дөрес, Тәлгатнең шәхси эшен бюрода тикшерү кебек күренешләр бар. Ләкин болар әсәргә ясалма рәвештә, соңыннан ябыштырылган ямаулар шикелле генә килеп керәләр, бу ике яшьнең тормышына, язмышына үзгәреш кертә алмыйлар.

Әсәрдәге шушындый кимчелекләрне алдан ук төзәтергә мөмкин булгандыр дип беләм. Автор яшь, тиешле киңәшләр алганда, ихтимал, әсәрен алардан арындыра алыр иде.

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, повесть «Эчтең!» сүзе белән башланган иде, яшь ирнең: «Аһ, эчмәгән булсам!» — дип үкенүе белән тәмамлана. Бер карагандa, болай башлану белән болай тәмамлануда логик эзлеклелек тә бардыр. Әмма тәүбә итү төзәлдем дигән сүз түгел бит әле!

**ӘНӘС КАМАЛ.**

## Шәүкәт Галиев

### Жираф белән Зариф

Жираф Зарифны,
Зариф жирафны
Күрмичә калмый.
Жираф Зарифны,
Зариф жирафны
Ерактан таный.

Муен дигәнең
Берсенең — озын,
Берсенең — кыска.

Муен дигәнең
Кыскасы — кара,
Озыны — чиста...

Зариф жирафка,
Жираф Зарифка
Текәлеп карый.
Зариф жирафны,
Жираф Зарифны
Муеннан таный!..

### Чәйгә чумган шикәр турында

экият

Бер шакмак шикәр
Чәйгә чумган, ди,
Икенче шакмак
Көтеп торган, ди.

Саный-саный ул
Меңгә җиткән, ди,
Ә теге һаман
Чыкмый икән, ди...

Санап караган
Янә бер меңне:
«Ә соң ул йөзә
Беләм идеме?»

...Экият бу, дип,
Бер дә син көлмә —
Йөзә белмәсәң,
Чәйгә сикермә!

### Әйбәт пычрак

Чокыр буйлап,
Чакыр буйлап,
Көн буе мин
Йөрдем уйнап.

Әңгер җиткән,
Меңгер җиткән,
Әнкәй мине
Күптән көткән...

— Борның белән
Җир сөрдеңме?
Пычрак эзләп
Син йөрдеңме?

Каралгансың
Шайтан кебек.
Пешерсен бер
Атаң күреп!

Миннән дә соң
Кайтты әти,
Бер генә сүз
Әйтте әти:

— Бик яратса
Буялырга,
Минем белән
Барыр кырга!

•

Көн буе без
Сабан сөрдек!
Арып-талып
Кайтып кердек.

Каралгансың
Шайтан кебек.
Артыграк та —
Атаң кебек...

Эңгер-меңгер
Җиткән иде,
Әнкәй шактый
Көткән иде...

Юындырды,
Киендерде:
— Улым,— диде,—
Сөендерде! —

— Әллә, улым,
Җир сөрдеңме?
Тракторда
Гел йөрдеңме?

Бүген шул бу
Бүтән очрак —
Эш пычрагы,
Әйбәт пычрак!

## Бусы — хәрби сер!

Минем абый сакта тора.
Әни эштә чакта тора,
Әти юлда чакта тора,
Мин уйнаган чакта тора,
Син йоклаган чакта тора!

Телевизор да карамый,
Читкә карарга ярамый,
Чиккә генә карап тора,
Дошман килеп кермәсен, ди,
Безнең серне белмәсен, ди.

Әниләр эштә булганда,
Бер үзең генә калганда,
Түгел өйне саклап тору,
Бу бит — илне саклап тору!

Еракта-еракта тора,
Минем абый сакта тора.
Сакта һәр-һәр чакта тора.
Әйтмим, кайсы якта тора,
Син үзең дә сорап торма,
Бусы — хәрби сер!
Еракта-еракта тора,

## Күргәнең бардыр...

— Күргәнең бармы
Бүре койрыгын
Тарткан малайны?
Аю колагын
Йолкудан кызык
Тапкан малайны?
— Юк.

— Тартмый гына тор,
Тарттырыр сиңа,
Кагылып кара —
Аю, бүреләр
Усаллар алар,
Тешли дә ала!
— Ой!

— Күргәнең бардыр
Агач ботагын
Тарткан малайны.
Кош ояларын
Туздырып җиргә
Аткан малайны...
— Бар...

— Әй, шул чагында
Агачларның да
Тешләре булса,
Рәнҗетүчене
Аю шикелле
Үкереп куса!..
— Их!

## Ниятең нинди

1

Бик сак кына
Басып кына,
Күләгәгә
Посып кына,

Күзләрне шар
Ачып кына,
Йөри бүре
Качып кына...

Ниятләре —
Качарлык шул,
Кылганнары —
Начарлык шул!

2

Әнә тукран:
Тук-тук! Тук-тук!
Ишетәсең
Ерактан ук.

Берәүдән дә
Тормый качып,
Күз алдында,
Һәрчак ачык.

Ниятләре
Изгедә шул.
...Илдә бар да
Сизелә шул!

## Чәй кәгазенә төреп...

Кульяулыгы Хәйдәрнең
Һәр вакыт чиста йөрер.
Ничек чиста йөрмәсен —
Чәй кәгазенә төрер!

Чәй кәгазенә төрер,
Төргән көенә генә,
Китап арасына салып,
Саклар өендә генә!

Булыр иде чистарак,
Булыр иде урынлы —
Чәй кәгазенә төреп
Өйдә тотса борынны...

## Һәркемнең үз эше...

1

Абзый таңнан
Эшкә бара.
Артыннан бер
Эт тә бара.

Әйләнә дә
Абзый карый —
Килә теге,
Һаман калмый!

«Мин, ичмасам,
Эшләп йөрим,
Ә бу маэмай
Нишләп йөри?!»

2

Инде маэмай
Алдан атлый —
Ул бит монда
Урам саклый.

Әйләнә дә
Маэмай карый —
Килә теге,
Һаман калмый!

«Мин, ичмасам,
Эшләп йөрим.
Ә бу абзый
Нишләп йөри?!»

## Ник соң әле итек җитмәде?

(мәзәк-мәсьәлә)

Эшли икән Аю кибеттә,
Сата икән Аю итекләр.
Киштәләргә, әнә, тезелгән,
Чамалаган Аю үзеннән —
Һәр борынга ике пар алган,
Һәммәсенә тигез каралган!

Иң беренче булып кем керә —
Иң беренче керә Кенгерә.
Аю әйтә:
— Сайлап ал, дия,
Сайлар өчен чама бар, дия.
Кенгерә тиз алып өлгерә,
Ике итек киеп йөгерә.

Сигезаяк керә үрмәләп:
— Карыйк әле, дия, бергәләп.
Аю әйтә:
— Сайлап ал, дия,
Сайлар өчен чама бар, дия.

Чыгып китте Сигезаяк та —
Сигез итек сигез аякта...

Йомшак басып керә Арыслан,
Харап инде моңа карышсаң.
Аю әйтә:
— Сайлап ал, дия,
Сайлар өчен чама бар, дия.
Үзе бер пар итек китергән...
Әй Арыслан яман үкергән:
— Кайда, дигән, минем итекләр!

Аңламыйча Аю интеккән,
Күзен кысып башын кашыган:
— Алган идем борын башыннан...
Беркем артык киеп китмәде,
Ник соң әле итек җитмәде?!
Санап бирер тизрәк кем генә,
Я, әйтегез инде, кем белә?

## «Бабай килә!»

Көйсезләндең,
Еладыңмы,
Тиешсезне
Сорадыңмы,

Әти-әни
Бер сүз белә:
— Бабай килә!
Бабай килә!

Без йөрибез
Тып-тын гына,
Мәче сыман
Мыштым гына...

Килсә бабай
Капчык алып!
Китсә бабай
Безне салып!

Ой-ой-ой-ой-ой...
Ой-ой-ой-ой-ой...

Еламаган-
Нитмәгәндә,
Курыкмаган,
Көтмәгәндә

Капчык асып
Бабай килде...
Тотып алды...
Куккә чөйде!

Күзен кысып
Үзе көлде,
Чәчләремнән
Минем сөйде!

Зур капчыгын
Бабай ачты...
«Беттем...» — дидем,
Тизрәк качтым.

Килеп тапты,
Кочып алды,
Чикләвекләр
Учка салды.

«Үскәнсез, ди,
Оныкларым!»
Куркырга да
Онытканмын,

Уйныйбыз без
Бергә-бергә:
— Китмә, яме,
Бабай, бер дә!

Хәзер ялгыш
Еладыңмы,
Артыгракны
Сорадыңмы,

Әти-әни
Болай итә:
— Бабай китә!
Бабай китә!

Без йөрибез
Тып-тын гына,
Мәче сыман
Мыштым гына.

Бабай китсә
Нишләрбез, ә?
Бик күңелсез
Булыр безгә!

Ой-ой-ой-ой-ой...
Ой-ой-ой-ой-ой...

# ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...




*Сугыш елларында тылда калдырылган язучыларны фронт газеталары редакцияләренә командировкага җибәрү практикасы бар иде. Төньяк-көнбатыш фронтында чыгып килгән «Ватан өчен» газетасы редакциясенә Гомер Бәширов (ул вакытта Разин иде) барып кайтканнан соң, партиянең өлкә комитеты мине җибәрде. 1943 елның кышын һәм язын мин шул газета редакциясендә булдым. Аның редакторы Гани иптәш Гыйльманов иде. Редакция сотрудниклары арасында Хатип Госман, Шәрәф Мөдәррис, журналист Әхмәди иптәшләр булды. «Ватан өчен» дүрт телдә чыга иде (русча, татарча, казакъча, үзбәкчә). Безгә анда рус язучыларыннан Кузьма Горбунов, Александр Исбах, Борис Жаков, казакълардан Җобан Мулдагалиев, Сагынгали Сеитов иптәшләр белән бер вагонда, бер гаилә булып яшәргә туры килде. Атна саен алгы сызыкка — дошман белән маңгайга-маңгай торып сугыш алып баручы бүлекчәләргә — окопларга, землянкаларга командировкага бара идек. Миңа Хатип Госман, Шәрәф Мөдәррис иптәшләр белән бергәләп шактый күп йөрергә туры килде. Немецларның Демянск плацдармын азат иткән көннәрдә, Хатип Госман белән бергәләп, немецларны куып киткән алдынгы полкларның артыннан җитә алмыйча, киез итекләрдән килеш, язгы юлларны тутырып аккан су эченнән йөзләрчә километр үткән чаклар аеруча истә калган.*

*Алдынгы бүлекчәләрнең сугышчан хәрәкәтләре, аерым сугышчы һәм командирларның (татар газетасы өчен булгач, бигрәк тә татарларның) геройлыклары турында хәбәр һәм мәкаләләр язу өстенә, миңа газетаның юмор-сатира бүлегендә дә актив катнашырга туры килде. «Чаян фронтта» исеме астында чыккан шул бүлектә басылып килгән әсәрләремнең берничәсен бүгенге укучының исенә төшереп китү зарар итмәс дип уйлыйм.*

МИРСӘЙ ӘМИР

## Немецча бишек җыруы

— Быел, шушы айда, Габдулла Тукайның үлүенә 30 ел тулды бит,— диде Сәми.— Шул уңай белән искә төшереп алыйк әле үзен,— диде.— Бик яраткан шагыйребез бит ул безнең. Аның шигырьләрен бишектән үк ишетеп киләбез. Менә бит, әни мине бишектә тирбәткән чакта Тукайның менә бу шигырен көйли иде,— дип укый да башлады:

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу...

Барыбызга да таныш инде бу. Бала чаклар искә төшеп китте. Рәхәтләнеп, эреп киттек без. Шунда бер сугышчы болай дип куйды:
— Һәр халыкның шундый Тукай кебек шагыйре булган. Һәрбер ана шуларны көйләп, үзенең баласын шулай яхшы теләкләр белән,

яхшы кеше итеп тәрбияләгән. Ә менә бу эттән туган немецны әйтәм, шундый шагыйрьләре дә булмады микәнни?

Бервакытта да җавапка аптырамый торган Шәми аңа сөйләп бетерергә дә бирмәде:

— Нигә булмасын, немецларның да яхшы шагыйрьләре булган. Тик фашистлар аларның шигырьләрен утта яндырып бетерделәр. Ә немец аналарына, балаларын йоклаткан вакытта көйләр өчен, Геббельс үзе менә мондый җыр язып биргән, ди:

Әлли-бәлли итәр бу,
Этлек әзләп китәр бу;
Этлек гыйльмен өйрәнгәч,
Фашист булып җитәр бу.

Йокла, убырым, йом күзең,
Йом-йом күзең, дуңгызым;
Төнлә йокың кала да,
Сугышып үтә көндезең.

Әлли-бәлли көйләрем,
Явыз уйлар сөйләрем,
Сиңа теләк теләрем,
Зур бандит бул диярем.

Жулигым син, бурым син,
Ач маймылдан тудың син;
Бирәнем син, убыр син,
Бар дөньяны умыр син.

Немец хатыннары, үзләренең балаларын йоклатканда, хәзер менә шуны көйләргә тиеш, ди.

## Тотса Мәскәүләр якаң

Тукайны искә алып утыра торгач, Сәми аның:

Нә кылырсың, Хаҗи абзый,
Тотса Мәскәүләр якаң?

— дигән шигырен укып җибәрде. Әлеге тиктормас Шәми тагын да болай дип куйды:

— Тукай хәзер исән булса, минемчә, бу шигырен болай язмаган булыр иде.

— Ә ничек язган булыр иде?

— Менә ничек:

Нә кылырсың, Гитлер-эт җан, тотса Мәскәүләр якаң?
Как ты будешь отвечать там, тотса Мәскәүләр якаң?
Сыймас идең киң җиһанга, каныңа мәгърур булып,
Даже в кабер сыярсың, тотса Мәскәүләр якаң.
Әйләнәңдә әйләнеп йөргән барон, бирән баең,
Үз хәле хәл булыр аның, тотса Мәскәүләр якаң...
Сыймыйча Германиягә, читләргә тыкшыну нигә?
Бер өнеңә зар булырсың, тотса Мәскәүләр якаң.

## Табышмак әйтәм, тап!

Беркөнне шулай блиндажда утырабыз. Ул-бу юк. Сәми әллә каян «Табышмаклар» дигән китап китереп чыгарды.

— Табыгыз,— ди бу,— табышмак әйтәм. Минем кулда бер мең дә дүрт йөз алтмыш сигез табышмак бар,— ди.

Шәми сикереп торды:

— Әйт табышмакларыңны,— ди,— китабыңның артына карамыйча дөп-дөрес җавапларын бирә барам!

Сәми укый башлады:

— Я, тап: «Күктә кибән яна».— Ул нәрсә?

— Немец бомбардировщигы инде, аны да белмәскә!

— Синеңчә булсын, җавабын карап та тормыйк. Инде монысын тап: «Җиде чатның башында бер ихахай утыра; канатына кар каткан, кагылмыйча утыра».— Бусы нәрсә?

— Немец ташлап качкан самолет.

— «Дию пәрие күккә аша, ашы-суы җирдә кала».— Бусы ни?

— Бумы? Немец генералы ашап утырган чакта безнекеләр бомба ыргыткан да, генералның көле күккә очкан.

— Юк, белмәдең, монда «төтен» дигән.

— Ну, төтен булып очкан, ди. Барыбер түгелмени? Әйт тагын.

— «Нинди ана үзенең кызларын имә?» — Я, тап!

— Мондый эшне фриц анасыннан гына көтәргә мөмкин.

— Синеңчә булсын. Инде монысын тап: «Ике алаша читән аша талаша», ди.

— Билгеле инде: Антонеску белән Хорти.

— «Кара аю өнендә кара азык әзерли».— Бусы ни?

— Гитлер.

— «Елан шуа килә, йорты җимерелә килә», дигән.

— Бусы инде Гитлер Германиясе.

— «Җирән айгыр егылган, йөз мең кеше җыелган».— Я, бел!

— Моны да белмәскә! Чолганышта калган немецлар ат үләксәсенә ташланганнар.

— Туры килә, җавабын эзләп тормыйбыз.

— Менә тагын бер бик озын табышмак:

«Канаты гәр булса да,
Һич тә оча алмыйдыр.
Тамак күпме җыйса да,
Һич тә туя алмыйдыр.
Минут саен ачыга,
Көчәнәдер һич юкка.
Канатлары үкерә,
Мисалы ач карчыга».

— Я, әйтеп кара!

— Гитлер армиясе инде бу.

— Юк, җавабында «җил тегермәне» дигән.

— Шул инде, Геббельс тегермәне. Әйдә, тагын әйт.

— «Җир астында җиз бүкән».

— Бусы инде аның кабергә кергән немец.

— Ә бусы: «Кырык кат күлмәк кигән, туңкаеп үлгән?»

— Анысы күмелмәгән кышкы фриц.

— Мә, алайса, тагы берне:

«Урманнан чыгар,
Койрык очы чуар.
Вәҗми тотар,
Нәҗми суяр».

— Бусымы? Бусы...

Нәкъ шул вакытта атыш тавышлары ишетелде. Шәми аз гына тыңлап торды да:

— Немецлар,— диде.— Әйдә, син Вәҗми булырсың, мин Нәҗми булырмын...

Шуның белән табышмак әйтешү тукталды. Бушаган арада тагын да әйтешербез әле.

Фашист тылындагы бер тимер юл станциясендә көнчыгышка таба килүче немец малайлары, ягъни эрзац-солдатлар арасында кызу әңгәмә бара:

— Шәһәрләрне планлы рәвештә калдыру бик шәп нәрсә инде ул, минемчә,— ди берсе.— Башта бөтен кораллар, кирәк-яраклар чыгарылып бетә. Аннан соң тәртип белән генә машиналарга утырып...

Аңа сөйләп бетерергә ирек бирмиләр. Көнчыгыштан көнбатышка таба кайтып баручы берәү — ике кулын, бер аягын, сыңар күзен Россиядә калдырып киткән, бинт белән чолганып беткән кечкенә башыннан беләк буе булып борыны гына сөрәеп торган тәҗрибәле карт фриц — сүзгә катнаша.

— Менә миннән сорагыз,— ди ул,— мин үз күзем белән күргән кеше.

Эрзац-солдатлар шым булып калалар. Барының да тәҗрибәле карт фриц сүзләрен ишетәсе килә.

— Планлы рәвештә шәһәр калдыру — ул бөтенләй көтмәгәндә башлана. Әйтик, син берничә сәгатьтән руслар өстенә һөҗүм башларга әзерләнәсең. Бу бик тирән сер була. Һөҗүм вакытында нык булыйм дип, ашап утырган чагың була, ә шунда снаряжениеләрне рәтләп, тишек-ертыкларны ямап утырасың. Алдагы постлар үз урыннарында. Берниндн куркыныч юк әле. Кыскасы, шәһәрне калдыру уеңда да булмый. «Немец бер кергән җирдән кире чыкмас»,— дип, үз өеңдәге кебек утырасың. Менә бер заман, уйламаганда, я кабыргадан, я бөтенләй арт яктан бәрергә тотыналар. Янында утырган иптәшең канатсыз-нисез һавага очып китә. Зирәбәр, дөбер-шатыр, доннер-веттер... кыскасы, син нинди дә булса план турында уйлый башлаганда, шәһәр берничә километр артта калып өлгергән була инде. Менә шулай ул шәһәрләрне планлы рәвештә калдыру.

Авызларын ачып тыңлап утыручы эрзац-солдатларның берсе тагын да сорау бирә:

— Менә, «немец бер кергән җирдән чыкмас», дибез. Шулай булгач, ул ничек була соң инде?

— Андый хәлләр дә еш була. Просто чыгарга мөмкинлек булмый. Менә минем иптәшләр тәки блиндаждан чыкмый ятып калдылар. Сталинград янында чолганышка кереп утырган бөтен армия дә чыкмый калды бит. Аңларга читен бернәрсә дә юк монда.

— «Рус артиллериясе» дигән сүзне бик еш ишетергә туры килә. Син инде, сугышта булгач, аны үз күзләрең белән күргәнсеңдер. Ниндирәк соң ул үзе?

— Юк, аны күреп булмый. Күзгә күренми торган металлдан ясалган диләр аны. Кинәт тирә-ягыңда җәһәннәм кайный башлый, блиндажлар җимерелә, янындагылар җен шикелле юкка чыга башлый. Шунда гына рус артиллериясе ата башлаганны беләсең.

— Ә аңардан ничек котылырга соң? Өйрәт инде син безне.

— Атаң-анаң изге кеше булсалар, аларның фатихасы белән генә исән калып була. Ләкин аңа гына ышанып торырга ярамый. Мөмкин кадәр кулларыңны саклап калырга тырышырга кирәк. Чөнки канонададан исән калсаң, русларның танклары килә башлый. Алар артыннан пехоталары өстеңә ташлана. Менә шул вакытта инде кулларың исән булса, икесен дә берьюлы югары күтәрәсең дә үлми каласың, башка юл юк.

— Ә менә син?
— Мин мин инде ул. Мин иң бәхетле немец булып...
Ләкин аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәделәр. Шул тирәдә утыручы гестапо агенты белдерде:
— Күтәр кулларыңны, шпион!
Солдат кул урыннарын селкетеп куйды һәм сыңар аягына басып күтәрелергә азапланды.

## Фриц фриц сүзеннән чыкмый

Безнең артиллерия тарафыннан ачылган ут өермәсе астында калган бер төркем фриц, борыннарын җиргә тыгып, фриц телендә иманнарын укып яталар. Тәҗрибәле фриц-ефрейтор Шайтанер аларга киңәш бирә:
— Карагыз, урыннарыгыздан кузгалмагыз, башыгызны күтәрмәгез,— ди.
Түрәләре каршында яхшы атлы булырга теләүче ялагай фриц Букәннер аңа җавап бирә:
— Берүк үзегезне саклый күрегез, һерр ефрейтор, безнең өчен кузгала күрмәгез,— ди.
Фриц фриц сүзеннән чыкмаган. Безнекеләр ул җирне таптап алга узган вакытта да, алар урыннарыннан кузгалмадылар. Башларын күтәрмәделәр. Башлары булса, бәлки күтәргән дә булырлар иде, ләкин аларның баш диярдәй җире калмаган иде инде.

## Кем нәрсә күтәрә

Яраланган офицерлары янында ике немец солдаты сөйләшә:
— Син кайсын күтәрәсең, фриц, һерр обер-лейтенантнымы, әллә һерр капитаннымы?
— Мин үкчәне күтәрәм.
— Ә мин кулларны күтәрергә уйлап торам.

## Урманда

Г а н с. Фриц, кайда син?
Ф р и ц. Мин рус разведчигын тоттым.
Г а н с. Алып кил үзен бирегә!
Ф р и ц. Җибәрми...

## Әйдә шулай булсын!

Гитлер һәм аның шайкасының ахмаклыкта, мәгънәсезлектә, җавапсызлыкта, оятсызлыкта һәм мактанчыклыкта тиңе булмаган белдерүләренә нинди дә булса мәгънә бирү читен иде. Саф акыл алар турында җитди фикер йөртергә баш тарта иде.
«Җиңелмәс армия», «немец бер кергән җирдән кире чыкмас», «кышкы квартира», «фронт линиясен турайту, кыскарту», «сыгылмалы фронт», «планлы рәвештә шәһәрләр калдыру» кебек кызыклы сүзләр; таушалып беткән «немец тәгәллеген» чыкылдап торган анекдотка әверелдергән срок билгеләүләр — аз булдымыни алар. Бөтен дөнья тавыклары бер булып чүпләсәләр дә, хәтта аларга

Җир шарында булган кыргый кош-кортлар булышса да, бетәсе түгел алар — геббельслар авызыннан чәчелгән ялган бөртекләре.

Ялган дибез. Ләкин дөреслекне дә яшереп булмый. Хәзер инде без ул сүзләрдә, билгеле бер дәрәҗәдә, дөресрәге, билгеле бер мәгънәдә, «хакыйкать» өлеше дә барлыкны күрдек. Әйтик, бер заман немецлар «кышкы квартирага күчәбез» диделәр. Кышның нәрсә икәнлеге турында безнең халыкка аңлатып торасы юк. Кыш — кар, буран, суык дигән сүз инде ул. «Бер кергән җирдән чыкмый» торган немецлар, «кышкы квартираларга күчү» сылтавы белән, кар өстенә, буран астына, салкын кочагына чыктылар. Дөрес бит? «Немец бер кергән җирдән чыкмас» дигән сүздә дә хакыйкать өлеше аз түгел. Әйтик, немец кабергә керә икән, ул инде анда чын-чыннан немец тәкәбберлеге белән нык урнаша. Чыкмый. Тимер тәре күрсәтсәң дә, үлгән ат ите күрсәтсәң дә чыкмый. Чыкмасын. Тагын, әйтик, немец чолганышта калган икән, ул инде аннан да чыкмый. Чыкмасын.

«Фронт линиясен кыскартабыз», диләр икән, монда да дөреслек юк түгел. Армияләрең тар-мар ителә башласа, гаскәрләрең йөзәр меңләп плен төшә башласа, сайлап җыелган дивизияләрең дистәләп-дистәләп юкка чыга башласа, фронтыңның кыскармый хәле юк. Кыскарсын. Кыскара-кыскара, Данциг коридоры киңлегендә генә кала икән, аның белән кемне куркытасың! Кыскарсын, кыскарсын.

«Планлы рәвештә» Ростовны, Ворошиловградны, Харьковны калдырабыз диләр икән, дөреслек өлеше юкмыни? Әйтик, «калдырабыз» дигән өлеше хакыйкать түгелмени? Калдырсын. Гитлер — ул планнарны зурдан бәрдерергә ярата торган нәрсә. Үзенең Берлинны калдырып, морҗадан очачагын планлаштырып куйган булса да, гаҗәп түгел. Эш калдыруда түгел, эш планда. «Бу сугышта җиңүчеләр яки җиңелүчеләр булмаячак, фәкать исән калучылар яки юк ителүчеләр генә булачак», дип, үзенең юк ителәсен дә планлаштырып куйды инде ул. Без каршы түгел. Юк ителсен. Әйе, без каршы түгел. Немец кабергә керәме, чолганышта каламы — чыкмасын! Фронт линиясен кыскартамы — кыскартсын, юк дәрәҗәсенә калганчы кыскартсын. Шәһәрләрне, авылларны, җирләрне калдырамы — күбрәк калдырсын. Без анда нишләргә белербез. Шәһәрләрне яңадан гөрләтеп, терелтеп җибәрербез. Җир өстен тутырып иген чәчәрбез. Көл белән, гади кош-корт тизәге, сыер «кабартмасы», ат, дуңгыз кебек хайваннар эшләп чыгарган тирес һәм фашист каны белән ашланган җир өстендә күкрәп үсәр безнең игеннәр.

Ә бүген, дошман теләсә ни дисен, кырыйк без аны, егетләр!

1943, март

## Хәйдәр Гатин

### Шәп машина

Баш күтәрми тәне буе яздым,
Шигырь белән тулды биш дәфтәр.
Әйбәтлектә шик юк, тик берьюлы
Бу кадәрне кабул итмәсләр.

Шунда кинәт, кояш чыккан кебек,
Даһи фикер килде башыма.
Тотарга да әмәлләргә кирәк
Шигырь сортлый торган машина.

...Чоландагы иске сепаратның
Шөребе дә читтә калмады.
Бер ягыннан акса сыек шигырь,
Бер ягыннан агар каймагы.

Вәт машина, болай оста итеп
Чүпләп бирә алмас тавык та...
«Кырлар-сырлар», «җырлар-мырлар» дигән
Дүрт сүз ята иде савытта.

### Бүкән

Йомыш төшеп кабинетка кергәч беркөн,
Мин анда бер күзлек элгән бүкән күрдем.
Карашлары шундый салкын, шундый эре,
Сүзләреннән өшеп чыга килгән бере.

Булыр икән елмаюны белмәс кеше,
Хуҗа Насретдин килсә дә, көлмәс кеше,
Кул бирүне, мөгаен, оныткандыр ул,
Бөгелмәскә уклау-фәлән йоткандыр ул.

...Очраштыргач көтмәгәндә язмыш тагын,
Аңладым мин үземнең нык ялгышканым.
Күр, ул бүген нинди көләч, игътибарлы.
Әллә, димен, моның берәр сере бармы?

Каршысында үзеннән зур түрә икән,
Елмаюы аның шуңа күрә икән.
Карап аның мышный-мышный бөгелгәнен,
Әй, шул чакта рәхәтләнеп бер көлгәнем!

## Элек һәм... хәзер

Элек миңа кондукторлар
Тынгы бирмиләр иде.
— Арткы ишектән кер,— диеп,
Һәрчак тиргиләр иде.

Сизеп торам, никтер алар
Хәзер мине күзәтми.
Алдан керәмме, арттанмы,
Беркем миңа сүз әйтми.

Киресенчә, мин бараммы,
Кайтаммы кичен эштән,
— Рәхим итеп утырыгыз,—
Дигән сүзләр ишетәм.

Яшьләр торып урын бирә,
...Картаеп барам, димәк.
— Рәхмәт,— дисәм дә, нигәдер
Шатландырмый бу хөрмәт.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЖЫР ҺӘМ БҮГЕНГЕ ЗАМАН

Татарстан язучылар һәм композиторлар союзларының март аенда Казанда үткән берләштерелгән пленумында менә шушы темага зур сөйләшү булды. Сөйләшүдә, композитор һәм язучылар белән бергә, жырчы һәм башкаручы музыкантлар, киң җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

Пленумны халкыбыз яратып тыңлаган жырларның сүзләр авторы, М. Горький һәм Г. Тукай премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким ачты. Ул бүгенге жыр культурасы, аны халкыбызның рухи тормышы таләпләренә тулырак җавап бирерлек итеп үстерү хакында фикер алышуның мөһим һәм өлгергән мәсьәлә булуын билгеләп үтте.

СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор секторы мөдире, филология фәннәре кандидаты Илбарис Надыйров пленумда бүгенге жырларыбызның сүзләрен анализлауга багышланган доклад белән чыкты. Докладта, зур мәгънәле, тирән хисләр алып килә торган жырлар белән бер үк вакытта, көй-музыкага ябышып кына яшәүче, жырга лаек камиллеккә ирешеп җитмәгән сай эчтәлекле текстларның аз түгеллеге күрсәтелде.

Пленумда жыр хәзинәбезне баету, аның тематикасын киңәйтү, жыр культурасын үстерүгә комачаулый торган киртәләрне бетерү, заманыбызга лаеклы жырларны күбрәк тудыру хакындагы фикерләре белән музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина, шагыйрь һәм композиторлар Нури Арсланов, Нәкый Исәнбәт, Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, Заһид Хәбибуллин, Хәй Вахит, Әхмәт Хәйретдинов, Әхсән Баянов, Гариф Ахунов, Рафаэль Билялов, Рәзил Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Галимҗан Латыйп, сәнгать фәннәре кандидаты Земфира Сайдәшева, Татарстан радиокомитетының музыкаль редакциясе хезмәткәре шагыйрь Зиннур Насыйбуллин, Татарстан китап нәшрияты редакторы Марк Зарецкий, Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе әдәби редакторы Әдхәт Синегулов иптәшләр чыктылар. Сөйләшүдә бүгенге жыр хуҗалыгыбызны тиешенчә тәртипкә салу, гүзәл жырлар күбрәк туа торсын өчен иҗади оешмаларда төрле оештыру эшләрен яхшырту буенча күп кенә конкрет тәкъдимнәр кертелде. Шул җөмләдән, һәр ел саен яңа жырлар кичәләре үткәрү, жыр иҗатына күренекле шагыйрьләребезне күбрәк тарту, яшь композитор һәм жырчыларга ана телебезнең нечкәлекләрен үзләштерүдә ярдәм итү, жыр текстларын тикшерү һәм бәяләү өчен иҗади оешмаларда махсус комиссия булдыру, Композиторлар һәм Язучылар союзларының иҗади элементләрен ныгыту, үзешчән авторларга тагын да нәтиҗәлерәк иҗади ярдәм күрсәтү, жыр жанрын фәнни өйрәнүне көчәйтү һ. б. күп кенә практик чараларны үткәрү турындагы тәкъдимнәр хупланды.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ БӨТЕНСОЮЗ КИҢӘШМӘСЕНДӘ ТАТАРСТАН ВӘКИЛЛӘРЕ

18—20 март көннәрендә Мәскәүдә ВЛКСМ Үзәк Комитеты һәм СССР Язучылар союзы яшь язучыларның Бөтенсоюз киңәшмәсен үткәрде. Киңәшмәдә Татарстаннан яшь каләм ияләре — прозаиклар Ә. Гаффаров һәм М. Галиев, КамАЗ турындагы очерклары белән танылган Р. Вәлиев, шагыйрь Р. Бохараев катнашты. Яшьләрнең әсәрләре ил күләмендә танылган өлкән әдипләр алдында сынау узды, семинарларда җентекләп тикшерелде, төпле бәя алды.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Татарстан язучылар союзы партия оешмасының әдәбият-сәнгать тәнкыйтен үстерү чараларына багышланган ачык партия җыелышы булып үтте.

Җыелыш әдәбият һәм сәнгать тәнкыйте өлкәсендә соңгы елларда җәелеп киткән күп кырлы һәм киеренке эшчәнлек нәтиҗәләренә йомгак ясады. Бу мәсьәлә буенча өлкән тәнкыйтьче Хәсән Хәйри дә, фикер алышуда катнашкан тәнкыйтьчеләр Флүн Мусин, Фарваз Миңнуллин, Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов та төп игътибарны алдагы елларда хәл ителәсе җитди бурычларга юнәлтәләр.

Әдәбият-сәнгать тәнкыйтен тагын да үстерү буенча алдагы өч елга билгеләнгән яңа чаралар планын җыелышта катнашучылар бердәм хупладылар. Планда тәнкыйтьчеләребезнең хезмәтләрен туплаган махсус җыентыклар чыгару, иҗади дискус-

сиялэр оештыру, яшь тәнкыйтьчеләрнең рецензияләренә конкурс үткәрү кебек мәһим чаралар бар.

## ДРАМАТУРГЛАР КИҢӘШӘ

Март аенда Татарстан язучылар союзында драматурглар һәм тәнкыйтьчеләр секцияләренең комедия жанры бурычларына багышланган берләштерелгән утырышы булды. Комедиянең бүгенге торышын, ул жанрдагы әсәрләрнең уңышларын һәм кимчелекләрен анализлап, филология фәннәре кандидаты Азат Әхмәдуллин доклад ясады. Утырышта чыгыш ясаган иптәшләр соңгы еллар эчендә иҗат ителгән әсәрләрне төрле яклап бәяләделәр, ул жанрны үстерү юлында хәл ителәсе мәсьәләләр хакында файдалы фикерләр әйттеләр.

## ТАТАР ӘДИБЕНЕҢ ӘСӘРЕ БОЛГАР ТЕЛЕНДӘ

Күренекле язучы Ә. Еникинең «Җиз кыңгырау» хикәясе «Дружба» исемле әдәбият-сәнгать һәм иҗтимагый-политик альманахның бишенче чыгарылышында Софиядә «Народна младеж» нәшриятында болгар телендә басылган.

## ИЛ МАТБУГАТЫ ТАТАР СӘНГАТЕ ТУРЫНДА

«Россия халыкларының ювелирлык сәнгате» (Ленинград, «Художник РСФСР», 1974 ел) дигән исем белән чыккан китапның бүлекләреннән берсе Идел буе татарларының ювелир бизәкләренә багышланган. Төсле иллюстрацияләр белән бирелгән бу мәкаләдә Идел буе татарлары эшләгән ювелир әйберләренең нәфислеге, төсләр ягыннан зәвыклелеге, оригинальлеге югары бәяләнә.

## «БАР ҖЫРЫМНЫ ИЛГӘ БАГЫШЛАДЫМ»

Шул исемдә Казанда һәм Чаллыда каһарман шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелде. Аларда М. Җәлилнең көрәш һәм иҗат юлын өйрәнүгә зур хезмәт керткән әдипләр Гази Кашшаф һәм Рафаэль Мостафин, композитор Рөстәм Яхин, Татарстанның халык артистлары Айрат Арсланов, Эмиль Җәләлетдинов катнаштылар.

* * *

Мартта һәм апрельдә Р. Мостафинның «Герой шагыйрь эзләреннән» дигән китабы буенча Казанның медицина работниклары йортында, пионерларның А. Алиш исемендәге һәм Ленин районы Сарайларында, хәрби частьта, профессиональ-техник училищеларда укучылар конференцияләре узды.

* * *

Мордовия дәүләт педагогия институтының филология факультеты студентлары патриот-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган әдәби кичә үткәрделәр. Анда шулай ук «Коммунист-шагыйрь» дигән китап күргәзмәсе оештырылган иде.

* * *

Пермь шәһәренең 109 нчы урта мәктәбендә Муса Җәлилгә багышланган әдәби кичә үткәрелде. Бу мәктәпнең пионерлары үзләренең отрядларына каһарман шагыйрь исемен кушу хокукы өчен көрәшәләр.

## БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 30 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

Март-апрель айларында республикабызның башкаласында һәм башка шәһәрләрендә «Казан язы» исемле традицион әдәби-музыкаль кичәләр булып үтте. Алар быел совет халкының Бөек Ватан сугышында Җиңүенә 30 ел тулуга багышланган иде. Очрашуларның үзәгендә халкыбызның фронтта һәм тылда җырларга, роман-поэмаларга кергән тиңсез батырлыгы темасы торды. Сугыш дәһшәтен үз башыннан кичергән, төрле фронтларда утлы сынаулар аша узган язучы һәм шагыйрьләр Сибгат Хәким, Риза Ишморат, Мөхәммәт Садри, Әмирхан Еники, Зәки Нури, Нәби Дәүли, шулай ук совет солдатының сугыштагы каһарманлыгын күрсәткән әсәрләр иҗат итеп, хәрби теманы әдәби үзләштерүгә өлеш керткән әдипләр М. Мәһдиев, Г. Ахунов, М. Шабаев, Р. Фәйзуллин, Ш. Рәкыйпов, В. Нуруллин, Зөлфәт һ. б. лар культура сарайлары һәм клубларда, предприятиеләрдә һәм уку йортларында, мәктәпләрдә, китапханәләрдә үткәрелгән кичәләрдә чыгыш ясадылар. Сәнгать осталары Ватан сугышына һәм Җиңү темасына багышланган әдәби һәм музыкаль әсәрләр башкардылар. Беренче мондый кичәләр Казанның сәүдә работниклары йортында, төзү конструкцияләре комбинаты клубында, төзүчеләрнең Культура сараенда үтте, аларда шәһәрнең меңнәрчә хезмәт ияләре катнашты.

* * *

Язучы Нәби Дәүли Казан дәүләт педагогия институтында, хәрби частьта һәм мәктәпләрдә сугыш темасына язылган әсәрләре буенча укучылар белән очрашулар үткәрде.

* * *

Февральдә Казанның Политик мәгариф йортында республикабыздагы комсомол райкомнарының беренче секретарьлары белән очрашу үткәрелде. Очрашуда, Бөек

Ватан сугышы ветераны М. Ф. Гайсин белән бергә, яшь шагыйрьләр Госман Садә һәм Роберт Миңнуллин да катнаштылар һәм хәрби темага язылган шигырьләрен укыдылар.

*
* *

Республика мәктәпләрендә, югары уку йортларында һәм техникумнарда, хәрби училищеларда, фронтовик язучылар катнашы белән, Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышланган укучылар конференцияләре узды. Шагыйрьләр Әхмәт Исхак, Мөхәммәт Садри, Сибгат Хәким, Нәби Дәүли, Зәки Нури, драматург Риза Ишморат, прозаиклар Атилла Расих, Габдрахман Минский һ. б. лар шундый дистәләрчә конференцияләрдә катнаштылар, укучыларга әсәрләренең язылу тарихы, сугыш истәлекләрен сөйләделәр.

## ОРША ШӘҺӘРЕНЕҢ ПОЧЕТЛЫ ГРАЖДАНИНЫ

Советлар Союзы Герое К. Заслоновның сугыш елларындагы атаклы партизаннар берләшмәсе разведчик-партизаны шагыйрь Зәки Нури март аенда Витебск өлкәсендә булды.

Орша шәһәр Советы башкарма комитеты карары белән аңа тантаналы төстә шәһәрнең Почетлы гражданины исеме бирелү турындагы таныклык тапшырылды.

## ҺАДИ ТАКТАШ ИСЕМЕ БЕЛӘН

Мордва АССР Министрлар Советы карары белән Тарбеево районының үзәк поселогы урамнарының берсенә шагыйрь Һади Такташ исеме бирелде. Мәгълүм булганча, ул шушы районның Сыркыды авылында туып үскән, Совет властеның беренче елларында культура-агарту эше алып барган, бу якларның табигате һәм кешеләре аның мәшһүр әсәрләрендә урын алган.

## ЯЗУЧЫ — КОЛХОЗ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

Буа районы «Искра» колхозының авыл хезмәтчәннәре һәм интеллигенциясе тормышын сурәтләгән иң яхшы әсәргә игълан ителгән конкурсында «Фронтовиклар» романының авторы язучы Мөхәммәт Мәһдиев җиңүче дип табылды. Аңа колхозның 1974 ел премиясе лауреаты исеме бирелде.

## ХЕЗМӘТКӘ — ХӨРМӘТ

ТАССР Верховный Советы Президиумының 1975 ел 6 март Указы белән Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең музыкаль лекторий жырчысы **Нажия Абдрахман кызы Теркуловага Татарстанның атказанган артисткасы** дигән исем бирелде.

## ЮБИЛЕЙ КИЧӘЛӘРЕ

19 март көнне Казанның Актерлар йортында мәшһүр татар труппасы «Сәйяр»ның һәм соңрак Татар дәүләт театрының танылган артистлары Ситдыйк Айдаров һәм Әшрәф ханым Синяеваның тууына 80 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе булып үтте. Татарстанның халык артисты Хәким Сәлимҗанов бу күренекле артистларның тормыш һәм иҗат юллары хакында кереш сүз әйтте. Драматург Р. Ишморат һәм К. Тинчуринның тормыш иптәше Заһидә Тинчурина истәлекләр белән чыктылар. Соңыннан педагогия институтының музыка факультеты студентлары концерт бирде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Махсус үткәрелгән утырышта «Язучының иҗат активлыгы» турында сөйләшү булды. Сөйләшүдә прозаиклардан Р. Төхфәтуллин, М. Хәсәнов, Ш. Бикчурин, шагыйрьләр Г. Афзал, Э. Мөәминова, Ә. Маликов, драматург Ю. Әминов катнашты. Алар иҗат эшендәге уңай һәм кимчелекле якларга тукталдылар, китапларын Мәскәү нәшриятларында бастырып чыгаруда Союз идарәсе тарафыннан һәртөрле ярдәм кирәклеген, әдәби ел йомгакларында нефть ягында яшәүче язучыларның әсәрләренә зуррак игътибар һәм җентеклерәк бәя бирелергә тиешлеген билгеләп үттеләр. Утырышта Татарстан язучылар союзының җаваплы секретаре Р. Фәйзуллин, Татарстан китап нәшриятының өлкән редакторы Р. Даутов катнашты.

*
* *

Әлмәт медицина хезмәткәрләре белән очрашу кичәсендә драматург, Берлинны алуда катнашкан элеккеге танкист С. Кальметов үзенең фронт истәлекләре белән уртаклашты, кыска хикәяләрен укыды. Шагыйрә Э. Мөәминова, әдәби берләшмә членнары Ф. Галиева, В. Туктарова яңа шигырьләре белән чыгыш ясадылар.

*
* *

Азнакай нефтьчеләренең Техника йортында районның иҗат көчләре белән очрашу кичәсе булды. Кичәдә язучы Мәхмүт Хәсәнов, яшь шагыйрьләр Нур Әхмәдиев, Әнәс Исхаков чыгыш ясадылар. Һәвәскәр җырчылар үзешчән композиторларның көйләрен башкарды.



*Янка Купала Печищида*

*МАНСУР РӘХИМОВ рәсеме.*

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210